# Казан утлары

9

СЕНТЯБРЬ · 1972

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**9**
СЕНТЯБРЬ
1972

## Бу санда

**Ә. ЕНИКИ.** Без дә солдатлар идек. Фронт дәфтәреннән . . . . . . . . . . . . . . 3
**Н. АРСЛАНОВ.** Еллар, язмышлар. Биографик парчалар . . . . . . . . . . . . . . 56
**С. ӘДҺӘМОВА.** Шул бит нарат. Хикәя . . . . 66
**И. ТУКТАР.** Җөмләләр . . . . . . . . . . 72
**Н. НӘҖМИ.** Мин озатам. Шигырьләр . . . . 73
**Г. ЗӘЙНАШЕВА.** Сөләйман абзый. Шигырьләр . 77
**Т. МИҢНУЛЛИН.** Ир егетләр. Драматик повесть 79

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

**М. ГАЛИЕВ.** Мин — дәвамы булып... Шигырьләр 110
**Г. САДӘ.** Адымнар. Шигырьләр . . . . . . . 112
**З. МАНСУРОВ.** Казлар китә. Шигырьләр . . . 115

ОЧЕРКЛАР

**Ж. КӘЛИМУЛЛИН.** Һәрбер теләк — якын киләчәк 118
**Ж. РӘХИМОВ.** Өченче этап . . . . . . . . . 126

СССР ТӨЗЕЛҮГӘ 50 ЕЛ

**Х. ЯКУПОВ.** Татарстанның сынлы сәнгате . . . . 134

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Р. ФӘЙЗУЛЛИН.** Хикмәтле дә җыры, дәртле дә 140
**Р. МОСТАФИН.** Тема, идея, әдәби осталык . . 151

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Н. ХАНЗАФАРОВ.** Мещанлык бәхетенә каршы . 162

ЯҢА КИТАПЛАР

**В. БРЮГГЕН.** Күп еллар аша . . . . . . . . 166
**Х. САРЬЯН.** Без капчыкта ятмый . . . . . . 167

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫННАН

**Р. ФӘХРЕТДИНОВ.** Болгар шәһәрләре . . . . 170

УКУЧЫЛАР СҮЗЕ

**Л. СОЛТАНОВА.** Җилкәнне җилләр екмаган . . 182

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Көчле рухлы шагыйрь . . . . . . . . . . . 183

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

**З. ГОМӘРОВА.** Яфрак-парашют. Шигырьләр . . 185

ЮМОР-САТИРА

**Г. АФЗАЛ.** Халык белән очрашу. Хикәя . . . . 186

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

**Хатлар өчен:** *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*
Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар. Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.

Баш редактор: **Гариф Ахунов.**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

---

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина.*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева.*

---

Производствога бирелде 8/VI-1972 ел. Басарга кул куелды 7/VIII-1972 ел. ПФ 14107. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 86046 экз. Заказ Г-412. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1972 ел.

Әмирхан Еники

# БЕЗ ДӘ СОЛДАТЛАР ИДЕК

## ФРОНТ ДӘФТӘРЕННӘН

Немецлар чигенә. Безнекеләр алга бара. Июль урталарында Идрица һәм Себеж шәһәрләрен алганнар иде, инде менә Латвия җиренә дә барып керделәр... Һөҗүм итүчеләр артыннан, ниһаять, без дә кузгалдык.

Без дигәнем — кечкенә генә бер взвод. Унбиш кешелек кенә. Безнең эшебез — каравыл хезмәте, без боеприпаслар складын саклыйбыз.

Армиянең һөҗүмгә күчеп, дошманны кыра-кыра алга таба баруы безнең өчен дә көтеп алган иң зур куаныч ул. Без дә бит алга таба барабыз, сугышның ахырына — соңгы җиңүгә таба!.. Үзебезгә калса, без дә һәрбер башланып киткән һөҗүмгә кечкенә генә булса да өлеш кертәбез: дошман өстенә явачак снаряд-бомбаларны көне-төне саклыйбыз, ә бик тыгыз-кызу көннәрдә, посттан кайткач, аларны машиналарга да төяшәбез. Кайчагында әнә шулай ялсыз-йокысыз посттан эшкә, эштән постка йөрү атналап та сузыла, ләкин сыкрану юк, чөнки аңлыйбыз, беләбез һәм эт булып арысак та түзәбез.

Тагын шуны да әйтергә кирәк, без барыбыз да нестроевойлар, ягъни алгы сызыкта сугышырга ярамый торган солдатлар. Безнең арада өч ел фронтта йөреп бер генә тапкыр да мылтык атып карамаган кешеләр бар. Болар «картлар», башта ук нестроевой хезмәткә алынган солдатлар: мәсәлән, казакълардан Өметбаев белән Байәхмәтов, үзбәк Ишмәмәт, яки менә руслардан Шумилов... Ләкин барыбер аларның өстендә дә соры шинель, башларында кызыл йолдызлы бүрек яки пилотка.

Шулай ук безнең арада, алгы сызыкта булып, сугыш эченнән шактый өтелеп чыкканнар да бар. Болар каты яраланып, госпитальләрдә ятканнан соң, нестроевой булып, фронтка кире кайткан солдатлар. Шундыйлардан менә Хафиз Акшалов, Дурду Ходайбирдин (икесе дә казакълар), минем якташлардан Төхфәт абзый белән чуваш Емелькин — боларны ипле чын солдатлар дияргә була, тик сугышырга гына

ярамыйлар... Ядан имгәнеп чыккан батырлар!.. Шулай да мылтык тотарлык булгач аларны кайтарып җибәрмиләр, каравыл хезмәтендә булса да тоталар. Илдән күпме генә яңа көчләр килеп тормасын, барыбер җитәсе түгел — сугыш убыр ул!..

Ләкин без барыбыз да, тегендә алда булганнар гына түгел, ә менә монда арттарак торучылар да, сугышның дәһшәтле, рәхимсез ерткыч чыраен, әйтергә кирәк ки, шактый «әйбәт» күреп-танып өлгердек. Бигрәк тә баштагы ике ел дәвамында. Ул чакларда немецларның авиациясе безнең теңкәбезгә бик нык тиде. Кайда гына тукталмыйк, баш очыбызда шулар. Кара тәреле саргылт самолетлар, ала каргалар шикелле, түбәннән генә очып киләләр дә, безне җиргә сеңдереп, дөмбәсләргә тотыналар. Яраланучылар да, үлүчеләр дә була иде. Бомбежкадан һәлак булу бик начар нәрсә ул, чөнки җирдәге солдат һавадагы дошманына каршы берни дә эшли алмыйча иң үкенечле рәвештә үлә дә китә.

Мин үзем дә бер-ике тапкыр кыл өстендә генә калдым. Шулай, кырык икенче елның кышында Баталино дигән станциядә торабыз (ул чагында әле мин ротада писарь булып утыра идем)... Яңа гына килеп төпләнгән чагыбыз. Рота станция поселогына урнашты, ә мине кечкенә «кәнсәм» белән ни өчендер тимер юл буена караган бер кызыл йортка куйдылар. Ә тимер юлларда туп-тулы эшелоннар, җирдә тау-тау бушатылган йөкләр — немец самолетларының килеп «каплавын» көт тә тор. Ләкин ул чакта без әле чынлап куркырга да һәм сакланырга да өйрәнеп җитмәгән идек.

Һәм менә бер көнне миңа ниндидер кәгазьләргә кул куйдырыр өчен рота командирын эзләп табарга кирәк булды. Өстәлемне әзрәк җыештырдым да, папкамны култыкка кыстырып, өйдән чыгып киттем. Чыккач, кайдан эзләргә икән дип аз гына уйланып тордым, шулай да башта командирның торган квартирына барырга булдым. Һәм поселокка таба атладым. Станция белән поселок арасында мәйдан сыман киң генә буш ара — мин менә шул буш араны, һичбер нинди куркыныч якынлашуын сизмичә, тыныч кына үтеп барам. Ләкин өйдән чыгып, йөз-йөз илле адым китәргә өлгермәгәнмендер, күк йөзен тоташ каплап, һаман көчәя барган шомлы бер гүләү тавышын ишетеп алдым. Бу миңа бик таныш гүләү иде. Шунда ук туктап, һавага күтәрелеп карадым һәм, ни күрим, поселок артындагы урман өстеннән генә безгә таба, өчәр-өчәр тезелешеп, немец самолетлары ашыкмыйча гына киләләр!.. Алар күбәү иде, билгеле бер ара саклап, гүя урман артыннан гына күтәрелгән шикелле, өчәрләп чыгып кына торалар. Бу бик куркыныч иде, бик дәһшәтле иде, мин ихтыярсыз артыма борылып карадым. Тимер юл буендагы кешеләр дә бу дәһшәтне инде күреп, тызбыз чабарга, төрле якка сибелеп качарга тотынганнар иде. Мин дә коелып төшкән бер хәлдә нишләргә, качаргамы, кая таба качарга дип тәмам аптырап калдым. Шул арада, шактый соңга калып булса да, ачык платформадагы безнең кечкенә зенит туплары кабаланып, тотлыга-тотлыга ата башладылар. Ул да булмый, алдан килгән өч самолет пикка кереп (түбәнәеп), юллар өстенә авыр бомбаларын бер-бер артлы төшереп тә җибәрделәр. Шул секундта ук мин дә йөзтүбән җиргә капландым. Башта кыеклап очкан бомбаларның, чучка шикелле, яман чинап төшүләре ишетелде, аннары шуның артыннан ук барлык тавышларны да күмеп, бөтен тирә-якны тетрәтеп, гөрс тә гөрс шартларга тотындылар. Бер ишеләреерактарак шартлаган кебек, ә кайберләре, чинаган тавышларына караганда, нәкъ минем өскә төшеп килә шикелле. Астымдагы җир олы бер җанварның сырты сыман калтырана һәм мине күтәреп-күтәреп җибәрә. Тирә-ягыма кар аралаш тузан-туфрак ява, ара-тирә зур гына җир кантарлары да килеп төшә, ә мин ике куллап башымны учлаган килеш, җиргә тагы да ныграк сеңәргә тыры-

шып, йөзтүбән ятам да ятам. Шушы минутларда ни уйлавымны, нәрсә теләвемне һич белмим, хәтерләмим — акылым тәмам сүнгән иде.

Бу мәхшәр бер ун минутка сузылгандыр. Самолетлар бер-бер артлы түбән кадалып, бомбаларын ташлап бетергәч тә, станция өстендә, авыр үкереп, әйләнә-әйләнә пулеметтан сиптереп йөрделәр. Бары шуннан соң гына киттеләр... Киттеләр, бәдбәхетләр! Дөнья бер мәлгә тып-тын булып калды.

Мин башымны җирдән сак кына күтәреп, бераз колак салып торганнан соң, ниһаять, әкрен генә торып бастым. Көн бөтенләй караңгыланып киткән, тимер юллар өстендә тузан-төтен асылынып тора, ачык кына бер нәрсәне дә күреп булырлык түгел, хәтта зур гына вокзал бинасы да куе тузан эчендә иде. Әйе, шик юк ки, анда һәлакәт-каза, кан-үлем күп булырга тиеш иде.

Барысыннан да элек минем үзем торган йортны кире кайтып күрәсем килде. Ни булды икән анда? Минем «хуҗалык» ни хәлдә?.. Ротаның бөтен эшләре, секрет кәгазьләре кечерәк кенә тимер сандыкта — аны мин башым кебек сакларга тиешмен. Ашыга-ашыга киттем. Йортка якынлашу белән үк инде мин кар өстендә аунап яткан берничә үлекне күрдем. (Шуны әйтергә кирәк, бомбежкада яраланучылар күп булмый; кеше күбрәк контузия ала яки бөтенләй һәлак була.) Килеп җиткәч, ни күрим, йортның нәкъ мин торган башындагы бер почмагы тәмам актарылган. Дөрес, бомба туп-туры йортка тимәгән, ул берничә метр гына читкәрәк төшеп шартлаган, ләкин шулай да почмакны актарып ташлаган. Эшләр яман икән, дидем мин, һәм ашыгып өйнең эченә уздым. Башлап күргәнем — кухня бусагасында үлеп яткан бер яшь хатын гәүдәсе булды. Ул йөзтүбән ята иде, ләкин нелебрәк карагач, мин аны таныдым: йа рабби, бу шушы йортта торучы хатын ич! Эчкәре бүлмәләрнең берсендә өч яшьлек кызы белән генә тора иде ул. Коридорга чыккан чакта мин аны гел кызчыгы белән бергә диярлек күргәли идем. Ләкин соңгы ике-өч көн эчендә алар күренмәс булдылар; ахрысы, хатын бу хәтәр җирдән кызын тынычрак урынга алып киткәндер дип уйладым. (Чөнки безнең хуҗаның да аны, кит, торма монда, тиле, дип куганын ничектер ишетеп калган идем.) Ә хәзер менә шул егерме дүрт-егерме биш яшьлек чибәр генә хатынның җансыз гәүдәсе монда кан эчендә ята. Ничек кенә булды икән соң бу?.. Берәр йомыш белән бүлмәсенә кайткан чагы булды микәнни бичараның?.. Һәм шунда ук тагын бер уй йөрәгемне өшетеп җибәрде: ә кызчыгы кайда соң моның, кызчыгы?.. Бәлки ул да... Юк, минем моңа ышанасым килмәде. Булмас, булырга тиеш түгел. Әнисе янында юк ич, коридорда да күренми, тавышы да ишетелми. Бәлки, әнисе, кызын калдырып, ялгыз гына кайткандыр — минем шуңа бик нык ышанасым килде. Минем хәтта кемнәндер шулай булуын ялварып сорыйсым килде. Бүгенге кебек фаҗигане бала йөрәге татырга тиешме соң, ходаем?!.

Инде үз бүлмәмә керсәм, аның бикле ишеге каерылып ауган, аскы тупсасына гына эләгеп тора, ә үзе бомба кыйпылчыкларыннан яргаланып, тишкәләнеп беткән. (Бәлки хатынга да шушы ишекне тишеп узган бомба кыйпылчыгы тигән булгандыр...) Эчкәре кердем һәм мондагы тамашага хәйран калып, күпмедер вакыт баскан җиремнән кузгала алмыйча тордым. Бүлмәнең бөтен эче актарылган иде: түр почмагы шыр ачык, ике зур тәрәзә икесе дә рамнары белән үк каерылып очканнар, идән тулы пыяла ватыгы, өстәл-урындыклар чәлпәрәмә килеп, тәгәрәшеп яталар, кыскасы, бер бөтен җиһаз калмаган. Тик идәндәге минем сандык белән тимер карават кына бөтен кебек... Тагын әнә стена буендагы түгәрәк галанка мичнең калаен бомба кыйпылчыклары тишкәләп бетергән. Ә мин бит шушы мич белән тәрәзә арасында утыра идем. Бары тик менә хәзер генә минем аңыма коточкыч хакыйкать килеп җитте: әгәр дә мин бу бүлмәдән бер-ике генә минут чыгып

китмичә торсам, миннән нәрсә генә калган булыр иде икән?.. Өстәлемә иелеп, кыштыр-кыштыр нидер язып утырган күзлекле писарьдан, мин әйтәм?.. Нервлар бик киерелгән иде, хәлсезләнеп караватъ читенә утырдым... Уйлыйм: мин бит бернинди хәтәр сизмичә чыгып киттем, әмма нәкъ соңгы чиктә генә кузгалганмын, бер генә минутка соңга калсам да, бүлмә эчендә булмаса, йортның тышында мин үлем тырнагына эләккән булыр идем... Кемнең генә догасы мине бу һәлакәттән йолып калды икән?.. Бәлки әнкәйнеңдер, бәлки әнкәй минем колагыма шыпырт кына: «Улым, тор, чык!» дип әйткәндер... Шулай... Гаҗәп икән бу кеше язмышының серләре — үлем килеп җиткәндә генә берәү чыгып китә, ә берәү әнә... кайтып керә!

Миңа бомбежканың төрлесен — бүгенге кебек бик дәһшәтлесен дә һәм вак-төяген дә (әйтик, бер-ике генә самолетның көтмәгәндә килеп чыгып, хәтәр йөген кая эләксә шунда ташлап качканнарын да) шактый күрергә туры килде. Ләкин аларны сөйләп торасым килми, бусы да бик җиткән, тик шулай да бер бомбежка вакытында булган гаҗәеп бер хәлне генә сөйләмичә үтә алмыйм — ничектер җәл. Әйтергә кирәк, фронтта гомумән бик гаҗәеп, хәтта аңлавы читен хәлләр булгалап тора иде. Менә бу да шундыйларның берсе.

Пено дигән зур гына авылда торган чакта булды бу... Безнең ротада Федько исемле бер шофер бар иде. Бик күп юл чапкан, утны-суны да күп кичкән, ләкин моңарчы әле бер дә бәла-казага юлыкмаган, үзе ваемсыз, үзе житез, русчалап та әйтсәк, шустрый гына егет иде ул Федько! Көннәрдән бер көнне рота командиры менә шул Федьконы, өч солдат белән бергә, станциягә азык алырга җибәрә. Баралар, тиешле урыннан кирәкле азыкны алалар, машинага төйи башлыйлар... Нәкъ шул чакта станция өстенә немец самолетлары килеп чыкмасынмы! Солдатлар төрлесе төрле якка йөгерәләр, ә Федько машинасына сикереп менә дә, тиз генә газ биреп, чаптырып китеп тә бара.

Бомбежка бетеп, күпме вакыт узды икән? Ун-унбиш минут — шуннан да артык булмас, чөнки мин үзем дә йорт янындагы траншеядан чыгып, яңарак кына канцеляриямә кереп утырган идем. (Шуны әйтергә кирәк, бомбежканың нәрсә икәнен белеп алгач, без хәзер кая гына килеп урнашсак та, иң элек бусагадан атылып чыгуга сикереп төшәр өчен тар-тирән генә траншеялар казып куя торган булдык.) Кыскасы, озак та үтми, минем янга Федько килеп керде... Керде бу, бер сүз әйтмәстән лып итеп табуреткага утырды, башыннан тапланып беткән бүреген алып, шуның эче белән буй-буй кара тир аккан битен сөртте, аннары бүрекне ни өчендер кулында әйләндерә башлады. Егет шактый сәер күренә иде, күзләре дә әллә ничек аларып киткән төсле... Нидер булган егеткә, шулай да мин аның сүз башлавын көтәм. Ә ул мине бөтенләй күрми дә шикелле, тик шунда бүреге белән мавыгып утыра, гүя бер эше дә, бер йомышы да юк кебек. Ахырда үзем дәштем:

— Кайттыгызмы, Федько?

Ләкин ул җавап бирү түгел, миңа күтәрелеп тә карамады. Бу инде шикле иде. Егетебез тәгаен бомбежкага эләккән булса кирәк. Алай дисәң, бар җире дә бөтен күренә. Әллә бераз чукракланып калганмы? (Бусы инде еш була торган хәл.) Шуннан тагы да кычкырыбрак дәштем үзенә:

— Федько, әйт, ни булды сиңа?

Моңа каршы Федько үзе миннән кинәт кенә:

— Командир кайда? — дип сорады.

— Командирмы?.. Белмим шул, парин!.. Ә нигә кирәк иде ул?

Федько җавап биреп тормады, терсәгенә таянды да башын гына түбән иде. Тәмам аптырадым. Әллә минем белән санлашмый, әллә чынлап та ишетми, әллә инде әзрәк мингерәүләнеп тә киткән?.. Шул арада безнең командир үзе дә килеп керде. Солдат командир килеп кергән

чакта торып басарга тиеш, ләкин Федько урыныннан да кузгалмады. Командир аңа кырыс кына карап алды:

— Федько, ә Федько!

Федько сискәнеп киткәндәй булды һәм авыр гына урыныннан торды. Командир үзе дә егеткә нидер булганын сизеп алды, ахрысы, шунда ук йомшарып, аңа утырырга кушты. Теге аңламыйчарак торгач, иңбашыннан басып диярлек утыртты һәм үзе дә каршысына утырды.

— Я, сөйлә, ни булды?

Федько кызганыч кына елмаеп, аңа беравык карап торды, ләкин авызыннан сүзе чыкмады. Командир аңа иелә биреп кычкырды:

— Ишетмисеңмени?.. Мин синнән ни булды дип сорыйм.

— Әллә ни булганы юк, иптәш командир! — диде Федько, һаман шулай елмаеп кына.

— Һе, булганы юк, имеш! Мин күрмимдер шул. Бомбежкага кай төштә эләктегез?

— Станциядә.

— Китеп өлгермәдегезмени?.. Иптәшләрең кайда?.. Иптәшләрең кайда дим?

— Иптәшләр... ни, төрлесе төрле якка чаптылар.

— Ә син?

— Мин машина янында калдым.

— Машинаң кайда соң?

— Машина чокырда.

— Нинди чокырда?.. Нинди чокырда дим?

— Бомба чокырында... Машинаны барып чыгарырга кирәк, иптәш командир.

— Туктале син, алла колы! Әйбәт кенә төшендер — ничек итеп ул алай машина бомба чокырына эләкте?

— Белмим,— диде Федько, гаепле бала сыман мөгрәнеп кенә.

— Белмим?!.. Ничек инде белмисең? Машинаны ташлап китмәдем дисең бит!.. Әллә киткән идеңме?

— Юк, китмәдем. То-есть, мин машинаны алып киттем.

— Шуннан... чокырга барып төштеңме?..

— Юк, мин үзем чокырга барып төшмәдем.

Командир ботын чабып, урыныннан сикереп торды:

— Валлаһи, һичнәрсә аңлый алмыйм, хет суегыз! Писарь, син берәр нәрсә аңлыйсыңмы?

Мин дә, билгеле, бер нәрсә аңлый алмыйча утырам, шуңа күрә иңбашымны гына җыерып куйдым.

— Ну, Федько, Федько! — диде командир, башын чайкап, аннары яңадан шоферның каршысына утырып, ничек тә сабыр булырга тырышып, тагын сораша башлады:

— Кара әле, Федько, син башлы егет бит, сөйли дә беләсең, әйбәт кенә аңлат әле, зинһар!.. Ничек булды соң, ничек итеп син машинаң белән бомба чокырыңа барып төштең, наконец, ничек соң син үзең исән калдың?..

— Менә шуны, иптәш капитан, мин үзем дә белмим шул! — диде Федько, кулларын җәеп.

Командир башын учлады:

— Я хода, тагын «белмим»!.. Ә кем белә соң? — диде ул, кинәт кычкырып.— Син бит шунда булгансың, син бит әле исән калгансың, һич югы, баштарак ни булганын беләсеңдер, хәтерлә!

Федько чыннан да нидер хәтерләргә тырышкандай кашларын җыерып, уйланып торды, бүреге белән тагын битен сөртеп алды, шуннан соң өзек-тәтек сөйләргә кереште:

— Без азыкларны төяп бетергән идек инде, шул чакта фашист козгыннары килеп чыктылар. Бомбежка башланды... Карыйм, берәү

дә юк, качканнар... Мин — машинага... Тиз генә газ бирдем... Куам, куам, ә бомбалар төшәләр. Ну, каядыр артта. Мин инде ычкындым дип уйлаган идем.

Федько сүзеннән туктап, көйгән иреннәрен ялап алды. Ахрысы, җеп очын югалтып җибәрде, озак кына дәшми торды.

— Я, шуннан? — диде командир сак кына.

— Шуннанмы? Шуннан, әллә уңда, әллә сулда, әллә артта, ну якында гына, бик яман бомба шартлады. Кинәт дөнья караңгыланып китте, мин дә бер мәлгә аңымны югалттым. Күпме вакыт узгандыр инде, бер заман күземне ачып җибәрсәм, мин бик әйбәт кенә кабинамда утырам, имеш! Даже мотор да эшли!.. Ну алдымда юл да юк, өйләр дә, юк, вообще, бер нәрсә дә юк, бары тик тау шикелле өелеп яткан кара җир генә... Шуннан, бу ни соң? дип чынлабрак карасам, ул тау түгел икән, ә тирән генә бер чокыр икән. Машина менә шул чокыр төбенә арты белән терәлеп, алгы тәгәрмәчләре белән югары карап тора, имеш!.. Нинди чокыр, кайдан килгән чокыр? — һич белмим, аңламыйм, шабаш!.. Ә алда чокыр юк иде — мин моны яхшы беләм. Булса, мин ул чокырга кадалып барып төшкән булыр идем, үзем дә, конечно, исән калмас идем. Ну, күрәсез, минем бөтен җирем дә үз урынында, аяк-куллар да, тик баш кына яман шаулый.

— Һәм колакларың бераз тыгылган, шулаймы?.. Ә машина ничек?

— Машина да бөп-бөтен, тырналган җире дә юк.

— Әллә нәрсә бу, шайтан белсен! — диде командир, тиз генә урыныннан торып.— Барып карамыйча булмый. Әйдә, Федько, киттек!

Федько тагын үзенекен кабатлады:

— Иптәш командир, машинаны чыгарырга кешеләр кирәк, мин шуның өчен генә кайттым.

— Писарь,— диде командир миңа,— давай, ротада калган кешеләрне җый да алып бар. Мондый көнне кеше җиткереп буламы соң, барысы да тимер юл буенда.

— Була, иптәш командир! — дидем мин дә җитез генә. Чокыр төбендә утырган машинаны барып карау минем өчен дә кызык иде, билгеле.

Тиз арада ротадагы итекчене, тегүчене, кладовщикны, поварның берсен, тагын бер-ике очраган кешене җыеп, станциягә таба алып та киттем. Таш юл буйлап ашыга-ашыга атлыйбыз. Юл туп-туры, шуна күрә без ерактан ук алда җыелышып торган кешеләрне күрдек. Килеп җиттек, һәм безнең күз алдыбызда менә нинди күренеш ачылды: нәкъ юл уртасында кечерәк кенә өй кереп утырырлык түп-түгәрәк, тирән бомба чокыры, һәм шул чокырның авыл яклап стенасында, тирес коңгызы шикелле, Федько машинасы ябышып тора. Нәкъ Федько үзе әйткәнчә, койрыгы белән чокыр төбенә терәлгән, ә алгы тәгәрмәчләре белән югарыга караган... Һич шик юк ки, бу хәзер генә булып узган бомбежка эше: юлга зур фугас бомбасы төшеп шартлаган, һәм... машина шуның чокырына төшеп утырган! Әмма ничек итеп ул бу чокырга эләккән? — моны һич кенә дә аңлап та, күз алдына китереп тә булмый иде. Чынлап та, әгәр дә мәгәр, әйтик, бомба чабып барган машинаның борын төбенә төшсә, ул чагында машинаңны йөге-ние белән әллә кая ыргытып бәрер иде. Инде ерактарак төшеп шартласа, ул чагында Федько машинасын я туктатып өлгерер иде, яки, өлгерә алмаса, чокырга машинасының борыны белән кадалып барып төшкән булыр иде. Ә бит машина һавага карап утырып тора! Әллә чокырны очып чыга яздымы икән?.. Ләкин моңа да ышануы читен, чөнки ул чагында йөк төягән машина ватылмыйча калмас иде. Ә ул, шайтан алгыры, бөп-бөтен, бергенә дә сынган-ниткән җире юк!.. Безнең командир үзе чокыр комын ишә-ишә төшеп, машинаны кат-кат әйләнеп, астын-өстен дигәндәй, җентекләп карап чыкты, әмма бер бөртек ватыл-

ган жирен таба алмады. Федько да шуны ук әйтеп тора: машинага берни дә булмады, чокырдан чыгаргач та үз ходы белән китәчәк, ди. Аннары иң хикмәтлесе шул: Федьконың әйтүенә караганда, бомба чабып барган машина алдында шартламаган, ул моңа чукына-чукына ышандыра, ул әйтә: бомба кайдадыр артта шартлады, ди. Димәк, машина алда торган чокырга түгел, артта калган чокырга барып төшкән була?!. Әллә нинди пәри табышмагы бу!..

Кыскасы, сүз күп булды, кычкырдылар, бәхәсләштеләр, көлделәр, әмма ләкин бу табышмакның ачкычын табучы булмады. Тик иң ахырдан безнең командир, аптырагач-йөдәгәч, башын кашып, сорау рәвешендә генә әйтеп куйды:

— Ә бәлки шартлау дулкыны машинаны үзенә тартып алгандыр, ә?.. Федько, син шуны сизмәдеңме?

— Кайдан сизим, иптәш командир? — диде Федько, хәтере калгандай.— Әйттем ич инде, шартлады, мин бер мәлгә аңымны югалттым, күземне ачып җибәрсәм — чокыр төбендә утырам, менә шул.

— Бик иплә төшеп утыргансың,— диде командир, көлемсерәп.— Бомба үзе сине шулай сак кына төшереп утырткан инде, чын-чын!

— Булмас ла, иптәш командир,— диде шунда солдатлардан берәү.— Чабып барган машинаны кире артка тартып алыр өчен, ай-һай, нинди көч кирәк!

— Ярты тонналы фугаскада көч җитәрлек, паровозны да аударып ташлый ул... Күргәнегез юкмыни?.. Монда хикмәт, минемчә, кире араның ераклыгында, ягъни бомба шартлаган чакта машина аңардан нинди ераклыкта булган. Әйтик, бик якын шартласа, машинаны чәлпәрәмә китерер иде, ерактарак шартласа, бәлки, аңа берни дә булмас иде, ә менә ул, дуңгыз түшкәсе, шундый бер төгәл ераклыкта шартлаган ки, безнең геройны машинасы-ние белән үзенең чокырына иплэп кенә суырган да алган... Нигә, булмас дисезме?.. Ә башкача моны ничек аңлатырга?.. Физика законнарын кем белә, писарь, син белмисеңме?..

— Белмим шул,— дидем мин, кыенсынып кына.

— Белергә кирәк,— диде командир, өзеп кенә.

Ләкин ничек кенә булмасын, командирның хәзер генә әйткәннәре, чынмы-ялганмы, физика законнарына туры киләме ул, юкмы, әмма Федько юлыккан бу гаять сәер хәлне берникадәр аңлаткан кебек булды. Машинаның йөген бушаттык, аннары бер унбишләп кеше аны чокырдан өстерәп тә чыгардык. Йөкне яңадан төягәч, Федько кабинасына утырып, «үз ходы белән» китеп тә барды.

...Әмма ләкин дөньяның кайчак озак кына тынып торган чаклары да була иде. Атналар буенча күк йөзе буш, кояш та йолдызлар гына, дошманның бер генә самолеты да өстебезгә ажгырып килеп чыкмый, тик бик сирәк кенә, бик биектән немецларның безнекеләр «рама» дип атаган разведка самолеты гына, тилгән шикелле, каранып уза,— безнең зенитчылар күп вакыт аңа ут та ачып тормыйлар... Шушындый ук тынлык һәм тынычлык алгы сызыкта да хөкем сөрә булса кирәк, ул тарафтан да туплар гөрелтесе ишетелми, яралылар агылып кайтмый, тик ул тирәләрдә ишле каргалар көтүе генә әйләнә... Җир өстенә әкренләп талгын-ялкау тынлык җәелә... Кеше һәм табигать, икесе бергә, вакытлыча гына булса да хәвеф-хәтәрләрдән арынып, оеп, рәхәтләнеп дигәндәй, бер ял итеп ала. Солдат үзалдына әкрен генә мөгрәнеп, җырлап йөри башлый, бик дикъкать белән ертык-сүтегән тегәргә тотына, чолгауларын салкын суда юып киптерә, аулак урын табып, ялгызы, ашыкмыйча гына хатлар яза. Билгеле, ул рәхимсез сугышны бер генә минутка да онытып тормый, ләкин сугыш үзе дә бу чакта каядыр чигенеп, посып торган шикелле булып тоела аңа... Ул аның

турында уйламаска тырыша, хыялы-күңеле белән икенче дөньяга — кан да, үлем дә булмаган, печән, иген өлгергән, хатынлы, мунчалы, бала-чагалы ерак дөньяга күчә...

Мин үзем бу килеп-килеп булгалый торган аз гына моңсу, аз гына сызландыручан, әмма бик кадерле, бик тансык тынлыкны каравыл хезмәтенә күчкәч аеруча нык тойдым. Шуны әйтергә кирәк, елдан артык писарь булып утырып, мин бу эштән бик туйган идем. Бәйдәге эт шикелле, бер урында бөкрәеп утырасың да утырасың, теләгән җиреңә ни чыгып китеп булмый, ни солдатлар белән аралашып булмый, ә солдат бит ул үзе кебек солдат белән ышкылып яшәргә ярата. Аңа әледәнәле кемгәдер эчен бушатырга кирәк. Ә мин күп вакытта ялгыз, рухым, җаным белән дигәндәй ялгыз... Инде яныма керүчеләр булса, алар дәрәҗәләре белән миннән өстен офицерлар — үзләре башлап сөйләшсәләр генә, минем сөйләшергә хакым бар. Дөрес, алар арасында бик гади, бик әйбәтләре очрый иде. Бер дә үзләрен өстен тотмыйча, тиң күреп сөйләшәләр, тәмәкеләре белән сыйлыйлар, хәтта берәр кайгылары булса, анысы белән дә уртаклашалар иде. Шундыйлардан берсен — азык-төлек складының начальник ярдәмчесе Николай Булгаков дигән өлкән лейтенантны һич тә онытасым юк. Көне-төне аяк өстендә чапкан бу кырыклар тирәсендәге түгәрәк битле, зур моңсу күзле кеше минем янга кереп, тәмәке пыскытып, әзрәк ял итеп утырырга ярата иде. Баштарак безнең арада юньләп сөйләшү дә булмый иде. Ул утыра, мин утырам, ник бер сүз дә әйтми бу дип эчемнән генә пошынам, ләкин сизәм: телсез утыруы мине санламаганнан булмаска тиеш. Я бик арыган ул, яки инде берәр төрле зур кайгысы бар. Соңрак, билгеле, аның теле чишелде. Ленинградтан икән ул үзе. Путилов заводыннан. Бабасы да, атасы да шунда эшләгән, үзе дә шуннан армиягә киткән... Ленинград фаҗигасен бик авыр кичерә икән, ләкин ул турыда күп сөйләргә яратмый. Хәер, аның хәлен болай да аңлап була — телдән әйтмәсә дә, сүз бит аның туып-үскән бишеге — аңа иң якын, иң кадерле, иң газиз шәһәре турында бара. Ул үзе дә, Ленинград турында мин бер генә минут та уйламыйча тора алмыйм, ди. Шулай булгач, моны сөйләп бетерү мөмкинме соң? Һәм кирәкме ул?

Ә бер көнне Булгаков минем янга килгәч, гадәтенчә, озак кына дәшми утырганнан соң, кесәсеннән өч почмаклы бер хат чыгарды. Ләкин укып тормыйча аңлатып кына бирде. Бу хатны агасының ундүрт яшьлек кызы язган икән. Хаттан күренгәнчә, кызның әтисе дошман шәһәрне тупка тоткан чагында, заводка барышлый, һәлак булган, әнисе ачтан үлгән, әбисе дә шулай ук, ә Юрка, кызның уналты яшьлек абыйсы, тоткан да, мин передовойга барам, дип чыгып киткән, имеш. Исәнме-түгелме, анысын белми икән. Ә япа-ялгыз калган балаларны «эвакопункт»ка җыеп алганнар, тәннәрендә җаны булганнарны әкренләп шәһәрдән озаталар икән. Бу үсмер кыз да шул «эвакопункт»та үз чиратын көтеп ята икән.

— Җитеп торырмы? — диде Булгаков, сәер бер җансыз тавыш белән. Мин дәшмәдем.

— Ә шулай да,— диде ул бераздан,— мин сезгә хатның бер генә төшен укып күрсәтим әле.

Хат аның кулында әкрен селкенә, әмма тавышын сынып китүдән саклагандай, сүзләрне юри хиссез итеп, өзеп-өзеп кенә укый: «Абыем, син мине күргәч,— дип яза кыз, балаларча беркатлылык белән,— танымассың да инде. Мин бик үзгәрдем, сөяк тә тире генә... Тук булу нәрсә ул, онытгым инде... Төшемдә гелән генә тәмле итеп ашаганымны күрәм. Кулыма китап эләксә, аның да ашау турында язган җирләрен генә эзләргә тотынам...»

— Җитәр булмаса,— диде Булгаков, башын күтәрмичә генә, һәм хатын ашыкмыйча гына кире өч почмак итеп бөкләде.

Без шактый вакыт сүзсез утырдык. Эчемнән генә бик борчылып, бәлки аны юатырга кирәктер дип уйлыйм. Ләкин куркам, аның ярсу, газап, хәсрәт тулы бәгыренә кагылудан куркам. Һәм сизенәм: аңа кызгану кирәкми, Гитлер башына нәләт яудыру да кирәкми — чөнки болар сүз, бары сүз генә! Чөнки бит ул үзе дә әнә бер генә сүз дә әйтми, бөтен ачык җирен яшергән керпе шикелле йомылып, тырпаеп тик утыра. Кагылып кара син аңа!..

Тик китәргә дип урыныннан торгач кына ул сабыр-тыныч кына әйтте:

— Рапорт бирдем, китәм! — диде.

Мин аның кая, ни өчен китүен шунда ук аңлап алдым һәм бары:

— Җибәрәләрме соң? — дип кенә сорадым.

— Җибәрми карасыннар! — диде ул, экрен-хәтәр итеп.

Әйе, аны хәзер тотып булмаячак иде. Шуны да әйтергә кирәк, ул әлек тә үз эшеннән бер дә канәгать түгел иде. Азык-төлек тирәсендә ямьсез эшләр һәрвакытта күп була. Бигрәк тә көн саен вагоннап килеп торган һәм ачык кырга бушатып өйгән азыкны саклау бик читен эш. Бомбежкадан да харап була ул, шул хәлдән файдаланып урлау, читкә озатулар да булгалап тора, һәм гомумән әрәм-шәрәм итүләр, кызганычка каршы, җитәрлек. Ленинград фаҗигасен белеп торган Булгаковның моңа, әлбәттә, җаны бик сыкрана иде. Хәтта кайбер зуррак начальникларның ашау-эчү мәсьәләсендә чамасыз кылануларына да аның ачуы килә иде. (Үзе ул солдатлар өчен пешерелгән Казаннан гына ашап йөри иде.) Кыскасы, бик гадел, намуслы һәм үтә тыйнак бер кеше иде ул, мәрхүм!

Киткән чакта ул үзенең тәмәке уты төшеп бер чите янган одеалын миңа: «Мә, сержант, инде син ябынып ят!» дип биреп киткән иде. Озак та үтми, без аның алгы сызыкта һәлак булуын ишеттек.

Әйе, кешеләр бер-берсеннән бик нык аерыла. Писарь булып утырганда миңа аларның төрлесен күрергә туры килде. Кеше язмышы — кеше кулында. Фронт шартларында солдат өчен бу аеруча шулай. Менә минем монда писарь булып утыруым һич тә үземнән түгел. Кемдер куйган иде, кемдер чыгарып та җибәрергә тиеш.

Безнең ротада ни сәбәптәндер командирлар еш алышынып торды. Шул ел ярым вакыт эчендә миңа бер-берсен алыштырган биш командирга буйсынып эшләргә туры килде. Биш командир — биш характер дигән сүз, һәркайсына җайлашырга, көйләнә белергә кирәк иде. Кайберсе белән ара бик әйбәт булып китә, ул сиңа писарь итеп кенә түгел, кеше итеп тә карый. Менә бу Федько вакыйгасын сөйләгән чактагы командирыбыз, капитан Баранов, әнә шундыйлардан иде. Миннән күп белүне таләп итсә дә, ул бервакытта да мине кимсетмәде, юккабарга кыерсытмады. Киресенчә, миңа үзенең якын бер ярдәмчесе итеп карый иде (һәм дөрес карый иде, чөнки писарь аңа рота хәле турындагы мәгълүматларны көн саен әзерләп кенә тора), сораша-киңәшә иде, хәтта еш кына: «Бел, син писарь гына түгел, ә ротаның штаб начальнигы!» дип, минем дәрәҗәне күтәреп тә җибәргәли иде. Ахрысы, шуңадыр, ул үзе үк миңа ара-тирә командирлар паегыннан өлеш тә чыгара иде, кием-салымның да яхшырагын бирә иде. Билгеле инде, мондый командирга эшең дә, җаның да жәл түгел.

Ләкин аны да бездән ни өчендер алдылар. (Строевой командир дип хәрәкәттәге дивизиягә күчерделәр булса кирәк.) Инде аның урынына килгән командир бөтенләй икенче кеше булып чыкты. Бу да капитан иде, ләкин интендант хезмәте буенча, ягъни хәрби тәэминат кешесе. Фамилиясе — Сидоров иде. Шушы Сидоров ротага килүе белән үзен үтә формалист, шунлыктан аеруча дорфа икәнлеген күрсәтеп өлгерде. Икенче көнне үк ул минем башымдагы бүреккә бәйләнә башлады: янәсе, ни өчен әле минем башымда командирлар бүреге?.. Кем бирде,

кем рөхсәт итте?.. Мин ни әйтергә белмичә аптырый калдым, чөнки моңарчы бер генә командирның да, шулай ук безнең ротага килеп чыккан бер генә зур начальникның да минем бүреккә бәйләнгәне булмады. Әллә юри шаярта инде иптәш капитан дип, мин бары елмаеп кына куйдым. Бу аның ачуын китерде.

— Мин сездән сорыйм,— диде ул, тавышын күтәрә төшеп.— Кем рөхсәт итте сезгә командирлар бүреге киеп йөрергә?

— Элекке командир,— дидем мин, каушамыйча гына.

— Нәрсә ул, армия тәртибен белми идемени?...

— Юк, белә иде, ләкин ул үзе миңа бу бүрекне алырга кушты.

— Димәк, белмәгән. Армиядә сержантка командирлар бүреге не положено. Барыгыз, хәзер үк солдат бүрегенә алыштырыгыз.

Мин бераз дәшми тордым, аннары кинәт туган үҗәтлек белән әкрен генә:

— Әгәр бармасам? — дидем.

Командир, колакларына ышанып бетмәгәндәй, миңа бик сәерсенеп карады. Күрәсең, минем тарафтан мондый тискәрелекне һич тә көтмәгән иде, сержант командирына каршы сүз әйтсен әле!.. Моның өчен бит... һәм ул, ниһаять, корыч тавыш белән өзеп әйтте:

— Бармасагыз, сезгә биш тәүлек гауптвахта!

Әлбәттә, буйсынырга кирәк иде, хәтта иң мәгънәсез боерыкка да буйсынырга кирәк, чөнки рәхимсез кагыйдәсе шул... Ачуымны һәм гарьлегемне йотып дигәндәй, мин үзебезнең старшинага киттем һәм сары тышлы, йомшак мехлы бик әйбәт бүрегемне катырак та, салкынрак та соры солдат бүрегенә алыштырып кайттым. Шулай да мин аны кырын салыбрак кидем. Әйдә күрсен, солдат бүреген дә йөртә беләбез без!

Билгеле инде, башта ук безнең арадан мондый йолкыш кара мәче узгач, килешеп, тату гына эшләү мөмкин булмаячак иде. Шуңа күрә мин бу писарьлык эшеннән ничек кенә булса да ычкынырга ниятләп куйдым. Дөрес, озак та үтми иптәш командир минем үзенә никадәр кирәкле кеше булуымны белеп алды. Һәм, әйтергә кирәк, миңа карата бераз йомшара да төште. Ләкин барыбер писарьлыктан китү уе миндә кире сүрелмәде инде, чөнки ике арадагы боз калды, боз эреп бетмәде. Моны мин генә түгел, командир үзе дә бик яхшы сизә иде шикелле... Тик миңа авыр, миңа гел йомылып та сагаеп кына торырга туры килә. Ә аңа нәрсә, аның эче пошмый миңа, ул бит үзен һәрвакытта хаклы дип санарга өйрәнгән кеше.

Минем бәхеттән, озакламый, безнең ротага госпитальдән чыккан бер төркем солдатлар килде. Алар арасында элек укытучы булган Спиридонов фамилияле, миннән олырак бер Пенза кешесе дә бар иде. Командир аны минем янга утыртты. Бәлки ул моны билгеле бер максат белән эшләгәндер, ләкин мин моңа һич тә көенмәдем. Киресенчә, икенче писарьның булуы миңа моннан китү өчен юл гына ачачак иде. Шул Спиридонов белән без икәү бер ай ярым чамасы тату гына эшләгәннән соң, мин, ниһаять, командирга мине каравыл хезмәтенә күчерүен сорап рапорт бирдем.

Командир рапортка күз йөртеп чыкты да миңа:

— Нигә китәсең? — дигән булды.

Мин аягүрә баскан килеш, бөтен шартын җиткереп:

— Иптәш командир,— дидем,— үзегез дә беләсез, безнең ротада штат буенча бер генә писарь булырга тиеш. Димәк, безнең беребез монда артык. Шуңа күрә мин сездән башка эшкә күчерүегезне сорыйм.

— Ә Спиридонов үзе генә эшне алып бара алырмы соң?

— Һичшиксез!.. Иптәш Спиридонов шәп писарь булачак!

Шуннан соң командир, бүтән бер сүз әйтмәстән, минем рапортка: «Боеприпаслар складының каравыл взводына җибәрергә», дип виза

салды. Әлбәттә, мин аңардан рәхмәт сүзе көтми идем, ләкин шулай да ул миннән күңел өчен генә: «Кая күчәргә телисез?» дип сорарга тиеш иде кебек. Безнең рота саклый торган төрле складлар күп, әмма шулар арасында иң хәтәре әнә шул боеприпаслар склады иде... Хәер, мин моңа артык борчылмадым, чөнки, беренчедән, минем шикелле солдат кеше язмыштан узмыш юк дип үзен юатырга өйрәнгән (чынлап та кемне кайда нәрсә көткәнен белеп буламыни?), икенчедән, боеприпаслар складында төрле милләт кешеләре күбрәк иде. Командирлары да миңа яхшы таныш кыргыз егете — Нугайбәк Кулибаев дигән лейтенант...

Әнә шулай ансат кына каравыл взводына күчеп, мин постка да йөри башладым. Постта торуның нәрсә икәнен сөйләрмен әле, ләкин хәзер бер уңайдан шуны әйтеп калырга кирәк. Взводта командир ярдәмчесе һәм разводящий булып Акшалов дигән казакъ егете йөри иде. Бу — утны-суны кичкән яшь, тәҗрибәле солдат, каравыл хезмәтен дә яхшы белә, ләкин каты яраланудан соң бер аягы бөтенләй бөгелми диярлек. Бик азапланып кына йөри, ә разводящийның бөтен эше аяк өстендә — чокырлы-чакырлы сукмакларны аңа көндезен генә түгел, төннәрен дә ничәмә тапкыр әйләнергә туры килә. Әлбәттә, Акшаловка авыр, бик авыр булгандыр. Менә шунлыктан лейтенант Кулибаев, озак та үтмичә мине, сержант та диптер инде, үзенә ярдәмче (ягъни помкарнач) һәм разводящий итеп куйды. Ә Акшаловны солдатлар торган землянкага даими кизү (дневальный) итеп билгеләде. Һәрбер казакъ баласы шикелле, ул да бик оста аш пешерүче булып чыкты.

Без җимерелеп беткән бер зур гына шәһәр читендә торабыз. Кышкы айларда бу шәһәр өчен бик каты сугышлар барды. Адәм башкайларын монда күп салдылар — шәһәр әйләнәсендәге ачык кырда безнекеләрнең үле гәүдәләре сибелеп ята, ә шәһәрнең эче-тышы немец үлекләре белән тулы... Кышын аларны җыеп та бетерә алмадылар, күбесе кар астында калды.

Хәзер менә яз башы. Гаҗәеп якты, җылы-йомшак көннәр. Күк йөзе бер офыктан алып икенче офыкка чаклы чалт аяз — бүрек кадәр генә болыт та юк, ичмасам! Ә дәртләнеп йөзгән яшь кояшка без яшьле күз кырые белән генә карап алабыз: ашыкма, китмә син безнең өстән, диясе килә үзенә... Рәхәт безгә, тән генә түгел, җан эри, җан һәртөрле михнәт-газаплардан арына кебек... Ә соң күптәнме әле без бу аяз күктән курка-шомлана идек, безнең өчен болытлы-караңгы көн яхшырак иде. Аяз көн булдымы — немец самолетларын көт тә тор. Еш кына безнең өстебезгә кояш нурлары белән бергә үлем ява торган иде. Ә хәзер инде алай түгел. Куркудан туйдык, ахрысы, куркасы килми башлады. Аннары немец авиациясе соңгы айларда, кыйналган эт шикелле, койрыгын бөтенләй кысты диярлек. Баштагы кебек азына, котырына алмый инде ул. Бик сирәк кенә килеп чыккалый, анда да күбрәк кире борылып сыза. Сызарга мәҗбүр.

Әйе, адәм баласы сугышның үзен дә, аның дәһшәтләрен дә онытып торырга ярата. Хәтта менә бу җимерелеп, ишелеп беткән шәһәр дә аны ул хәтле шомландырмый һәм борчымый кебек. Чөнки шәһәр өстеннән сугыш өермәсе котырынып узган инде, ул да үзенең коточыргыч хәрабәләре белән язгы кояш нурларында тын гына коена, аның да исән калган почмакларына, ышыкланып торырлык ярыкларына, бүрәнә, кирпеч астындагы подвалларына кешеләр кайтып керергә өлгергән — шунда алар нидер кымшана, кага-суга, чүп-чардан тазарта, кыскасы, яңадан тамырланыр, яшәр өчен тырышып ята.

Бу хәрабәләр әйләнәсендә, бу патрон гильзалары, бомба, снаряд

кыйпылчыклары тулып яткан җирдә яңадан терелүнең гаҗәеп билгеләрен күрергә мөмкин. Шуның бер генә мисалы. Лейтенант Кулибаев башта мине тимер юлдан шактый читтә ялгызы гына торган бер иске сарай янына постка куйган иде. Сарайга немецлардан калган снаряд, миналарны җыеп тутырганнар — мин шуларны сакларга тиешмен. Мең шул постка бара торган юл буенда, дүрт-биш адым гына читтәрәк, кар астыннан чыккан өч немец солдатының үлек гәүдәләре аунап ята. Мин көн дә аларны күреп узам. Беренче күрүемдә ихтыярсыздан чирканып, бик җирәнгән идем — алар инде бик ямьсез бүртенеп, черитаркала һәм төчкелтем үләксә исе тарата башлаганнар иде. Безнең бәгырьләр бик каткан, фашистлар солдатын һич кызгану юк, ләкин шул солдатның үлек гәүдәсен күргәч, ул да бәхетсез бер адәм баласына әйләнеп кала. Чиркана-чиркана булса да ирексездән үзең кызганып узасың... Ә берничә көннән соң ни күрим, боларның чатлы-ботлы яткан гәүдәләре тирәсеннән, күм-күк битләренә ышкылып, ямь-яшел үлән баш калкытып чыгып килә!.. Ничектер бик серле дә, бик мәгънәле дә булып тоелды миңа бу асылда бик табигый күренеш. Җитмәсә, якты кырлар өстендә сабан тургайлары кояшка каршы талпынып-талпынып берөзлексез сайрыйлар!.. Чит-ят җирләргә килеп башларын салган, череп яткан шул бичараларның үзләренә дә узышлый: «Я, комрадлар, безнең Рәсәйдә яз матурмы?» — дип дәшәсе килеп китә.

Әмма ләкин сугыш искиткеч явыз, мәкерле нәрсә икән. Кайда гына сагаламый ул безне! Менә шундый тургайлар сайрап торган кояшлы көннәрнең берсендә безнең Ефимов дигән солдатыбыз яшь үлән каплап киткән минага туры килеп һәлак булды да куйды. Ефимов транспорт взводында ат йөртүче (ездовой) булып эшли иде. Бер көнне командир аны, атын җиктереп, шәһәр читендәге үлекләрне җыярга чыгарып җибәрә. Аның белән тагын ике солдат та була. Алар юлсыз-нисез кыр буйлап йөриләр, берничә үлекне табып, арбаларына да күтәреп салалар. Ефимов дилбегә тотып, гел арбасы кырыннан бара, ә теге ике солдат бераз арткарак калып, үзара сөйләшә-сөйләшә атлыйлар. Шулай барган чакта кинәт коточкыч шартлау!.. Тузан-төтен... Арттарак килгән ике солдат, җил очыргандай, тәгәрәшеп китәләр. Ләкин аларга әллә ни зур зыян булмый — җиңелчә контузия генә алалар. Бераздан торып карасалар,— бу ни әкәмәт? — ат тора, ә арба юк! Арба, өстендәге үлекләре белән бергә, ваткаланып очкан... Бер читтәрәк ярты бите, ярты башы актарылган Ефимов җирдә чалкан ята,— хәтта кулыннан дилбегәсен дә ычкындырмаган. Ә ат тора, атка берни дә булмаган. Тагын үзенә күрә бер хикмәт! Ничек кенә булган соң бу болай?.. Теге ике солдат, ат янына килеп, тикшеребрәк карагач, ниһаять, беләләр: немецның танкка каршы куйган минасы өстеннән ат басмыйча уза, арбаның алгы тәгәрмәче дә аңа ничектер туры килми, ә арткы тәгәрмәченең берсе (Ефимов атын бераз каера төшкәндерме инде) минага килеп тә менә. Көчле шартлау, һәм кеше бер мизгел эчендә һәлак тә була. Я, нәрсә әйтәсең? Язмыш... Ләкин теге ике солдат өчен дә язмыштыр инде бу, әмма бәхетле язмыш, чөнки үзләре дә белмәстән арткарак калып атламаган булсалар, алар да шунда беткән булырлар иде... Әнә шулай көтмәгәндә сискәндереп, сугыш үзен вакыт-вакыт безнең исебезгә төшереп куя. Әйе, чүпләнмичә калган миналар очрый әле, очрый...

Мәрхүм Ефимовны мин күптән белә идем. Бу ротага без бер вакыттарак килеп эләккән идек. Ул гәүдәгә базык кына, холкы белән дә басынкы-юаш кына бер кеше иде. Очрашканда миңа: «Исәнме, писарь!» дип дәшмичә калмый иде. Үзе ул шушы якныкы иде. Моннан бер-ике атна чамасы элек кенә аның янына хатыны да бер генә кичкә килеп киткән булган. Ирен әйбәтләп сыйлар өчен хатын букчасына күп кенә күчтәнәч тутырып, хәтта, чүпрәккә урап, агач бөке тыккан ике шешә самогон да китергән икән... Транспортчылар землянкасында

унбишләп кеше тора иде. Ләкин солдатлар ул кичне барысы да дәррәү ятып, яман гырылдап, бик каты йокларга тырышканнар... Шул караңгы землянканың бер почмагында Ефимов хатыны белән тавыш-тынсыз гына утырып, төнне уздырып җибәргән. Авыр туфрагы җиңел булсын, бик тыйнак, кыюсыз кеше иде, мәрхүм!

* * *

Җитеп торыр... Солдатның хәтер сандыгында бик күп нәрсә саклана, барысын да сөйләп бетереп булмас, хикәянең башына күчик. Әйе, менә без Латвия җирендә. Машиналарда, йөкләр өстенә утырып, тирә-якны бик ачык күзәтеп килдек, шул сәбәпле латышлар җирен ничектер бик тиз танып алдык. Безнең Рәсәй җирләренә бер дә охшамаган икән. Монда бөтен нәрсә — кырлар, басулар, урманнар — күләме белән шактый кечкенә икән. Шәһәрләре дә кечкенә, җыйнак кына... Бездәге кебек зур-зур авыллар бөтенләй юк, бары бер йортлы, күп булса, ике йортлы утарлар гына. Алар бер-берсеннән чакрым-чакрым ярымда ялгыз гына утыралар. Бер утар — бер хуҗалык булса кирәк. Арада бик тазалары очрый: өе дә таштан, каралты-куралары да таштан, түбәләре калай белән ябылган... Искергән, тузганнары да күренә — болары инде агачтан, түбәләре дә каралып беткән дранча гына. Һәммәсенең күпме-азмы иген басуы, печәнлеге, бакчасы шул утар тирәсендә — әллә кая китеп йөрисе юк. Барысы да якында, кул астында гына. Терлекләре дә шунда гына йөриләр. Әйтергә кирәк, бу утарлар безгә башта сәер-кызыклы да һәм ничектер күңелле-ямьле дә булып күренде. Аларның хуҗалары үз көйләренә үз җайлары белән эшләп, дөнья ыгы-зыгысыннан читтә, тук-тыныч кына яшиләрдер кебек тоелды. Ләкин безнең солдатларның бу утарларга карап телдән әйткәннәре бөтенләй икенче нәрсә турында булды. Чын гаҗәпләнү белән алар:

— Боларны колхозга ничек итеп оештырырлар икән соң? — диештеләр. — Барысын да бер урынга җыярлар микән?

Билгеле, алар фикеренчә, бу җирләргә яңадан Совет власте кайткач, колхоз да булачак, булмыйча калуы мөмкин түгел... Аннары тагын бер нәрсә безне гаҗәпләндерде: монда шактый терлек күренә иде. Һәрбер утар тирәсендә сыерлар, башмак таналар, сарыклар йөри. Бигрәк тә сарыкларны күргәч, безнең казакъларның исләре китте:

— Ой-бой, монау латышта куйлар калган гой!

Искитмәслек тә түгел, чөнки немец аяк басып киткән Рәсәй авылларында терлек бөтенләй беткән диярлек иде. Берән-сәрән сыер күренгәли, аз-маз дуңгыз бар, әмма сарык юк, сарыкларны ашап бетергәннәр. Ә монда һәрбер утар тирәсендә унлап, унбишләп сарык күренә. Чынлап та гаҗәп иде бу... Ләкин безнең солдатлар төрлечә юрап карасалар да, бу хәлнең серенә, билгеле, төшенә алмадылар.

Безне кечкенә бер станциядән ике километр чамасы читтәрәк торган урман буена китереп туктаттылар. Хәрби кирәк-яраклар складьы шушы урман эчендә булачак икән. Склад кешеләре бирегә килеп урнашканнар иде инде. Без дә тиз генә урнашу хәстәренә керештек. Нарат, каен, усак аралашып үскән бу урман шактый җепшек, сазлыклы икән — торыр өчен шәп урын түгел. Җире калын юрган кебек йомшак, йөргәндә аяклар батып-батып китә. Мүк җиләге күп булырга тиеш монда. Ә менә землянкаларны кайда казырга? Немецлардан калган землянкаларга очрасак, безнең эш бик ансатлаша торган иде. (Немец землянканы гадәттә таза, иркен итеп сала.) Мина-мазар калдырып китмәгәнме дип тикшергәннән соң, шул землянкаларны немецларның төрле чүп-чарыннан тазартып, әзер «өйгә» генә керә торган идек. Чүп-чар дигәннән,

ул фрицлардан нәрсәләр генә чәчелеп калмый!.. Төрле-төрле печатьле шешәләр, конфет, шоколад, сигарет кәгазьләре, ялангач хатыннар төшерелгән журнал битләре, оятсыз фоторәсемнәр, уен карталары, сынган тарак, ватык күзге, яньчелгән фляга — тагын әллә ниләр, санап та бетерерлек түгел. Баштарак безнең солдатлардан кайберәүләр шул чүпләр арасында эзләнергә ярата торганнар иде. Соңыннан без аларны бу эштән бик нык тыйдык. Командир үзе ташландык землянканы тикшереп чыкмыйча, аңа берәүне дә якын җибәрми, ә тикшергәннән соң бөтен чүп-чарын бер төшкә өеп, үз күзе алдында яндырта. Исе дә калмасын, ди.

Хәер, бу урманда безгә андый «трофейга» бай әзер землянка очрамады. Башта казыклардан һәм агач ботакларыннан бер өч куыш ясадык, эчләренә бик әйбәт итеп печән түшәдек. Сиртмәле караватың да кирәкми!.. Соңыннан инде, бераз баш-күз алгач, калкурак урында берсе кечерәк, берсе зуррак ике землянка да казырга тотындык. Бу якларның көн саен диярлек килеп торган яңгырыннан землянкасыз һич тә котылып булмый. Ә безнең солдатлар, әйтергә кирәк, «җир сараен» менә дигән итеп салырга өйрәнделәр. Түбәсе өч кат бүрәнәдән — трактор үтсә дә ишелмәс!

Яңа урынга күчеп урнашкан чакта эш гадәттә бик күп, бик тыгыз була. Килеп машинадан төшкәч тә алдан билгеләнгән пост нокталарына беренче часовойларны куябыз. Аннары калганнарыбыз тиз генә үзебезгә торыр җир әмәллибез, склад территориясен әйләндереп берничә рәт чәнечкеле тимер чыбык сузабыз, территориягә керә торган төп юлга шлагбаум белән кечкенә будка сыман нәрсә ясап куябыз... Ул да булмый, складка вагон-вагон боеприпаслар килә башлый. Шул ук чакта, шул ук боеприпасларны алгы позициягә алып китәр өчен территориягә автобат машиналары килеп тула. Бу эшкә кагыйдә буенча каравыл хезмәтендәге солдатларны алмаска тиешләр. Ләкин сугыш синең кагыйдәләрең белән хисаплашып торамыни ул. Кыска гына бер боерык, һәм без, посттан азат солдатлар, барыбыз да вагон бушатырга яки машина төяргә китәбез. Күбрәк төнлә эшләргә туры килә, чөнки төнлә хәвефсезрәк. Ә боеприпас дигәнең ул әрҗәләргә тутырган конфет түгел, боеприпас ул тимер дә корыч, аларның (мәсәлән, авыр снарядларның) берсе-берсе сиксән кило тартканнары бар, абзыкаем! Менә шуларны инде безнең гарип-гораба солдатларыбыз кара тиргә батып, көчәнә-көчәнә күтәреп төшерә яки күтәреп мендерә. Кайчагында солдатның басып торырлык хәле дә калмый. Ә бит аңа яңадан постка да барырга кирәк.

Тыныч шартларда, әйтик, берәр хәрби объектны саклаучы яшь солдат постта бары ике генә сәгать тора. Каравыл хезмәтенең уставы буенча да ул шулай гына торырга тиеш. Ә монда безнекеләр тоташтан алтышар сәгать торалар. Чөнки кеше җитешми. Һәр постка бары икешәр генә кеше туры килә. Менә шунлыктан көзге караңгы төннәрдә дә, кышкы салкын бураннарда да безнең әлеге карт солдатыбыз, мылтыгын бер иңенә асып, бер кулына алып, пост дип әйтелгән берәр агач төбендә алты сәгать буена таптанырга мәҗбүр. Утырып тору аңа рөхсәт ителми, арыса — басып кына торырга ярый. Дөрес, без аларны дүрт сәгатьтән дүрт сәгатькә дә алыштырып карадык. Ләкин солдатлар моңа риза булмадылар: кайтып тамак ялгарга да, йоклап алырга да вакыт җитми кала, алты сәгать торып, алты сәгать ял итү безнең өчен әйбәтрәк, диделәр. Үзләре шулай дигәч, билгеле, яңадан алар теләгәнчә калдырдык.

Алты сәгать постта торуның нәрсә икәнен ничек кенә аңлатырга? Разводящий буларак мин моны яхшы беләм, ләкин шуның өстенә әле

минем үземә дә каравыл взводына күчкән көннәрдә алтышар сәгать постта торып карарга туры килде. Күнекмәгән кеше өчен бу искиткеч авыр хезмәт. Япа-ялгыз тик бер урында торгач, шул озын төнгә охшаган вакыт һич кенә дә үтеп бетмәс кебек тоела. Арлы-бирле йөренгән дә буласың, авыз эченнән генә берәр көйне дә шыңшырга тотынасың, фикерне читкә җибәрер өчен юк-бар нәрсәләр турында да уйларга тырышасың. Әмма миеңне һаман бер нәрсә — күпме вакыт үтте икән дигән уй кимерә дә тора. Баштагы ике-өч сәгатьне шулай да җиңелрәк үткәрәсең, иллә мәгәр калган яртысын үткәрә алмыйча тәмам интегеп бетәсең. Ахырга таба бөтен җирең — башың, күзең, аякларың — барысы да арый һәм шулкадәр арый ки, күзеңә инде һичбер нәрсә күренми башлый. Смена килер алдыннан, үзең сәгать теленә әйләнеп дигәндәй, калган минутларыңны гына санап торасың.

Минем беренче мәртәбә постта торуларым әнә шулай ифрат азаплы үтте. Ләкин адәм баласы, мәгълүм булганча, барысына да күнегә, һәм мин дә, билгеле, әкренләп күнектем. Тора-бара хәтта бу постта торуның үзенә күрә бер, ничек дим, уңай-рәхәт ягын да тапкандай булдым: хыял диңгезендә йөзәр өчен бик шәп урын икән! Тик вакытны гына уйламаска кирәк. Теләсә нәрсә турында уйлан, хыяллан, әнә сәхрәләр кич, диңгезләр кич, Һиндстанга барып чык, Һималай тауларына менеп төш, берәр һинд кызын урлап, Питрәчкә алып кайт, иллә мәгәр вакыт үтәме икән дип һич кенә дә борчылма!.. Ә вакыт үтә ул, үтә, алты сәгать кенә түгел, алты мең елы да үтеп китә, әйдә, чәнчелсен!.. Ул да булмый, смена килә, син алмашыңны дусларча елмаеп каршы аласың — менә рәхәт ял вакыты сиңа да килеп җитә. Землянкага кайтып, дневальный борчак концентратыннан пешереп торган ашны ашыкмыйча тәмләп кенә ашыйсың, ашап беткәч, кашыгыңны әйбәтләп ялыйсың, котелогыңны җылы су белән чайкап куясың. Аннары бер утырып, урта бармак юанлыгы итеп төргән махраны тәмен-ләззәтен белеп кенә, очына өргәләп кенә көйрәтәсең. Шуннан соң чолгауларыңны кибәргә куясың да печән түшәгән сәкегә, шинелең белән баштан ук бөркәнеп, йокларга ятасың. Җылынып, изрәп, төшләр күрә-күрә... Нигә, рәхәт түгелмени?

Хәер, безнең картрак солдатларга каравыл хезмәтенә күнегү болай ук авыр булмагандыр, чөнки, беренчедән, аларның берсе дә минем кебек җылы урыннан бу эшкә күчмәгәннәр, икенчедән, барысы да диярлек күптән инде каравыл взводында хезмәт итәләр. Әлбәттә, алар тизрәк күнеккәннәр дә, тизрәк няләшкәннәр дә, сыкранмыйча гына постка баралар-кайталар, әмма ләкин аларга да барыбер җиңел түгел. Бигрәк тә авыр йөк бушату эшеннән соң постка баруы һәм алты сәгать аяк өстендә торуы — ай-һай, күпме чыдамлык, күпме көч кирәк моның өчен!.. Миңа аларның берсеннән дә каравыл хезмәтен мактап яки яратып әйткән сүзләрен ишетергә туры килмәде.

Шуны да онытмаска кирәк: постта торучыга каты таләп тә куелган һәм зур хокук та бирелгән. Барысыннан элек ул, билгеле, һәр сәгатьтә, һәр минутта уяу-сизгер булырга тиеш. Караңгы төндә дә, томанлы иртәдә дә, җилле-яңгырлы көндә дә... һәм һич беркемне янына якын җибәрмәскә тиеш. Әгәр берәр кеше якын килә башласа һәм: «Тукта, кем килә?» дигән сүзгә җавап бирмәсә, солдатның аны ату белән куркытырга хакы бар. Хәтта килгән кешене ул таныса да, хәтта килүче үзебезнең берәр зур начальник булса да аңа: «Тукта, атам!» дияргә хакы бар. Туктамаса, атачак һәм солдатка берни дә булмаячак.

Ике генә кешене ул үзенә якын җибәрә — каравыл начальнигын һәм разводящийны. Шулардан башка һич беркем, хәтта генерал, хәтта маршал да аңа якын килә алмый. (Яки килсә дә каравыл начальнигына нярен килә ала.) Әнә шулай каты куелган ул каравыл эше!

Яңа урында әзрәк баш-күз алдык шикелле. Безнең солдатлар үзләренә бер зур гына землянка да өлгерттеләр. Хәзер командир белән икебезгә аерым, кечкенәсен, төзеп яталар. Мин бит разводящий гына түгел, командирның ярдәмчесе дә, ары-бире киткән чагында аны алыштырам, шуңа күрә ул мине үз янында тота торган булды.

Постларның сменалары да тәртипкә салынды. Казакъларны без бер сменага тупладык. Ни әйтсәң дә алар бер-берсенә җылышып, бергә сайрашып яшәргә өйрәнгән халык. Сменадан кайткач, бергәләп ашыкмыйча чәй эчә-эчә, озак кына гәпләшеп утыру алар өчен үзе бер хозур, үзе бер ял... Югыйсә, ялгыз казакъ бик күңелсезләнә, бик моңая ул.

Сменаларны тәүлеккә дүрт мәртәбә — иртән алтыда, көндез уникедә, кич алтыда һәм янә төнге уникедә алыштырабыз. Бусы инде минем эш. Сменага бер ярты сәгать калгач, мин солдатларга киенеп, әзерләнеп землянкадан чыгарга кушам. Төрле кеше төрлечә дигәндәй, монда да кайберсе бик тиз җыенып чыга, ә кайберләре (мәсәлән, Байәхмәтов) бик озак кыймылдый. Кабатлап, үтемлерәк сүз кушып, кычкырып та әйтергә туры килә. Ниһаять, кыштырдый торгач, барысы да чыгып бетәләр. Мин аларны сафка тезәм дә өс-башларын, мылтык-коралларын тәртиптәме дип тикшереп чыгам. Мылтыкларына сүз юк, чиста, әйбәт. (Чөнки көн саен диярлек чистартырга мәҗбүр итәбез.) Ә менә өс-башларына килгәндә инде, пөхтәлек — ташка үлчим! Кайсының төймәләре каптырылып бетмәгән, кайсының бил каешы буш — йодрык сыярлык, ә Ишмәмәт әнә пилоткасын башына аркылы кигән. Хәер, аның һәрвакытта шулай: я аркылы, я алдын артка кигән була — әйтерсең, пилоткасы башында әйләнеп йөри!.. (Гомумән, карт солдат — каткан тал кебек, аңардан чын солдат ясавы бик читен.)

Тиешле төзәтүләрне ясаганнан соң, каравыл хезмәтенең кайбер кагыйдәләрен янадан исләренә төшергәч, мин аларны сулга таба борам да:

— Киттек, бөркетләр! — дип, үз артымнан җилле генә ияртеп алып китәм.

Беренче пост — шлагбаум янында. Бирегә солдатның төзегрәген, үткенрәген һәм грамоталырагын куябыз, ник дисәң, шушыннан өзлексез машиналар да, кешеләр дә үтеп йөриләр. Аларның пропускларын карап үткәрергә кирәк. Шулай ук бу юлдан үтеп-сүтеп йөрүче төрле начальниклар да бер дә өзелми. Часовой монда штык шикелле торырга тиеш. Шуңа күрә бирегә ни житте солдатны куеп булмый. Хәер, карт солдатлар үзләре дә начальниклар күзенә алай бик кереп торуны яратмыйлар.

Хәзер анда бер күзе пыяла, әмма буе-сыны бик килбәтле Шумилов дигән солдат тора. Сугышка чаклы ул кайдадыр май заводында бухгалтер булып эшләгән, имеш. Ахрысы, шуңадыр, һәртөрле кагыйдәләрне бик төгәл үтәргә ярата һәм кергән-чыкканнарның язуларын да ашыкмыйча бик җентекләп тикшерә.

Менә хәзер мин аңа алмашка Җантимеров дигән солдатны китердем. Бу казакълар арасында иң яше, укый-яза белгәне, сугыштан өтелеп чыккан чын солдат, ышанычлы часовой... Сүз уңаеннан тагын шуны да әйтергә кирәк, Җантимеровның гаҗәеп бер сәләте дә бар: сандугачбылбыл булып искиткеч матур сызгыра ул. Агачлар арасына китеп, шундый чын, шундый өздереп чутылдарга тотына ки, ишеткәч, сандугач иконенә тәмам ышанып, сихерләнеп тыңлыйсың үзен... Ничәмә тапкыр ул безне шулай алдады. Казакълар да үзен бик яраталар.

Без шлагбаум янына килеп житкәндә, Шумилов боеприпаслар төягән дүрт «студебеккер» машинасын үткәреп тора иде. Үткәреп бетергәч, мин аңа якынлашып:

— Я, Шумилов, эшләр ничек, бик арымадыңмы? — дип сорадым.

— Әзрәк булды, иптәш сержант,— диде Шумилов, турая биреп.

— Нәрсә, машиналарны күп үткәрергә туры килдеме?

— Ничек дип әйтергә? Бик күп булмаса да, һаман килеп торалар, китеп торалар, так што шлагбаум киртәсеннән бер адым да читкә китәргә туры килмәде.

Бу складның шунысы яхшы: моннан урлап чыгар нәрсә юк. Йөкләрне тикшереп тору кирәкми дә, барыбер артык ящикны эләктереп чыгарга тырышучы табылмаячак. Ә менә азык склады каравыл өчен бик начар — анда инде машинада нәрсә барын карамыйча чыгару юк. Бигрәк тә аракы төягән булса, шоферның утыргычын да күтәреп карарга туры килә.

Бездә часовойларны алмаштыру бик гади эшләнә. Берсе китә, икенчесе торып кала. Бушаганнарын мин үзем белән ияртеп йөрмим, шунда ук кайтарып җибәрәм. Аз булса да ял итә торыр. Кайберләре, бәйдән ычкынгандай, землянкага таба сыптыра гына.

Шумиловны алыштыргач, мин, калган солдатларны ияртеп, чәнечкеле тимер чыбык буйлап сузылган тар сукмактан икенче постларга китеп бардым. Солдатлар җитмәгәнгә күрә, пост аралары шактый ерак, бик кирәк урыннарда гына тора. Шлагбаумнан соң әле берсенә, әле икенчесенә җитеп, часовойларны алыштыра-алыштыра бара торгач, менә иң соңгысына да Ишмәмәт белән икәү генә килеп җиттек. Бу постның урыны бик аулак, бик матур җирдә: урман кырые, каршыда адәм аяк басмаган киң генә аланлык, чабылмыйча калган бил тиңентен куе үлән — ул инде шулай утырган килеш саргаеп картайган, хәтта чәчәкләре дә коелмыйча гына кипкәннәр... Монда ялгыз-ялгыз бик мәһабәт имәннәр, каеннар үсеп утыра. Бирегә килгән саен мин эчемнән генә, тукта, бу урын миңа малай чактан ук таныш түгелме соң дим, бик сәерсенеп уйламыйча калмый идем.

Әнә, тимер чыбык буендагы ялгыз имән төбендә чуваш Емелькин басып тора. Мылтыгына беләге белән таянып торышыннан ук күренә, дәдәебез бик арыган булса кирәк.

— Ну, Емелькин,— дим мин аңа килеп җиткү белән,— безне көтәкөтә зарыгып бетмәдеңме?

— Бетмәгән кайда инде ул, парин! — ди Емелькин, урыныннан авыр гына кузгалып.— Алты сәгатенә түздек, алты минутка калгач түзүләре бик читен икән.

— Шулайдыр шул... Синең пост иң ахыргы бит, көтмичә дә хәлең юк. Әллә якынрак постка күчерикме үзеңне?

— Юк, кирәкми. Монда әйбәт.

— Әйбәт дисең... Нәрсәсе белән?

— Монда, парин, уйлавы рәхәтрәк. Мишәйт итүче юк.

— Шулаймыни?Ниләр уйлыйсың соң син?

— Барысын да... Әйтеп бетереп буламыни аны?!

— Түтәйне дә сагына торгансыңдыр инде?

— Аны да сагынам, парин, сагынам.

Емелькин җиңе белән юешләнеп торган күзләрен сөртеп алды. Мин сүзне икенчегә борыр өчен сораган булдым:

— Тынычлыкмы, ул-бу юкмы?

— Нәстә булсын... Бер куян гына сикерә-сикерә узып китте. Атмакчы идем дә тревога ясармын дип курыктым.

— Нигә атасың аны? — диде Ишмәмәт, ничектер кинәт кырыс кына.

— Бәй, нигә дип, суеп ашарга. Тиресеннән бүрек тегәргә.

— Харам ул!

— Харам? Куянмы? — диде Емелькин, бик гаҗәпләнеп.— Их, син, үзбәк, белмисең икән әле куян итенең тәмен, тавык итенә биргесез ул.

— Үтереп ашау харам... Җан иясен үтерергә ярамый, гөнаһ булады ку...

— Һе, таптың сүз! Кеше үтерергә ярый, куян үтерергә ярамый, имеш!

— Кеше — явыз.

— Кем, минме? — Емелькин аның өстенә ук бара башлады.

— Я, я, җитәр сезгә! — дидем мин, араларына кереп.— Юк өчен әтәчләнмәгез. Кая, эшегезне бетерегез!

— Ортак Емелькин аңламый шул,— диде Ишмәмәт, тыныч кына.— Мин аның кальбен аяп әйтәм, кальбе ташка әверелмәсен...

— Аңламыйм шул мин сине, Ишмәмәт,— диде Емелькин да шактый йомшарып.— Кальбе дисең, нәрсәдер инде ул, белмим, иллә мәгәр монда таш булырга кирәк, таш... ярар, кил әйдә, карт имәнгә терәл!

Ишмәмәт Емелькин урынына басты һәм мылтыгын җиргә төшерде. Үзе дә мылтык буйлык бәләкәй-юка гына бер кеше инде ул. Чырае да сабыйныкы, күңеле дә сабыйныкы, чебен үтерергә дә кулыннан килмәс, ә шулай да мылтык тотып постта торырга ярый. Хәер, бу сугышта эшкә ярамаган кеше калмады.

— Я, Ишмәмәт, әйбәт кенә тор инде,— мин әйтәм,— бик боекма, күбрәк йөргәлә... Мин синең янына килеп китәрмен әле.

Ишмәмәт мөлдерәп туларга торган күзләре белән миңа моңсу елмаеп кына карый. Бик тә нечкә, йомшак бәгырьле кеше ул безнең Ишмәмәт. Чак кына җылырак сүз әйтсәң, әнә шулай эри дә китә. Җавап бирергә дә көче җитми. Аны хәтта безнең лейтенант та тирги алмый. Ә тиргәргә кирәк чаклар булгалый, чөнки ул, ничек дим, арада иң пешмәгән, иң тугарылып йөри торган солдатларның берсе. Әмма үзе бик чыдам, бик күндәм, кая гына куйсаң да тора һәм алты сәгать түгел, ун сәгать тә тора ала, тавышын-тынын чыгармый. (Бүтәннәр, мәсәлән, ун гына минут артыграк торсалар да сукрана, сүгенә башлыйлар.) Аның дүрт баласы бар икән инде, ул шуларны бик сагына һәм гомумән илен-өен бик сагына булса кирәк, шулай сизелә. Әмма, әйткәнемчә, эчтән сүзсез генә сагына, бүтәннәр кебек тышка чыгарырга, уфтанырга яратмый. Үзенә күрә сәер, серле генә бер кеше ул... Минем аңардан сораганым да бар:

— Ишмәмәт әкә, әйт әле, син үлемнән куркасыңмы?

— Юк, курыкмыйм,— ди ул, тыныч кына.

— Ник?

— Минем береннән-бере кечек дүрттә балам бар! — һәм ул балаларының җирдән күпмегә биек булуын кулы белән күрсәтеп чыга: — Миңа үләргә ярамый, ходай мине саклаячак.

Һәм Ишмәмәт моны бик нык ышанып әйтә.

Карт имән янәшәсендә генә чәнечкеле чыбыкның кечкенә чокыр өстеннән узган бер иркен урыны бар — без Емелькин белән шул төштән иелеп эчкәре уздык та тар гына сукмактан взводка кайтып киттек. Емелькин салган сукмак бу, иң туры, иң кыска юл... Минем арттан килә-килә ул миңа зур бер нәрсә итеп сөйли:

— Куянның маңгаена туп-туры карап барсаң, парин, ул кача алмый. Ник дисәң, куян туры каршысына килгән кешене күрми, аның күзләре маңгаеның ике ягына чалыш утыртылган... Чапканда да ул башын бер унга, бер сулга борып, алдына да, артына да карый-карый чаба. Ышанасыңмы?

Мин нәрсә дим?.. Куянның алай чапканын һич тә күргәнем юк, ләкин Емелькинга «юк, ышанмыйм» дип әйтәсем килмәде. Чуваш агай куянны миңа караганда яхшырак белергә тиеш.

Алданрак кайткан солдатлар землянка каршындагы тар өстәлдә дневальный сосып биргән борчак ашын котелокларыннан шөбердәтеп ашап утыралар иде инде. Емелькин да мылтыгын агачка терәп, билен-

нән каешын салып ташлады да кулын юып ашарга утырды. Дневальный китереп биргән котелогына кашыгы белән тыгылгач:

— Рәхмәт төшкере, бүген дә борчак икән,— диде.— Каян алып житкерәләр бу борчакны, әллә Әмерикәдән килә инде?!

Солдатлар көлешеп алдылар. Арадан берсе:

— Юк, булмас,— диде.— Борчак Американың үзенә дә житми торгандыр...

— Нишләп?

— Нишләп дип, моңарчы бит алар немецка каршы борчак кына атып яттылар.

Солдатлар тагын көлештеләр. Сүзнең мәгънәсе аларга бик ачык: союзниклар (Америка белән Англия) ике-өч ел буена икенче фронтны ачмыйча сузып килделәр. Безнең солдатларның бу хәлгә бик ачулары килә иде, шунлыктан җай чыккан саен Америкасына да, Англиясенә дә тибеп узмыйча калмыйлар иде. Бик әшәке итеп сүккән чаклары да күп булды, ләкин хәзер тынычлана-басыла төштеләр инде, чөнки союзниклардан башка да немецны җиңеп чыгуыбызга ышана башладылар.

Ашау-эчү бездә төрле вакытта төрлечәрәк була. Безне үзебезнең рота тәэмин итә. Әгәр ротага якын торсак, азыкның һәртөрлесен вакытында алабыз, әгәр инде хәзерге шикелле ротадан ерак китсәк, үзебез алып килгән коры-сары (концентрат, консерв, шпик) белән генә туенып торабыз. Тик икмәкне генә без көн саен диярлек шушы склад келәтеннән алып кайтабыз.

Башта әйткәнемчә, бу урынга күчеп килгәч бер-ике атна чамасы эш бик күп, бик тыгыз булды. Әлеге дә баягы боеприпас дигән бик кадерле нәрсәне төяшергә куалап, безне тәмам алҗытып бетерделәр. Зур һөҗүм вакытында гел шулай була инде ул: склад территориясенә йөзләрчә машина килеп тула, көне-төне анда кешеләр кайнаша, зур гына начальниклар сүгенеп, тиргәп, берөзлексез ашыктырып йөриләр. Ә төяп озатучылар барыбер житешми. Менә шуннан соң инде посттан бушаган солдатка да чират житә. Әлбәттә, каравылда торучыларга тияргә ярамый дип әйтүче юк. Ә арыган, өшәнгән солдат постында йокласа, башы белән җавап бирергә тиеш.

Кыскасы, берьюлы ике камытны киярга туры килде безгә... Бик арыдык, чиләндек, өс-баш та тетелеп бетте, ә соңга таба инде аякларны сөйрәрлек тә хәлебез калмады. Ләкин без бер нәрсәне белеп тора идек: дошман чигенеп, фронт ераклашса, безнең хәлебез дә җиңеләячәк. Бөтен теләгебез шул, бөтен өметебез дә шунарда гына... Чөнки ул чагында тылдан килеп торган боеприпасларны монда бушатмыйча алгарак, фронтка якынрак җиргә куачаклар.

Һәм шулай булып чыкты да ул: башта фронт моннан сигез-ун километрда гына иде, ә бер ун көннән инде автобат кешеләре фронтның 30—40 километрга ераклашканын әйттеләр. Хәер, без моны үзебез дә сизеп тордык: сугыш бит ул, көчле күк күкрәве шикелле, акрынлап ераклаша һәм тоныклана бара.

Менә безнең территориядә дә эш әкренләп сүрелә башлады, машиналарның килүе шактый кимеде, аннары зуррак начальниклар да китеп беттеләр. Бу инде яхшы фал иде. (Димәк, эшнең кызуы алга күчте дигән сүз.) Дөрес, машиналар һаман әле килгәләп тора, ләкин безне борчымыйлар иде инде. Шулай итеп, без яңадан үзебезнең төп эшебез — каравыл хезмәтендә генә калдык һәм тынычланып, нормага кереп дигәндәй, солдат кешесенә хас көндәлек ашау кайгысы, йокы кайгысы белән генә яши башладык.

Ашау дигәннән, безнең казакълар теге килгән чакта утарлар тирәсендә күренгән сарыкларны бер дә исләреннән чыгармаганнар икән. Шуны әйтергә кирәк, сухой паекны алар гомумән яратмыйлар, ирексездән көчләнеп кенә ашыйлар, ә шпикны инде бөтенләй авызларына да алмыйлар. Үзебезнең Россия җирендә торган чакта, әгәр якын-тирәдә генә авыл булса, аларның кайберләре, шул шпикны чүпрәккә төреп, авыл арасына чыгып китә иде дә берәр марҗадан бәрәңгегә яки сөткә алмаштырып кайта иде. Ничә тапкыр лейтенант үзләрен шуның өчен эт итеп тиргәде. Ләкин казакъ гаеплемени, нәфсе аның борын-борыннан ашап өйрәнгәнне сорый, йортына кермәгән чучканы ничек ашасын ул?!. Ә монда әнә сөйкемле куйлар утлап йөриләр...

Һәм менә бер көнне землянка алдындагы тар өстәл әйләнәсендә чәй эчеп утырган чакта Байәхмәтов шул сөйкемле мәхлукны кинәт кенә исенә төшергәндәй миңа әйтә куйды:

— Анау латышның берәр куен алып чалганда жаксы булыр иде, ә, жулдаш сержант! Казан асып, казакъча бер мәҗлес кылып утырыр идек, ни дисез шуңа?

— Ни әйтим, Байәхмәт әкә, бик хуп күрәм мин бу эшне,— дидем мин дә аны-моны уйламыйча гына.

Казакълар бердән җанланып киттеләр:

— Һа, сержант — үземезнең нугай, казакъның җоласын белә гой!

Акшалов бөтенләй сикереп үк торды:

— Эш нимәдә? Тотарга да алырга латышның куен...

— Ничек итеп?

— Сатып, сержант! Сатып...

— Сатыр сиңа! Тот капчыгыңны!

Байәхмәтов тагын ашыкмыйча гына үз сүзен кыстырып куйды:

— Мондагы латыш частный адәм! Частный адәм сата ул, баһасыннан гына тормаска кирәк.

Мин моңарчы бу сөйләшүне бары уенга гына алып утыра идем. Гадәттәге бер хыяллану дип кенә... Ә хыяллану — куй турында да, кирәксә, кыз турында да — солдатка бик килешә ул! Ләкин Байәхмәтнең соңгы сүзләрен ишеткәч, мин бераз сагая калдым: әллә болар чынлап та латыштан куй алып суймакчылар инде?!. Кара син аларны!.. Әмма ләкин мондый эшнең булуына ышануы бик читен бит әле. Кем йөри аның артыннан, кем рөхсәт итә аны безгә?.. Аннары мондагы халыкны да без яхшылап белмибез әле. Дусмы-дошманмы дигәндәй, нинди(рәк кешеләр алар?.. Бәлки, ул хутор иясе безгә куен түгел, чебешен дә сатмас. Шуңа күрә мин бары кул селтәп:

— Булмас, юлдашлар! — дидем.— Юкка нәфсегезне сузмагыз!

— Ой-бой, нимәгә булмас?! — диештеләр казакълар, бик гаҗәпләнеп.

Ә моңарчы дәшмичә хәйләкәр генә елмаеп утырган Дурду кинәт минем алдыма ук торып басты:

— Булмас дисеңме, сержант?.. Менә сиңа кара сакалым, иртәгә үк мин синең алдыңа куйның башын табакка салып китереп куям! Инанасыңмы?

— Ай-һай, Дурду әкә! — дидем мин, көләргә итеп.— Кем генә бирер икән соң сиңа куй башын?

— Латыш үзе китереп бирер! Инанасыңмы, юкмы? Әйт, инанасыңмы?

Мин икеләнебрәк:

— Юк, ышанмыйм! — дидем.

— Алайса, җирәбә тартабыз! — диде ул, миңа кулын сузып.— Мин оттырсам, сиңа... бер мәскәуский! Булдымы?

— Ә мин оттырсам?

— Синнән дә мәскәуский!.. Сүз бәйләдекме?

— Хуп мәйле! — дидем мин, аның сузган учына сугып.— Ләкин белеп тор, Дурду әкә, әгәр дә мәгәр латышны рәнҗетсәң, яки куен урлап алсаң, башың штрафнойга китәчәк!

— Бу ниткән сүз?! — диде Дурду, кинәт караңгыланып.— Ходай сакласын андый эштән! Әйттем гой латыш куен үзе апкилеп бирер дип.

Һәм ул тынычланыр өчен кесәсеннән кечкенә шешәсен чыгарып, тел астына насбаен салды да бер читкәрәк китеп барды.

Әнә шулай бетте бу уйламаганда гына килеп чыккан сүз. Ә безнең бәхәс чын булдымы, әллә юри генәме — мин моңа ышанырга да, ышанмаска да белмәдем. Ярый, күтеп карарбыз... Ләкин шуны әйтергә кирәк, Дурду утны-суны кичкән, бик үткен, бик хәйләкәр казакъ иде. Иң элек ул картада искиткеч оста уйный белә иде. Казакътан картежник! — башта бу минем өчен һич көтелмәгән бер яңалык булды. Әле кемнәр белән уйный диегез?.. Бары капитан, майор, подполковник кебек зур чичнар белән генә, чөнки алар үзләре буш вакыт табып картага утырдылар исә, тизрәк Дурдуны чакыртып алалар. (Невель янында торган чакта минем үземә аны, лейтенант кушуы буенча, посттан бушатып, начальниклар җыелган землянкага җибәрергә дә туры килгәләде.) Һәм кем белән генә уйнамасын, Дурду ул кешене чишендермичә калмый иде шикелле. Моның сере нәрсәдә? — хода белсен, ләкин казакъларның шыпырт кына әйтүенә караганда, аның бармаклары картаны «күрә», имеш!.. Һәрхәлдә, бер нәрсә ачык билгеле — Дурду акчалы кеше, аның гимнастерка астыннан зур яулыкка урап биленә бәйләгән утыз-кырык мең сум акчасы гел янында йөри, диләр.

Шуның өстенә, тагын бу Кара-Калпак казагы (туган иле шунда аның) төскә-биткә дә шактый чибәр кеше иде. Бите аның, бүтәннәрнеке кебек, ипи каравае сыман түп-түгәрәк түгел, озынчарак та, җыйнаграк; кечкенә генә кара сакал, куе гына кара мыек, ә иреннәре ак сызыклы — ачык беленеп тора. Буе-сыны да аның ыспай-җыйнак, тыгыз-таза... Ул теләгән чагында бик сөйкемле итеп елмая белә һәм кысыграк майлыелтыр күзләре белән бик үткәзеп карый ала. Шуңадыр, ахры, кешеләр аңа тартылалар, аңа якынрак булырга тырышалар. Начальниклар да бит аны, юньләп русча сөйләшә дә белмәгән гади солдатны, тиң күргәндәй яннарына чакырып алалар. Хәтта очраган хатыннар да аңа, эчләреннән генә нидер уйлап, карамыйча узмыйлар иде.

Кыскасы, Дурду — теләгәнен булдыра ала торган кеше. Ләкин мондагы латышны ул ничек итеп сихерли алыр икән? — монысына минем, дөресен әйтергә кирәк, күзем җитми иде. Ахрысы, ана сарык башы урынына «мәскәүский»не минем алдыма куярга туры килер. Ә «мәскәүский»не таба инде: станциягә бара да тылдан килгән машинистлардан ярты литрны биш йөз тәңкәгә сатып алып та кайта. Моны берничә тапкыр эшләде инде ул...

...Бер көн узды, ике, өч көн узды, ә дүртенче көнне Дурду мине: «Бире килче, сержант, синең белән гәп бар», дип, бер читкә алып китте. Агачлар арасынарак узып, җирдә яткан юан бүрәнә өстенә утырдык. Аягын сузып, чалбар кесәсенә тыгылды бу; әллә «мәскәүский»не чыгара инде, юк, насбай шешәсе икән... Шуннардан уч төбенә бер чеметем насбай кагып төшерде дә сакаллы иягeн күтәреп, тел астына салып та җибәрде. Мәгълүм булганча, армиядә солдатларга насбай бирмиләр, насбайны Дурду үзе ясый. Бөрмәле капчыгында аның каяндыр табып алган бәләкәй генә табасы бар. Менә шул табасында ул чыршы ылысын һәм үзе генә белгән тагын нинди дер үләннәрне бергә бутап көйдерә дә, шуннан насбай сыман кара-яшькелт бер нәрсә килеп чыга. Татарча әйтсәк, ит югында үпкә дә ярый!

Дурду насбаен тәмләп суырып, бер төчкергәч, бик гади генә итеп миңа:

— Сержант, без, аллага тапшырып, латышның бер куен алдык! — диде.

Мин, тиз генә сүз таба алмыйча, беравык аңа сынап карап тордым: шаяртамы бу, әллә чынлап әйтәме? Әмма Дурду эчендәге тантанасын һич тә сиздермичә тыныч кына утыра иде. Ахырда үзем сорарга мәҗбүр булдым:

— Ничек алдыгыз?

— Сатып, сержант, сатып...

— Күпмегә?

— Мин латышка үземнең ике мең тәңкә хәләл акчамны чыгардым да бирдем! — диде бу, байларча гына.

— Хәләл акча!.. Ну ярый, ә куегыз кайда соң?

— Куй иясендә калды әле.

— Нигә, китереп бирмимени? — дидем мин, аңа төрттеребрәк.

— Китереп тә бирер,— диде Дурду, бер дә исе китмичә генә, аннары миңа елыша төште:— Беләсеңме, сержант, без лейтенантка әйтми торып куйны алып кайтырга курыктык. Лейтенантка әйтү кирәктер гой!

— Әйе, аңа әйтмичә ярамый.

Шуннан соң Дурду чибәр йөзенә әлеге сөйкемле елмаюын чыгарып, миңа йомшак кына болай диде:

— Алайса син, чырагым, аңа үзең яхшылап-җайлап кына әйтсәңче.

— Туктале, ни өчен мин?.. Ни өчен син үзең түгел?

— Юк, миннән булмый, миңа ярамый... Син, чырагым, лейтенантка якын торасың, син әйтә беләсең, син грамотный адәм, яхшы атаның баласы...

— Я, я, Дурду әкә, салам кыстырмыйча гына... Куйны сез алгансыз — җавабын да сез бирергә тиешсез... Шулай ул!

— Кодавәндә! — диде Дурду, ачынып.— Лейтенант безне тыңламый гой! Анау Шумиловны тыңлый, чуваш Емелькинны да тыңлый, ә безне юк, тыңламый... Казакъны башкалардан аеру, якын итү була дип курка. Үзең дә беләсең гой!

Әйе, бу дөрес, мин моны белә идем. Һәм чынлап та лейтенантның эшне бозып куюы бик мөмкин иде.

Хикмәт монда нәрсәдә?.. Лейтенант Нугайбәк Кулибаев милләте белән кыргыз, шуңа күрә казакълар аңа бөтенләй үз кеше итеп карыйлар. Армия тормышында исә бу бик ярый торган эш түгел, армия ул ата белән баланы да аерып, һәркайсын үз урынына куя. Ә казакълар менә шуны һич тә аңларга теләмиләр, алар өчен Кулибаев гүя бертуган кече энеләре... Баштарак әле аңа туп-туры исеме белән генә дәшә торганнар иде: Нугайбәк тә Нугайбәк, ә кайчагында үзләренчә назлап, Нугайбәк чырагым да дип җибәрәләр. Билгеле инде, лейтенант моны ишеткән чакта бик уңайсызланып кала, хәтта ачуыннан бүртенеп тә китә торган иде. Хәер, соңрак ул аларны бу кадәр «якын» итүләреннән тыйды:

— Җитәр! Моннан киен «Нугайбәк» дип әйткәнегезне ишетәсе булмыйм. Мин сезгә командир, миңа устав кушканча дәшегез! — диде.

Кыскасы, лейтенант Кулибаев белән казакъ солдатлары арасында, ничек дим, милли якынлыктан туган әнә шундый бер каршылык яшәп килә иде. Бу каршылык күп вакытта үзен сиздерми дә кебек, ләкин кайчагында кискен генә бәреп тә чыга иде.

Менә хәзер нәкъ шундый хәлнең булуы бик мөмкин. Казакъларның аңа әйтмичә куй алып йөрүләрен белсә, ул моны, һичшиксез, үзе белән санлашмау дип караячак һәм кызган баштан бер сүз белән тегеләрнең эшен өзәчәк! Яшь командир өчен куйдан да битәр абруй кыйммәтрәк.

Димәк, Дурдуның ялварып соравына колак салмыйча да булмый. Алларына килергә торган ризыктан аларны мәхрүм итү ярамастыр

инде. Нишлисең, минем кебек сержант кешегә кайчак шулай командир белән солдат арасында буфер хезмәтен дә үтәргә туры килә.

— Ярый, Дурду әкә,— дидем мин, ниһаять,— лейтенант белән сөйләшеп карармын.

— Һай, чырагым, рәхмәт сиңа!..

— ...Тукта, рәхмәтең белән ашыкмый тор әле син... Әйтеп беткәнне көт. Әгәр мин казакълар үзләре өчен куй алалар дип әйтсәм, лейтенант, мөгаен, моңа риза булмас...

— Нигә, ни кылып?.. Безнең хакыбыз юкмыни?.. Без үз акчабызга алабыз гой!

— Хакыгыз бар, мәсьәлә анда түгел... Мәсьәлә менә нәрсәдә: сез, әйтик, биш-алты казакъ, аяк бөкләп, куй ашап утырганда башкалар нишләрләр икән? Иреннәрен ялап торырлармы?

— Ой-бой,— диде Дурду, бик гаҗәпләнеп һәм борчылып.— Син, тамырым, казакъның җоласын белмәйсеңме?.. Казакъ куй суеп, казан асса, берәүне дә өлешсез калдырмый ул... Безгә бер табын корып утыру җитә гой!

Шулай итеп, казакълар мине бу эшкә күндерделәр. Инде мин үз нәүбәтемдә командирны күндерергә тиешмен. Моны эшләп булыр кебек, чөнки лейтенант Кулибаев белән теләсәм нәрсә турында бер дә курыкмыйча сөйләшергә хакым бар, сөйләшә алам һәм үз сүземне үткәрә алуыма да ышанам. Тик аның характерындагы кайбер четерекле нечкә якларны гына истән чыгармаска кирәк. Һәрхәлдә, башта ук аны өркетмәс өчен әзрәк кенә хәйлә кормыйча да булмас.

Бүген лейтенант склад начальнигы белән каядыр китеп, шактый вакыт югалып торды. Кичке разводтан соң землянкага кайтып керсәм, ул да кайткан, итеген, каешын салып, такта тапчанга чалкан сузылган иде.

— Сәлам, лейтенант! — дидем мин,— күп тәпиләгәнсез, ахрысы?

— Булды бераз.

— Кайларда йөрдегез?

— База начальнигында булдык.

— Я, ниләр ишеттегез?

— Хәбәрләр күп,— диде лейтенант, миңа таба, сул ягына борылып.— Әнә бүгенге сводканы алып кайттым, карагыз. Солдатларга да укырсыз.

— Була ул...

— ...Фронт һаман алга тәгәри. Безнең армия дә Литва җиренә кергән икән инде... Шул кызулык белән барсалар, анда Германиянең үз җиренә — Көнчыгыш Пруссиягә дә ерак калмый. Сизәсеңме эшләрне?

— Сизмәгән кайда инде!

— Менә шулай... Чәй эчәсе иде бит, сержант!

— Хәзер булдырырбыз аны, лейтенант! — Мин ишекне ачып кына Акшаловка чәй китерергә куштым.— Алайса, без дә тиздән кузгалабыз?

Лейтенант күтәребрәк җавап бирде:

— Безне тиз генә кузгатмаслар, ахрысы.

— Нишләп?

— Монда, әнә, күрәсең, тау чаклы боеприпас өелеп ята. Аларны хәзер күчереп торырга вакыт та юк, анңары транспорт та җитешми. Барлык автобатларны алга куганнар. Шулай диде подполковник Агеев... Хәзер эшелоннарны да монда бушатмыйча туп-туры передовойга таба куалар. Анда инде яңа кыр склады оештырылган...

— Ә рота кайда?

— Рота да безне күптән узып китკән.

— Без генә койрыкта торып калганбыз икән, кызганыч!

— Хафа булма, сержант, безгә дә чират җитәр. Әллә сугышны шушында бетерербез дип куркасыңмы?

— Юк, анысы өчен курыкмыйм, лейтенант! Ләкин, үзең беләсең, армия алга ыргылган чакта, аңардан бер дә торып каласы килми бит. Аннары бер урында озак яту да туйдырып бетә гой, сезнеңчә әйтсәк... Менә бу хәбәрләрне безнең солдатлар ишеткәч, аларның да кәефләре бозылачак, рухлары төшәчәк. Солдатның бит бөтен хыялы алга бару, бары тик алга бару, шулай түгелме?

— Анысы шулай инде,— диде лейтенант, җиңел генә сулап.

Акшалов безгә калай чәйнек белән чәй кертеп куйды.

— Карале, Акшал,— диде лейтенант аңа,— син ужынга берәр нәрсә таярлыйсыңмы?

— Таярлап ятам, җолдаш лейтенант!

— Нәрсә инде ул?

— Тары боткасы.

— Алай икән. Маең бармы соң?

— Мае эчендә. Концентраттан гой!

Алар сөйләшкән арада мин снаряд ящигыннан гына корылган кечкенә өстәлгә эмаль кружкаларны һәм бөрмәле янчык белән шакмак шикәрне куйдым. Шикәр гадәтенчә бик дымлы иде. Лейтенант торып, ялангач аякларын салындырып, тапчан кырыена утырды. Акшалов чыгып киткәч тә мин беренче кереш сүзсез туп-туры аңа әйттем:

— Беләсеңме, лейтенант, менә бу якын-тирәдәге хуторлардан куй сатып алырга була икән.

— Куй? — диде лейтенант, бал капкандай киң битен бик төче җыерып.— Куй! Булмас ла! Кайдан ишеттең?

— Бүген станциядәге зенитчикларның берсен очраткан идем, шул әйтте. Без бер куй алып суйдык, икенчесен алырга җыенабыз, ди.

— Ышанмыйм, алдаша торгандыр.

— Ә нигә алдашсын ул? Бик гади эш бит бу... Үзегез дә күрәсездер, хуторлар тирәсендә куйлар йөри, хуҗалары, сатмыйча, аларны нишләтсеннәр?

Лейтенант, ышаныргамы-юкмы дигәндәй, дәшмичә, миңа ит баскан кысык күзләре белән бераз карап торды. Әлбәттә, сүзне бик тирәнгә җибәрмәскә һәм бу эшне ничек тә гади генә бер нәрсә итеп күрсәтергә кирәк иде. Иң мөһиме — лейтенантны төрле шикләр кимерә башламасын! Шуңа күрә мин ялгап:

— Аннары без үзебез дә аны белә алабыз бит,— дидем.— Менә мин иртәгә үк якындагы берәр хуторга барып чыгармын, сорашып карармын, әгәр сатулары дөрес икән, берәр куйны җитәкләп алып кайтырга да була.

— Шунда укмы? — диде лейтенант, көләргә итеп.

— Изге эшне китап озакка сузарга кушмаган,— дидем мин дә шаярткан булып.

— Изге эш! Кызык кына сөйлисең әле син, сержант! Ә кем рөхсәт итәр икән безгә андый «изге эшләр» артыннан йөрергә?

— Сезнең рөхсәт җитә, лейтенант! — дидем мин, өзеп. Бу аңа ошарга тиеш иде.

— Ай-һай! — диде ул, шулай да икеләнебрәк.— Миңа бит андый права бирелмәгән.

— Аның каравы, сезгә солдатларның тамак ягын кайгырту правасы бирелгән. Күптән инде аларга суйган ит ашатканыбыз юк. Гел сухой паекта утырабыз. Бер куй алып чалган өчен беркем бер сүз әйтмәс, ә солдатлардан сезгә рәхмәт кенә явар!

Лейтенант чәендәге шикәрен пычак очы белән болгаткан булып, бераз дәшми торды. Аннары сорады:

— Ә акчасын кайдан алабыз? Син шуны уйладыңмы?

— Солдатлардан җыябыз.

— Һе,— дип куйды лейтенант,— барысы да уйланган икән... Сол-

датны үз акчасына ашатабыз, алайса! Армиядә мондый эшнең булганы юк иде әле.

— Ник булмасын,— дидем мин тиз генә, чөнки лейтенантның бу кинаясе хәтәр иде.— Солдат бит үз акчасына кирәк нәрсәсен сатып алырга хаклы. Онытгыгызмыни, безнең солдатлар авылларда торган чакта үз акчаларына сөтен, бәрәңгесен, тәмәкесен дигәндәй сатып алалар иде, беркем дә тыймый иде бит... Ә хәзер салышып алалар, бары шул гына.

— Дипломат булып беткәнсең син, нугай! — диде бу миңа, чәнчеп.— Әллә үзләренә әйттең дәме?

— Юк, нишләп әйтим, сезнең беләң сөйләшмичә торып,— дидем мин, әз генә үпкәләгән булып.

Лейтенант бераз уйга калды. Һаман икеләнә иде шикелле, шайтан алгыры! Ләкин аңа икеләнергә дә, уйланырга да ирек бирмәскә кирәк иде, шуңа күрә мин сүзне тизрәк очлар өчен бик дусларча, әмма житди итеп әйттем үзенә:

— Сез, лейтенант, бу эшне миңа ышанып тапшырыгыз. Сүз бирәм, кирәксә менә ант итәм, мин барысын да бик законлы итеп эшләрмен. Хужа белән дә бик сак кына сөйләшермен, куйны да үз ирке белән сатса гына алырмын, шулай ук солдатларга да бу турыда артык шауламаска кушармын. Я, фатихагызны бирегез, лейтенант!

Ул миңа җитди генә бер сынап карап алды.

— Ә соңыннан берәр чатаклык килеп чыкса, җавабын кем бирер?

— Ай алла, бик кирәксә, җавабын да үзем бирермен. Ләкин эш аңа барып җитмәячәк, лейтенант, ышаныгыз!

— Ну... ярый алайса! — диде ул, ниһаять, һәм кинәт көлеп тә җибәрде.— Куйны, мин әйтәм, гаҗәп сагынгансың икән, ә, сержант?

— Кыргыз миңа караганда да ныграк сагынгандыр әле,— дидем мин, елмаеп кына.

Лейтенант дәшмәде, тик кул сырты белән авызын гына, гүя ихтыярсыздан, сөртеп куйды.

Икенче көнне иртәнге разводтан соң без Дурду белән, ашап-эчеп тә тормыйча, аллага тапшырып дигәндәй, куй хуҗасына киттек. Шлагбаумны узгач та уңга каерылдык, бераз тар сукмак буйлап бардык, аннары икенче пост турысына җитәрәк, Дурду сулга борылып, мине буш кырлар аша, юлсыз-нисез, алда күренгән бер утарга таба алып китте. Урман буйлары чабылмыйча калган куе үлән, ләкин ул саргаеп, кибеп беткән инде, атлаган саен кыштырдап сына, коела һәм аяк астыннан, бөрек бәреп куркыткандай, чикерткәләр сикереп китә. Бераздан урган җир өстенә дә чыктык, йомшак камыл таптап, кызу гына атлыйбыз. Ачык кырга чыккач, әллә ничек сәер булып китте: көз дә килеп җиткән икән ләбаса! Игеннәр урылган, көлтәләр ташылган, кырлар буш, тын ята, бөтен тирә-юньгә сары, моңсу төс кергән... Хәтта үзебезнең урман да моннан ничектер тавыш-өнсез, боек булып күренә икән. Күңел күзе күрмәсә, маңгай күзе — ботак тишеге, диләр. Шул урманда күпме яттык, күпме тапкыр кояш чыкканын каршыладык, күпме кошлар сайравын ишеттек, үләннәрен таптадык, чеккиләреннән таландык, ә менә уй-хыяллар каядыр читтә, еракта булгач, җәй узганын сизми дә калганбыз.

Бер утарны читләтеп уздык, икенчесенә якынлашып киләбез. Дурду әйтә, куй хуҗасы шунда, ди. Без корал-мазар алмыйча гына чыктык, шулай да мин бик шәп трофей пистолетны шинель кесәсенә тыккан идем — белмәссең дөнья хәлен!

Монда утар аралары бик якын — чакрым-чакрым ярым гына булыр. Менә килеп тә җиттек. Утар дигәнебез тип-тигез кырда япа-ялгыз утыр-

ган бер хуҗалык: озынча итеп салынган, дранча түбәле иске генә өй, өйнең үзенә караганда шактый таза, нык каралты-куралар, әмма бернинди капка-коймa дигән нәрсә юк. Дүрт ягы да кыр, тик өйнең кояш чыгышына караган башында гына берничә карт өянке үсеп утыра, ә кыйбла ягында рәшәткәләп алган кечерәк кенә бакчасы күренә. Анда бары тик чәчәкләр генә — төрле төстәге безгә билгесез бик эре, бик купшы, ләкин инде көзнең беренче салкын сулышыннан шиңә башлаган чәчәкләр! Безгә бик тансык тыныч тормыш галәмәте! Тагын нәрсә? Ә, әнә өй белән каралтылар арасында зур тәгәрмәч-чыгырлы коесы да бар икән... Бөтен ихатасында йокымсыраган тынлык һәм, ялкау гына тибенеп йөргән тавыкларны исәпләмәгәндә, бернинди җан иясе барлыгы да сизелми.

Ләкин без якынлашуга, каяндыр эт өргән тавыш ишетелде. Мин туктала калдым — этнең тавышы шактый калын иде. Шул арада кулына сәнәк тотып абзардан чыккан хуҗа үзе дә күренде. Беравык ул безгә, без аңа карашып тордык. Аннары хуҗа безгә якын килмичә генә:

— Курыкмагыз, эт — биктә,— диде.

Моны ишетүгә Дурду ачык тавыш белән кычкырып дәште:

— Ә, хәзәин, исәнме-саумы!.. Менә без килеп тә җиттек.

— Яхшы! — дип кенә куйды хуҗа.

Без аның янына килдек. Мин дә аңа:

— Исәнмесез, хуҗа! — дидем, кулны сузмыйча гына.

Бу — яңакларын кара-җирән каты төк баскан, иллеләр тирәсендәге таза бер ир иде. Өсте-башы да бик хөрти — сәлперәеп төшкән свитер, ямаулы чалбар, тузып беткән галошлар, башында тишек эшләпә. Ул үзе башлап бер сүз дә әйтми, гел көтеп тора, ә саргылт күзләре куе кашлары астыннан салкын-уяу карыйлар.

Сүзне миңа яңадан, әлбәттә, гади-тыныч кына итеп башларга туры килде:

— Өченче көн безнең ике солдат сездә булганнар икән. Берсе — менә шушы казакъ иптәш, танырсыздыр?

Хуҗа таныйм дип башын гына какты. Русчаны начар белә, ахрысы, дип уйлап алдым мин һәм сорадым:

— Сез латыш буласызмы?

— Юк,— диде ул,— без староверлар булабыз.

— Димәк, рус милләтеннән, үзебезнең Россия кешесе?

— Без Россиядән күптән киткәнбез.

Ләкин шуннардан башка өстәп бер сүз дә әйтмәде. Күрәсең, бу хакта да ул артык җәелергә теләми иде. Үтә саклык, нишләтәсең! Шуңа күрә мин төп мәсьәләгә күчәргә булдым.

— Менә иптәшләр кайтып әйттеләр, сез бер сарыгыгызны безгә сатмакчы икәнсез, дөресме?

— Әйе, шулай сөйләшкән идек.

— Билгеле, үзегез теләп сата торгансыздыр инде?

— Аңламыйм,— диде хуҗа, коры гына.

— Минем әйтәсем килә: үзегез теләп сатсагыз гына без алырга риза.

— Мине берәү дә көчләгәне юк. Аннары без килештек бит инде.

Ярый, бу кырыс хуҗа алдында оста дипломат булып булмады, мать якасын!.. Алыш-бирешне тизрәк өзәргә кирәк.

— Алайса сүз бетте,— дидем мин.— Димәк, сарыкны алып китәргә дә була?

— Пожалысты!.. Җитәкләргә бавыгыз бармы соң? — диде ул, Дурдуга карап.

— Бар, бар,— диде Дурду, житез генә.— Куйларың кайда?

— Куйлар абзарда.

— **Түлке, хәзәин, үзем сайлап аламын.**

— Белмим, ничек сайларсыз икән, мин тотып бирмәсәм,— диде хужа, ниһаять, көлемсерәп.

— Әйдә керик әле абзарына!

Өчәүләшеп иркен генә абзар эченә кердек. Сарыклар түр почмакта нидер көткәндәй сагаеп, башларын күтәреп, тик кенә өелешеп торалар иде. Дурду ишекне ябып, аркасы белән шуңа терәлде дә миңа сарыкларны үзенә таба куарга кушты. Ә хужага, сез бер читтә карап кына торыгыз, диде. Мин түр башка узып, «һайт!» дип бер кул гына селтәгән идем, сарыклар өерләре белән кубып, тыпырдашып чабып та киттеләр. Башта барысы да өелешеп, аннары бер-бер артлы тезелешеп, абзарны әйләнеп чабарга тотындылар. Шул чакта Дурду үз алдыннан чабып узган сарыкларны берәм-берәм сыртыннан ике куллап эләктереп ала да күтәреп карый, эләктереп ала да күтәреп карый. Шулай бер биш-алты сарыкны күтәреп карап җибәргәннән соң, бу, ниһаять, берсен кулыннан ычкындырмады: «Безгә менә шушы куй ярый»,— диде һәм кесәсеннән элмәкле бау чыгарып, тиз генә сарыкның муенына да кидерде.

Яктыга чыктык. Сарык чыннан да таза һәм яшь тә күренә иде. Дурду маңгай тирен сөртеп:

— Вәт, хәзәин, безгә насыйбы шушы булыр! — диде.

— Ярый инде,— диде хужа,— ә шулай да сайлый беләсең икән!

Дурду мәгънәле генә итеп тамак кырып куйды, ә мин аның өчен:

— Белмәскә, куйлар арасында аунап үскән казакъ бит ул! — дидем.

— Күрәм, күрәм! — диде хужа, Дурдуның елтыр-шома битенә житди генә карап.

Икебез дә аңа хушлашыр өчен кул бирдек, рәхмәтебезне әйттек, тагы да күрешербез әле дидек. Хужа үзе дә бездән канәгать иде шикелле, һәрхәлдә, йомышыгыз төшсә, пожалысты, килегез дип әйтүне кирәк тапты.

Ә хәзер китәргә дә ярый торгандыр.

— Әйдә, житәклә куеңны,— дидем мин Дурдуга.

— Юк, алай бармый ул,— диде Дурду,— без аны менә болай итәбез.— Һәм чүгәләп, башта сарыкның алгы-арткы аякларыннан тотып алды, аннары башын корсагы астына тыгып, тиз генә жирдән күтәрде. Сарык тыпырчынырга да өлгермәде. Ә Дурду муенына атландырган сарыкны ипли төшәр өчен бер-ике генә селкенде дә кызу гына китеп тә барды. Мин аның артыннан иярдем.

Ихата аша узганда безгә коедан зур тәгәрмәчне әйләндерә-әйләндерә су чыгарып торган унжиде-унсигез яшьлек кенә кыз очрады. Шушы йортның кызыдыр инде ул... Өстенә бер кат ситсы күлмәк кенә кигән бу ялан баш, ялан аяклы кыз гәүдәгә искиткеч зифа-сылу иде. Туры-тыгыз аяклары, батыбрак торган нечкә биле, таррак кына тигезтөз аркасы, ике якка аерылыбрак караган груша сыман түшләре шул кадәр төгәл, камил, килешле иде ки, күрү белән мин ничектер югалып калдым. Әйтерсең күз алдымда бер мәлгә ак мәрмәрдән терелеп килгән жанлы сын пәйда булды, әйтерсең колагыма гажәеп бер нәфис музыка чагылып узды... «Я хода,— дидем мин, тыным кысылып,— чыннан да могжиза тудыра беләсең икән! Әмма ничек ул сакланып калган бу ялгыз утарда? Немец тырнагына ничек эләкмичә калган ул?..» Аннары әкрен генә Дурдуга дәштем:

— Күрдеңме әнә үзен!

Дурду сарык астыннан башын борып, коега таба карады да тирән генә сулап:

— Их, сержант, без әле аны кичә үк күреп шаша яздык! — диде.

— Шулай укмыни?

— Беләсеңме, Акшалов нәрсә диде?

— Я, нәрсә диде?
— Моның кебек ай-сылу очраган чакта башны учлап, җиргә капланасы килә, диде.
— Гаҗәп, нигә ул алай дип әйтә?
— Тәкате беткәнгә күрә, сержант, сагынуы чиктән ашканга күрә! Төшенәсенме?
Әйе, бу хәлне аңларга мөмкин иде. Еллар буенча хатын-кыз җылысыннан, хатын-кыз назыннан мәхрүм солдатның мәхәббәтне үлеп сагынуы, мәхәббәткә сусап тилмерүе гаҗәпмени соң?!.
Ә Дурду унга-сулга карамыйча, бөгелә-сыгыла алдан сыптыра гына. Сыптырмас иде, җилкәсендә теге сарык утыра. Бу инде төшенә генә керүе мөмкин булган хуҗа кызы түгел, бу — көтмәгәндә кулга эләккән чын бер ганимәт — аны тизрәк үзебезгә илтеп җиткерергә кирәк.
— Бик авыр түгелме? — дип сорыйм мин, артыннан чак өлгереп.
— Һе, куйның кандай авырлыгы булсын,— ди Дурду, кычкырып.— Менә миңа алаптай немец мәлгуньне өч чакрым күтәреп кайтырга туры килде, вәт шул чакта, сержант, күзләремнән хәтта тир бәреп чыкты.
Мин моны аңардан беренче тапкыр ишетә идем.
— Кайчан, нинди немецны?
— Күптән. Передовойда чакта... Бик кадерле немец иде ул, сержант! Без аны оясыннан барып алдык.
— Аңлап җитмим әле мин сине, Дурду!
— Ну «телне» беләсең гой!.. Менә без, төнлә барып, бер «тел»не каптырдык... Ычкынып кача башлагач, старшина немецның аягына атты, ну шуннан киен, хош ни хош, миңа аны аркама атландырырга туры килде... Астында калып үләм дип торам!.. Ә бу куйны, чырагымны, без йөгертеп кенә алып кайтабыз!
Солдат хәтерендә ниләр генә сакланмый, дип уйладым мин, һич көтмәгәндә менә шулай килә дә чыга. Ә сөйләнми калганы күпмедер әле аның?!.
Дурду исә «йөгертеп кенә» илтә торгач, үзебезнең «лагерьга» китереп тә җиткерде. Шунда ук землянкадан казакълар чыктылар, сарыкны сырып та алдылар. Барысы берьюлы шауларга, сөйләнергә тотындылар: «Сөбеханалла!» диләр, «Куй яман имәс гой!» диләр, әле түшеннән, әле янбашыннан тотып-тотып, басып-басып карыйлар. Әйтерсең алланың күктән иңгән кашка тәкәсе бу — шулкадәр сокланырлар һәм куанырлар икән...
Шул арада безнең янга лейтенант Кулибаев та килеп җитте. Сарыкны күргәч, ул да киң бите белән җәелеп елмайды.
— Кара, алып та кайткансыз икән... Ә мин ышанмыйчарак торган идем.
— Нигә, кулдан ычкынып китәр дип уйлаган идегезме әллә? — диде Дурду, көлеп.
— Юк, синең кулдан ычкынмый инде ул, бер эләккәч... Хуҗасы сатмас дип уйлаган идем.
— Сатты, лейтенант, бик куанып сатты! Адәм баласы акчага барысын да — малын да, хәтта кызын да сата гой, әйтик, безнең казакъта...
Казакълар дәррәү генә көлешеп алдылар.
— Күпме түләдегез? — диде лейтенант, миңа карап.
— Акчасын әнә Дурду түләде,— дидем мин, турысын гына әйтергә кыймыйча.
Дурду шунда ук миңа ялгап:
— Сорама да инде, лейтенант, сорама да! — диде хәйләкәр генә.— Кыйбат булмады бу хайван, чучка баласыннан да арзанга килде. Ризыкка яза күрсен!.. Инде син, лейтенант, безгә шуны әйт: кайчанрак моны, аллага тапшырып, читәрбез, чалырбыз икән?

— Бүгеннән дә калдырмагыз,— диде лейтенант, борчыла башлагандай.— Ят адәмнәр күргәнче эшен бетерергә кирәк.

— Бик хуп, лейтенант! Без үзебез дә шулай уйлаган идек. Алайса, тапшырдык?

— Давай, башлагыз!.. Ә син, сержант, бөтенесенә күз-колак бул! Җавапкәрлек синең өстә.

— Яхшы! — дидем мин, теләр-теләмәс кенә: тагын нинди «җавапкәрлек» кирәктер инде аңа.

Лейтенант китеп барды, ә казакълар дәррәү генә эшкә дә тотындылар. Өметбай пычак кайрарга утырды. Акшалов савыт-сабаларын әзерли башлады, Шанаев белән Жантимеров урман эчендәге коега суга киттеләр. Байәхмәтов балта алып, таган асар өчен җәпле агачлар кисәргә тотынды. Ә Дурду исә иң зур эшне үтәгән кеше буларак, бу вак-төяк эшләргә катнашмыйча, бер түмгәк өстенә чүгеп, насбаен тел астына салып, шуңардан би хуш булып, дәм алып кына утырды. Мин дә шул арада землянкага кереп, әзрәк тамак ялгап чыгарга булдым.

Ә бераздан Дурду, Өметбай, Шанаев пычак-бауларын алып, сарыкны муеныннан сөйрәп, землянкадан читкәрәк, агачлар арасына кереп киттеләр. Мин инде алар артыннан иярмәдем. Бу казакъларның үз эшләре, миңа анда булуның һич тә кирәге юк иде. Гомумән, бу тирәдән минем нигәдер китеп торасым килде. Күз-колак булуның да һич хаҗәтен күрмим — барысын да үзләре бик әйбәт башкарып чыгарлар әле. Шуңа күрә постларны бер тикшереп, йөреп кайтырга булдым. Тик китәр алдыннан Акшаловка шуны гына әйтеп китәсем килде:

— Хафиз, син дневальный кеше, икенче сменаны да онытма. Аларга дигән өлешне баштан ук алып куй, ярыймы?

— Ярый, ярый, юлдаш сержант, хафа булмагыз, барысын да үзем эшләрмен.

— Ә мин постларны йөреп кайтам әле, лейтенант сораса, әйтерсең.

— Әйтермен... Тик нигә китәсез әле? Менә хәзер таганда чәй кайнатам, учак янында чәй тәмле була, чәй эчеп китәрсез!

— Кайткач, Хафиз! — дидем мин һәм землянканың ишек яңагына элгән автоматымны алдым да үз юлым белән китеп бардым.

Иң элек Шумилов янында тукталырга булдым. Аның посты җанлы урын, хәзер дә әле үтеп-сүтеп йөрүчеләр, килгән-киткән машиналар булгалый, кайчагында берәр якташ та шунда очрап куйгалый. Һәрхәлдә, күп кенә яңа хәбәрләрне без шул шлагбаум яныннан ишетеп кайтабыз.

Очрашу дигәннән, бер кызыклы хәл искә төште әле.

Килгән көннәрдә шушы шлагбаум янында мин бер Җаек татарын очраткан идем. Бу озын гына, арык кына бер агай иде. Сөйләшеп киттек. (Җаек белән Татарстан арасы шактый ерак булса да, без инде барыбер якташлар!) Ул миңа сер итеп кенә шуны әйтте:

— Менә әле, туган, госпитальдән качып, үземнең чәсне эзләп барам. Монда боеприпаслар төяп чыккан машиналарны көтеп торуым әле,— бер шофер үзе янына утыртмакчы булган иде. Азык та юк, тамак та ач — бедa, парин!

— Ә нигә качтың соң?

— Түзеп булмады, туган, эч пошуга түзеп булмады!

— Ә тотылсаң?

— Тотылсам ни булыр? Мин бит тылга түгел, передовойга качып барам. Тотсалар да барыбер шунда җибәрерләр — башка юлы юк аның!

— Дөрес чамалыйсың,— мин әйтәм,— соң анда, передовойда, әйбәтрәкмени?

— Ничек дип әйтергә?.. Булмаган кеше өчен — коточкыч, ә булган кеше өчен — ничава, әкренләп ияләшәсең... Мин инде биш тапкыр су-

гышка кердем, ә соңгысында бер ай буена передовойдан чыкмадым. Әллә нихәтле кеше үлеп бетте, парин, әллә күпме пополнение килде, ә мин, ичмасам, бер генә тапкыр да ранен булмадым. Пулялар ышкылып-ышкылып уздылар, ну тешләмәделәр ничектер... Алла саклады... Тик минем эчтә язве бар, хәерсез, шул каһәрдән кан килә башлагач, мине көчләп дигәндәй госпитальгә җибәрделәр. Әмма, туган, мин андагы сасыга, андагы ыңгырашуларга түзә алмадым, тоттым да качтым менә!..

— Ә иленә кайтасың килмиме соң?

— Килмәгәннәр кайда инде ул, туган! — ди агай, өзелеп сулап.— Очып кына кайтыр идем дә бит, булмый шул! Мина, туган, икесенең берсе: я илгә, я передовойга... Ату йөрәкнең януына түзәр хәл юк!

Мин аны землянкага алып кайтып, калган ботка белән сыйладым, кулына да бераз икмәк бирдем. Агай бик канәгать булды. Ә озата чыккач, үзенә: «Бу юлы да пулялар тешләми генә узсыннар инде», дидем. «Иншалла!» диде ул, гади генә итеп. Агай үзенең исән-имин калуына бик ышанып китте бугай.

Монын кебек һич уйламаган-көтмәгән кыска гына очрашып аерылышулар фронт шартларында солдат кешесе өчен бик табигый хәл. Ләкин бик күбесе онытыла икән. Бары аерым кеше үзе (әгәр аның кайсыдыр ягы күңелгә ошап калса) яки ул сөйләгән берәр кызыклы вакыйга гына ничектер әле хәтердә сакланып тора. Әмма күбесе онытылса да, көтелмәгән очрашу һәрвакытта ниндидер бер эз калдырып китә. Чөнки һәр солдатның күргән-белгәне үзе бер дөнья, шуның өстенә, әле аның бөтенесенә үз карашы, үз аңлатмасы, үз фәлсәфәсе дә була. Боларны син бер газетадан, бер китаптан да таба алмыйсың.

Бүген дә менә, әлеге куй белән әвәрә килеп йөргәннән соң, нигәдер шундый бер очрашу табасы килеп китте. Яңа кеше күрү, яңа сүз ишетү кайчагында бик кирәк була. Ләкин урман эче буш, сукмакларда һичкем күренми, штабельләр ягыннан бер генә машина тавышы да ишетелми, тик мәһабәт-биек, шәрә наратларның чатыр ябалдашлары гына салмак селкенеп, үзенең ямансу-тоньк гүләвен урман өстеннән каядыр еракка ашыкмыйча гына куалый. Ахрысы, кызык бетте безгә монда да...

Мин килгәндә Шумилов шлагбаум киртәсенә күкрәге белән терәлеп, юл буена тик кенә карап тора иде.

— Нихәл, Шумилов, кемне көтәсең?

— Ә, сержант,— диде ул, әкрен генә урыныннан кузгалып.— Кемне көтим, кем килсен безгә? Аякларга бераз җиңелрәк булсын дип кенә шлагбаумга таянып торуым... Вакыт күпме әле?

— Вакытмы? — Мин сәгатемә карап алдым.— Унынчы ярты.

— Шулай гынамыни!.. Күп торасы бар икән әле... Ник, мин әйтәм, бу вакытны теләгән чакта тизләтеп яки әкренәйтеп булмый икән, ә?!.

— Вакыт — рәхимсез нәрсә. Аның йөрешен үзгәртерлек кодрәт юк дөньяда. Тик шулай да без аны төрлечә тоябыз: кайчакта үткәнен сизми дә калабыз, ә кайчакта үткәрә алмыйча җаныбыз чыга... Шулай түгелме?

— Анысы шулай инде... Менә машиналар өзлексез килеп торган чакта алты сәгать вакыт ничектер тизрәк үтеп китә торган иде. Ә хәзер юк, барысы да тукталды.

— Бүген килүчеләр бер дә булмадымыни?

— Кайсыдыр станциядән зенитчиклар гына килеп, ике машина төяп киттеләр.

— Аз икән шул. Я, ни сөйлиләр, берәр яңа хәбәр ишетеп калмадыңмы үзләреннән?

— Ә нәрсә ишетәсең алардан? — диде Шумилов, кулын селтәп.— Көне-төне күккә карап яталар шунда... Ә күк йөзе чип-чиста хәзер,

немец адашып кына да килеп чыкмый, ичмасам. Койрыгын тәмам кысты, мин әйтәм...

— Вакыттыр инде, житәрлек котырынды.

— Вакыт, вакыт, бик вакыт! — диде Шумилов, бу сүзгә тагы да зуррак мәгънә салып.— Да, зенитчикларның шоферы шуны сөйләп торды әле: немецлар, имеш, Балтик диңгезенең ниндидер ярыматавында тупланып, ныгып алганнар, имеш. Шунда хәзер бик каты сугышлар бара ди, ник дисәң, безнең мондагы тыл өчен бик куркыныч икән алар.

— Нинди ярыматау соң ул, сорамадыңмы?

— Курляндия диде шикелле. Әйе, Курляндия!.. Син, сержант, шуны әйт әле, дөресме икән бу, сводкада берәр сүз бармы ул турыда?

— Белмим, тулы сводканы күптән инде күргән дә, ишеткән дә юк.

— Рота да безне онытты,— диде Шумилов та, күңелсезләнеп.— Нишләп ятабыз соң без монда, кайчан кузгалабыз инде?

— Алдан әйтмиләр бит аны,— дидем мин,— вакыты житкәч, капыл гына кубып китәрбез әле, гадәттәгечә... Ярый, Шумилов, мин киттем, тыныч кына көт сменаңны...

— Көтәбез инде, көтәбез! Без көтәргә өйрәнгән,— дип калды Шумилов, арлы-бирле йөренеп.

Шуннан мин өченче постка, Төхфәт абзый янына киттем. Төхфәт абзый миңа якташ дидем шикелле — Баулы тирәсеннән ул. Монда татарлардан без икәү генә, ә шулай да безгә эчләрне бушатканчы иркенләп сөйләшергә бик сирәк туры килә. Төхфәт абзый алты сәгать постта торып кайта да, ашап-эчеп, тизрәк ял итәргә ята. Аннары тагын постка барыр вакыты житә. Мин дә төрле мәшәкатьтән, арлы-бирле чабудан бушый алмыйм. Шулай итеп, бер тәгәрмәчнең ике теше кебек янәшә әйләнәбез дә әйләнәбез. Әмма шуңа карамастан, без барыбер эчке бер якынлык белән якташ булуыбызны гел генә тоеп яшибез.

Баштарак Төхфәт абзый казакълар белән бер сменада иде. Казакълар аңа атлаган саен «нугай» диләр. Төхфәт абзый әллә белмичә, әллә белмәмешкә салынып:

— Ә кем ул нугай? — дип сорый.

— Кем булсын, син гой! — диләр ана.

— Юк, мин нугай түгел, мин саф татар,— ди Төхфәт абзый, күкрәк сугып.

Тегеләр көләләр генә:

— Без татарны белмәймез, без нугайны гына беләмез!

Кайчагында шул юк кына нәрсәдән чак талашып китмиләр иде. Соңыннан бер авыз русча белмәгән Ишмәмәтне казакълар янына күчереп, аның урынына Төхфәт абзыйны куярга туры килде. Хәзер бу сменада рус, чуваш, татар — үзенә күрә кечкенә генә бер интернационал. Төхфәт абзый аеруча чуваш Емелькин белән дуслашып китте — серләре килеште, күрәсең.

Өченче пост бәләкәй генә бер калкулык өстендә тора. Өч ягы урман, каршы якта — ачык кыр. Төхфәт абзый шул калкулык түбәсендә әйләнеп йөри-йөри үзенә түп-түгәрәк бер сукмак салып бетергән. Мин килгәндә дә шунда әкрен генә әйләнеп йөри иде.

— Төхфәт абзый, бу мин әле,— дидем, аңа якынлашып.

— Әйдүк, туган, рәхим ит! — диде ул, өенә чакыргандай бик ачык кына.

— Кәефләр ничек соң?

— Кәефләр шәп!

— Шулай укмыни?

— Көнен кара син, көнен! Атланмай кебек бит. Жылы, тымызык, пәрәвезләр оча, әбиләр жәе инде бу...

Бүген көн чынлап та гаҗәеп хозур иде. Күктә бер болыт әсәре юк, кояш үзе генә бик иркенләп, җәйгечә юмартланып кыздыра, каяндыр тагын әкрен генә иркә-йомшак җил дә искәләп куя — кыскасы, бу якларда, мондый вакытта бик сирәк була торган көннәрнең берсе иде.

— Әле, туган,— диде Төхфәт абзый, нигәдер үзеннән-үзе җанланып,— эзли торгач, мин малай чакта атай мәрхүмнең җырлый торган бер көен тәки таптым бит. Күптән эзли идем инде мин аны... Ни хикмәттер, ул көйне хәзер җырламыйлар да, уйнамыйлар да. Белүче юк, ахрысы... «Агач башы» дип атала. Җырлап күрсәтимме?

Аның бу көтелмәгән сәер куанычына мин бераз гаҗәпләнә калдым. Юри генә:

— Постта җырларга ярыймы соң? — дигән булдым.

— Сез рөхсәт итсәгез, ярый торгандыр.

— Хәйләкәр үзең дә!.. Җырла инде, алайса.

Төхфәт абзыйның тавышы көр, матур гына иде. Ул мылтыгына таянып, аз гына тынып торганнан соң, бер тамак кырып алды да каядыр югары карап, тавышын тыя төшеп җырлап та җибәрде:

Агач башкайлары тәсбих әйтә,
Әкрен искән җил белән.
Сәвешеп-сәвешеп тә кауша алмаган
Бер без генә түгел, ил белән.

Җырның соңгы ике юлын бик хисләнеп, сузып-тибрәтеп бетерде дә аннары бәхетле елмаеп:

— Я, ничек соң, малыкаем! — диде.

— Әйбәт, бик әйбәт! — дидем мин дә әсәрләнеп.

Юк, чыннан да, бу бер дә ишетелмәгән бик матур көй иде. Үзе бик борынгы да булса кирәк. «Агач башы» ... «Агач башкайлары тәсбих әйтә...» Гаҗәп, кешенең күңел хәзинәсеннән ниләр генә табылмый! Җитмәсә, менә монда, туган илдән ерак чит-ят җирләрдә!.. Хәер, язмыш кешене кайларга гына ташламасын, күкрәгендә шул бер үк йөрәкне йөртә инде ул...

Тик Төхфәт абзыйдан бер нәрсәне сорыйсым килде:

— Ник син «сәвешеп... сәвешеп» дип җырлыйсың, мишәр түгел ич син!

— Шулай тәмлерәк чыга ул,— диде Төхфәт абзый.— Атай мәрхүм дә шулайрак җырлый иде. Нигәдер ялгыз чакта үзе өчен генә җырлый иде ул аны, күрәсең, бәгыренә төшкән җыру булгандыр инде... Ә мин бәләкәй ул чакта, бер нәрсә аңлый да, уйлый да белмәгәнмен, ә шулай да күңелнең әллә кай җирендә генә сакланып яткан бит әле. Табылды, ходаның хикмәте!

— Тагын югалта күрмә инде.

— Юк, кайда ул югалту! Мин аны, туган, башлар исән булса, илгә алып кайтам әле, авылыбызга... Мәҗлесләрдә җырлыйм әле мин аны, алла бирсә, фашисттан тере калган җыр итеп...

— Амин диген!

— Амин алайса, амин!

Бу сөйләшүдән соң мин инде башка нәрсәләр (әйтик, безне туйдырып бетергән каравыл хезмәте) турында сүз кузгатып тормыйча, Төхфәт абзыйны үзенең бәхетле табышы һәм күтәренке кәефе белән генә калдырып китәргә булдым. Тагын бер постка сугылып, тизрәк үзебезнекеләр янына ашыктым — анда ниләр бар икән?

Кайтсам — тамаша! Казакъ агайлар, әйтергә кирәк, эшне бик кызу тотканнар. Землянкадан бер читтә зур гына таган ясап, астына ут ягып җибәргәннәр, шул таганга аскан ике чиләктә куй ите богыр-богыр кайнап, инде пешеп тә ята!.. Тагын иң гаҗәбе шул — учактан ерак

түгел чиста үлән өстенә плащ-палаткалар җәеп әзерләгән табын әйләнәсендә Өметбаев, Байәхмәтов, Шанаев кебек картрак казакълар аяк бөкләп, ашыкмыйча вәкарь белән генә үзара сөйләшеп утыралар, ә учак тирәсендә — кем диегез? — безнең лейтенант белән Акшалов тирләп-пешеп булашалар. (Лейтенант каешын салып ташлаган, изүен чишкән, җиңнәрен сызганган, күренә — бик дәртләнеп эшкә тотынган.) Монда хәзер чин, дәрәҗә дигән нәрсә беткән. Тегеләре өлкәннәр сыйфатында, кунак шикелле, табынга ит килгәнне көтәләр, ә болары яшь булганга күрә дә алар алдына барысын да пешереп-төшереп китерергә тиешләр. Гаҗәп икән ул традиция дигән нәрсә! Башка чакта безнең лейтенант — үзенең шул кечкенә званиесенә дә зур әһәмият биреп, солдатлардан өстен торырга яраткан кеше — хәзер исә бөтенесен онытып, гади бер кыргыз егетенә әверелеп, шул ук солдатларга чын ихластан бик бирелеп хезмәт күрсәтә. Ә мин, җүләр, аны бүген куй тирәсеннән читтәрәк йөрер дип уйлаган идем.

Табындагы казакълар мине дә, күрү белән, үз яннарына чакыра башладылар:

— Ә, сержант, кил, утыр безнең янга!

Ләкин мин утырырга ашыкмадым. Бердән, аларга караганда мин дә бит әле шактый яшь кеше — өлкәннәр рәтеннән аяк бөкләп, ит килгәнне көтеп утыру килешмәс, йолага сыеп бетмәс дип уйладым. Икенчедән, ничектер лейтенанттан да яхшы түгел иде — казакъларның чин, дәрәҗәне онытып торырга хаклары булса да, мин сержант башым белән онытырга тиешме?.. Әмма казакълар чын ихластан кыстыйлар: кил, утыр да утыр! Бүген син табынның хуҗасы! — диләр. Бигрәк тә Дурду, җиргә учы белән суга-суга, үз янына чакыра:

— Килсәнче, кил!.. Бүген синең белән миңа түрдә утыру хәләл гой!.. Законный...

Ахырда лейтенант та әйтеп куйды:

— Утыр, сержант! Казакъның әңгәмәсен тыңла, сиңа бүтән эш юк монда.

Билгеле, мин, артык кыстатмыйча, рәхмәтне әйтеп кенә Дурду янына урнаштым. Башта аякларны бөкләп утырган булдым, ләкин буыннар күптән катып беткәннәр икән инде, тизрәк кырын утырып, «тәртәләрне» читкә сузып җибәрергә туры килде.

Казакъ агайларның әңгәмәсе бүленеп торган икән, мин утыргач та яңадан шуңа күчтеләр. Сүз ашау мәсьәләсе турында барган, ахрысы.

— Я, сөйләп бетер, Дурду! — диде Шанаев.— Ризык хакында нидер әйтмәкче иден...

— Ә, ийе,— диде Дурду, селкенгәләп.— Кай төштә бүленеп калдык әле?..

— Госпиталь дип башлаган идең гой!

— Тугры... Менә шул, бу ротага килгәнче, мин бераз вакыт үзем яткан полевой госпитальдә эшләп алдым. Зур гына бер рус авылында торабыз. Көн дә передовойдан атларда, машиналарда яралыларны китерәләр, без шуларны носилка белән өйләргә ташыйбыз... Авыр эш димәс идем, әмма җанга бик тия торган эш. Аннан-моннан гына марля ураган, кан саркып торган нинди генә яралыларны күрмисең анда!.. Күбесен алып керү белән өстәлгә салабыз. Докторлар, кассапчыдай, кулларыннан пычакларын төшермичә, ярып-кисеп кенә торалар... Каннан, үле истән тамакка тәмам ризык үтмәс булды, бушаган арада бары кайнар чәй генә эчәбез... Ләкин бер көнне шулай яралылар килгәч, уң аягы тездән түбәнрәк өзелгән бер солдатны носилкасы белән машинадан төшердек... Һушында бу, ыңгырашмый да, җитмәсә, әкрен генә нидер кимерә. Карасам — сухари! Кемдер моңа сухари тоттырган, бу бичара шуны кан эчендә кимереп җатыр!.. Күреп исләрем китте. Әстәгъфирулла, бу ни тамаша, мин әйтәм!.. Шул чакта адәм баласы

өчен тамакның никадәр яман нәрсә булуына тагын бер мәртәбә иман китердем гой!

Казакълар гаҗәпләнеп баш кактылар, аннары Дурду белән килешеп, дөрес шул, тамак яман нәрсә, ач тамак барысын да, хәтта өзелгән аякны да оныттыра диештеләр.

Гомумән, солдатның моның ише искә төшереп сөйләр әкәмәт нәрсәләре күп була. Ышанырлыгы да, ышанмаслыгы да... Тик шулай да карт солдатлар артык тузга язмаганын тыңларга яратмыйлар, күбрәк гыйбрәтлесен генә тыңлыйлар. Менә Шанаев та башыннан кичкән бер хәлне сөйләгән булды. Имештер, ул кышкы төндә, кайдадыр бер урман авызында постта торган чакта, әрле-бирле йөри торгач, аяклары арып бер бүрәнәгә ял итәргә утырган булган. Яктыра төшкәч, утырган «бүрәнәсенә» караса, ни күрсен, ул туңып каткан немец гәүдәсе, имеш!

— Вай-вай, атаңа нәләт! — ди Шанаев, шул чактагы куркуын, янәсе, исенә төшереп.— Тәннәрем эсселе-суыклы булып, арка буйларым кымырҗып китте гой!

Ләкин аның бу әкиятенә берәүнең дә исе китмәде, көлүче дә булмады,— колак төпләреннән генә уздырдылар. Ышанмаудан түгел, мондый нәрсәнең булуы бик мөмкин, тик мәгънәсе юк, мәгънәсе булмагач, кирәге дә юк. Аннары, дөресен генә әйткәндә, алар Шанаевның еш кына борчак сибәргә яратуын да беләләр иде.

Әмма безнең казакъларның иң яраткан эшләре — күргән төшләрен сөйләү һәм шуны юрау... Әйтерсең һәркайсы төш күрер өчен генә ятып йоклый һәм уянгач та хикмәтле төшен бик тәмләп, бик тәфсилләп иптәшләренә сөйли. Тыңлаган чакта, бу төшме икән, әллә үзе уйлап чыгарган берәр әкиятме диеп тә аптырыйсың. Чөнки бик тә инде җөе җөйгә килеп торган гаҗәп төгәл, бөтен бер вакыйга булып чыга. Андый төшне бик рәхәтләнеп тыңлыйлар һәм җыйнаулашып юрыйлар. Билгеле инде, бары тик яхшыга.

Шулай да араларында төшнең төрлесен күреп тә, сөйләп тә иң остарганы — Байәхмәтов. Әйткәнемчә, бу гәүдәгә зур-таза, мәһабәт казакъ иде. (Менгәндә, атның билен сыгып төшергәндер.) Бөтен җире эре аның — башы, бите, аяклары, куллары... Хәрәкәтләре салмак, тавышы да көр-калын... Нигәдер ул миңа токымы белән казакъның борынгы аксөяк түрәләренә яки ыруг башлыкларына барып тоташкан, хәзер инде бик сирәк очрый торган, санаулыга гына калган бер кеше булып тоела иде. Шуңа күрә аны саклыйсы да килә. Бездәге нестроевойларны карап үткәргән бер комиссия вакытында врач та аңа көлеп:

— Син, агай, бу бүсереңне күз алмасыдай сакла, кайтсаң, шуның аркасында гына иленә исән-сау кайтырсың,— дигән иде.

Әлбәттә, ул казакъның түгәрәк табыннарында күп утырган, легендаларны күп ишеткән, думбыра чиертеп әйткән үләңнәрне күп тыңлаган булырга тиеш. Шуңадыр, ахры, аны бик яратып тыңлыйлар. Ул инде төшендә Сталинны да берничә тапкыр күрде, Рузвельтны да күрде, хәтта Гитлерны күрүдән дә куркып тормады. Ә аларны төштә күрүнең хикмәте бик зур икән: сугышның кайчанрак бетүен яки тагын күпмегә сузылуын аеруча шуларның төшкә ничегрәк керүләренә карап юрыйлар.

Менә хәзер дә ул үткән төнне генә күргән төшен сөйләргә җыенды. Көр генә итеп бер тамак кырып куйды. Башкалар шунда ук тынып калдылар.

— Төшем озын имәс,— диде Байәхмәтов, салмак кына сүзен башлап,— әмма хикмәтле булса кирәк. Шулай, бик күп халык кызыл эшелонга төялеп, үземезнең казакъ даласы буйлап китеп бара-җатырмыз икән. Яз башы, дала ямь-яшел, бихисап куйлар, җылкылар утлап йөри икән. Шул гаҗәеп тә хозур, сәйран сахраны тамаша кылып барганда, кинәт вагоннарымыз дөбер-шатыр сикерешергә, уңга-сулга яман чайка-

лырга тотынды гой! Бу ни булды дип ишектән сузылып карасак, эшелонымыз шпаллар өстеннән генә китеп бара-жатыр икән. Төшенәсезме, рельслар жук, шпаллар гына! Шул шпалларны вата-сындыра, мәтәлә-кадала, эшелон алга ыргыла гой! Туктау уенда да жук җен органның! Бөтенебез идәнгә тәгәрәшеп беттек, сикереп төшәр мәҗәл дә жук, менә-менә хәзер вагоннар авып, бер-берсе өстенә өелеп, барымыз да һәлак буламыз гой, дип үкереп-бакырып ятамыз. Шуннан киен күпмедер вакыт узгач, вагоннарымыз, кодайның кирәмәте, чайкалмый башлады. Сикереп тордык, ишеккә жабырылдык, карыймыз — ярабби, эшелонымыз яңадан рельслы юлга чыккан, шома гына, җилдереп кенә китеп бара-жатыр икән!.. Я куандык, я куандык, шатлыгыннан хәтта жылаучылар да булды. Яңадан үземезнең сәйран казакъ даласын, шунда утлап йөргән бихисап малларны тамаша кылып, хәйран булып барамыз икән. Аннан киен, озакламый эшелонымыз ак таштан салынган бик матур, бик мәһабәт бер станция алдына килеп туктады. Мәйданда ул халык, ул халык! — дингездәй чайкалып тора. Бәйләм-бәйләм гөлләр тоткан казакъ кызлары, балаларын кулларына күтәргән казакъ әлләре безне каршы алырга килгәннәр икән! Барымыз да вагоннардан шаулашып төшә башладык, шул чакта мин дә... уянып киттем. Әлемне бик күрәсем килгән иде, яңадан күземне җомып та карадым, лікин, жук шул, күреп булмады... я, ни диярсез?

Қазакълар барысы беравыздан:

— Яхшы төш бу, яхшы төш! — диделәр куанышып.

Дөрестән дә, Байәхмәтов күргән (әллә уйлап чыгарган) бу төшнең «хикмәте» бик өстә ята иде. Вагоннар аумаган, кешеләр исән калган, һәм эшелон ак таштан салынган станциягә дә барып җиткән. Билгеле инде, моның шунда ук тиздән сугыш бетүгә, барысының да исән-аман илгә кайтуларына юрадылар. Өметбаев белән Шанаев исә кулларын күтәреп:

— Амин, шулай булсын! — дип дога да кылдылар.

Байәхмәтовның башка вакытта күргән төшләре катлаулырак та, кызыграк та була торган иде. (Тик аның шуны казакъча гаҗәп бай тел һәм казахча интонация белән сөйләвен генә биреп бетерүе мөмкин түгел, хәерсез!) Бу юлы аңа төшнең шәбрәген «күрергә» нидер (мәсәлән, учак тирәсеннән килгән искиткеч тансык, тәмле ис) комачаулады булса кирәк.

Ул арада куй да пешеп чыкты шикелле... Акшалов котелокта жылытылган суны китереп, үзе чамалап кына коя-коя, барыбызның да утырган җирдә генә кулларын юдырып чыкты. Ә лейтенант һәркайсыбызга кул сөртергә иңендәге тастымал очын биреп торды. Бу да казакъның өлкәннәргә хөрмәт йөзеннән эшләнә торган бер әйбәт йоласы икән.

— Дурду әкә,— диде лейтенант,— инде син куйны бер күреп баксаңчы! Алсак та буламы?

Дурду торып учак янына барды да чиләктәге итне пычак очы белән чәнчеп-чәнчеп карады.

— Булган гой! — диде ул, ләкин шулай да чиләкне утлы күмер кызуында әзрәк кенә тотарга кушты. Ит тәмам йомшарып, сөягеннән аерылырлык булырга тиеш икән әле.

Инде сүз дә бетте. Көтәбез. Тантана башланганны көткән шикелле сабыр гына көтәбез. Һәркемнең алдында пычагы белән кружкасы. Ләкин берәү дә кашыгын чыгармаган. Шулай ук табында икмәк тә юк. Бусы мине бераз борчый: ашавын, казакълардан күрмәли, кашыксыз да ашап булыр, ә менә икмәксез ничек ашарга? Мин үзем итне түгел, ботканы да икмәксез ашый белмим.

Акшалов бик әйбәтләп юган бер ящик капкачын китереп, Өметбай алдынарак куйды. Итне шуңа бушатырсыз, диде. Бездә, билгеле, зур

табаклар да, тәлинкәләр дә юк. Котелок, кашык, кружка — менә безнең бөтен сервизыбыз шул.

Кинәт Дурду Ишмәмәтне исенә төшерде:

— Ишмәмәт кайда, нигә Ишмәмәт жук?

— Йоклап ятыр,— диде Акшалов,— уяттым, хәзер килер.

Акшаловның әйтүе булды — землянкадан шинелен иңбашына салып Ишмәмәт үзе дә килеп чыкты. Ашыкмыйча гына табын янына килде, казакъларга сәлам бирде һәм минем яныма аякларын бөкләп, бөрешеп кенә утырды.

— Син нәрсә, экә жан,— диде Дурду аңа,— казакъларны санга сукмыйсыңмы әллә?..

— Нигә алай дисең?

— Дәстерханга чыкмыйча йоклап ятасың гой!

— Тугры әйтмисең, Дурду! — диде Ишмәмәт, сабыр гына.— Син, миһербанлы адәм булсаң, иң әүвәл минем хәлемне сорап белең.

— Хуш, ни булды соң сиңа, экә жан? — диде Дурду, шунда ук юмаланып.

Ишмәмәт бераз дәшми торды. Аннары ничектер сабыйларча гына:

— Өшим,— дип куйды.— Бизгәгем кузгалып тора, жылынмаммы дип яткан идем.

— Алайса, без хәзер сине терелтәбез. Аракы эчәсеңме?

— Юк, мин аракы эчмим.

— Жәл,— дигән булды Дурду.— Аракыдан да шәп дару жуктыр, экә жан!

Шунда Байәхмәт сүзгә кушылды:

— Без хәзер аңа кайнар куй шулпасы салып бирербез. Шуны эчкәч тә жылынып китәр.

— Рәхмәт, кардәш!..— диде Ишмәмәт, башын Байәхмәткә таба бөгеп.— Яхшы сүз — жан азыгы, бүтән дару миңа кирәк тә имәс!

Ниһаять, ике чиләкне дә таганнан алып, табынга китерделәр. Чиләкләр янына зур кастрюльне дә китереп куйдылар.

Лейтенант, Өметбайга карап:

— Ата, сез хужа булыгыз инде,— диде.

— Нимә өчен мин? — диде Өметбай, гаҗәпләнгән булып.— Янымызда өлкән адәм Байәхмәт тә бар, аңа тапшырыйк.

Ләкин табындагылар барысы беравыздан:

— Юк, ата, арабызда иң өлкәне син, әйдә башла! — диделәр.

Шуннан соң Өметбай чиләкне үзалдына тартыбрак куйды, жиңнәрен кайтара төште, аннары бик әйбәтләп бисмилласын әйтте дә, пычак белән генә кадап, чиләктән зур-зур ит кисәкләрен чыгара башлады.

Шуны әйтәм әле, бу казакъларда өлкәнгә буйсыну, өлкәнне хөрмәт итү бик тә нык сакланган икән. Менә Өметбаев карап торырга гапгади бер казакъ, бүтәннәрдән һичбер өстен жире юк шикелле. Дурдудагы чаялык та юк аңарда, Байәхмәтов кебек оста сөйләүче дә түгел, киресенчә, бик аз сүзле, бик басынкы бер кеше. Ләкин аңардан алда табынга утырмыйлар, аңардан узып кашык сузмыйлар, чөнки ул барысыннан да өлкән, ата, аксакал дәрәҗәсендәге кеше — аңа күбрәк шулай «ата», «чал» дип кенә дәшәләр дә. Шуңадыр, ахры, аның әллә нидә бер әйткән сүзе дә хөкем урынына йөри диярлек. Атналар-айлар буена кешеләр бер-берсенә бәрелеп-ышкылып яшәгәч, алар арасында ызгыш-талаш та чыгып киткәли, ләкин шул чакта Өметбайның каты гына бер сүз әйтеп куюы житә — талашучылар шунда ук «шып» туктыйлар. Ни баш бирмәс Дурду да аны тыңларга мәжбүр, безнең лейтенант та аңа бервакытта да каты бәрелми, хәтта руслар да картка хөрмәт йөзеннән: «Умутбай — это наш главный казах!» дип кенә жибәрәләр.

Ике чиләктән дә такта капкач өстенә бушаткач, ит тау хәтле булды. Кабарып пешкән, тәмле булары чыгып торган бер өем ит!

Акшалов зарлана:

— Минә куйның башын пешерергә савыт булмады, башы калды,— ди. Казакълар да — гаҗәп — шуна үртәләләр: «Баш кирәк иде, башны калдырмаска иде»,— диләр.

Өметбай ит өемен уртага этәрә төште.

— Җәгез, кордаслар, җитешегез!

Ләкин берәү дә сузылырга ашыкмый иде. Шуннан Өметбай лейтенантка:

— Җәле, Нугайбәк карагым, син безнең командирыбыз, сиңа хөрмәт, алың әле башлап!

— Юк, ата,— диде лейтенант, елмаеп кына,— бу табында мин командир имәсмен, мин кече адәм, сез инде арамызда иң өлкән адәм, аксакалыбыз, кичерегез, сездән уза алмаймыз!

— Тугры әйтә лейтенант! — диештеләр бүтәннәр дә.

Шуннан соң Өметбай: «Ярый, җоладан узмак җук»,— диде дә, үрелеп, бик зур кисәкне кулы белән генә алдына алып куйды. Аның артыннан Байәхмәт сузылды, аннары Шанаев белән Дурду, тик шуннан соң гына лейтенант та үрелде. Аның артыннан инде мин дә үрелдем. Ишмәмәткә шунда ук кайнар шулпасын да салып бирделәр.

Минә изге бер эш үтәгәндәй, дөнья сүзләрен онытып, бик ипләп бирелеп кенә мәрхүм куйны ашау башланды. Казакъларның һәркайсында үткен пычак яки пәке, шуның белән итне җиңел генә калҗалап кисә дә пычак өстеннән төшермичә кабып та җибәрә. Бер калҗа артыннан икенчесен, өченчесен каба, аннары авызы тулгач, ашыкмыйча, озак кына итеп чәйнәргә тотына. Мин дә, алардан күрмәли, пәкемне чыгарып, кискәләп ашарга тотындым, ләкин беренче калҗадан ук икмәксез күңелгә авыр буласын сиздем. Акшаловтан икмәк сорагач, казакълар бик гаҗәпләнделәр:

— Нимәгә нан? Итнең тәмен бетерәсең гой!

— Гадәт, мин әйтәм, шулай өйрәнгәнбез инде.

Үзләре инде алар, билгеле, калҗаның иң майлысын да чырай да сытмыйча голт иттереп кенә йотып җибәрәләр. Һәм шул чакта бик хуш булып, Дурдуны куйның зурысын, симезен сайлый белгәне өчен, ә Акшаловны тәмам җиренә җиткереп пешереп чыгарганы өчен мактап-мактап куйгалыйлар. Бүтән сүз юк, авыз да буш түгел, игътибар да пычак белән иттә генә. Ит белән эш тәмам булгач, кастрюльдән кружкаларына шулпа салып, шуны ашыкмыйча гына эчәргә тотындылар. Казакъча әйтсәк, бу тозлык та бик тәмле-үткер иде. Аны эчкәч, карынга тулган ит бердән сеңгәндәй булып, күңел ничектер ачылып та китте.

Шулай итеп, сүзе, мәшәкате шактый озынга сузылган бу латыш куен — урыны җәннәттә булсын! — ярты сәгать эчендә очлап та куйдык. Аллаһе әкбәр!

Хәзер инде, бәлки, гадәт буенча, мул иттән соң аксакалларга әзрәк мендәргә таянып тору кирәк булгандыр, ләкин безнең лейтенант иң башлап урыныннан торды да сәгатенә карап:

— Постка барыр вакытыгыз җиткән, давай кузгалыгыз! — диде һәм гимнастерка төймәләрен каптырып, агач ботагына элгән каешын алып биленә буды.

Куй хөрмәтенә кыска гына вакытка килгән иске йола тәртибе бетте, чин, дәрәҗә, дисциплина — барысы да кире үз урынына кайтты, яшь Нугайбәк яңадан командирга, ә өлкән казакълар гади солдатка әйләнделәр дә куйдылар... Мин дә ашыгып урынымнан тордым — чыннан да, смена алыштырырга ярты гына сәгать калган иде. Ләкин

казакълар ялварып диярлек әз генә чәй эчеп алырга вакыт сорадылар.

— Тиз булсагыз гына! — дип кисәтте командир аларны.

Акшалов ашыгып зур кара чәйнеген китерде, һәркайсының шулпадан бушаган кружкасына чәй ясап чыкты. Казакълар дегеттәй каты чәйне, кабаланып, өрә-өрә эчтеләр.

Ә бер егерме минуттан соң инде мин тирләгән-пешкән, пух итеп торган агайларны сафка тезеп, өс-башларын, мылтыкларын тиз генә күздән кичереп, үз артымнан няртеп постларга алып та киттем. Акшалов исә сменадан кайтучыларга, алар өлешенә калган итне пешерер өчен, яңадан таган аса калды.

«Әбиләр» җәе дә үтеп китте, көннәр, ниһаять, бозылды, көзге салкын вак яңгырлар башланды. Монда, бу Латвия җирендә, яңгырлар бер башланса, һич тә туктый белми икән. Көне буе ява, төне буе ява, атналар буенча ява — әйтерсең бөтен дөньясын суга гарык итмәкче була. Һавасында — су тузаны, агач ботакларында су агып йөри, ылыслардан тамчылар терекөмештәй өзлексез тәгәрәшә... Үлән арасыннан ун адым да үтәр хәл юк, шинель чабулары шунда ук юешләнә, ә юлга чыксаң, кара, үзле балчык итекне аяктан суыра... Һавада йөзгән бу юешлек безнең өстебезгә сеңеп бетте, землянканың бөтен бүрәнәләренә сарылды, хәтта ашый торган азыкларыбызга үтеп керде.

Иң әшәкесе тагын шул, солдат посттан кайткач, юеш землянкада өс-башын киптерә алмыйча интегеп бетә. Акшалов землянка уртасындагы кечкенә түгәрәк тимер мичне өзлексез ягып торса да, бердән, аның җылысы да аз, икенчедән, аның тирәсенә бары чолгауларны элеп, итекләрне генә тезеп куеп була. Ә плащ-палатка, шинель кебек зур киемнәрне киптерергә, гомумән, бернинди дә мөмкинлек юк. Кайберәүләр шинельләрен мич өстенә салындырып, түшәмгә элеп куйган булалар, ләкин аңардан ни файда — шинельнең чабуыннан тамчы тамып, өстеннән пар гына чыгып тора. (Җитмәсә әле, солдат йоклаганда шул шинелен ябынып та ятарга тиеш.)

Яңадан постка барыр вакыт җиткәч, ул, солдат дигән кеше, тагын дымлы чолгавын урап, җылынып җитмәгән итеген, юеш, авыр шинелен киеп, яңгыр сеңеп беткән плащ-палаткасын бөркәнеп, караңгы, пычрак, салкын төн эченә чыгып китәргә мәҗбүр... Әмма иң гаҗәбе — шушындый хәлдә дә берәүнең дә авырганы юк, ичмасам, томау төшеп төчкергән кеше дә юк. Хәтта безнең Ишмәмәт — көзге чебеш — ул да ник кенә бер зарлансын! Бизгәген дә җиңде шикелле... Ә бит аңа, эссе коры яктан шушы салкын юешлеккә килеп эләккән кешегә, күптән авырып егылу кирәк иде. Юк, егылмый, тора, бите йодрык хәтле генә булып калган, авызы-борыны күгәреп беткән, ә шулай да алты сәгатен «эһ» тә итмичә тора! Бер каклanса каклана икән адәм баласы!

Ләкин, дөресен әйтергә кирәк, солдатларның кәефләре бик начар. Эчләрендә гел ачу кайный, нервлары бик тартылган, юктан да ызгышып китәргә генә торалар, плащ-палатка бавы чәбәләнсә дә, бик әче итеп сүгенергә тотыналар. Бу җәһәттән казакълар бик зәһәр икән. Бер сүгенә башласалар, Гитлерның җиде бабасына барып җитәләр... Билгеле инде, болар барысы да шушы бер урында һәм билгесез бер хәлдә каңгырып торудан килеп чыга. Әгәр кузгалып китә калсак, солдатларның кәефләре көне-сәгате белән үзгәрәчәк.

Кайчагында лейтенант белән без дә «чәкәләшеп» алабыз. Мин аңа: «Кайчан бу сазлыктан ычкынабыз инде, син, командир кеше, ник шуны белергә тырышмыйсың?» — дип бәйләнә башлыйм. Ә ул кызып: «Кайдан, кемнән беләсең аны? — ди. — Армиядә бервакытта да бернәрсәне дә алдан әйтеп куймыйлар. Может, иртәгә үк приказ килер. Безнең эш — көтү, сержант, көтәргә кирәк!»

Димәк, көтәргә, көтәргә һәм, чуваш Емелькин әйтмешли, службаны онытмаска!.. Минем эш билгеле инде — развод ясау һәм постларны әледән-әле тикшереп тору. Хәзер төннәр бик озын, постларны берничә тапкыр йөреп чыгарга туры килә. Әйтергә кирәк, безнең солдатларның һәркайсы бу дегеттәй төн эчендә, агач башындагы ябалак шикелле, бик уяу тора, якынлаша башлауга шунда ук: «Тукта, кем килә?» — дип кычкырып тавыш та бирә. Инде мин икәнне белгәч, ничектер куанып та китә. Үз кеше, җанлы сүз — менә хәзер аңа бик тансык бит ул, биш-ун минут кына сөйләшеп тору да аның күңелен күтәреп җибәрә, әзрәк кенә вакыты да кыскара төшкәндәй була.

Ә бер көнне лейтенант, Акшаловны ияртеп, үзебезнең ротаны эзләп китте. Ротаның бездән каядыр алга таба бик ерак киткәнен ишетеп белә идек, ләкин урнашкан җире ачык кына билгеле түгел иде. Елгавадан көнчыгыштарак диделәр... Йомыш күп җыелды. Бу урынга килеп эләккәннән бирле хатлар алганыбыз юк (чөнки хатлар рота адресына киләләр), шулай ук үзебезнең бик кадерле солдат акчасын да (аена 32 сум) менә өч ай инде алганыбыз юк, аннары ротадан безгә азык-төлекнең дә яхшысы тия торган иде, кыскасы, лейтенант чакыру көтеп ятты-ятты да ахырда тәвәккәлләп китәргә булды.

Аның урынына мин калып тордым. Служба шулай бер көйләнгән көе бара да бара, таң ата да кич була, ләкин без хәзер барыбыз да лейтенантның әйләнеп кайтканын көтеп яшибез. Минем исәбемчә, ул кимендә берәр атна йөрергә тиеш иде. Ротаны табасы бар, бер өч-дүрт көн торасы бар (кумасалар, нигә ашыгырга?), аласы нәрсәләрне аласы бар — боларның барысы өчен дә бер атна күпмени ул? Ләкин лейтенантыбыз өченче көн дигәндә әйләнеп кайтты да төште. Хәер, нәкъ кайткан чагында гына мин взводта юк идем, территориядә йөри идем. Бер заман землянкалар янына килсәм, солдатларның барысының да кулларында хат! Һәркайсы аулаграк урынга китеп, я сөялеп, я чүгәләп дигәндәй, хат укып тора!.. Алай, лейтенант кайтып та житкән икән. Бик шәп. Хат килгән көн бит ул, җан кисәкләрем, солдат өчен иң шатлыклы көн! Чын бәйрәм! Бигрәк тә айлар буе көткәннән соң...

Иң элек мин Төхфәт абзыйга тап булдым. Бер агач төбендә бу борынын тартып, шыңшып утыра — кулында хаты.

— Әллә җылыйсың инде, якташ? — дим мин моңа, янында туктап.

— Җылыйм шул,— ди Төхфәт абзый, бер дә тартынып тормыйча.

— Ник, әллә берәр кайгылы хәбәр язганнармы?

— Юк, андый хәбәр юк, аллага шөкер!

— Соң шулай булгач?

— Мә, үзең укы,— ди бу, миңа хатын сузып.— Башыннан ук укы!

Мин хатны алып, эчемнән генә укыйм:

«Сезки сөекле, дөньяда иң якын күргән кадерле абыем, сиңа безки туганың Шәрифәдән күңелемнең иң нечкә җирләреннән парланып чыккан ялкынлы саф сәламемне җибәреп, алма бакчаларында төрле матур гөлләргә кунып, тирән үйларга чумып сайраган сандугач-былбыллар санынча сагынып, саргаеп, абыем, синең нурлы йөзләреңне бер күрергә зар-интизарлар булып, өзелеп, күптин-күп сәламнәремне, абыем, сиңа бүләк итәм...»

Һәм тагын әнисеннән, Төхфәт абзыйның хатыныннан, балаларыннан, туган-тумачаларыннан, күрше-күләннән шундый ук бик өзелеп, бик ялкынланып, шуңадыр, ахры, шактый керделе-чыктылы итеп язылган сәламнәр тезелеп киткән....

Шуларны укыгач, мин хатны кире Төхфәт абзыйга суздым:

— Бик матур язылган хат ич бу!

— Менә шул шул! — диде Төхфәт абзый, учы белән күзләрен сөрткәләп.— Кайдан гына сүзләрен табып бетергән, бәгырькәем, күз нурым! Ый-ый!..

— Я, я, килешмәгәнне! — дигән булдым мин, китә башлап, ә үземнең бугазга шулай да төер килеп тыгылды, хәерсез!.. Һай, бу сагышлар! Солдатның күз яше күптән кибеп бетте инде, бер генә газаптан, бер генә бәхетсезлектән дә җылый алмый ул, ә менә сагыну яшьләре калган, сагыну яшьләре бәреп чыга. Гаеп итеп буламыни аны моның өчен?!.

Мин ашыгып үзебезнең землянкага кердем. Лейтенант инде ялгызы гына җәелеп чәй эчеп утыра иде. Хәрби тәртип буенча мин аңа рапорт бирә башлаган идем дә, ул шунда ук мине бүлеп:

— Ярый, сержант, беләм, барын да беләм, әйдә, уз, әллә кайда йөрисең! — диде. Бу инде дусларча үз итеп каршы алу иде. Димәк, лейтенантның кәефе бүген аеруча шәп. Шулай да мин сорадым аңардан:

— Бик тиз әйләндегез, иптәш лейтенант, юлыгыз уңышлы чыктымы соң?

— Әйтмә, юлыбыз җөдә уң булды, сержант!

Шулайга охшый. Аның түп-түгәрәк киң бите чыгып килгән ай шикелле балкый иде. Ә өстәлдә күптән күрмәгән ризыклар: ак май, каклаган колбаса, печенье, хәтта берничә шоколад плиткасы да ята. Шуның өстенә әле лейтенант кыр сумкасыннан чыгарып, миңа ике пачка сигарет та сузды.

— Мә, бусы сиңа күчтәнәч!

Мин дөя сурәте төшерелгән бик матур пачканы әйләндереп-әйләндереп карадым:

— Немецныкы, ахрысы?

— Трофей бу, сержант. Безнекеләр Риганы алганда немецларның азык складларын бөтен килеш кулга төшергәннәр. Шуннан чыккан нәрсә бу.

— Чигәргә ярыймы икән соң?

— Ярый, ярый, безнең рота командиры үзе даим шуны чигеп йөри. Аннары ул миңа өч хат та чыгарып бирде.

— Менә болар өчен сезгә, лейтенант, Алатау чаклы рәхмәт! — дидем мин, хатларга ябышып. Ләкин шунда ук ачып укый-башларга яхшысынмадым — мине сыйлыйсы килеп, көтеп утырган командир белән ничектер санлашмау булыр иде. Шуңа күрә хатларның сызык астындагы адресларын гына карадым да хәзергә үзләрен чалбар кесәсенә генә салып куйдым. Әйдә, мине җылыта торсыннар!

Лейтенантның бу тансык сыйлардан башка төяп алып кайткан яңа хәбәре дә шактый икән, мин чишенеп утыргач та ул шуларны сөйләргә тотынды.

...Безнең мондагы фронтларда зур үзгәрешләр булырга тора, диде. Балтик буенын күп өлеше немецлардан азат ителгән, сугыш хәрәкәтләре тиздән Польша җиренә һәм Көнчыгыш Пруссиягә (димәк, Германиянең үзенә) күчәргә тиеш, шул сәбәпле мондагы Совет гаскәрләренең күп өлешен бүтән фронтларга күчерүләре ихтимал, шулай булгач, безне дә монда озак тотмаслар, диде. Мин лейтенанттан, теге немец частьларының кайдадыр бүленеп калуы турында йөргән сүзләр дөресме? дип сорадым. Әйе, дөрес, диде лейтенант, фашист гаскәрләренең шактый зур группасы (утызлап дивизия, имеш) Курляндия ярыматавында бүленеп калган, шунда ныгып, безгә бирелергә теләмичә бик каты сугышып ята икән. Әлбәттә, ул группаны бетерү өчен монда безнең берничә армияне калдырырлар, ләкин барыбер күпмедер гаскәрне моннан икенче фронтларга күчерергә тиешләр. Шулай дигән рота командиры, офицерлар арасында шундый сүзләр йөри дигән, әмма кайчан, кайда? — бу кадәресе хәрби сер, берәү дә белми икән әле аны.

Сыйлар тәмле, хәбәрләр кызыклы иде, ләкин күрәм, лейтенантка

ял кирәк. Озын, авыр юлдан ватылган кеше әнә чәйдән соң изри дә башлады.

— Сез ял итегез, лейтенант! — дидем мин, урынымнан торып.

— Әзрәк кенә ҡирәк шул.— диде лейтенант, тапчанына күчеп.

Мин шинелемне кидем дә кесәдәге хатларны аулакта тыныч кына укыр өчен землянкадан чыгып киттем.

...Тагын җепшек, шыксыз, соргылт көннәр сузылды. Сугыш бар да кебек, юк та кебек, вакыт уза да кебек, узмый да кебек... Көтүдән дә әшәке нәрсә бармы соң?.. Ләкин, мең шөкер, бу юлы безгә шулай да бик озак түзәргә туры килмәде. Иң элек, көннәрдән бер көнне, безнең склад территориясендә ниндидер яна кешеләр күренде. (Погоннарына караганда, артиллерия офицерлары.) Алар склад начальнигы белән берлектә төрле җиргә өелгән штабельләрне карап йөрделәр, территориягә керү-чыгу юлларын тикшерделәр, аннары сөйләштеләр-иттеләр дә китеп тә бардылар. Безнең лейтенант та гел аларга ияреп йөрде. Соңыннан мин сорагач ул, болар унынчы армиядән килгән кешеләр, боеприпасларны моннан чыгару турында сөйләштеләр, дип әйтте. Күңелле хәбәр иде бу... Шуннан соң өч-дүрт көн дә узмагандыр, ниһаять, безнең рота командиры да килеп җитте. Үзе генә түгел, аның белән бергә Армия базасыннан майор Исаев һәм безгә таныш булмаган бер капитан да килгән иде.

Армиядә һәрвакытта шулай ул — берәр төрле эш башланса, бик кызу тоталар. Рота командиры өлкән лейтенант Поляков безнең белән күрешеп, әзрәк кенә хәл-әхвәлне сорашкач та әйтте:

— Ну, егетләр, сезгә монда кызынып ятулар бетте. Иске-москылларыгызны җыя торыгыз, бер-ике көннән бу урманда сукыр тычканнардан башка беркем дә калмаячак!

Ҡыскасы, аның ярым шаяртып әйткәннәреннән шул мәгълүм булды: мондагы барлык боеприпасларны тиздән вагоннарга төяп, алгы позициядәге икенче бер армиягә алып китәчәкләр. Бу склад исә гомумән бетереләчәк.

Ул шунда ук лейтенант Кулибаевка постларны кыскартырга, бары шлагбаум белән штабельләр янында гына ике пост калдырырга кушты.

— Ә сактан бушаганнарның барысын да — боеприпаслар төяргә! — диде.

Без моңа әйтеп бетергесез шат идек. Ниһаять, китәбез! Каядыр алга таба — Литва, Польша якларына таба китәбез! Ротабызга кайткач, мунча керербез, күлмәк-ыштан алыштырырбыз, бәлки, әле җылы өйләрдә дә йокларбыз. Солдатка тагын ни кирәк?!

Шул ук көнне төштән соң биш «студебеккер» машинасы (зур, таза машиналар!) килде, һәм боеприпасларны шуларга төяп, ике чакрымдагы тимер юлга ташу да башланды.

Безнекеләр җен урынына эшләделәр. Авыр снарядларны төяү-бушатудан бик җәфаланган чаклар да бар иде, ләкин бу юлы тансык бер эш итеп, ничек тә тизрәк бетерәсе килеп, ару-талуны белмичә эшләдек. Командирларыбыз да көне-төне гел яныбызда булып тордылар. Безнең рота командиры, әйтергә кирәк, кешеләрне эшләтә белә иде. Теле белән дә, кулы белән дә. Гомумән, ул бик оптимист табигатьле, шаулап яшәргә өйрәнгән, тынгы белмәс кешегә охшаган иде. Дөрес, мин аны аз беләм, мин писарьлыктан киткән чакта, хәтерлисездер, рота командиры Сидоров дигән бер караңгы чырайлы интендант кисәге иде. Ләкин ул да ни өчендер озак мантый алмаган, аның урынына менә шушы өлкән лейтенант Поляковны билгеләгәннәр. Барлык командирларга караганда да бу гомерлерәк булып чыкты. Менә елдан артык инде ул безгә командирлык итә. Күрәсең, эшне оста алып бара

белә торгандыр... Аннары бу инде сугышасын сугышкан кеше, күкрәгендә ничә тапкыр яралануын күрсәткән тасмалары да бар (шуларның икесе — сары төстә), ә карап торуга болай бөп-бөтен кеше кебек... Җөйләре күлмәк астында булса кирәк.

Бер тәүлек эчендә без барлык боеприпасларны ташып, сигез пульман вагонына һәм жиде кечкенә вагоннарга төяп тә куйдык. Склад территориясендә ватык әрҗәләрдән башка бернәрсә дә калмады. Соңгы ике постны да бетердек. Вәссәлам!.. Инде кайтып бераз ял итәсе дә моннан төялеп китәсе генә калды. Әлбәттә, үзебезнең ротага — шулай уйладык без.

Ләкин кайтып ашарга-эчәргә өлгермәдек, безнең землянкага рота командиры үзе килеп керде.

— Давай, лейтенант,— диде ул, гадәтенчә сүзне туп-туры башлап,— эшелонны озатырга кешеләр билгелә.

Лейтенант аптырабрак урыныннан торды.

— Ничә кеше?

— Алты солдат, шуларга бер старший... Менә сержантны җибәрербез,— диде рота командиры, миңа ымлап.— Калганнарын үзең сайла!

Әллә ничек көтелмәгәнчәрәк килеп чыкты бу, ләкин нәрсә әйтә аласың?.. Бернәрсә дә әйтә алмыйсың, абзыкаем!.. Китәргә икән — китәргә, мать якасына!.. Алгы позициягә чаклы — бу әле кызыграк та булыр.

Рота командиры чыгып китәр алдыннан:

— Әзерләнеп бетәргә ике сәгать вакыт сезгә,— диде.— Өч көнлек азык алыгыз, җылырак киенегез. Менә шул. Ике сәгатьтән үзем килермен!

...Ул чыгып киткәч, без лейтенант белән башларны кашыдык та яңадан өстәл янына утырдык.

— Кемнәрне бирәсең, кемнәрне алыйм? — дип сорадым мин лейтенанттан.

— Син старший, үзең сайла,— диде лейтенант.

— Хуп мәйле!

Бер кәгазь кисәге алып, мин үзем теләгән солдатларның исемнәрен яза башладым: беренче итеп, билгеле, Дурдуны яздым — бу үткен-чая һәм ышанычлы солдат; аның янына үз казакъларыннан Шанаев белән Байәхмәтовны теркәдем; дөрес, Шанаев бәлачелрәк кеше, ләкин Дурду аны тезгенләп тота белә. Аннары Төхфәт абзыйны үземнән калдырасым килмәде. Аның янына чуваш Емелькинны да яздым — ике дусны ничек итеп аерасың?.. Бишәү булды. Алтынчыга кемне язарга?.. Акшаловны дигән идем дә, ләкин лейтенант «аны калдыр» диде. Беләм, ул Акшаловны үзенең ординарецы сыманрак итеп йөртә. Шуннан аз гына уйлап тордым да алтынчыга әлеге бик күндәм, бик чыдам бәләкәй солдат Ишмәмәтне язып куйдым.

Исемлекне лейтенантка күрсәттем. Ул бер күз ташлады да: «Ярый, булган!» — диде.

— Алайса, әйтәм үзләренә.

— Бар, әйт!

Мин торып чыктым да солдатлар землянкасына кердем. Авыр эштән соң солдатларның күбесе тир, чолгау исләре белән аралаш дымсу һавалы, караңгы землянкада гыр-гыр йоклап яталар иде. Мин үземә кирәк кешеләрне генә төртеп уята башладым:

— Төхфәт абзый, Дурду әкә, Шанаев, давай торыгыз әле, торыгыз!

— Ой-бой, ни булды, сержант? — дип күзен ачты Дурду.

— Китәбез, Дурду, моннан китәбез...

— Кайчан?

— Менә хәзер үк.
Шулай дигәч, бер Дурду гына түгел, барысы да тиз генә торып, сәке читенә шуышып килделәр. Тик Шанаев кына гадәтенчә кычкырып сукрана башлады:
— Бу ни эш бу, адәмнәргә дәм алырга да ирек бирмәйсез!..
— Шаулама! — дидем мин аңа, каты гына.— Командирның приказы бу. Ике сәгатьтән без, менә мин әйткән кешеләр, тимер юлда булырга тиешбез. Эшелон озата барабыз. Төшендегезме?
— Төшендек, сержант, төшендек! — диде Дурду.— Ә бүтәннәр?
— Бүтәннәр калып тора...
Моны ишеткәч, алар ничектер тагы да җанланыбрак киткәндәй булдылар. Кузгалып китү солдатны һәрвакытта дәртләндерә, ә монда бүтәннәрдән алда, менә хәзер, бүген үк икән! Һәркайсы шунда ук йокысыннан айнып, шытыр-шытыр кашына-кашына, кием-салымына да тотынды.
Командирның әйткәнен искә төшереп, мин аларга җылырак кинергә куштым. Безнең взвод ротадан күбрәк аерылып яшәгәнгә күрә, солдатлардан кайбер җылы киемнәрне (мәсәлән, бүрек белән сырган чалбарны) җыеп та алмый идек. Көннәр суытып җибәргәч тә солдат аларны капчыгыннан чыгара да кия. Ә хәзер тышта ноябрь башы, һава сөяккә үтәрдәй җепшек-салкын, көн дә диярлек карлы яңгыр явып тора.
Акшаловтан мин үзебезгә дигән өч көнлек азыкны исәпләп алдым. Шул бер үк нәрсәләр инде: шикәр, тәмәке, борчак һәм тары концентраты, шпик урынына әзрәк ак май һәм Америкадан килгән колбаса консервысы... Тик икмәкне генә склад кешеләреннән барып алырга туры килде.
Шушы мәшәкатьләр артыннан йөреп, минем үземә җыенырга вакыт җитәр-җитмәс кенә калды. Тиз генә землянкага кайтып, иң элек бритва, көзге, сабын кебек вак-төяк әйберләремне кыр сумкасына тутырдым, аннары яңабаштан әйбәтләп киенергә тотындым: искесен салмыйча, шуның өстеннән генә җылы күлмәк-ыштан кидем, аякларга чолгауны яңадан урап, итекләрне иплэп кидем, пилотканы бүрек белән алыштырдым. Бу эшләр дә беткәч, юл капчыгының бөрмәле авызын ныгытып бәйләдем дә пистолет белән автоматымны, ачып-ябып дигәндәй, тиз-тиз генә күздән кичердем. Пистолетны теләсә кемгә күрсәтергә ярамый, ул миңа тиешле нәрсә түгел, ләкин моның кебек асыл әйбердән, кулга бер эләккәч, аерылып буламыни?!. Шуңа күрә мин аны шинель кесәсендә генә йөртәм.
Кыскасы, җыенып өлгердем. Солдатлар да әзерләнеп бетеп, билләрен буып, капчык-коралларын күтәреп землянка алдына чыкканнар иде инде. Тик Дурдуның гына эше бетеп җитмәгән икән. Ул агачлар арасына китебрәк, үзе генә белгән ниндидер үләннән һәм чыршы ылысыннан кечкенә табасында юллык насбай «көйдереп» маташа иде. Безнең лейтенант моны күргәч кинәт кабынып китте:
— Хәзер үк ташла бу эшеңне, югыйсә, табаңны тибеп очырам,— диде ул яман кычкырып. Башка вакытта аның болай каты бәрелгәне юк иде, күрәсең, менә хәзер начальниклар килеп җитәр дип курыккандыр инде.
Дурду, авыз эченнән генә нидер сукранып, кайнар табасын насбае белән бергә махсус тегелгән капчыгына тыкты да башкалар янына килеп басты. Емелькин аңа дусларча кайгырткан булып:
— Юкка җәфаланасың, товарищ! — диде.— Менә миндә чуваш тәмәкесенең аюны үтерә торганы бар, шуны гына суырырсың!
— Тукта, мин сиңа суыртырмын әле, моннан китик кенә,— диде Дурду, күзләренең агы белән генә карап.
Солдатлар бер кәефләнеп көлешеп алдылар.

Ә бераздан сукмак буйлап безгә таба килгән рота командиры белән әлеге ят капитан да күренделәр. Мин солдатларны тиз генә сафка тездем һәм үзем дә алар белән бергә бастым. Тегеләр килеп җиткәч тә, безнең лейтенант рота командирына, солдатлар юлга чыгарга әзер, дип рапорт бирде.

— Яхшы! — диде рота командиры, безгә вольный торырга кушты, аннары лейтенанттан:—Авырулар юкмы, яхшылап ашаттыгызмы, кирәк-яракларның барысын да алдыгызмы? — дип сорашырга тотынды. Лейтенант, ике кулын да бот буена сузган килеш, бик төгәл итеп җавап биреп торды.

Шуннан соң өлкән лейтенант алгарак чыгып, безгә болай диде:

— Сез, иптәшләр, боеприпаслар төягән эшелонны билгеләнгән җиренә чаклы озата барасыз. Эшелон станциядә, паровоз килгәнне генә көтеп тора. Боеприпасның нәрсә икәнен сезгә әйтеп торасы юк... Менә шул хәтәр йөкне бик уяу саклап, тиешле урынына илтеп җиткерергә кирәк. Онытмагыз, сез үтәсе юллар яңарак кына дошманнан әрчелде, анда посып калган диверсантларның да булуы мөмкин. Димәк, сезгә, иптәшләр, зур җаваплы эш йөкләнә, шуны сез чын солдатларча намус белән үтәргә тиешсез. Аңладыгызмы?

Без дәшмәдек. Ләкин безнең аңа төбәлгән күзләрдән ул һәр әйткән сүзенең безгә бик яхшы килеп җиткәнен болай да күрергә тиеш иде.

— ...Эшелон начальнигы булып менә шушы иптәш, капитан Судаков барачак,— диде командир, сүзен дәвам итеп.— Сез турыдан-туры аңа буйсынасыз. Бөтен кирәкле боерыкларны сезгә ул бирәчәк. Бу, сержант, күбрәк сиңа кагыла, белеп тор!

— Есть! — дидем мин, өзеп кенә.

— Тагын шул. Эшелонны исән-сау илтеп җиткергәннән соң, сез үзебезнең ротага кайтырсыз. Капитан безнең ротаның кайда икәнен белә, ул сезгә маршрутны өйрәтеп җибәрер. Ә хәзер кузгалсагыз да була. Хәерле юл сезгә!

Мин сафтан чыгып, үземнең алты бөртек солдатыма сулга борылырга команда бирдем. Һәм без кирәк-яракларыбызны күтәреп, пычрак ера-ера китеп тә бардык. Командирлар безнең арттан иярделәр.

Эшелон станциядән агачлык эченә сузылган тупикта тора иде. Килеп җиткәч, безгә шуның сигезенче вагонына урнашырга куштылар. Бу зур пульман вагоны иде. Авыр ишеген шылдырып ачтык; вагонның ике башына да, түшәменә чаклы, ящик-ящик снаряд өелгән, тик ишек турысындагы урта бер җире генә буш калдырылган иде. Башта мин, минем арттан Дурду эленеп торган тимергә басып, вагон эченә күтәрелдек. Иптәшләрнең кулларыннан капчыкларын, коралларын алдык, аннары үзләрен дә берәм-берәм өскә тартып мендердек.

Ике яклап өелгән снарядларга карап, Шанаев:

— Ой-бой, әҗәлнең үзе янында барамыз икән гой! — диде.

Ә Дурду исе китмичә генә:

— Һи, снәрәд дигәнең юаш нәрсә ул, аңа башны куеп йокларга да була,— диде, көлдерергә тырышып.

Ләкин берәү дә көлмәде. Безнекеләр боеприпаслар янында торып күнегеп беткән булсалар да, менә болай хәтәр йөк белән бер вагонда барганнары юл иде әле. Шуңа күрә әзрәк кенә шомланалар да булса кирәк. Хәер, солдат шомлануын бервакытта да сиздерергә яратмый,— дөрескә чыга күрмәсен дип курка ул.

Ярый, анысын куеп торыйк, менә монда вагон идәне шыр ялангач та, пычрак та икән—шунысы начар. Иптәшләр печәнме, саламмы табарга кирәк диләр. Озак эзлисе нәрсә түгел, әнә юл буенда гына киртәләр белән бастырган бер чүмәлә тора — барып, төбеннән генә йолкып, дүрт-

биш кочак печән китердек тә идәнгә җәйдек. Шуннан соң солдатлар снаряд ящикларына аркаларын терәп, аякларын сузып, печән өстенә ял итәргә утырдылар.

Бераздан безнең вагон янына эшелонны озата баручы әлеге Судаков дигән капитан килде. Мин аның каршысына сикереп төштем.

— Я, урнаштыгызмы? — дип сорады ул миннән.

— Урнаштык, иптәш капитан! — дидем мин, честь бирмичә генә.

Капитан вагон эченә дә үрелеп карады: солдатлар тора башлаганнар иде, ул кулын селкеп, тормаска кушты.

Командир-начальникларның төрлесенә очрап, билгеле бер сизгерлеккә өйрәнгәнгә күрәдер инде, мин бу артиллерист погонлы, сүлпәнрәк хәрәкәтле, озын-чандыр капитанның форма таләпләренә артык игътибар итмәвен, солдатларга карата үзен гади генә тотуын чамалап өлгергән идем. Җиңел-азапсыз булыр кебек аның кул астында баруы... Хәер, алгы сызыктан килгән командирлар күбесенчә шундый булалар да.

Ул минем фамилиямне сорады, мин аңа әйтеп бирдем. Шуннан соң беләгемнән алгандай итеп, вагоннар буйлап атлый-атлый, ашыкмыйча гына миңа үзенең боерыкларын бирә башлады.

— ...Ин элек шул: составның ике очына ике часовой куярсыз. Берсен паровозга якын тамбурга, икенчесен — койрыкка. Туктап торган җирләрдә алар төшеп, ике яктан состав буйлап йөреп торырга тиешләр. Бусы аеруча кирәк... Тик менә часовойларны алыштыру мәсьәләсе... сезнеңчә, күпме вакыттан алыштырырга ярый?

— Ике постка алты солдат, иптәш капитан, дүртәр сәгать торсалар, җитәр! — дидем мин.

— Күп булыр,— диде капитан.— Тамбурда өшеп бетәрләр... Ике сәгать, ну, өч сәгать, шуннан да артык тотарга ярамас. Аларны бит эшелон туктап торган чакта гына алыштырырга туры киләчәк, шуна күрә төгәл вакыт билгеләве дә читен. Сез үзегез моны чамалап хәл итәргә тиешсез!..

— Яхшы, иптәш капитан!

— Аннары, сержант, вагон эчендә электр фонарьдан башка нәрсә яндыра күрмәгез. Шырпы сызу булмасын. Тәмәке тартуны онытыгыз... Туктап торган арада гына төшеп тартырга рөхсәт итегез. Аңладыгызмы?

— Аңладым, иптәш капитан!

— Хәзергә шул... Мин үзем паровозда булырмын, кирәксәм, шунда килерсез!

— Яхшы, иптәш капитан!.. Ә паровоз тиз килерме икән?

Капитан ике кулын җәйде:

— Көтәбез... Күрше станциядән килергә тиеш.

— Часовойларны хәзер үк куяргамы?

— Тамбурга китәр алдыннан гына куярбыз. Ә хәзер ике патруль билгеләгез, состав буйлап йөри торсыннар.

— Була, иптәш командир!

Ул киткәч тә мин вагонга кире кайтып, Байәхмәт белән Ишмәмәтне беренче патрульләр итеп билгеләдем. Болар арада иң өлкәннәр, төнлә тамбурда баруы алар өчен читенрәк булачак, ә йөреп тору ярый, йөреп торганда кеше өшеми дә... Икесе дә мылтыкларын алып төшәргә әзерләнгәч, мин аларның берсенә составның бер ягыннан, икенчесенә икенче ягыннан йөрергә һәм вагоннарга чит-ят кешеләрдән берәүне дә якын җибәрмәскә куштым.

Ярый, бу да булды. Бер яктан җан тыныч әле; менә күпме вакыттан бирле инде дошман авиациясенең тыны да чыкмый. Ә тоташ болытлы көзге һавалар башлангач, гомумән, бу тирәләрдә бер генә разведчик-самолетның да күренгәне юк... Һәр начарның бер яхшы ягы була

дигәндәй, күзге яңгырлардан интегеп бетсәк тә, элекке шикелле гел шомланып, һавага колак салып тормыйбыз.

Бераздан солдатлар, чәй эчеп аласы иде бит, сержант, дия башладылар. Кирәктер шул, тик ятып өшеп тә киткәннәрдер, аннары иртәнгә чаклы ашау-эчү белән маташып та булмаячак.

— Әйдәгез, алайса, яктырак чакта эчеп калыйк,— дидем мин үзләренә.— Син, Дурду, давай, кара чиләкне ал да су табып китер, ә без әнә агачлыкта ут яга торырбыз.

Барыбыз да вагоннан төшеп, юл буендагы ватык әрҗәләрне җыештырып, агачлар арасына кердек тә кечкенә бер аланлыкта ут ягып җибәрдек. Дурду табып китергән суны чиләге белән кайнатырга куйдык, үзебез чатыр-чотыр янган учак әйләнәсенә чүгәләшеп, кәкрәйгән кулларны, тез башларын җылыта тордык. Солдатлар миннән һаман бер нәрсәне сорыйлар: кая барабыз, сержант?

— Алга таба,— мин әйтәм.

— Юк, син точкасын әйт! — диләр.

— Точкасын паровоз гына белә, ә паровозның килеп җиткәне юк әле,— дигән булам.

— Яшерәсең, сержант!

Мин юри дәшмим, гүя сер саклыйм, имеш! Аннары бераздан:

— Атагызның башы,— мин әйтәм,— сержант белсә, сез белми калыр идегезмени?!.

— Тугры, тугры,— диләр тагын үзләре.

Су кайнап чыккач, шуңа бер уч чәй бутап, аяк өсте генә алюмин кружкалардан пешә-пешә чәй эчтек. Төхфәт абзый, җаена мач китереп дигәндәй, такмаклап та җибәрде:

> — Чәй эчүнең шарты бар, бавырсак та коймак,
> Сары майга манып-манып кунак алдына куймак!

— Кара мынау нугайны, бавырсакны белә икән гой! — диде Шанаев, гаҗәпләнеп.

— Һе, белмәскә,— диде Төхфәт абзый, тел шартлатып.— Без ашарбыз әле шишара, ә син карап торырсың, бичара!

Барыбыз да рәхәтләнеп бер көлештек.

Калган чәйне алып кайтып, Байәхмәт белән Ишмәмәткә дә берәр кружка салып бирдек. Ишмәмәт кружкасын ике учына кысып, Дурдуга кат-кат рәхмәт укый — гаҗәп бер тәүфыйк иясе безнең бу Ишмәмәт!

Әмма бу паровозлары озак килмичә тәмам җилеккә үтте. Көтүдән дә әшәке нәрсә юк. Әллә кайчан караңгы төште, төн булды, ә без салкын вагон идәнендә утырабыз да утырабыз... Әледән-әле торып, ишектән башны тыгып карыйм — дегет шикелле кара төн, үлек дөнья, шылт иткән тавыш та юк... Тагын утырам, күкрәктәге фонарь белән вагон эчен бер генә минутка яктыртып алам: солдатлар аркаларын бер-берсенә терәп печән өстендә яталар — йоклыйлармы, әллә болай җылы саклап кына яталармы, хода белсен!.. Мин үзем дә аяк чәнчеп утырган килеш, әз генә черем итеп алырга тырышып карыйм, вакыт-вакыт башны төшереп җибәреп, яртылаш кына онытылып киткән кебек тә булам, ләкин шунда ук юк кына бер кыштырдаудан да сискәнеп, күзләремне чекрәйтеп ачам... һәм ни өчендер бүрегемне ике куллап тотып карыйм... Юк инде, юк, булмый, койрыгын да тоттырмый йокы!.. Әмма әйтеп куйган нәзерем бар: исән-сау илгә кайтсам, әнкәйнең түшәк-ястыкларына чумып, бер өч тәүлек тоташтан мәрткә киткәндәй йоклаячакмын, алла бирсә!

Ниһаять, төн урталарында теге мөртәт паровоз килде шикелле — нәрсәнеңдер авыр итеп ухылдавы ишетелде. Сикереп торып, ишеккә ташландым: килгән икән шул, рәхмәт төшкере, әнә ике күзе ялтырап күренә.

Ә бераздан ул безнең составка әкрен генә килеп тагылды, авыр вагоннарны шома гына кузгатып, тупиктан алып чыкты. Тагын күпмедер вакыт безне бер алга, бер артка сөйрәп, юлдан юлга күчереп йөртте, аннары туктап, тынып калды. Шул арада мин Төхфәт абзый белән Емелькинны аякка бастырдым.

— Ягез, агайлар, тиз генә җыеныгыз, постка киттек!

Алар сүзсез генә торып, кымшана башладылар. Мин ашыктырам, ә Емелькин сукрана:

— Куалама ул хәтле, сержант, бүрекнең колакларын гына төшереп бәйлик, тамбурда барасы бит!

Ахырда әзерләнеп беттеләр, җиргә төштек. Фонарь белән юлны яктыртып, Төхфәт абзыйны паровозга таба алып киттем, ә Емелькинга вагон янында көтеп торырга куштым. (Аны койрыкка илтәсе.)

Безгә ашыга-ашыга килгән капитан очрады:

— Сержант, сезме бу?

— Әйе, мин, иптәш капитан!

— Часовойны илтәсезме? Ярый. Бер биш минуттан кузгалабыз. Кешеләрегез барысы да яныгыздамы?

— Әйе, иптәш капитан! — дидем мин һәм шунда ук Байәхмәт белән Ишмәмәтне искә төшереп борчылып куйдым: алар кайда соң?.. Тупик буенда торып калмасалар ярар иде.

Ләкин борчылырлык эш булмады. Алар да, Ишәй белән Кушай шикелле, каяндыр юллар буеннан абына-сөртенә килеп чыктылар. Мин дә часовойларны илтеп куярга өлгердем... Ә бер-ике минуттан паровоз кычкыртмыйча гына кузгалып, безне алга, сугыш барган якка таба алып та китте.

...Инде бер җинел суладык. Кәеф тә әйбәтләнеп, йокы да качты. Җанланып, шаулашып, сөйләшеп тә алдык. Ләкин дөм карангыда сүз озакка сузылмый — иптәшләр берәм-берәм әкренләп тындылар. Мин дә кырынрак ятып, башны снаряд ящигына терәдем. Вагон бер көйгә салмак кына чайкала, ә колак төбендә генә тәгәрмәчләр өзлексез такылдыйлар... Аннары йокы барысын да йотты.

...Минем кечкенә балам бар икән, ләкин ул тавык күкәе эчендә, имеш. Мин шул күкәйне учымда сак кына тотып йөртәм. Ә бала күкәй эченнән бик ачык-нечкә тавыш белән: «Әти, мине төшереп җибәрмә!» дип әйтә, имеш... Борчылып, кая гына куеп торыйм икән үзен дип, мин иске, ватык җиһазлар белән тулы бер бүлмә эчендә тыныч, хәвефсез урын эзләп, бәрелә-сугыла йөрим икән...

...Кинәт вагон каты гына тартылып куйды — мин, сискәнеп, күзләремне ачып җибәрдем. Менә сиңа кирәк булса төш! Кайдан гына табыла диген, әкәмәт?!. Әмма күкәйне төшереп җибәрмәдем, юк, җибәрмәдем!..

Торып, вагон ишеген ачтым. Төн, бетмәстәй төн, әкрен генә сыекланып, офыкларга таба чигенә башлаган, иренеп кенә салкын-соры көн туып килә, ә поезд яңа төзәтелгән юлны үтә шикелле — бик сакланып кына китеп бара. Әйләнә-юньдәге күренештә дә үзгәреш юк диярлек: якында һәм еракта утрауларга охшаган урманнар, урманнар арасында җыйнак кына басулар, басулар янында ялгыз утарлар, ләкин мондагы утарлар төзегрәк тә, баерак та икән!.. Алар әйләнәсендә ниндидер тын бушлык хөкем сөрә кебек — бер дә җан иясе барлыгы сизелми. Бу — Латвия җире...

Безнең поезд вак-төяк станцияләрдә туктап тормыйча шактый кызу барды. Тик юлның яңа төзәтелгән яки төзәтелеп яткан урыннардан гына бик әкрен узды. Вакыт-вакыт ачык кыр уртасында туктап та торгалады. Мин инде, капитан кушканча, һәр тукталыштан файдаланып, часовойларны алыштыра килдем.

Шулай бара торгач, без кичкә табан, ниһаять, бер зур гына

станциягә килеп життек. Монда рәт-рәт сузылган юллар да күп иде, юлларга килеп тыгылган эшелоннар да күп иде, күмер, мазут, төтен исе дә житәрлек — ахрысы, бер узловой станция булса кирәк. Мин вагоннан төшеп, капитанны күрер өчен паровозга таба киттем. Бередә күпме торырбыз икән — шуны беләсем килде... Барышлый, состав буенда капитан үзе миңа очрады.

— Я, эшләр ничек, сержант? — дип сорады ул миннән, килеп житүгә.

— Эшләр ярыйсы хәзергә, иптәш капитан!

— Ярыйсы күренә шул,— диде ул, мине баштанаяк карап.— Өс-башыгыз чиста, артык изелмәгән дә, спальный вагонда килгән шикелле... Инде миңа карагыз!

Чынлап та капитанның кыяфәте шәптән түгел иде: шинеле күмер тузанына буялып беткән, йөзендә дә кара таплар, үзе дә бик йончыганга охшый.

— Әшәке нәрсә икән ул паровоз, моннан соң утырырга язмасын! — диде ул, кулын селтәп.

— Әллә безнен янга күчәсезме, иптәш капитан?

— Юк, булмый, ярамый,— диде ул сүлпән генә.— Хәзер мин комендатурага барып, шунын берәр почмагында әзрәк йоклап алмакчы булам. Теге жәһәннәм казанында бер бөртек тә күз йомарга туры килмәде...— һәм мин сораганны да көтмичә өстәде:— Без монда шактый торачакбыз әле.

— Шулай да күпме?..

— Тәгаен әйтә алмыйм, һәрхәлдә, төн урталары житмичә жибәрмәсләр.

— Иптәш капитан, ә сәбәбен белергә ярыймы?

— Сәбәбен... Сәбәбен мин сезгә китәр алдыннан әйтермен. Ә хәзер сез дә бу вакытны файдаланып калырга тырышыгыз. Әйбәт кенә ашап-эчеп алыгыз, чиратлап ял да итегез — бу төнне безнең беребезгә дә күз йомарга туры килмәячәк. Менә шул. Үзегез эшелоннан бик читкә китеп йөрмәгез, солдатларны да таратмагыз... Ә мине, бик кирәксәм, комендатурадан табарсыз!

— Яхшы, иптәш капитан!

— Ну пока!..

Ул китеп баргач, мин аз гына уйланып тордым: төн уртасына чаклы монда торуның сәбәбе нәрсәдә икән?.. Капитан ни өчендер әйтеп бетермәде, ләкин аның сүзләреннән ниндидер бер куркыныч барлыгы шулай да сизелеп калды. Нәрсә булырга мөмкин? Бәлки, тәгаенләнгән жиргә (алгы позициягә) барып житәргә күп калмагандыр, һәм безнеке кебек хәтәр йөкне ул жиргә бары төнлә генә илтеп житкерергә ярый торгандыр. Тагын нәрсә?.. Хәер, юрап маташудан мәгънә юк, вакыты житкәч белербез.

Вагонга борылып кайткач та мин солдатларыма:

— Менә нәрсә, егетләр! — дидем,— без монда шактый торачакбыз икән әле... Әйдәгез, ашап-эчеп алу ягын карыйк. Бу зур станция, бәлки кайнаган су табарбыз.

Моны ишетүгә Дурду урыннан сикереп торды:

— Һе, сержант, кая үзем генә табып килим булмаса!

Ләкин минем аны ялгызын гына жибәрәсем килмәде. (Моның кебек зур жирдә аның үзенә кирәк «суны» да эзләп, мутланып йөрүе бар.) Шуңа күрә мин:

— Әнә, Төхфәт абзый белән икәү барырсыз,— дидем.

— Бер бидерә сугамы? — дип гажәпләнгән булды Дурду.

— Әйе, ике ягыннан тотып китерерсез, жиңелрәк булыр... Ләкин әллә кайларда йөрмәгез, туры станциянең үзенә барыгыз, тапсагыз, шул тирәдән табарсыз.

Солдатларның кайберләре:

— Җылы аш ашыйсы иде бит, сержант! — диделәр.

— Ашыйсы иде шул,— дидем мин, бик килешеп.— Ләкин кайда пешерәсең аны? Монда бит төшеп, ут ягарлык кыр-мазар юк, үзегез күрәсез!.. Ярый инде кайнар су тапсак...

— Ә тапмасак?

— Ул чагында паровоздан алырга туры килер...

Солдатлар чырайларын гына сыттылар. Паровоздан алган су чынлап та бик тәмсез ул...

— Берәр хәзәйкәдән булса да кайнатып алам! — диде Дурду, бик кисеп. Мин инде каршы дәшеп тормадым.

Алар Төхфәт абзый белән икесе, чиләкне алып, вагоннан төштеләр дә составлар астыннан иелә-иелә чыгып, станциягә таба китеп бардылар.

Шулай да безнең бәхет бар икән, озак та үтми, болар бер чиләк кайнар су белән кайтып та җиттеләр.

— Кайдан таптыгыз? — мин әйтәм.

— Кипәтүк алачыгыннан,— ди Төхфәт абзый.

Чиләккә тиз генә бер әчмуха чәйне тондырдык та, суынмасын өчен, өстенә сөлге каплап куйдык. Вагон идәненә плащ-палатка җәеп, түгәрәкләнеп утырдык. Капчыклардан ипине, шикәрне чыгардык, берничә «сыер тушонкасы»н ачып куйдык. Бушатырга тәлинкә-мазар юк, пычак очы белән генә казып, әләктереп ашый башладык. Емелькин шуның өстенә әле чүпрәккә төргән шпигын чыгарып, телем-телем кискәләп, бик тәмләп кенә ашарга тотынды. Казакълар аңардан җирәнәләр:

— Кафер, кодайдан да курка белми! — диләр.

— Ә минем кодай башка! — ди Емелькин, шпигын чәйни-чәйни.

— Алла — бер,— дип куя Ишмәмәт, тыныч кына.

— Емелькәнең алласы, үзе кебек, чуваш гой! — ди Шанаев.

— Гуй, гуй! — ди Емелькин, аны үчекләп.— Ә сезнең үз аллагыз юк, сез алланы татарлардан алгансыз. Ышанмасагыз, әнә, сержанттан сорагыз!.. Сержант, казакъны намаз укырга сез өйрәткәнсез бит?

Мин көлеп җибәрәм — каяндыр, нидер ишеткән бит бу шайтан Емелькә!.. Гомумән, боларның ачусыз гына әрепләшүләре һәрвакытта шулай көлке килеп чыга һәм күп очракта көлешү белән бетеп тә куя.

Ни бары белән ашап-эчтек... Эч тулды, күңел хуш булды. Төшеп, җиргә чүгәләп кенә тәмәке дә тарттык. Инде караңгы да төште, тагын озын, бик озын төн башланды. Безнең паровозда һичбер җан әсәре сизелми — күрәсең, торачакбыз әле... Солдатлар менеп печән өстенә ятканнар иде инде. Мин дә арлы-бирле йөрендем-йөрендем дә, менеп, Төхфәт абзыйның аркасына терәлеп кенә яттым. Ахрысы, якташның җылысыннан мин шунда ук йоклап та киткәнмен.

Күпме вакыт үткәндер, белмим, менә бер заман вагонның селкенүен ничектер сизәм шикелле... Ләкин һич уяна алмыйм. Ә акылның ниндидер бер ноктасы миңа «уян, уян!» ди... Ахырда күземне ачып җибәрдем. Бу ни хикмәт? — китеп барабыз түгелме соң? Тиз генә торып, вагон ишеген ачып карыйм: ой-бой, чынлап та барып ятабыз гой!.. Ә тышта ерып йөри алмаслык кус-кара төн!

Күпмедер баргач, эшелоныбыз туктады. Башны тыгып карыйм-карыйм, әмма яланмы-кырмы, берәр станция-мазармы — һич кенә дә белеп булырлык түгел. Шул чакта состав буйлап килгән берәүнең башта аяк тавышы, аннары дәшкән тавышы да ишетелде:

— Сержант!

Бу безнең капитан иде. Мин тиз генә җиргә сикереп төштем.

— Мин монда, иптәш капитан!

Ул килеп, караңгыда бәрелешмәс өченме, мине капшап карагандай итте, аннары әкрен генә:

— Әйдәгез, бераз читкәрәк китик әле,— диде.
Без вагон буйлап читкәрәк киттек.
— Менә нәрсә, сержант,— дип, сүзен башлады капитан, тыныч, әмма киеренке бер тавыш белән,— без хәзер юлның иң куркыныч өлешен үтәчәкбез. Куркыныч шул: без үтәсе бу арага немецлар авыр туплардан атып торалар... Шуңа күрә һәртөрле көтелмәгән хәлгә әзер булып торырга кирәк. Часовойларны да тамбурлардан алырга туры киләчәк. Барыгыз да бер урында булырга тиешсез. Ләкин курку булмасын, паника булмасын, нык тот үзләрен!.. Аеруча кисәтеп әйтәсем килә: бер генә бер тычкан уты да күренмәскә тиеш. Фонарегызны яндырмыйсыз, хәтта бер генә секундка да! Безгә кап-караңгы төн кирәк, аңлыйсыңмы?
— Аңлыйм, иптәш капитан!
— Юлның бу куркыныч өлеше озын түгел, бер өч километр чамасы гына, ләкин аны бик әкрен үтәргә туры киләчәк. Менә шул әкрен барудан файдаланып, кайберәүләрнең җиргә төшәселәре килер, ләкин сез моны һич тә рөхсәт итмәгез! Бары иң актык чиктә генә, ну әйтик, составка берәр снаряд тия калса гына, барыгыз да вагонны ташлап, җиргә сикерегез... Шуңа әзер булып торыгыз!
Капитан авыр гына сулап куйды, ә мин тын да алмыйча аны тыңлап тордым. Эшләр әнә ничек икән!.. Нидер сорыйсы килә, ләкин сорар нәрсә юк. Әйтер сүз дә юк. Әллә ни каушамадым да шикелле, ә шулай да менә тел бәйләнде.
— Ярый, сержант,— диде капитан, минем шул хәлне сизгәндәй,— тыныч булыгыз! Бәлки әле, шома гына үтеп тә китәрбез, юл үзебезнеке!.. Ә хәзер часовойларыгызны алыгыз.
Ул китә башлагач кына мин кинәт исемә төшкәндәй сорадым:
— Ә солдатларга әйтергәме, иптәш капитан?..
— Әйтергә кирәк, әлбәттә,— диде ул.
Аның артыннан ук мин часовойларны барып алып кайттым. Вагонга менгәч, аз гына хәл җыеп тордым. Ничектер ашыкмыйча, тыныч кына әйтергә кирәк иде. Посттан кайтучылар да иптәшләре белән сүз алышудан, кыштырдаудан туктасыннар... Аннары сорадым:
— Барыгыз да уяумы?
— Уяу шикелле,— диде кемдер.
Мин электр фонарен бер генә мизгелгә яндырып, вагон эчен «капшап» карадым.
— Әнә теге кем ул, уятыгыз әле!
Дурду аны төрткәли башлады:
— Әй, Шанай, Шанай дим, торсаңчы!.. Сержантның безгә әйтер сүзе бар икән!
Алар селкенешеп, мышнап тынгач, мин:
— Хәзер генә капитан килеп китте,— дидем,— без алгы позициягә якынлашабыз икән... Дошман ерак түгел... Капитанның боерыгы шул: тугарылып ятмаска, бөтенесенә әзер булып торырга!.. Мылтыкларыгыз янныгызда булсын! Тыныч кына утырыгыз! Мин әйтмичә кузгалу юк, төшендегезме?
— Төшендек, сержант! — диде Байәхмәт барысы өчен дә.— Әмма кая чаклы барамыз без, алгы позициягә якынлашкач, нигә туктамаймыз?.. Шуны әйтеп бирсәңче безгә, сержант!
— Билгеләнгән урынга тиздән барып җитәргә тиешбез, тик юлның шушы... куркынычрак төшен генә үтәсе бар,— дидем мин, ләкин дошманның туптан ату ихтималын әйтеп тормадым. Әллә ата, әллә юк, дип уйладым. Баштан ук куркытып куясым килмәде.
Солдатлар бүтән бер нәрсә турында да сорамадылар. Әмма бик тын калып утыруларына караганда, нидер сизенәләр иде шикелле...
Поезд бераздан тавыш-тынсыз, шома гына кузгалып китте. Күпме-

дер вакыт ул кызу гына барды, аннары әкренәя башлады... Әкренәя, әкренәя, һаман әкренәя, ниһаять, бөтенләй туктаган кебек булды... Мин ишекне баш сыярлык кына ачып, тышка сузылып карадым, ләкин бу дөм караңгыда һич нәрсә күреп тә, белеп тә булырлык түгел иде... Барабызмы соң, туктап торабызмы?.. Чүгәләп, тәгәрмәчләргә колак салып карыйм: тәгәриләр булса кирәк, рельсның сыгылганы ничектер сизелгән кебек, ләкин һич берниндн ышкылган-ниткән тавыш чыкмый иде. Ахырда төшеп беләсем килде. Җиргә сикердем дә баскан җиремдә туктап калдым: вагон минем яннан үтәме, юкмы?.. Үтә шул, үтә!.. Әмма шул кадәр әкрен үтә ки, хәтта җәяү атлап та бу кадәр әкрен барып булмас иде. Исем китте минем бу хәлгә!.. Состав очына карадым. Паровозны күрү түгел, аз гына шәйләп тә булмый иде. Ул әйтерсең бөтенләй юк!

Яңадан вагонга менеп, ишекне бер генә карыш ачык калдырып, кире шылдырдым. Дурду шунда ук сорап куйды:

— Кайда туктап торамыз, сержант?

— Туктап тормыйбыз — китеп барабыз!

— Барамыз... Поезд шулай барамыни?

— Бара икән шул!..

Мин идәнгә, ишекнең ябылып бетмәгән кырыена урнаштым. Нидер көткәндәй, тын гына утырабыз... Һаман бер уй борчый мине: ни өчен без юлның бу хәтәр өлешен бик кызу гына үтеп китмибез, ни өчен бу хәтле әкрен өстерәләбез?.. Күрәсең, кызу үтәр өчен паровоз топкасына гел күмер ташлап барырга кирәктер, күмер ташлагач, морҗадан төтен белән бергә чаткылар да оча торгандыр... Ә бу инде күзәтеп яткан дошманга үзеңне сиздерү була, күрәсең... Шулай уйларга өлгермәдем, каядыр шактый еракта зур агач чүкеч белән нәрсәгәдер китереп суккан шикеллерәк тавыш ишетелеп калды һәм шуның артыннан ук бер авыр снаряд составтан уңдарак төшеп тә шартлады. Солдатлар сискәнеп киттеләр, ләкин ни булганын шунда ук аңлап җиткермәделәр, ахрысы. Тик Емелькин гына: «Бусы тагын нәрсә?» — дип куйды. Мин җавап бирергә ашыкмадым, мин, тын да алмыйча, ату тагын кабатланырмыюкмы дип көттем. Бик озак тоелды бу көтү... Ниһаять, минә кинәт җил исеп киткәндәй булды, һәм тагын бер снаряд состав өстеннән очып, юлның икенче ягында ухылдап шартлады. Бу юлы инде берничә солдат беравыздан кычкырып җибәрделәр:

— Бу ни тамаша? Нәрсә бу?..

— Шауламагыз! — дидем мин, тыелып кына.— Ишетмисезмени, немец атып маташа!

— Немец ата?!. Ах, бәдбәхет!

— Белеп атамы, белмичәме?

— Белмәсә дә ата инде ул,— дигән булдым мин, аларны әзрәк тынычландыру өчен.— Тик ятудан курка немец!

— Үз башына булсын! — дип куйды Төхфәт абзый.

Шул арада өченче снаряд шактый якында төшеп шартлады. Бу юлы Дурду сикереп торды.

— Сержант, ата гой! Нишлибез?

— Бер нәрсә дә эшләмибез, тик кенә утырабыз! — дидем мин, һаман тышка колак салып.

— Ничек ул алай?.. Мондый чакта тик кенә утырып буламыни?

— Була, Дурду, була,— дидем мин, ачулана башлап.— Тик шыр җибәрмәскә кирәк!

Солдатлар бер мәлгә тындылар... Хәзер мине (мине генә түгел, барыбызны да, билгеле) бер генә уй биләп алган иде: ни булып бетәр моның ахыры?.. Чынлабрак уйлаганда безнең хәл искиткеч мөшкел иде, без кыл өстендә, без һәлакәтнең кырында гына торабыз...

Дөрес, боеприпаслар тулы составның шартлаганын безнең күргәне-

без юк, ләкин моны күз алдына китерүе бер дә читен түгел. Әгәр шуннан бер генә снаряд берәр вагонга тия калса... Әмма коточкыч бу хәлне күз алдына китерүдән курыкмаган акылга каршы кешенең җанын, өметен саклый торган бик могҗизалы күңел дигән нәрсәсе бар әле: шушы иң хәтәр минутта да миһербанлы күңел мине һәм минем иптәшләремне, снаряд безгә тимәс, тисә дә, иң очтагы вагонга гына тияр, ул шартлаганчы, аңа ияреп башкалар шартлый башлаганчы, без сикереп төшеп өлгерербез, без юл буендагы чокырга тәгәрәп өлгерербез, дип юатып кына тора... Бу инде, бәлки, мәгънәсез юанычтыр, әмма кирәк ул, кирәк, кирәк!..

Ә немец ата, төгәл бер интервал аша ата да ата. Без һәр снарядның кайдарак төшеп шартлаганын көтеп, тыңлап утырабыз. Дошман сукыр килеш, чамалап кына ата булса кирәк, күп кенә снарядлары безгә килеп җитмичә төшеп шартлыйлар. Тик кайберләре генә якын төшкәлиләр. Ләкин берсе дә бит аның безгә бик җиткән!..

Мин, ишек ярыгына бер аягымны терәп утырган килеш, вагон эченә дә колак салгалыйм. Иптәшләр, җаннары учларында булса да, болай тып-тыныч кына утыралар. Тик Байәхмәт кенә авыз эченнән үгез шикелле һаман нидер мөгрәнә — белгән догаларын укып маташа, ахрысы. Кемдер әледән-әле тамак кыргалый, кайсыдыр, Емелькин булса кирәк, снаряд төшеп шартлаган саен «Ух, гад!» дип куя. Ә менә Ишмәмәтнең бөтенләй өне-тыны юк, бу галәмәт башланганнан бирле шулай тавышын чыгармый. Ни хәлдә икән ул, бичара?!

...Кинәт — мин сизми дә калдым — бик якында гына авыр снаряд яман гөрселдәп шартлады. Безнең вагон хәтта чайкалып куйгандай булды. Шул ук мизгелдә Шанаев әче тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Сержант, ач ишекне!

Мин секундның күпмедер бер өлеше дәвамында аптырый калдым, хәтта аягым белән ишекне шылдырып җибәрә яздым, ләкин шул секундта ук сикереп торып, ишеккә аркам белән терәлдем:

— Якын киләсе булма, Шанай!

— Синең безне монда тотарга хакың юк! — диде Шанаев, отыры чәрелдәп.

— Бар, паника куптарсаң, атарга да хакым бар!

Шул арада Дурду, Шанайның чабуыннан тартып булса кирәк, аны шап иттереп кире идәнгә утыртты:

— Бакырма, ишәк!

Шанай ямьсез итеп шыңшый башлады, ә Байәхмәт гадәтенчә салмак кына:

— Куйсаңчы, Шанай! — диде.— Әҗәлнең кайда икәнен белеп буламыни? Әллә җирдә, әллә монда, кодайның бер үзенә тапшырыйк!

Ниһаять, барыбыз да әзрәк тынычландык. Шулай да нык икән әле безнең абзыйлар!.. Шанаевка ияреп түгел, селкенеп тә карамадылар. Ә бит дөресен генә әйткәндә, вагон эчендә безгә йөз мәртәбә куркынычрак — моны һәркайсыбыз белеп торабыз. Әмма ләкин солдат психологиясенең гаҗәеп бер сере бар — нәкъ менә иң куркыныч, иң киеренке чакта ул иптәшләреннән аерылырга һәм теләсә кая ташланырга яратмый. Ни күрсәк тә бергә! — һәм шушы нәрсә аларны күп вакытта паникадан коткарып та кала.

Теге котыбызны алган снаряд соңгысы булды, ахрысы, бүтән якынтирәгә төшкәне ишетелмәде. Ләкин немец һаман ата иде әле. Поезд да шулай чак-чак кына шуышып бара. Иң җанга тигәне, иң ачуны китергәне — шушы әкренлек!.. Болай шуышып, кайчан гына без дошман уты астыннан чыгарбыз соң?!. Түзәргә инде, ничек кенә булса да түзәргә!..

Һәм менә күпмедер вакыттан соң немец снарядларының каядыр составтан арттарак төшеп шартлаганы сизелә башлады. Мин бөтен игътибарымны җыеп, һәр снарядның каярак төшкәнен чамалап, тың-

лап кына торам. Юк, чынлап та отыры арттарак шартлый бит, отыры арттарак!.. Я хода, үтәбез, чыгабыз, котылабыз шикелле! Моны мин генә түгел, солдатлар да бик яхшы сизеп торалар иде. Алар жанлана төштеләр, селкенә, кыймылдый башладылар. Ә Дурду хәтта дәртләнеп:

— Байәхмәт! — диде.— Тагын бер аять әйтсәң, котыламыз гой!.. Давай, туктап торма!

Ә бераздан инде без вагон тәгәрмәчләренең кызурак тәгәри башлавын сиздек. Минем моңа чынлап ышанасым килде. Шауламаска кушып, мин тәгәрмәчләр тавышына бик нык колак салып тордым. Әйе, алар кызурак тәгәриләр, рельс ялгаулары өстеннән ешрак сикереп узалар... Ләкин шулай да бу әле чынлап торып кызулап китүгә охшамый иде. Ә дошман снарядларынын якында гына түгел, артта шартлаганы да ишетелми башлады. Туктады, ахрысы, мөртәт! Хәзер инде ишекне ачып, юл буена карарга да ярый торгандыр. Әллә азрак кына сабыр итәргәме?

Кинәт поезд тартылып куйды, вагон буферлары шакылдашып алдылар... һәм менә паровозның авыр сулап алга омтылуы ишетелде. Мин түзмәдем, ишекне бөтен көчемә шылдырып ачып жибәрдем. Тизрәк сузылып паровоз ягына карадым. Паровоз чаткылы төтенен ишеп чыгара-чыгара алга ыргыла иде. Отыры кызурак, кызурак!.. Бу инде котылу иде, котылу!..

Мин, бүрегемне баштан сыдырып алып, вагон эченә кычкырдым:

— Иптәшләр, бетте, котылдык!

Барысы да ишеккә ташландылар — мине чак этәреп төшермәделәр. Сузылып-сузылып бер алга, бер артка карадылар. Кычкырдылар, шауладылар, сүгенделәр:

— У-у фашист, атаңа нәләт!

— Жиде бабаңның гүр тактасын...

— Аллага мең шөкер!

— Шанай, бар сикер, ник сикермисең?!

Аннары бер-берсенә шап-шап суктылар, берсен-берсе төртеп-төртеп жибәрделәр, ә Емелькин, чувашча такмак әйтә-әйтә, идән уртасында тыпырдап биергә үк тотынды... Шулай тилерешеп алдылар безнең карт солдатлар. Тик бу галәмәт эчендә Ишмәмәтнең генә барлыгы сизелми иде. Мин электр фонарен кабызып, вагон эчен яктыртып карадым. Бер почмакта, чәйханә сәкесендәге шикелле, аякларын бөкләп, тын гына һәм тик кенә Ишмәмәт утыра... Утыра, әйтерсең бернәрсәдә гаме дә, эше дә юк! Мин бик гажәпләндем.

— Нишләп утырасың, Ишмәмәт әкә?

— Тамаша кылып,— ди бу тыныч кына.

— Нәрсәне тамаша кылып?

— Менә бу адәмнәрнең тилерүен...

— Алар бит шатлыктан тиләрәләр... Нигә, син исән калуына шатланмыйсыңмыни?

— Ә мин, ортак сержант, исән каласымны алдан ук белеп тордым,— ди ул, бер дә исе китмичә генә.

— Кайдан, ничек итеп?

— Минем береннән-бере кечек дүрттә балам бар кү! — һәм кулын идәннән күтәрә-күтәрә балаларын күрсәтә башлый.

Безнең бу сөйләшүне тынлап торган солдатлар моны ишетүгә, бердәм шаулап, Ишмәмәтне тиргәргә тотындылар:

— Эх, син, дивана!

— Шашкан адәм!

— Кодайның мәжнүн колы!

Әмма бу һич ачусыз, бары күңелләре ташудан тыела алмыйча гына тиргәү иде. Билгеле инде, үзенең үлемсезлегенә ышанган безнең Ишмәмәт моның ише тиргәүләргә ниндидер бер өстенлек белән, сабыр гына елмаеп карый...

# Нури Арсланов

# ЕЛЛАР, ЯЗМЫШЛАР

*Биографик парчалар*

Тәнкыйтьчедән мондый әсәрләргә
Киресенчә була гел бәя:
Чәчмә итеп язсаң — поэзия,
Тезмә итсәң — гади хикәя...
Ни булса — ул, салдым тезмәгә,
Ошар әле бәлки сезгә дә.

●

Олыгайган саен
Үткәннәрем
Искә ешрак төшә, мин анда
Сары чәчле бер шук малай идем,
Туры килдем гаҗәп заманга:


Шауладылар: «Милләт! Хөррият! — дип,—
Көн килде,— дип,— бәни исламга!»
Гаскәр җыеп йөрде «Яшел байрак»:
«Коралланыйк форсат кушканда!

Без аклар да, кызыллар да түгел,
Максатыбыз — изге газават!»
Унбиш яшьлек Закир абый алды
Мылтык һәм ат — булды азамат!

Әни каршы иде,
качып китте.
Качып кайтты дүрт-биш атнадан.
Башындагы кара папаханың
Бөдрәләре күзен каплаган...

Кайда ул ат, мылтык һәм азамат?!.
Борын тартып тора таптанып.
Әни аны башта тиргәсә дә,
Кочаклады соңра шатланып.

Кызылларга чыккач,
коралларын,



Атын алып, акыл биргәннәр:
«Сөйләшербез бераз үсә төшкәч,
Бар, кайтып тор әле»,— дигәннәр.

●

«Яшел байрак»-фәлән кебекләрдән
Халык бик тиз йөзен чөерде:
Бөек көрәш ташкынына эләккән
Төрле чүп-чар читкә чөелде.

Агылдылар безнең кала аша
Анненковлар, Дутовлар... чиксез...
Ә без йолдыз тактык күкрәкләргә,—
Тик кызыллар яклы идек без!

Ленин исеме җиңүчеләр белән
Байракларда килде, җырларда,
Яңгырады илдә яңа моңнар,
Яңа көйләр яңа кылларда.

Күкрәп торды анда «Марсельеза»,
«Бәйнәлмиләл» илне уятты,
Елатты бу моңнар берәүләрне,
Берәүләрне сөеп юатты.

Җыелдылар яшьләр нардомнарга,—
Тоталмады дин дә, гадәт тә:

Сусаганнар икән иркенлеккә,
Яши торгач гел бер халәттә.

Мәскәүгә юл тотты Закир абый,
Үз йолдызын шунда тапты ул:
Яза иде горур йөрткәнлеген
Кызыл курсант дигән атны ул.

●

Гражданнар сугышы давыллары
Күкрәп узгач безнең якларда,
Әни китте Омбы каласына[1],
Съездга дип, утырып атларга.

Сөйләде ул кайткач шундый итеп:
Чуен коя торган мичләрне,
Сәхнәдәге гүзәл аккошларны...
Ә Коллантай телдән төшмәде!

Татар хатыннары фай күлмәктән,
Чиккән калфаклардан килгәннәр.
«Буржуйкалар түгелдер бит, нигә
Киендегез болай?!» дигәннәр.

Күрсәткәннәр болар Коллантайга,—
Ул бик зәвык белән киенгән! —
Бөтен җире балкып торган аның,
Әйтерсең лә туйга дип килгән.

Европада Жан Жореслар[2] белән
Турне ясап илләр гизгән ул.
Халыкларны азатлыкка өндәп,
Күп азаплар чиккән — түзгән ул...

Алыштырган гаиләсе бәхтен
Халыклар һәм илләр бәхтенә,
Алыштырыр өчен патшаларны
Азатлыкның бөек тәхтенә.

●

Мин сабыйның шуңа хыялында
Кызыл байрак тоткан Жореслар,
Коллантайлар иде каһарманнар —
Париж таңнарына варислар.

Соңга таба Марат, Робеспьерлар,
Мәктәп җәдвәлләре аркылы
Күтәрелеп басты күз алдына.
Париж коммунасы ялкыны

---

[1] Омбы — Омск каласы.
[2] Жан Жорес — француз компартиясе җитәкчесе.

Алсуланды безнең күңеллэрдә.
Шулай булды безнең язмышлар:
Агач мылтык асып, хәнҗәр тагып,
Шаулап үстек татар Гаврошлар.

●

Закир абый кайтты, винтовкасы
Үзе белән бергә — янында,—
Илдә әле һаман диверсия,
Заговорлар барган чагында.

Мин шлемын киеп абыемның
Малайларның күзен яндырдым,
Каешын да бирде,
а мылтыгын...
Киләчәккә диеп калдырды.

Ул киләчәк чынлап килеп җитте.
Бу турыда ләкин соңыннан.
«...Каркаралга, Уком комсомолга...»
Дигән кәгазь килде Губкомнан.

Кәрәкәүнең[1] сәйран далаларын
Алыштырды шулай таш таулар.
Шул тауларда, ахры, уяндылар
Иҗат серен аңлый башлаулар!..

●

Онытасым юк ямен
Каркаралдан
Кызылъярга[2] кайту юлының.
Дүрт-биш тапкыр үтеп чыккан идек
Без кечүен Нора суының.

Нора суы ука булып яткан
Тугайларга, дала өстенә.
Тарих монда ерак бабайларның
Кичерешләрен искә төшерә.

Ә Күкчәтау!
Туган айлы булып
Истә калган никтер кышлары.
Бер мәктәп бар иде безнең анда —
Татарларның изге штабы:

Җыела идек шунда бәйрәмнәрдә
Кичәләргә.
Шушы төп йортта
Олы җанлы ватандарлар булдык,
Һәм җитештек балигъ булып та.

---

[1] Кәрәкәү — Коряков, Павлодарның борынгы исеме.
[2] Кызылъяр — Петропавловск каласының төркичәсе.

Кукчэтауның яшел мәктәбеннән
Озатканда әни Казанга:
— Бабаларың йортын бәйнә-бәйнә
Онытма син,— диде,— язарга.

●

Казан, сине беренче кат күрү
Истә әле, истә хәзер дә:
Таулы-үрле сәер урамнарың,
Алма исең килә хәтергә.

Беренче кат таныш манараңны
Күрдем, Казан, вокзал турыңнан.
Таныш: ишетеп, рәсемнәрдән күреп,
Укып бөек Тукай җырыннан.

Шул манара төпләрендә элек
Корбан булган күпме каһарман.
Хатирәгә кабер ташлары да
Сакланмаган хәтта алардан...

Рус патшалар белән алышынган
Татар тәхте — татар ханнары:
Тик халыкка төшкән бар шомлыгы,
Күккә ашкан аның аһ-зары...

Шуңа Уралдамы, Себердәме,
Урта Азиядәме... кайда да
Уртак уйлы татар,
ул табынган
Ирек дигән тик бер аллага.

Кешелекле, тугры, батыр халкым
Күтәрелгән шушы нигездән,
Октябрьда беренчеләр белән
Давылларда атлап бер эздән,

Юлбашчыбыз Ленин өндәвенә
Бар халыклар белән кушылган,—
Гасырларча изгән коллыгыннан
Ул котылгы тапкан шушыннан.

●

Шул Казанда, сәнгать мәктәбендә
Үткәргәндә яшьлек елларын,
Мин таныдым пәйгамбәрләр итеп
Италиянең бөек улларын:

Леонардоны, Микель, Рафаэльне...
Мин охшарга теләп аларга,
Илһам эзләп, Идел буйларына
Чыгып китә идем таңнарда.

Илһамланып кире кайткан чакта,
Идел манзарасы урнына,

Яңа язган бер мәхәббәт шигыре
Була иде минем куйнымда.

Үзем уйлый идем: Мадонналар
Иҗат иткән бөек рәссамнар,
Нигә инде батыр Спартакка
Язмаганнар рәсем-дастаннар?!.

●

Дәрдмәндне, Тукайларны яттан
Белә идем.
        Менә Такташны
Беренче кат күрдем мин урамда.
Аның сыны, аяк атлашы,
Елмаюы...
        бөтен хәрәкәтен
Таныш кебек тойдым күптәннән.
Ә күзләре!
        Шигърияген Такташ
Шул күзләрдән, ахры, үткәргән.

Мин шуннан соң күпме көзгеләрдән
Үз күзләрем серен эзләдем:
Юләр яшьлек! — бик борчыла идем
Табалмагач шагыйрь күзләрен.

Баксаң, үзенчәлек канун икән
Карашларда, моңда, йөрәктә...
Шулай да мин Такташ күзләренә
Карыйм әйбәт шигырь кирәктә.

●

Менә җитте абый әйткән теге
Мылтык-кылыч алыр киләчәк:
Мин сугышка киттем үзем теләп,
Күрик, язмыш нәрсә бирәчәк?!.—

Идел йорттан Суомига[1] җиттем,
Беренче кат дары исләрен,
Янган атлар, туплар, калаларның
Көек исен шунда иснәдем.

Кар илендә беренче кат белдем
Вәхшилекнең нәрсә икәнен:
Дәүләт, милләт дигән төшенчәләр
Акыллыны ахмак иткәнен!..

●

Еллар үтте.
        Шомлы кырык бердә,
Су буенда безнең төркемне,

[1] Суоми — Финляндиянең финчә аталышы.

Кинәт баскан хулиганнар төсле,
«Сугыш!» дигән хәбәр өркетте:

Хатын-кызлар никтер елаштылар...
Ә мин гаҗәп бер хис кичердем,—
Өйләнмәгән хатыным һәм тумаган
Балаларым искә төшердем...

Мин, Финдәге кебек, бусында да
Теләп китмәк булган идем дә,—
Кырт кистеләр:
«Ватан сафка баса!
Нәүбәт җитәр, егет, синең дә».

●

Без — өч туган идек,
әни безне:
«Өч терәгем — алтын баганам!»
Дия иде,
җайсыз була иде
Моны ишетү горур анадан...

Алай алтын белән тиңләшерлек
Кайсыбызның булды зур эше?!
Хәер, әни өчен булса гына...
Менә чыкты ватан сугышы:

Зилзиләдән алтын баганалар
Кузгалдылар шунда барсы да:
Өч арыслан булып ташландык без
Фашист дигән ерткыч каршына.

Закир абый, батыр солдат булып,
Ятып калды Мамай Курганда...
Ә Хәйретдин, фашистларны куып,
Барып җитте ерак Болгарга.

Скрипкада татар моңы уйнап
Юанган ул, илен яд иткән.
Шуңа аның Болгариядән кайткан
Кушаматы — «Мюзик капитан».

●

Колшәрифләр, Япанчылар кебек [1],
Тәвәккәлгә салып башымны,
Төрле милләт солдатлары белән,
Үз иркенә куеп ачуны,

Кан түктем мин сугыш кырларында;
«Без җиңәргә тиеш!» дидем мин,—
Кышкы сарай алган армиянең
Бер солдаты кебек идем мин.

[1] XVI йөздә ил өчен сугышта һәлак булган каһарманнар.

Ерак түгел Муса, Фатих йөргән,—
Минем кебек утта, пехотта:
Сараиның күпме варислары
Башын салды шушы походта...

Верещагин өйгән тау — таумыни![1]
Менә безнең заман яулары
Уздырдылар:
болытларга җитте
Сөякләрдән өйгән таулары!..

Бергә мәйдан тоткан дуслар белә,
Яклаганда Ватан, Ил хакын,—
Тугрылыкта нәкъ Пиладтай[2] тугры,
Аттай чыдам татар солдатын!

●

Кайчагында басып алуларны
Бозык тарих тырыша акларга:
Прогресс кирәк,
ярдәм кирәк, имеш,
Җәһаләттә калган якларга.

Шул «ярдәмне» күпме миссионерлар,
Күпме яулар өләшеп йөргәннәр:
Берәүләрне алдап, берәүләрне
Кылыч айкап басып кергәннәр.

Кол булганнар, яки бөтенләйгә
Югалганнар илләр, халыклар!
Югалганнар: Шумер һәм Бабилләр[3],
Тавр, Болгар...
Кемнәр аныклар —

Тагын күпме һәлакәтләр булган?!
Шуңа охшаш хәлләр гел безне
Озатып килә әле бүгенгәчә:
Талый, буа көчле көчсезне...

●

Ничә мең ел элек нинди булса,—
Кызганыч,
ул шулай хәзер дә...
Уйлаганда ерак үткәннәрне
Бер вакыйга төшә хәтергә:

---

[1] Танылган рус рәссамының «Сугыш апофеозы» исемле картинасына ишарә.
[2] Грек мифындагы Орест дусы Пилад исеме Европа халыкларында бөек тугрылык символы булып йөри.
[3] Шумер — Вавилон культурасына зур тәэсир ясаган халык. Бабил — Вавилон.

Рим котырган чакта илләр басып,
Понт җиренә яулар кул сала.
Мин кызганам әле дә
агу эчкән
Митридатны,
патша булса да:

Лукуллдан соң Помпей басып керә[1],—
Триумфатор көтә Рим-Сенат.
Хыянәт итә Тигран белән Фарнак[2],—
Һәлак була ил дип Митридат.

Безнең чорның үзенең хаиннәре —
Фарнаклары булды булуын:
Власовлар, бандерчылар чыкты...
Тик фидакарь ватан улының,

Җан түзмәслек авыр вакытларда
Какшамады рухы, төшмәде!
Ачы яшьләр кайчак эчсә дә ил,
Митридаттай агу эчмәде.

●

Безнең әни, барлык аналардай,
Илбасарлар явын каргады:
«Сугыш» дигән җәрәхәтле сүзне
Сыкранмыйча әйтә алмады...

Сугышлардан ике улы кайтты,
Закирын да кичтә, сәхәрдә
Көтте байгош...
көтте — ышанмады
Кара пичәт суккан хәбәргә.

Бик күрәсе килеп сагынып яшәү
Өмет бирә икән кешегә:
Акбүз атта, һаман исән булып
Закир керә иде төшенә...

Шул өмете белән дөнья куйды:
Ал байраклы гаҗәп заманда
Коллантайлар белән бергә типкән
Йөрәк тынды шәһри Казанда.

●

Кешелекнең инде акылы камил,
Күптән төшеп яшел бишектән,
Миллион чакрым ераклыктан серле
Планеталар тавышын ишеткән,

---

[1] Безнең эрага кадәр яшәгән Рим полководецлары.
[2] Митридатның кияве белән улы.

Алтын айга менеп, ай туфрагын
Җирдәгечә таптап, актарып,
Космос юлы ачып йөргән чакта,
Үз эшенә үзе таң калып,

Атом көчен канатлы ат итеп,
Гарешләргә кадәр ашканда,
Җир йөзендә берни булмагандай,
Җәһаләт үз эшен башкара...

Африкада, Азия күкрәгендә,
«Азат» Европаның түрендә
Ирек өчен канлы сугыш бара...
Гаҗәп түгелмени... бүген дә!

Берәүләре океан артларыннан
Баскан яулар белән тартыша,
Тетри дөнья бомбалардан,
искә
Безнең баштан кичкән дау төшә...

Берәүләре җимерек шәһәрләрдән
Сахраларга алып башларын,
Мәрхәмәтсез кояш асларында
Сусын итеп эчә яшьләрен...

Берәүләре бөек сугыш бетеп,
Төзәлсә дә тәндә яралар,
Кайталмыйча туган илләренә,
Җан ярасы белән яналар...

●

Әйе, хәлләр шулай, мин чыннан да
Туры килдем гаҗәп заманга:
Бер карасаң — ул бик мәгърифәтле,
Бер карасаң — җаһил һаман да!..

Шул җәһаләт белән алышканда
Чакыр безне сафка, илебез,
Теге Гаврошлардан үсеп җиткән
Коммунарлар хәзер инде без!

Бөек Ленин бездән риза булсын,
Гел елмайсын —
эштә, җырларда,
Ул теләгән изге теләкләрне
Алып барыйк чиксез елларга!

1972

5 «К. У.» № 9

Сәрвәр Әдһәмова

# ШУЛ БИШ НАРАТ

хикәя

Рәшитнең: «Барыбер Бишнаратка тиеп үтәм», дигән телеграммасын алгач, Сәлимә каушап калды. Аны каршы алырга барыргамы? Барса, аның күзенә ничек күренергә? Егет аңа алдакчы кыз дип караячак бит! Әллә ул килеп киткәнче берике көнгә үз урынына Җамалны калдырып, күрше Күгәрчен авылына китеп торыргамы? Алай дисәң, Сәлимәнең үзенең дә Рәшит белән очрашасы, аны күреп, якыннан танышасы килә иде. Соңгы вакытта кыз ничектер ул егетне аеруча якын күрә башлаган һәм аңардан озаграк хат килми торса борчыла иде. Ләкин кешене хатларына, рәсеменә карап кына белеп булмый шул. Теге вакытта Сәлимә шукланып, алдын-артын уйламый, аны алдамаган булса, ни әйтер идең дә бит!.. Эш узган...

Моны танышу дип әйтергә яраса, аларның танышуына ел ярымнан артык иде инде. Ул елны Сәлимә, унъеллык мәктәпне бетереп, өлгергәнлек аттестаты алса да, әнисе авыру сәбәпле шәһәргә укырга китә алмыйча, үзләренең авыл Советында хисапчы булып эшли башлаган иде. Бер көнне авыл Советына килгән эш язулары арасында бер хат кызыксындырды Сәлимәне.

«Кадерле иптәшләр! — дип башланган ул хатта түбәндәге сүзләр язылган иде: — Минем үтенечем Сезгә сәер дә тоелыр, бәлки, шулай да хатымны игътибар белән укып чыгарсыз һәм җавапсыз калдырмассыз дип өметләнәм. Мин үзем Үзбәкстанда туып үскән егет. Хәзерге көндә Совет Армиясе сафында хезмәт итәм.

Әти-әниемнән яшьләй ятим калып, балалар йортында тәрбияләнеп үстем. Аннан, армиягә киткәнче, ике ел һөнәр мәктәбендә укыдым. Баларак чакта үземнең якын туганнарым булмавын әллә ни артык сизмәгән идем. Менә хәзер үзем белән бергә хезмәт итүче иптәшләрем өйләреннән, туганнарыннан хат алганда күңелем нәүмизләнә башлады. Һәм: «Шулай ук минем беркемем дә юкмы икән?» дип уйлана торгач, мин биш яшьлек малай чагында,

әнием үләсе елны, икебез Татарстандагы бер авылга әнинең сеңелесенә кунакка баруыбыз исемә төште. Шунда ул авылның басу капкасы янында тезелеп торган бик төз, шактый юан биш нарат агачы күз алдыма килеп басты да кылт итеп хәтеремдә ул авылның исеме дә калкып чыкты. Әниемнең сеңелесе Гөлкәй булуын ачык хәтерлим. Ләкин фамилиясен белмим. Исән булса, бәлки, ул әле хәзер дә шунда яшидер дигән өмет белән Сезгә язып карарга булдым. Моңарчы Сезнең авылның кайсы районда икәнен белми идем. Бирегә бергә хезмәт итүче иптәшем Фәрит ничектер сүз арасында Бишнаратны телгә алгач, шатланып сораштыра башладым. Минем бәхеткә каршы дип әйтимме, Фәрит шул районныкы булып чыкты.

Шуны әйтергә онытканмын, әниемнең исеме Әсмабикә иде.

Анам турында берәр нәрсә белеп, миңа хәбәр итә алсагыз, чиксез куаныр идем. Сезне борчыган өчен гафу итегез.

Сәлам белән Рәшит Рәхимов».

Кыз балага бик нык тәэсир итте бу хат һәм аның танышт булмаган ул егеткә ярдәм итәсе килде.

Сәлимә шул көнне үк хатны өенә алып кайтып әнисе Саҗидә апага да укып күрсәтте. Әнисе:

— Дөньяда нинди генә хәлләр булмый. Ятимлек бик читен нәрсә шул,— дип, егетне чын күңелдән кызганып куйды һәм: — Аның туганын эзләп кара син, кызым. Мин дә сораштырып багыйм. Тик Гөлкәй аның тулы исеме түгелдер, мөгаен. Гөлҗиһанмы, Гөлзифамы — шуның ишерәк исем булмагае? Шуны да исеңдә тот эзләгәндә,— дип киңәш бирде.

Шуннан Сәлимә Бишнаратта яшәүче барлык хатын-кызларның исемнәрен авыл Советындагы исемлек буенча карап чыкты. Авыл шактый зур. Андагы Гөлҗиһан, Гөлкамал, Гөлфагыйлә, Гөлниса кебек, исемнәре гөл белән башланган хатын-кызлар үзләре генә унҗиде булып чыкты. Гөлбакчасымыни!

Кыз, иренмичә, аларның һәркайсының өйләренә барып сораштырды. Тик күбесе бик өлкән яшьтә булып чыктылар. Урта яшьләрдәгеләре исә: «Сезнең Әсмабикә исемле апагыз юк идеме?» дигән сорауга күңел юатырлык җавап бирә алмадылар.

Әгәр Сәлимәләр үзләре һаман шул авылда торган булсалар, эш башкачарак булыр иде. Саҗидә апа үзе дә белгән булыр иде, бәлки, ул Гөлкәйне. Ләкин Сәлимәнең әтисе тимер юлда эшләгән елларда алар разъездда яшәгәннәр, әтиләре үлгәннән соң Бишнаратка күчеп килеп тора башлауларына алты-җиде ел гына иде әле. Ә Рәшитнең бу авылга кунакка килеп китүенә унөч-ундүрт еллар чамасы вакыт үткән булырга тиеш бит.

Эзләнүләр Рәшитне юатырлык нәтиҗә бирмәсә дә, Сәлимә аның үтенечен игътибарсыз калдыруны яхшысынмады. Эш менә шулайшулай дип аңлатып, хат язып җибәрде. Егет тә аңа тырышулары өчен рәхмәт укып язды.

Шуннан соң алар сирәк-мирәк хат алыштылар. Саҗидә апаның киңәше буенча, Совет Армиясе көненә Рәшиткә кечкенә генә булса да посылка да әмәлләп җибәрде Сәлимә. Ләкин ул үзе егетнең апасын табуда ярдәм итә алмавына һаман борчылып йөри иде.

Һәм менә һич уйламаганда...

Яз башында Күгәрченлегә, карт җиңгәсенең хәлен белергә баргач, бу вакыйганы ул җиңгәсе Фәхрия апага сөйләде. Тегесе озак уйланып торганнан соң:

— Гөлбикә булмагае ул Гөлкәй дигәнең, Сәлимә. Моннан унбер-унике еллар чамасында микән, безнең авылның Нигъмәт исемле егете Бишнараттан яшь кенә бер тол хатынны алып кайтып өйләнгән иде. Исеме Гөлбикә ие аның, хәтерем ялгышмаса...— диде.

Сәлимә, күктән эзләгәнне җирдән тапкандай, куанып:
— Анасы Әсмабикә булгач, аның сеңелесе Гөлбикә булуы бик мөмкин шул! Хәзер дә монда торалармы алар? — диде.
— Юк. Безнең авылда озак тормадылар. Каядыр Урал ягына китеп, шунда урнашып калдылар бугай.
Моны ишеткәч, Сәлимә тагын күңелсезләнде.
— Бу җеп очы да өзелде, алай булгач.
— Ник? Нигъмәтнең эти-әнисе Күгәрченледә калды бит.
— Кайда? Биредәме? Ник башта ук әйтмәдең аны? Әйдә алып бар мине аларга!
Кыз, табындагы чәйне рәтләп эчәргә дә ирек бирмичә, Фәхрия апасын җилтерәтеп алып чыгып китте. Һәм ул әйткән Нигъмәтнең эти-әнисен күреп сөйләшкәч, алар килене Гөлбикәнең чыннан да Рәшитнең туганы булып чыгуын аңлады.
Гөлбикәгә анасының үлүен, Рәшитнең балалар йортына урнаштырылуын вакытында әйтүче булмаган (кеше кайгысы кешегә иртә керә, кич чыга дигән кебегрәк булган, күрәсең). Байтак вакыт үткәч, бу хәлне белгәннән соң, ул Рәшитне Үзбәкстандагы балалар йортларыннан эзләтеп караса да, таба алмаган булуын ничектер каенанасына йөрәге әрнеп сөйләгән икән.
Шуларны белгәннән соң, Сәлимәнең инде берниндн дә шиге калмады. Һәм ул Гөлбикәнең хәзерге фамилиясен, тулы адресын язып алып, куанычы култыгына сыймый кайтып китте.
Бишнаратка кайту белән үк, Рәшитне генә түгел, аның апасын да тизрәк шатландырасы килеп, аларның икесенә дә хат язды, берберсенең адресларын җибәрергә ашыкты.
Шуннан соң инде егет белән кызга язышыр тема да калмаган иде кебек, ләкин киресенчә булды. Ике арада хат алышу ешайды гына. Һәм Рәшит, хат белән бергә фоторәсемен дә җибәреп, кызның да рәсемен сорап язган иде.
Сәлимә нәкъ менә шунда юләрлек эшләде. Тәскә-биткә беренче күрүдә үк үзенә җәлеп итәрлек чибәрләрдән булмаганга, ул үзен ямьсез дип йөри, томыраеп торган зур кара күзләренең нинди сихерле көчкә ия булуын, һәрвакыт шат, ачык чыраеның сөйкемлелеген белми иде. Шуңа күрә, алдын-артын уйламастан, тотты да егеткә авылдагы матурлардан берсе саналган сердәш кызы Җамалның рәсемен җибәрде.
Яшьләрчә шаярту теләге дә булды бугай ул чакта Сәлимәдә. «Ул егет белән кайчан да булса очрашасыбыз юк. Хезмәтен тутыргач, туганы янына Уралга китәр»,— дип уйлады кыз.
Рәшит соңгы хатларының берсендә Сәлимәне күңеле якын күрүен, хезмәт срогы тулгач, Бишнаратка килергә теләвен белдергән иде. Сәлимә, әгәр егет чыннан да алар авылына килеп төшсә, нинди җайсыз хәлдә калачагын күз алдына китереп, күңел тынычлыгын җуйды. Ничә әйтсәң дә, чибәрләргә төшә бит егетләрнең күзе! Рәшитнең дә аңа шул сылу Җамал рәсеменә карап күңел куйган булуы мөмкин түгелмени?..
Шул чакта берничә көн уйланып йөргәннән соң, Сәлимә фоторәсем белән булган вакыйганы Рәшиткә ачыктан-ачык әйтеп: «Мин синең алдыңда ни дәрәҗәдә гаепле булуымны яхшы аңлыйм, шуңа күрә үземнең сине шулай алдавым өчен гафу үтенергә дә кыймыйм», дип хат язып җибәрде. Һәм аңа каршы җавап алмагач, инде егет белән иңе ара тәмам өзелгәнгә санап, шул ук вакытта күңеле нидер юксынып, ямансулап йөри иде.
Менә көтмәгәндә бүген аңардан телеграмма килеп төште. Шатланыргамы моңа, көенергәме? Ул телеграмманы икенче тапкыр укыганда, Сәлимә андагы «барыбер» дигән сүзгә игътибар итте.

Моны ничек аңларга? «Минем сиңа булган карашым үзгәрмәде, синнән күңелем сүрелмәде», дип аңларгамы? Ул серле «барыбер» сүзен әнә шулай аңлыйсы килде кызның. Һәм ул Рәшитне каршы алырга төшәргә булды. Телеграмма кичә Мәскәүдән җибәрелгән, димәк, Рәшит хәзер Казанда. Аннан төнлә Уфа поездына утырырга тиеш. Ул поезд иртәгә көндез Бишнараттан өч километрдагы станция аша үтәчәк.

Шуны исәпләп чыгарганнан соң, иртәгесен Сәлимә станциягә хатлар, посылкалар йөртүче Зиннур абзыйга:

— Минем анда үз йомышым да бар. Почтаны бүген мин генә илтим, син ял ит,— дип, аның ат-арбасы белән китте. Ә инде китәр алдыннан өйләренә кереп, әнисенә Рәшит киләсен әйтте.

— Син тәмле генә итеп аш пешереп торсаң, әйбәт булыр иде, әни,— диде.

Сажидә апа:

— Тавык суярбыз, кызым. Шуннан да затлы аш булмас,— дип калды.

Сәлимә станциягә барып җиткәндә, поезд килергә егерме минут чамасы калган иде әле. Ул үзе алып килгән посылка белән хатларны тапшырганнан соңгы вакытын перронда арлы-бирле йөреп уздырды. Күңеле тыныч түгел, йөрәге ашкынып тибә иде.

Ниһаять, ул көткән поезд килде. Төшүче күп булмады. Алар шундук як-якка таралышып та беттеләр. Станциядәге азык-төлек палаткасыннан тегене-моны алырга төшкән узгынчы пассажирлар да яңадан үз вагоннарына кереп утырдылар. Бары тик гаскәри киемле зифа буйлы бер егет кенә перронда торып калды.

— Бишнаратка килүче Рәшит түгелме сез? — диде Сәлимә, аның янына килеп.

Егет талпынып куйды, сызып куйгандай кара кыйгач кашларын сикертеп, кызга текәлеп карады.

— Әйе. Сез мине каян беләсез?

Шунда Сәлимә, аның үткен коңгырт күзләренең гаҗәпләнү дә, кызыксыну да чагылдырган карашыннан югалып калгандай булып, үзенең кем икәнлеген турыдан-туры әйтергә кыюлыгы җитмичә:

— Сәлимәнең дус кызы мин. Ул үзе килә алмады. Миңа сезне алып кайтырга кушты. Станция артында җигүле ат тора. Шунда таба бара торыгыз. Мин хәзер бүгенге почтаны гына алып чыгам,— дип, станция бинасына кереп китте һәм биш-ун минуттан, иңенә хатлар, газета-журналлар белән тулы почта букчасын элеп, килеп тә чыкты.

Рәшит аны ат янында көтеп тора иде инде.

— Әйдәгез, утырыгыз! — диде Сәлимә егеткә арбада урын күрсәтеп.— Чемоданыгызны миңа бирегә куйыйк.

Ат кузгалып киткәннән соң, Рәшит кыздан:

— Сез үзегезне Сәлимәнең дусы дидегез. Мин белгән дусына охшамыйсыз. Хәер, яхшы күңелле кешенең дуслары да күп булырга тиеш анысы. Шулай да исемегез ничек сезнең? — дип сорады.

Кызга хәзер чигенер урын калмаган иде. Беткән баш беткән, ни булса ул булыр дип, теленә килгән беренче исемне әйтте:

— Гөлсем!

Аннары егетнең юлда ничек килүен, Мәскәүдә һаваларның әйбәтме булуын сораштыра башлады. Үзе аз сөйләде, күбрәк егетне сөйләтергә тырышты.

Үзен Рәшиткә вакытыннан алда белдермәс өчен, әйтер сүзен чамалап әйтте. Ләкин шулай да, авылга җитәрәк, башлары күккә тиярдәй биек карт нарат агачлары күренүгә:

— Әнә шул инде кайчандыр сезнең хәтерегезгә сеңеп калган биш нарат! — дип әйтүен сизми калды.

Рәшит:

«Минем Сәлимәгә язган сүзләрне каян белә икән бу кыз?» — дип, әсәренеп Сәлимәгә борылып карады. Шул мәлне аның күңелендә ниндидер томанлы бер шик тә туган иде тууын. Ләкин бала чак истәлекләре белән дулкынлану аркасында шиген шундук онытты ул.

Авыл уртасына җитәрәк, кыз:

— Сәлимәләр әнә шул чаттагы өйдә торалар. Сез бер дә тартынмый аларга барыгыз. Сезнең киләсен Саҗидә апа белә. Сәлимә үзе дә озакламый кайтыр. Ярый, хәзергә хуш-сау булыгыз. Күрешербез әле. Мин киттем,— дип, Рәшитне төшереп калдырды да атын кире борды.

Рәшит, ул күрсәткән өйгә үзе генә туп-туры барып керергә базмыйча, кулына чемоданын тоткан килеш, уңайсызланып торган арада, ян капкадан башына ак яулык бәйләгән Саҗидә апа килеп чыкты. Егетне күптәнге танышы кебек үз итеп, якты чырай белән:

— Абау, ник болай капка төбендә генә торасың, улым? Исән-сау гына килеп җиттеңме? Әйдә, өйгә керәбез,— дип алып кереп китте. Аннан: — Бәй, Сәлимә үзе кайда соң? Сине каршы алырга бармакчы ие бит ул...— диде.

— Белмим шул. Мине аның дусы Гөлсем алып кайтты станциядән.

Саҗидә апа аптырый төште.

— Гөлсем дисеңме? Нинди Гөлсем булыр икән соң ул? Ярый, кем булса да булсын. Исән-сау килеп җиткәнсең. Юлдан килгән килеш юынасың-нитәсең булса, җылы су бар...

Рәшит кече якта бит-кулын юганнан соң, Саҗидә апа аны пөхтә итеп җыештырылган җыйнак кына бүлмәгә алып керде дә:

— Әйдә, түрдән уз. Укыйм дисәң, газета-журналлар бар әнә. Карточкалар альбомы да бар. Шуларга исе-акылы китә инде безнең Сәлимәнең. Шәһәргә барган саен бер кочак алып кайта шул карточкаларны. Син шунда утырып тор. Мин аш хәстәрлим,— дип чыгып китте.

Егет, почмак тәрәзә турысындагы язу өстәле янына барып утырып, иң элек шунда өстәл өстендә яткан зәңгәр тышлы альбомны карарга тотынды.

Кемнәр генә юк иде ул альбомда: атаклы кино артистларының рәсемнәре дисеңме, татар язучыларының рәсеме дисеңме! Шунда уртадагы бер биттә Рәшит үзенең армиядән Сәлимәгә җибәргән фотокарточкасын да күрде. Һәм шуның белән янәшә ике кызның рәсеме игътибарын җәлеп итте аның. Аларның берсе, һичшиксез, Җамал иде. Сәлимә рәсеме дип, ничә айлар куен кесәсендә кадерләп саклады бит Рәшит ул кызның фотосын!.. Ә икенчесе?.. Егетне станциядән алып кайткан Гөлсем ич!..

Рәшит шунда, кашык-тәлинкәләр күтәреп кергән Саҗидә апага борылып:

— Гөлсемнең карточкасы да бар икән монда...— диде.

Саҗидә апа кызыксынып:

— Кая күрим әле...— дип, килеп рәсемне карагач, гаҗәпләнеп: — Бәй, ниткән Гөлсем булсын?.. Сәлимә ич бу! — диде.

— Шулаймыни?..

Рәшит, көлемсерәп, альбомны урынына куюга, Сәлимә үзе дә кайтып керде һәм, ишек яңагына сөялеп, сүзсез туктап калды.

Егет, аның каршысына килеп, ике кулын берьюлы сузып:

— Я, таныш булыйк, Гөлсем-Сәлимә! — диде.

Сәлимә аңа ни дип җавап бирергә белми каушап торганда, миски белән аш күтәреп кергән әнисе аны җайсыз хәлдән коткарды.

— Әйдәгез, утырыгыз, ашны суытмыйк.

Табын янына утыргач, Сәлимә бераз үз хәленә кайтты. Саҗидә апа Рәшитне кыстый-кыстый сыйлаган арада:

— Гөлбикә апаңнан хат алып торасыңдыр инде? Исән-саулармы? Бала-чагасы бармы? — дип сораштыра башлады.

— Исәннәр. Рәхмәт. Бер улы, бер кызы бар икән.

Шулай сүзгә сүз ялганып китеп, аш янында алар күңелле генә сөйләшеп утырдылар.

Аннан Сәлимә Рәшитне авыл күрсәтергә алып чыгып китте. Саҗидә апа аларга сокланып карап калды.

Авылның югары очына клуб янына барып җиткәч:

— Бүген кино бар, әллә керәбезме? — диде Сәлимә.

— Кино һаман булыр ул...— дип, серле генә әйтеп куйды Рәшит.

Алар клубка кереп тормадылар. Урамда йөреп кайткач, капка төбендәге эскәмиядә сөйләшеп утырдылар. Бала чакларын, яшүсмер чакларын, мәктәптә укыгандагы кызыклы вакыйгаларны искә төшерделәр.

Бишнаратка килгәндә, Рәшит бер генә көн торырмын да китәрмен дип уйлаган иде. Ләкин Саҗидә апа:

— Ул ниткән сүз? Шул чаклы җирдән кил дә... Булмаганны! — дип авыз ачарга да ирек бирмәде. Рәшитнең үзенең дә китәсе килми иде...

Уралга сәфәр чыгасы көннең элекке көнендә Сәлимә белән алар икесе авыл читендәге биш нарат янына бардылар. Март аеның аяз көне. Һавада яз исе аңкый. Асфальтлы юлдагы кар эрегән булса да, әле кырлардагысы ап-ак булып, кояш нурында җем-җем итеп тора иде. Шул күренешкә һәм үзе өчен истәлекле мәһабәт наратларга сокланып, байтак вакыт дәшми карап торганнан соң, Рәшит:

— Мине синең белән таныштырган наратлар бит болар, Сәлимә. Шулар хәтеремдә сакланмаган булса һәм син булмасаң, апамны да таба алмаган булыр идем,— диде.— Мин ел ярым буена синең йөрәк җылыңны тоеп яшәдем. Рәхмәт сиңа. Синнән дә якын кешем юк хәзер дөньяда. Син теләсәң, мин, Гөлбикә апамны барып күргәннән соң, бөтенләйгә Бишнаратка кайтыр идем,— диде.

Сәлимә дулкынланып, оялып, башын түбән иде.

## Идрис Туктар

# Җөмләләр

Берәүләр эшчәнлеккә күнегә, берәүләр әчкечелеккә...

* * *

Аз гына булса да ялгышмауның аз гына булса да кызыгы бар микән?

* * *

Сумлап бурычка алганчы, тиенләп сакларга гадәтлән.

* * *

Берәүләр «эшләргә ашык» дигән сүзләрне «тешләргә ашык» дип ишетәләр.

* * *

Һәркем үз бәхетенә лаек... әгәр дә булса аек.

* * *

Иярмә төлкегә, калырсың көлкегә.

* * *

Кеше бакчасына карама, кеше акчасын санама.

* * *

— Үзем бетсәм бетәрмен, сезне бетереп бетәрмен,— ди икән аракы.

* * *

Миниләнмә! (Хәзергечә «вакланма» дигән сүз.)

## Наҗар Нәҗми

### Мин озатам...

Мин озатам сине... Үзем инде
Көтәм синең кайтыр көннәрне.
Мин озатам... Синең белән бергә
Озатам мин көзге җилләрне.

Җил туздыра агач яфракларын,
Җир сап-сары, һава сап-сары.
Мин озатам көзне... Үзем инде
Көтәм яфрак ярыр чакларны.

Олпатлана төштем кебек үзем,
Сабырсызлык инде ят кебек.
Ә күңелем һаман тезгеннәрен
Чәйнәп өзеп чапкан ат кебек.

### Шагыйрьләр һәм хатыннар

ТАССРның халык артисткасы
Рәшидә ханым Җиһаншинага.

Кышкы Казан иде. Урамда
Декабрьның иде салкыны.
Чәчкә сипте шагыйрь юлына
Чәчкә кебек татар хатыны.
Әй шагыйрьнең берчә чалт аяз,
Берчә болыт баскан язмышы!..
Шул язмышның сезгә, хатыннар,
Уртак икән кайсы яртысы?
Ә шагыйрьләр сезнең юлларга
Нинди чәчкә икән сиптеләр?
Аларныңмы сезне сөюе
Калды эзсез... Эзсез үттеләр?
Алардан бит сезгә төште нур...
Ә соңыннан инде гомергә
Сүнмәс йолдыз булып үзегез
Балкыдыгыз җирдә, күңелдә.
Бернс һәм Джин, Пушкин һәм Натали,

Матильдалар[1] яшәү ямена,
Мәгърур җыры булып заманның
Кушылдылар Җәлил-Әминә.
Җырда мәңге калыр өченме,
Анна Керн, башка-бүтәннәр,
Даһилар бит сезне, сылулар,
Безнең өчен дә бит сөйгәннәр.
Тетрәп киттем... Шагыйрь юлына
Чәчкә сипте татар хатыны.
Кышкы Казан иде. Урамда
Декабрьның иде салкыны.

## Өч тел

Беренчесе — анам теле —
Җирем, һавам, каным теле
Гомер буе кешеләргә
Мәхәббәтле итте мине.

Икенчесе керде аз-маз
Ерак корьән битләреннән.
Салды курку, итте азат
Фани дөнья чүпләреннән.

Өченчесе фән, мәгърифәт
Дөньясына ачты киң юл.
Бернәрсәсен җәлләмәде,
Барсына да өйрәтте ул.

## Гармун

«Әл дә гармунчы түгелмен,
Уйнар да елар идем».

*Мостай Кәрим.*

Кулларыма алсам сине —
Билләрең бөгелмәле.
Бер сыздыру белән моңың
Күңелгә түгелмәле.

Биш яшьлек чагымның бармак
Эзләре телләреңдә.
Тәү уйнаган көйләр чыңы
Һаман да йөрәгемдә.

Моңыңда — туган җиремнең
Кояшлы тарафлары,
Абыйларымның яшьлеге,
Әнкәем карашлары.

[1] Матильда — Генрих Гейне хатыны.

Яшьлекләр дә, карашлар да
Сүнделәр инде күптән.
Ә синдә һаман шул ук моң,
Тик уйнаучылар бүтән.

Юк синдә һич ялган тавыш —
Кушылып җырлыйммын да.
Ярый гармунчы булганмын,
Елыймын, уйныймын да.

## Кәкүк тавышы[1]

Габәши каберен эзләп,
Тимер Арслан белән
Икәү зиратта йөрибез...
Тирә як ять-яшь үлән...

Еллар, еллар... Без окоплар
Казыдык җирдә ул чак.
Ә монда бер чит кешегә
Кабер казыган Чалкак.

Һәр кабер — җирнең ярасы,—
Төзәлми калмый яра.
Кайда соң ул? Кешедән бит
Кабер булса да кала?!

Йөрибез урап-урап,
«Кайда?» дип сорап-сорап...

Янәшә кәкүк кычкыра
Елларны санап-санап.
Ул кычкырмый, ул моңлана
Татарча, башкортчалап.
Әй ул моң, җыр якын көбек,
Тик безгә, безгә генә.
Хуш, Чалкак!.. Кәкүк тавышы
Үзәкне өзә генә.

## Таң алдыннан әйтелгән...

Таң атарга калды өч сәгать,
Өч сәгатьтән инде китәсең.
Өч сәгать — ул меңә өч минут,
Өч минуттан ялгыз итәсең.
Син китәсең... Кала якты көн,
Якты көндә калам көн күреп,
Кала кояш, ләкин китәсең
Йолдызларның барын сүндереп;
Кояш баер, янар йолдызлар,

---

[1] «Кәкүк» диган мәшһүр җырның авторы композитор Солтаң Габәши Башкортстанның Борай районы, Чалкак авылында күмелгән.

Кабатланыр таңнар яңадан;
Кабатланыр көннәр, сәгатьләр,
Булыр ай, ел шулар саныннан;
Кабатлана барыр мизгелләр,
Кабатланыр гореф-гадәтләр —
Кабат килеп, кабат китәрсең,
Ә тик
Кабатланмас шушы сәгатьләр —
Гомернең бер алтын кисәге,
Иртәгә ул инде кичәге...

## Кичәге хәлдән соң дуска әйтелгән сүз

Чәнчелеп китсен барсы да —
Барсына төкер.
Табигатьнең үз законы —
Аллага шөкер.
Сиңа бит күбрәк бирелгән —
Шуны белсеннәр,
Сиңа түгел, үзләренә
Үпкәләсеннәр.
Кешеләр әле һаман да
Мәкерле, усал —
Берсенә-берсе ачалар
Рәхимсез кыйтал [1].
Ә җирдә күпме яхшылык —
Нинди саф һава!
Бернинди мәкерсез-нисез
Җиллэп кар ява.
Чәнчелеп китсен! Җирдә бит
Кар бар, җилләр бар!
Алда әле кар астыннан
Чыгар гөлләр бар.
Шул гөлләр өчен генә дә
Яшәргә мөмкин.
Киң булса әгәр күңелең,
Дөньялар иркен.
Булсын яшәү таянычы —
Акыл һәм йөрәк.
Явызларга яшәр өчен
Мәкерлек кирәк.
Чәнчелеп китсен! Булыйк без
Табигать яклы!
Гомер бакый булган адәм
Эреле, вакль...

[1] Сугыш.

## Гөлшат Зәйнашева

# Сөләйман абзый

Кулбай-Мораса авылында
Гаҗәп бер абзый күрдем.
Шул абзыйның чиста, такыр
Ишек алдына кердем.
Кердем курчак өе кебек
Җыйнак, матур өенә.
Сәгать сәлам бирде миңа,
Сайрап күке көенә.
Күкеле сәгатен абзый
Төзәтә икән үзе.
Кием шкафы ясаган,
Шкаф ишеге — көзге!
Мичләр дә үзе чыгарып
Куя икән бу оста.
Күпләрнең өе май кебек
Җылы була ди кышта.
Сез әйтерсез: «Нәрсәсе бар?!
Була инде андыйлар!
Балта, чалгы саплаучылар,
Мич чыгарган абзыйлар!
Ашыкмагыз, хикмәте бар:
Килеп керсәң сарайга,—
Дөм караңгы шул сарайда
Эшләр абзый бер җайга.
Дөм караңгы бу сарайның
Хуҗасы икән күзсез.
Бу күзсез остага карап,
Мин күзле калдым сүзсез!..
Түзмәдем, сорап куйдым мин:
— Ничек эшлисең шулай?
Бик авырдыр, бик кыендыр,
Берни күрмисең бугай?!.
— Янымда күзле кешеләр
Яшәгәч, мин дә күзле!..—
Диде дә Сөләйман абзый,
Елмаеп куйды үзе.

●

Яңа елда яңа яуган карга басып,
Кайтып киләм тыштан балкып, эчтән ярсып,
Ватык гармун уйнагандай кар шыгырдый,
Яңа елда иске көйгә җилләр җырлый.
Җилләр алар һаман бер көй суза гына,
Кеше гомере искән җилдәй уза гына...
Яңа елда яңа шатлык килер әле,
Иске кайгым, бетмәсә дә, кимер әле.
Юк-бар кайгы өчен башлар иелмәсен,
Ил иңенә авыр кайгы өелмәсен!..
Шулай уйлап кайтып киләм бер ялгызым,
Ялгызларга Яңа елның төне озын.
Таңга кадәр тәрәзәмдә ай нурлары,
Төн йокымны нуры белән ай урлады.
Моңсу җилләр һаман бер көй суза гына,
Кеше гомере искән җилдәй уза гына...

## Туфан Миңнуллин

# ИР ЕГЕТЛӘР

ДРАМАТИК ПОВЕСТЬ

### ӨЧ ПӘРДӘДӘ, ҖИДЕ КҮРЕНЕШТӘ

КАТНАШАЛАР:

Мәрвән — колхоз председателе.
Әхтәм — Мәрвәннең фронтовик дусты.
Гашия — Мәрвәннең хатыны.
Сайра — Мәрвәннең кызы.
Нажия — Әхтәмнең хатыны.
Посыпов — милиция лейтенанты.
Зәйнуллин — колхоз председателе.
Сәлимә — сатучы.
Исмаев — архитектор.
Милиционер.
Карт.

### БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

#### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шәһәрдә татлы сулар сата торган павильон. Шунда ук арзанлы винолар сатыла. Бер өстәл дә бар. Пәрдә ачылганда Әхтәм прилавка янында сатучы хатын Сәлимәдән бер стакан вино сорап тора.

Сәлимә. Кит диләр! Бер грамм да юк! Туйдырып бетердең. Күрәсем килми.

Әхтәм. Минем дә сине күрәсем килми, Сәлимә. Монда сине сагынып килмәдем. Салып бир дә тыныч кына аерылышабыз. Син миннән котыласың, мин — синнән. Я әйдә, сузма.

Сәлимә. Акчаңны бир.

Әхтәм. Нәрсә ул акча, Сәлимә! Акчаны кешеләр берсен-берсе алдар өчен уйлап тапканнар. Әшәке нәрсә ул акча, Сәлимә. Шуңа күрә мин аны кесәмдә йөртмим.

Сәлимә. И сөйләнүе, милианир диярсең. Болай эчеп йөргәнче...

Әхтәм. Син демагог, Сәлимә. Акыл һәм аракыны бергә сатасың. Я син акыл сатуыңны ташла, я аракы сатма.

Сәлимә. Сиңа аракы салып биргән саен, йөрәгем әрни. Нинди күркәм кеше — әрәм буласың бит. Дуңгыз булганчы эчәргә димәгән.

Әхтәм. Синең бу кырык тиенлек черек виноград суың белән әтәч булып булмый шул. Сал инде тизрәк.

Сәлимә *(стаканга вино салып)*. Мә, күз алдымда торма икенде күләгәсе кебек сураеп.

Әхтәм *(стаканны алып)*. Кызык корылган дөнья, Сәлимә абыстай. Син миңа агу эчерәсең, шул агуга пычрак сүзләр кушып бирәсең. Икенде күләгәсе — шәп! Ә бит синең аңа хакың бар. Чөнки мин иртәгә сиңа килеп ялынырга мәҗбүр. Кем син, беләсеңме? Юк, юк, мыскыл итмим. Син — кеше. Син меңгә хәтле саный беләсең. Ә ул бик җиткән. Нигә артыгын белергә. Бәхетле син. Шулай да рәхмәт. Мең яшә, галиҗәнапбикә Сәлимә!

Мәрвән керә.

Сәлимә. Сезгә нәрсә, гражданин?

Мәрвән. Газлы су.

Сәлимә су агызып бирә. Мәрвән янына Әхтәм килә.

Әхтәм. Эчәсез, ә?

Мәрвән *(гаҗәпләнеп)*. Сезгә ни кирәк?

Әхтәм. Эчәсезме дим?

Мәрвән. Эчәм.

Әхтәм. Газлы су эчәсез? *(Мәрвән эндәшмәгәч.)* Сөйләшәсегез килмиме?

Мәрвән. Эшегездә булыгыз, иптәш.

Әхтәм. Ә нигә вино эчмисез? Ярамыймы, акча кызганасызмы?

Мәрвән. Китегез.

Әхтәм. Куасыз? Ә сезнең мине куарга хакыгыз бармы? Монда без барыбыз да бертигез. Кеше кешегә дус, туган һәм иптәш. Газлы су эчә. Акыллы баш! Аракы эчегез. Газлы су эчкәннәргә дә, аракы эчкәннәргә дә үлгәч җир бертигез бүлеп бирелә.

Сәлимә. Әхтәм, бәйләнмә.

Әхтәм сузен ишеткәч, Мәрвән Әхтәмгә текәлебрәк карый.

Әхтәм. Маяковский әйтмешли, нәрсә афишага баккан кәҗәдәй карап торасыз? Әллә дөрес түгелме?

Мәрвән. Әхтәм?.. Мохтаров!..

Әхтәм. Оһо! Әллә таныйсызмы? Әйе, Әхтәм Мохтаров. Сезне кем дип белик?

Мәрвән. Мәрвән Идрисов.

Пауза. Әхтәм һәм Мәрвән бер-берсенә карашып торалар.

Әхтәм *(ниһаять, танып ала)*. Мәрвән! Мәрвән Идрисов... Шайтан!.. Синме бу? Чынлап әйт, синме?

Мәрвән. Берлин урамында эпипәгә биеп...

Әхтәм. Мәрвән!!! *(Кинәт Мәрвәнне күтәреп алып әйләндерә. Дөп иттереп идәнгә бастыра.)* Нихәл? Ничек син?

Мәрвән. Менә шулай, газлы су эчәм.

Әхтәм. Малай гына идең бит... Сәлимә, сал! Күп сөйләнми генә сал. Беләсеңме кем бу? Бу бит Мәрвән. Дөньяда бердәнбер рәтле кеше! Дус! Ничә ел?..

Мәрвән. Егерме биш.

Әхтәм. Егерме биш ел. Юк, ышанмыйм... Гитлер капут!.. Ура!..

Бас, кызым Әлипә,
Син басмасаң мин басам.
Берлинның таш урамында
Биеп алыйк, ичмасам.

Ә?! Сәлимә!

Сәлимә. Акчаңны бир.

Әхтәм. Шушындый вакытта. Хайван!

Мәрвән. Әхтәм, син нәрсә?

Әхтәм *(кызып китеп Сәлимәгә)*. Син монда... Без бот буе малайлар синең өч тиенлек җаныңны саклап сугышып йөрдек. Син!.. Күзең чыкмаган булса, күрәсеңдер...

Сәлимә. Синең дусларың көнгә илле...

Әхтәм. Бу бит, бу бит Мәрвән. Аңлыйсыңмы, алла бәндәсе?

Мәрвән. Әхтәм, миндә акча бар.

Әхтәм. Синең акчаң миңа кирәкми. Мин сине сыйларга тиеш. Беләсеңме син, Мәрвән. Син бит... Ә! Әх!.. Сәлимә җаным... *(Мәрвәнгә.)* Яле, утыр әле, бер туйганчы карыйм әле үзеңә. *(Мәрвәнне өстәл янына алып барып утырта. Карап тора.)* Мәрвән... Разведчик!.. Кайларда син?

Мәрвән. Авылымда. Син?

Әхтәм. Син мине сорама. Сөйлә, үзең турында сөйлә. Егерме биш ел күргән юк бит.

Мәрвән. Әхтәм, миңа бик тиз бер җиргә барырга кирәк. Аннан соң иркенләп сөйләшербез. Казанда яшисеңме?

Әхтәм. Мәрвән, Мәрвән!..

Сәлимә өстәлгә ике стакан вино китереп куя.

Мәрвән *(Сәлимәгә)*. Алыгыз, кирәкми.

Әхтәм. Юк, тот әле, Мәрвән.

Мәрвән *(Әхтәм кулыннан стаканны алып куеп)*. Сиңа җиткән. Әйдә, киттек.

Әхтәм. Мәрвән!

### ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шәһәр бакчасы. Артлы утыргычта Әхтәм белән Мәрвән утыралар. Вакыт кич.

Мәрвән. Фронттан кайткач, дөнья мәшәкатьләренә чумып, күрешергә вакыт та булмады. Ничә ел үтеп киткән.

Әхтәм. Фронтта очрашкан һәр кеше белән күрешеп, йөрешә башласаң, кунактан кунакка гына чабарга кирәк.

Мәрвән. Без бит синең белән һәр кеше түгел идек. Бер телем каткан икмәкне урталай бүлеп ашаган, исән калсак, гомерлек дус булырга вәгъдәләр бирешкән. Без очрашырга тиеш идек.

Әхтәм. Димәк, беркайчан да вәгъдәләр бирешергә ярамый. Адәм баласы вәгъдәсеннән көчсез. Вәгъдә биргәндә ул дөньяны үз кулында дип саный: ничек борсаң, шулай борыла, дип уйлый. Бактың исә, кеше үзе — дөнья кармагында, дөнья аның муенын бора, башын дөмбәсли, аңгырайта, онyттыра... Колхоз председателе булдым дисең инде? Верховный Совет депутаты. Илгә икмәк игәсең? Шәпме соң колхозың? Алда барасыңмы?

Мәрвән. Артка калган юк. Яле, үзең турында сөйлә. Кем син? Кайда?

Ә х т ә м. Мин сиңа берни сөйләмим, Мәрвән дус, гафу ит. Менә күрдең. Аерылышабыз, шул җиткән. Сөйләсәм дә аңламаячаксың. Мине беркем дә аңламый. Мин үзем бер дәүләт: ул дәүләтнең премьер-министры да, короле дә мин үзем. Корольгә, аның йомышларын үтәр өчен, аңа баш ияр өчен кол кирәк. Ул кол да мин үзем. Кирәк икән, король булып ул колны җәзалыйм, кирәк икән, кол булып җәзаланырга әзер. Хәтта ул җәзаны шатланып кабул итәм. Указ үземнеке, канәгатьме?

М ә р в ә н. Аңламадым.

Ә х т ә м (*көлеп*). Аңлама син аны. Аңласаң үзеңә читен. Чөнки син бүтән корольләргә кол булырга күнеккән кеше.

М ә р в ә н. Әйдә, Әхтәм, җитдирәк сөйләшик. Рәтлерәк сүзләребез беткәнме әллә?

Ә х т ә м. Җитди итеп әйткәндә, дөнья минем рәтле сүзләремне оныттырды. Кыйнады ул мине, Мәрвән дус. Мин һәрвакыт яхшылык эшләргә тырыштым, һәм шуның өчен күбрәк кыйналдым. Юк дөреслек дөньяда, Мәрвән, яши-яши мин шуны аңладым. Хәзер мин дөреслек эзләп йөрүче хыялый бер бәндә түгел, ә бөтен дөньясына төкереп яшәүче ирекле җан. Менә кем мин. Өем дә юк минем, атым да юк, хатын да юк.

М ә р в ә н. Кызык түгел бит әле бу.

Ә х т ә м. Кызык түгел, әмма факт. Син философия дигән фәнне бераз беләсеңме? Түшеңдә ромба бар, димәк, азмы-күпме сукалыйсың. Философия әйтә: тормыш көрәштән тора, ди. Ә кем белән кем көрәшә? Җәмгыять белән шәхес көрәшә. Шәхес җәмгыятькә каршы чыга, ә җәмгыять аны сытып үтә. Аның үз юлы бар, шәхестә аның эше юк.

М ә р в ә н. Син кайсы җәмгыятьне әйтәсең? Буталма, туган.

Ә х т ә м. Әйтәм бит, аңламыйсың син мине... Шуңа күрә сөйләшеп торудан мәгънә юк. Хуш, хатыныңа сәлам әйт.

М ә р в ә н. Син кая?

Ә х т ә м. Барам шунда — белмим кая, табам шуны — белмим нине. Әкият!

М ә р в ә н. Ташлап китәсеңме?

Ә х т ә м. Нишләтим. Кунакка чакырыр идем, фатирым юк, сыйлар идем, акчаның юк чагында туры килдең. Сүзләребез ялганмый. Гостиницаңа кайтып йокла. Иртәгә дәүләт алдындагы бурычыңны үтәргә әзер бул. Эчмә, тартма, хатыныңны аерма. Ә минем дүрт ягым кыйбла.

М ә р в ә н. Алай булмый.

Ә х т ә м. Ә ничек була?

М ә р в ә н. Син мондый түгел идең.

Ә х т ә м. Ә нинди идем? Я ник җавап бирмисең? Нинди идем? Арслан кебек егет идемме? Ил өчен дип ут эченә керә идемме? Ул чакта мин ил өчен кирәк идем, ә хәзер кирәкмим. Илнең миндә эше юк. Кемнең чын батыр, кемнең камыр батыр икәнен тикшереп тормый ул хәзер. Кем күбрәк кычкыра, кем күп сөйли — шул батыр. Нигә кычкырмаска, алда, автоматын төзәп, фашист тормый. Менә нинди мин. Илгә кирәкмим икән, мин нишләргә тиеш? Мин үземнең кирәк чагымны көтеп йөрим. Кирәк булгач, чакырып алыр.

М ә р в ә н. Әйт әле, Әхтәм, нишләп шундый син, ни булды? Мин бит бернәрсә дә белмим. Кайда эшлисең?

Ә х т ә м. Ә нигә эшләргә? Минем хезмәтем беркемгә дә кирәкми. Шуңа күрә, минем хезмәтем җимешләреннән авыз итегез, дип күкрәк какмыйм.

М ә р в ә н. Кызганыч.

Ә х т ә м. Кызганма мине, мин син уйлаганча кызганыч хәлгә төшкән кеше түгел. Төшкән чагым бар иде, хәзер көннән-көн күтәреләм.

Мин үземнең кеше икәнлегемне аңлый башладым. Сатин дигән кешене беләсеңме син? Менә кара — мин тере Сатин. Кеше — горур яңгырый.

Мәрвән. Әлегә син тере тиле, Әхтәм. Мин синнән шикләнә үк башладым.

Әхтәм. Шикләң. Юләрләр йортыннан качкандыр, дип уйла. Ләкин ялгышасың. Юләрләр йортыннан качып булмый. Чөнки дөнья үзе юләрләр йорты. Син үзең дә миллионлаган пациентларның берсе. Син үзеңне акыллы баш дип саташасың. Мин тилелегемне яшермим. Шулай да ярата идем мин сине, Мәрвән дус. Әйбәт малайлар идек бит, ә? Күгәргән калайлар түгел идек. *(Утыргыч өстенә менеп басып.)* Кара, Мәрвән, нәрсә ул анда кыймылдый? Фриц дәдәй. Тәвәккәлләдек. Синнән тел, миннән көч! Ахтунг! Ауф фидерзейн. Фашист швайн, Нах һаус! Там-тра-трам-рам, там-тра-рам, там-тра-ра!.. *(Шул чак утыргыч артында бөкшәеп беткән бер карт пәйда була.)*

Карт. Әссәламегаләйкүмнәр! Концерт куясыңмы, Әхтәм?

Әхтәм. Сәлам, карт алаша! Таныш бул, минем фронтовик дус. Хәзер алдынгы колхозның уңган председателе, Верховный Совет депутаты.

Карт *(нәзакәтле итеп)*. Исәнмесез.

Әхтәм. Ниең бар?

Карт. Бүген пенсияне китермәделәр.

Әхтәм. Аллаһе тәгаләң сыйламадымыни? Я, чыгар.

Карт. Ашыктырма, Әхтәм энем. *(Көлеп.)* Һәр нәрсәнең үз җае бар. *(Мәрвәнгә.)* Шулаймы, иптәш? *(Әхтәмгә.)* Кунагыңны миңа алып килергә иде.

Әхтәм. Сиңа иш түгел ул.

Карт. Нишләп? Кешеләр барысы да бер каннан яралган. Барыбызны да Адәм белән Һава балалары, ди дин китабы.

Әхтәм. Каян килгән Ишми ишан. Синең аллаң — шешә, пәйгамбәрең — портвейн.

Карт *(кесәсеннән шешә чыгарып)*. Уртак пәйгамбәребез!

Әхтәм. Мәрвәнгә салма, ул эчми.

Карт. Җирәнәме?

Әхтәм. Җирәнә.

Карт *(Әхтәмгә салып биреп)*. Менә анысы юкка. Безнең ил чыгарган нәрсә. Аңардан җирәнү килешми. *(Әхтәмгә.)* Алай күтәрмә, кызыл погоннар йөрөнә.

Әхтәм стаканын качырып эчә.

Мәрвән. Нигә куркасың, син король бит.

Әхтәм. Я, туктале, эчен пошса, янымда көчләп тотмыйм. Үзең килеп ябыштың, мин сине эзләп йөрмәдем.

Карт. Дустыңа андый ямьсез сүзләр әйтмә, Әхтәм энем. Без барыбыз да адәм балалары. Ә сез аңа гажәпләнмәгез, иптәш. Кызу канлы ул. Миңа да кайвакыт әйтмәгән сүзләрне калдырмый. Ә мин аңа ачуланмыйм. Нигә ачуланырга? Кеше болай да бәхетсез, болай да кыерсытылган. Канатын каерганнар кешенең. Канаты каерылган кош нишли? Үзенә җылы урын эзли. Җылы урын бирергә кирәк канаты каерылган кошка, кулга иялаштерергә кирәк. Тешләшсә дә түзәргә кирәк. Ә кешеләр кансыз. Кыйналганны күбрәк кыйныйлар. Кешеләрдә шәфкать юк.

Мәрвән. Әхтәм, кемең бу?

Әхтәм. Үзеннән сора.

Карт. Юк, кирәкми. Мин аның беркеме түгел, иптәш. Без барыбыз да кешеләр. Без аның белән сөйләшеп утырырга яратабыз. Бераз менә... үзегез күрәсез. Кеше үзенең тиңен табарга тиеш. Без Әхтәм энем белән...

Әхтәм *(кычкырып көлеп)*. Син нәрсә, карт алаша!

Карт. Бернәрсә түгел, Әхтәм энем.

Әхтәм. Нинди тиң мин сиңа! Син кабахәт.

Карт. Син дә кабахәт, Әхмәт энем. Мин кабахәт булганга мин гаепле түгел, син кабахәт булганга син дә гаепле түгел. Дөнья шулай эшләтә. Димәк ки, дөньяга синең белән минем кебекләр кирәк. Менә әйтегез әле, иптәш, дөньяга безнең кебекләр кирәкме? Сез җирәнмәгез, әйтегез.

Мәрвән. Гафу итегез, абзый кеше, сезнең белән сөйләшергә һич кенә дә теләгем юк. Барыгыз, юлыгызда булыгыз.

Карт. Минем барыр юлым юк бит, иптәш. Мин дөньяның читенә килеп җиткән. Менә шушында ул дөнья чите, аны Каф тавы артыннан эзләргә кирәкми. Сез әйтәсез, сөйләшергә теләгем юк, дисез. Менә шулай, сезнең кебекләр безнең белән сөйләшергә теләмиләр. Телисезме, теләмисезме, без бар бит, без яшибез. Бергә, бер кояш астында яшибез. Кояш мәрхәмәтле — арысланга да, куянга да нурын тигез итеп бүлеп бирә. Тик кешеләр генә...

Әхтәм. Җитәр, карт философ! Нәрсә җылыйсың? Барыбер малыңны кире кайтарып бирмәсләр. Пенсия алсаң, шуңа риза бул.

Карт. Ә мин риза. Пенсия бирәләр, ачтан үтермиләр. Әмма ул пенсияне мин бөкрем чыгарып алдым.

Әхтәм. Тагын НЭП ясар идеңме? Үтте ул вакытың, оныт. Үл син.

Карт. Син дә үләсең, Әхтәм энем. Син сәүдәгәр түгел идең. Товарларыңны да тартып алмадылар. Сугышып та кайттың. Орденнар да алдың, институт та бетердең, шулай да үләсең. Минем әҗәлем белән үләсең. Хәтта сиңа пенсия дә түләмиләр. Ник дисәң, бу заманга ир йөрәкле кешеләр кирәкми. Арысланнар куян әҗәле белән үтә торган заман. Куяннар арыслан булып яши. Менә иптәш тә...

Әхтәм. Ана тел тидермә, сасы көзән.

Карт. Исердең, Әхтәм энем.

Мәрвән. Әхтәм, әйдә киттек.

Карт. Кая? Аның да барыр җире юк. *(Әхтәмгә вино салып бирә.)* Мә! Менә шулай корылган ул дөнья, иптәш.

Әхтәм. Булды. Бар, карт, оянга ычкын.

Карт. Миңа иптәш белән сөйләшеп утыру күңелле. Билгеле, ул минем белән сөйләшергә теләми. Ул безгә иш түгел.

Мәрвән. Әгәр яшьрәк кеше булсагыз, абзый...

Карт. Яңагыма сугар идегезме? Бәхәстә көчсез кешеләр һәрвакыт кулларын уйната башлыйлар. Ә син мине тел белән җиң. Тел белән ышандыр.

Мәрвән. Әйе, Әхтәм дус, театрда берәр комедия карап китәрмен дигән идем, сез миңа бушлай кәмит күрсәттегез. Шундый кызык, җылыйсылар килә. Кем уйлаган синнән әйбәт артист чыгар дип. Әшәкелек бит бу. *(Картка күрсәтеп.)* Шулмы синең суфлерың? Бар, абзый кеше, хәзер үк югал. Бар, яхшылап әйтәм. Бар, шартлаганчы эч, күбен, тик кара аны, дөнья сасытып йөрмә.

Әхтәм *(кычкырып көлеп)*. Әй, җәмәгать, күреп калырга ашыгыгыз. Сугыш булачак, кан коечак булачак. Бирешмә, карт алаша. Ник тор, Алпамша. Якасыннан эләктер. Танавына тондыр. Тип! Тешлә! *(Картның якасыннан эләктереп.)* Оянга кайт, дип әйттемме мин сиңа, карт эт. *(Этеп җибәрә. Карт чайкала-чайкала чыгып китә.)*

Әхтәм. Күңелең булдымы, кудым. Инде нишлим?

Мәрвән. Ишетүемчә, син институт бетергәнсең. Кайсын?

Әхтәм. Ә сиңа кайсы кирәк?

Мәрвән. Архитектор булам дип хыялланган идең.

Әхтәм. Хыялланган идем. Һәм булдым да.

Мәрвән. Чынмы? Болай булгач, без синен белән. Беләсеңме, Әхтәм, без авылның яңа генеральный планын төзергә җыенабыз. Менә шуның артыннан чабып йөрим. Проект институтларында булдым.

Әхтәм. Минем анда ни катнашым бар?

Мәрвән. Син архитектор.

Әхтәм. Юк, мин сукбай. *(Утыргычка сузылып ята.)*

Мәрвән. Әхтәм, килешми, кешеләр йөри.

Әхтәм. Миңа бөтен нәрсә килешә. Минем югалтасы авторитетым юк. Тыныч йокы, иптәш Мохтаров. Әгәр милиционер килеп уята башласа, әйт, ул минем дустым, диген, аңа шушында йокларга мин үзем куштым, диген. *(Җайлабрак ята.)*

Мәрвән берара нишләргә белми тора да Әхтәмнең изүеннән тотып торгызып утырта.

Әхтәм. Нишлисең?

Мәрвән. Оятсыз!

Әхтәм. Әй, син, әкрен. Мин теге карт түгел.

Мәрвән. Сук, я сук. Күземә карап әйт. Сугарсыңмы?

Әхтәм. Бәйләнмә. Мин сиңа бәйләнмим ич. Я, торгызып нишләтмәкче буласың? Вәгазь укыргамы? Алай ярамый, болай кирәк, дисеңме. Берни дә кирәкми, йокым килә. Ят минем янга, окоптагы чакларны искә алып кочаклашып йоклыйбыз. Курыкма, монда фашист юк. Монда: «Минем милиция мине саклап тора».

Мәрвән *(бер фикергә килеп)*. Әхтәм, әйдә минем белән.

Әхтәм. Кая?

Мәрвән. Безнең авылга.

Әхтәм. Ни калган миңа синең авылында?

Мәрвән. Синдә кунак булдым инде, үзеңне кунакка чакырам.

Әхтәм. Кунакка? Шәп бу. Дустымның биләмәләрен урап, сыеннан авыз итү начар эш түгел. Хәзер үкме?

Мәрвән. Соңгы поездга өлгерәбез.

Әхтәм. Киттек! Шагом марш, сержант Мохтаров. Сатинны авылга алып кайталар.

### ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Мәрваннәр өе. Тумбочка өстендә радиола бар көченә кычкыра. Нинлидер аңлаешсыз, моңсыз көй. Өй уртасындагы өстәл өстендә бер шешә аракы белән яшел суган. Әхтәм өске киемнәре белән диванда ята. Сайра кайтып керә. Аның өстендәге матур ефәк күлмәге машина маена буялган. Битендә, кулларында да май таплары. Ул өй эчендәге галәмәткә бераз аптырап тора. Барып радиоланы туктата.

Сайра. Әллә сез саңгыраумы? Урамның аргы башына ишетелә.

Әхтәм. Шәп музыка.

Сайра. Һе. Бигрәк аңлыйсыз икән музыканы.

Әхтәм. Начармыни?

Сайра. Искиткеч. Җыештырып куйган урынга киемнәрегез белән менеп яткансыз.

Әхтәм. Ярамыймы?

Сайра. Ярамый. Үз бүлмәгез бар. Шуннан чыкмагыз. Әни кайтмадымы?

Әхтәм. Юк.

Сайра. Әти дәме?

Әхтәм. Юк.

Сайра. *(өстәл өстенә күз салып)*. Гомумән, безнең өйдә аракы эчмәгез.

Әхтәм. Анысын этиең белән сөйләшербез.
Сайра. Нигә сезне сөрмиләр?
Әхтәм. Кая?
Сайра. Әрәмтамакларны еракка җибәрәләр бит.
Әхтәм. Мин әрәмтамакмы?
Сайра. Кем соң? Әтигә ияреп кайттыгыз да китә белмисез.
Әхтәм. Беренчедән, мин ияреп кайтмадым, этиең алып кайтты. Кунакка.
Сайра *(кычкырып көлеп)*. Кунак!
Әхтәм *(яткан җиреннән сикереп торып)*. Селкенмә. Селкенмә, тик тор.
Сайра *(куркуыннан катып кала)*. Нишлисез?
Әхтәм. Шунда тор. Өегездә карандаш белән кәгазь бармы?
Сайра. Нәрсәгә ул?
Әхтәм. Бармы?
Сайра. Тумбочка тартмасындадыр.

Әхтәм тумбочкадан кәгазь, карандаш табып өстәл янына килеп баса. Сайрага карап ала-ала кәгазьгә сызгалый.

Нишлисез?
Әхтәм. Селкенмә. *(Сызгалап бетерә дә кәгазьне Сайрага бирә.)* Мә! *(Үзе тагын диванга сузылып ята.)*
Сайра. Һа! Койган да куйган! Сез художникмы?
Әхтәм. Дилетант.
Сайра. Архитектормы? Әти шулай дигән иде бугай.
Әхтәм. Синең сөйгән егетең бармы?
Сайра. Нәрсә-ә-ә?
Әхтәм. Сиңа ничә яшь?
Сайра. Нәрсәгә ул сезгә?
Әхтәм. Әйт инде.
Сайра. Унҗиде.
Әхтәм. Егерме сигез яшькә яшьрәк булсам, сиңа гашыйк булыр идем.
Сайра. Һе. Тиле-миле. Әни кайтсын әле. Күрсәтер сезгә болай яткан өчен гашыйкны.
Әхтәм. Әниең усал, дөрес әйтәсең.
Сайра. Әйтегез инде, нинди кеше сез? Әти белән сугышта булганыгызны беләм. Башкасын белмим. Әни дә белми.
Әхтәм. Әтиең дә белми. Серле кеше мин.
Сайра. Һе.
Әхтәм. Син әтиеңне яратасыңмы?
Сайра. Ник яратмаска? Әти ич ул. *(Рәсемне карый.)* Һе. Укып художник булып буламы?
Әхтәм. Сәләтең булса була.
Сайра. Укытучы булып буламы?
Әхтәм. Сәләтең булса була.
Сайра. Булмаса?
Әхтәм. Булмый. Син, кызый, ашарга әзерләргә җыенасыңмы?
Сайра. Монда сезгә әзер повар юк.
Әхтәм. Кунакны ач тотмыйлар.
Сайра. Кунак өч көн тора, сез бер атна яшисез.
Әхтәм. Әтиең нәрсә ди, тизрәк китсен иде, диме?
Сайра. Түзәр, түзәр дә әйтер әле. Безнең әти әйтсә, берәгәйләп әйтә.
Әхтәм. Беләм. Мин синең әтиеңне белгәндә син тумаган да идең әле, чибәр кызый. Әйдә, берәр нәрсә әзерлә инде.
Сайра. Ә сез минем рәсемне буяу белән ясарсызмы?

Әхтәм. Юк.
Сайра. Ни өчен?
Әхтәм. Ясый белмим.
Сайра. Һе.

Тәрәзәдән Гашияне күреп.

Әни кайтып килә. Аракыгызны яшерегез.

Әхтәм. Торсын.
Сайра. Куып чыгарачак бит.
Әхтәм. Чыгарсын.
Сайра. Һе.

Икенче бүлмәгә кереп китә. Гашия кайта. Әхтәмгә күз кырые белән генә карап ала да чыгып китә. Тагын әйләнеп керә. Өстәл өстен җыештыра. Тәрәзәне ачып суганны ташлый. Аракы шешәсен Әхтәм алып өлгерә. Әхтәм белән Гашиянең сүзсез сәхнәсен Сайра бүлмә ишегеннән күзәтеп тора. Гашия Сайраның рәсемен күреп кулына ала. Әйләндереп-әйләндереп карый.

Сайра (*түземчә*). Әни, ертма. (*Әнисе кулыннан рәсемне ала.*)
Гашия. Син нишләп өйдә?
Сайра. Кайда булыйм соң?
Гашия. Ник китмәдең?
Сайра. Барасым килмәде. Әйттем ич мин сезгә, бармыйм, дидем. Икеле алып кайтыр өчен нишләп Казанга барыйм.
Гашия. Әйдә чыгыйк әле.
Сайра. Ник?
Гашия. Чык дим.
Әхтәм (*урыныннан торып*). Рәхәтләнеп талашыгыз, мин үзем чыгып торам. (*Чыгып китә.*)
Гашия. Нигә китмәдең дим мин сиңа?
Сайра. Һе. Әйттем ич.
Гашия (*Сайраның буялган кулларын, өс-башын күреп*). Ходаем, нишләттең бу күлмәгеңне?
Сайра. Машина ремонтладык.
Гашия. Машина?!! (*Сайра өстенә килә.*)
Сайра. Әни, кулың белән кагыласы булма. Мин бала-чага түгел. Әйтсәң, телең белән әйт.
Гашия (*кинәт туктап калып*). Җир бит икәнсен. Шул сиңа актыккы сүзем. Мәңге рәхәт күрмәссен. Мине картайтыр өчен туган бала икәнсең.
Сайра. Син үзеңне-үзең картайтасың.
Гашия (*әче тавыш белән кычкырып*). Дәшмә-ә! Оятсыз!
Сайра. Алай итсәң, әни, чыгып китәм һәм бүтән кайтмыйм.
Гашия. Бар! Бар шул машиналарың янына. Тузан ашап чихуткага әйләнгәч, кайтып егылырсың бусагама. (*Чыгып барган Сайрага.*) Тукта! (*Утырып елап җибәрә.*)
Сайра (*әнисе янына килеп*). Нигә елыйсың инде, я? Үз нервыңны үзең бозасың да еларга тотынасың. Укыйсым килми минем. Унынчыны бетердем — шул житкән. Керә алмыйм мин институтка, барыбер икеле куялар. Нәрсәгә аның өчен елыйсың?
Гашия. Үтерәсез сез мине. Атаң белән икәүләп үтерәсез. Беркемгә кирәгем юк. Кая барыйм?
Сайра. Син миңа әйбәт кенә әни бул, әтигә әйбәт кенә хатын бул.
Гашия. Өйрәтмә. (*Әхтәмнең диван башына куйган пиджагын йолкып алып, ишек янына ыргыта.*) Җирәнгеч. (*Сайра пиджакны алырга баргач.*) Тимә. Алсын да китсен аламасын. Күземә күренмәсен. (*Пиджакны алып тәрәзәдән ыргыта.*)

Сайра. Нигә инде, әни?
Гашия. Бар, җыен да хәзер үк кит.

Машина килеп туктаган тавыш. Бераздан Әхтәмнең пиджагын тотып Мәрвән керә.

Мәрвән *(пиджакка күрсәтеп)*. Нишләп ишек алдында ята ул? *(Турсаешкан Гашиягә һәм Сайрага карап.)* Ни булды сезгә? Әллә тоз ашадыгызмы? Әхтәм кайда, Гашия?
Гашия. Нигә миннән сорыйсың?
Мәрвән. Күрше хатыныннан сорыйммыни?
Гашия. Йөрәгең алынмасын. Беркая да китмәгәндер. Җибәрерсең синең ул хәерчеңне. Минем башыма җитмичә торып.
Мәрвән. Булды. Ашарга бирәр нәрсә бармы?
Гашия. Пешерегез дә ашагыз. Монда сезгә кәҗүнни кеше юк.
Мәрвән. Гашия, мин иртән сәгать өчтә чыгып китәм. Көненә мең кеше белән очрашам. Кайсының кәефе юк, кайсына кайгы килгән, кайсына фәлән кирәк, кайсына төгән җитми. Инде өйгә кайткач, адәм баласына аз гына тынычлап ашарга ярыйдыр бит?
Гашия. Чыгып китсән, минем өчен чыгып китәсең мәллә.
Мәрвән. Кем өчен соң?
Гашия. Кем белгән синең кем өчен чабып йөргәнеңне. Кешеләр дә кешеләр. Бөтенесенә ярыйсың, өең генә гамеңә кереп чыкмый. Ашарга, имеш. Әле яңа гына аякларымны көчкә сөйрәп дуңгыз көтеп кайттым. Кешедән оят, председатель хатыны булып дуңгыз көтүе көтеп йөр инде. Кыш буе дуңгыз абзарыннан чыккан юк, хәзер дә...
Мәрвән. Бер көнгә түзәрсең. Үзең беләсең, Садыйк хатынын больницага илтә китте. Аның урынына бүтән кешене үз эшеннән аерып булмый.
Гашия. Көтүченең хатыны бәбәйләгәндә, аны больницага ире илтә китә. Мин...
Мәрвән. Син район кибетенә пальто эзләп барганда, председатель машинасына утырып барасың.
Гашия. Күпсендең шуны, ярар, җәяү барырмын.
Мәрвән. Булды. *(Сайрага.)* Безнең эштә икәнне беләсең. Буйга җиткән кыз, ашарга гына әзерли аласыңдыр.
Сайра. Өйдә аш пешереп ятарга, әллә мин бүтән эшкә ярамыйммы?
Мәрвән. Менә рәхәт тормыш. Әйдәгез, җыеныгыз, ашханәгә киттек.
Гашия. Йөрисең юк кеше көлдереп. Базда сөт, катык, алып чыгыгыз да ашагыз.
Мәрвән. Ә син?
Гашия. Тамагымнан аш үтәмени минем. Сәгать өчтә чыгып китәм, дисең. Кызыңа күз дә салмыйсың.
Мәрвән. Ни булган?
Гашия. Әнә кара, сөен. Кызың тракторчы булган. Үтереп мактарлар инде үзеңне. Хатыны дуңгыз карый, кызы җир сукалый, диярләр. Ике көннән сынаулары башлана, ул бармыйм, укыйсым килми, ди.
Сайра. Әти, үзең бит мәктәпкә килеп җыелышта сөйләдең. Безгә белемле яшьләр кирәк, дидең, механизатор булырга чакырдың. Кызлар кулына да техниканы тапшырырга курыкмыйбыз, дидең. Рәхим итегез, дидең.
Мәрвән. Шуннан?
Сайра. Минем педагогия институтында укыйсым килми. Анда мин барыбер укый алмыйм. Минем шофер буласым килә.
Мәрвән. Укыйсың килмәсә укыма. Укыйсы килгәннәр укыр.
Сайра. Нигә соң әни шәһәргә куа?

Мәрвән. Беркем дә кумас.

Гашия. Кумам ди менә. Кыз башың белән мазутка буялып йөрер иденме? Үзем кеше көлкесенә калган да җиткән. Укыган булсам...

Мәрвән. Укыган булсаң, нишләр идең?

Гашия. Дуңгызлар арасында йөрмәс идем.

Мәрвән. Алар арасында кем йөрер?

Гашия. Син.

Мәрвән. Кирәк булса йөрермен, әнисе. Тик әлегә миңа кешеләр белән эшләүне ышанып тапшырганнар. Шуны акларга кирәк. Сиңа, Гашия бәгырем, уку бөтенләй икенче нәрсә өчен, эшләмәс өчен кирәк. Нигә әле син үзеннең укымаганлыгыңны кызың үсеп җиткәч кенә исенә төшерден. Әйттем бит мин сиңа, икебез дә читтән торып укыйк, дидем. Син нәрсә диден? Исеңә төшер. Я, ярый. Тагын ашауны оныттык. Бар, Сайра, базга төш.

Гашия *(әрнеп)*. Йөрмәгез.

Чыгып китә.

Мәрвән *(Сайрага)*. Кайда буялдың?

Сайра. Машина ремонтладык.

Мәрвән. Шуннан?

Сайра. Механик әйтте, урак өстендә шул машинада Нәҗип абыең белән алмашлап эшләрсез, диде.

Мәрвән. Укытучы буласым килми, дисең инде?

Сайра. Юк.

Мәрвән. Ә бит институтның бүтәннәре дә бар. Авыл хуҗалыгы институты, мәсәлән. Техниканы алай нык яраткач, инженер-механик булыр идең. Укыйсым килми дип булмый. Югары белемле кешеләр кирәк булмаса, институтларны ябарлар иде.

Сайра. Минем эшләп карыйсым килә.

Мәрвән. Эшләп кара, алайса. Тик миңа аркаланырга җыенма. Бүтәннәр кебек эшлисең, бүтәннәр кебек үк җавап бирәсең. Аннан соң, өйгә кайткач, өстәл артында болай утырма. Буялып йөрү әлегә сиңа кызыктыр, бәлки. Өстәл артында минем кызым кызларга охшаган булсын. Егетләр янына чыкканда да бензин исе килерлек булмасын. Бар юын, өстең алыштыр.

Сайра чыга башлый.

Мәрвән. Син Әхтәм абыеңны күрдеңме бүген?

Сайра. Мин кайтканда өйдә иде.

Мәрвән. Кая китте?

Сайра. Белмим. Бакчага чыккандыр. Менә ул минем рәсемемне ясады.

Сайра чыгып китә. Мәрвән рәсемне карый. Сөт, катык күтәреп Гашия керә.

Мәрвән. Арыгансыңдыр, әнисе, көтү көтү ардыра. Я, пырлама, утыр, чүкердәшеп ашап-эчик. Нишләтәсең, агай-эне, бөтен нәрсәне механикалаштырып була, ә көтү көтүне... Бәлки, махсус роботлар уйлап табарлар. Ул вакытта без мич башында ятып приказ гына биреп торырбыз. Әлегә авыл кулга мохтаҗ, маңгай тиренә мохтаҗ. Мактансак та, мактанмасак та, моны яшереп булмый. Менә уракка төштек, гектарыннан егерме биш центнер көтәбез. Ә шуны дәүләт амбарына ташырга машина җитми. Акча бар, сатыгыз, дибез. Әлегә юк, көтегез, диләр. Ә икмәк үсә тора. Син дуңгыз карыйсың. Йөзләгән тонна ит тапшырабыз. Ә шәһәр кибетләрендә ит юк. Әлегә җитми. Булдырырга кирәк, Гашия. Бездән көтәләр. Ә син кызың укырга теләмәгәнгә дөнья куптарып йөрисең. Керер. Башы яшь.

Мәрвән сөйләгәндә Гашия өстәл әзерли. Мәрвән соңгы сүзен әйткәндә өстәл өстенә Әхтәмнең шешәсен китереп утырта.

Мәрвән. Монысы нәрсә?

Гашия. Күрмисеңмени?

Мәрвән. Мин бит кибетчегә әйткән идем, Әхтәмгә аракы сатма дигән идем.

Гашия. Дуңгызның кайчан пычрак тапмый калганы бар. Син бик әйбәт бит. Акчаңны кызганмыйсың. Күпме сораса, шул чаклы бирәсең. Әйдә, эчсен, рәхәтләнсен. Әйт, нишләргә җыенасың аның белән?

Мәрвән. Аптыраган инде.

Гашия. Син аптырасаң, мин аны куып чыгарам.

Мәрвән. Ашыкма әле, уйлансын.

Гашия. Уйлансын, алайса. Мин үзем чыгып китәм. Бер башыма урын табылыр. Барыбер бу йортта мине кешегә санамыйлар. Ичмасам, кеше көлмәс. Дуңгыз көтсәм дә, тол хатын, ашарына җитмидер, диярләр.

Мәрвән. Я инде, Гашия. Җитте инде, булды инде. Ничек арымыйсың?

Гашия. Котылырсың.

Мәрвән. Без синең белән егерме ел яшибез. Шул егерме ел эчендә китәм дип ничә тапкыр әйткәнеңне беләсеңме син? Йөздән ким түгел. Ничек түзмәк кирәк. Я китсәң кит инде син, я шул сүз белән теңкәгә тимә. Нәрсә җитми? Күтәрелеп авыр сүз дә әйткәнем юк бит минем сиңа. Һаман үзеңне-үзең талкыйсың. Әнә күршеләр. Икесе дә таңнан торып эшкә китәләр. Берсе синең кебек үк фермада, икенчесе — тракторда. Кич кайталар. Өй тулы бала-чага. Тәрәзәләре каршыннан үткәндә, өй эчендәге көлү тавышларына сокланып үтәсең. Егет белән кыз шикелле яшиләр. Ә без? Икебезгә бер бөртек бала, сукранышудан башка эшебез юк. Болай ярамый бит. Икенче ул сүзеңне әйтмә. Мин түзәрмен түзәрмен дә, үзем үк чыгып китәрмен. Рәхәт булырмы сиңа? Дөнья түгәрәкләнерме? Кешеләр ич без.

Гашия. Кеше дип исерекнең пычрагын тазартыргамыни?

Мәрвән. Нишлисең? Без аны аякка бастырырга тиешбез.

Гашия. Аны аякка бастырганчы, без егылырбыз. Дөньядагы бөтен исерекне өеңә җыеп алып кайт инде, алайса. Барысын да аякка бастыр.

Мәрвән. Кирәк булса, анысын да эшләрбез. Бергәләп, ил белән. Әлегә безнең өйдә — Әхтәм. Минем җан дустым. Син минем яраткан хатыным.

Тышта мотоцикл килеп туктаган тавыш. Йосыпов керә.

Йосыпов. Исәнмесез. Гафу итегез, Мәрвән абый. Идарәгезгә кергән идем, сез юк. Бик кирәк идегез.

Мәрвән. Урак өстендә идарәдә утырган председатель кем була инде ул? Утырыгыз. Кызык, сезгә ни өчен кирәк булдым икән?

Йосыпов. Чыгып кына керик, Мәрвән абый.

Мәрвән. Сер үкмени, Гашия...

Гашия чыгып китә.

Йосыпов. Ул чаклы сер дә түгел. Шулай да артык кешенең ишетмәве яхшы. Үтәмеш авылындагы кибетне басканнар.

Мәрвән. Кибетне? Әле шундый нәрсәләр дә бармыни дөньяда?

Йосыпов. Килеп чыккалый шул. Еллар буе тынычлап яшибез, вак-төяк белән генә шөгыльләнәбез. Менә шунда тәки килеп чыга.

Мәрвән. Миннән шикләнмисездер бит?

Йосыпов. Шаярмагыз инде, Мәрвән абый. Тәк. Менә болай... Тик, зинһар, башта ук әйтеп куям: гафу итегез. Бүген иртән Бортас

магазинына бер кеше кергән. Шикле, диләр. Күргән-белгән кеше түгел, диләр. Теләсә ни сөйләнә, ди. Аракы алган. Сораша торгач, ул кеше сезнең авылга килгән кеше булып чыкты. Ялгышмасам, хәтта сезнең үзегезгә, ди.

Мәрвән (*рәхәтләнеп көлә*). Әхтәмме?

Йосыпов. Исем-фамилиясен белмиләр. Нигә көләсез?

Мәрвән. Соң, Йосыпов иптәш, Әхтәм минем дус.

Йосыпов. Шуңа күрә башта ук гафу үтендем. Ләкин үзегез беләсез, безнең эш...

Мәрвән. Аңлыйм, аңлыйм. Әмма бу очракта... Әхтәм.... Юк, Йосыпов иптәш, андый кеше түгел Әхтәм. Сөйләгәндер, кылангандыр, ә кибет басарга. Миңа килеп дөрес эшләгәнсез.

Йосыпов. Шулай да нинди кеше ул?

Мәрвән. Минем кунагым, фронтовик дустым, шул җитәме?

Йосыпов. Җитә, Мәрвән абый. Ярый, исән булыгыз, тагын бер кат гафу.

Мәрвән. Зарар юк.

Йосыпов чыгып китә. Гашия керә.

Гашия. Шуның турындамы?

Мәрвән. Шуның турында.

Гашия. Әйттем бит. Әле тезелешеп суд каршына басасыбыз бар. Нишләгән?

Мәрвән. Үтәмеш авылының кибетен баскан.

Гашия. Нәрсә?!

Мәрвән (*Гашияне кочаклап*). Әй, әнисе, әнисе. Чуртым да юк, утыр әле, аша әле тынычлап. (*Гашияне үз янына утырта.*)

Әхтәм (*керә*). Күрәм, берәүнең дә мине чакырырга исәбе юк. Ә мин көнозын ашамаган.

Мәрвән. Нихәл, Әхтәм.

Әхтәм. Ал да гөл. Ашыйсы килүен исәпләмәгәндә. Күрәм, хәләл җефетеңнең кәефе юк.

Гашия. Ачуымны китереп...

Мәрвән. Гашия!..

Әхтәм. Нигә тыясың. Әйтеп бетерсен. Яратам хатын-кызның шәпчүен. Чөнки алар чәпчеп киткәндә, үзләре дә сизмәстән, хакыйкатьне әйтеп ташлыйлар, икейөзләнмиләр, кыланмыйлар. Ә безнең заманга хакыйкать җитми. Без аны әйтергә куркабыз яки оялабыз. Сөйләгез, Гашия ханым, мин сезне тыңлыйм, ирегез дә тыңласын. (*Сайра кергәнне күреп.*) О, сез дә килегез, туташ, сезгә дә хакыйкатьне ишетергә кирәк.

Гашия. Оятсыз ук икәнсез.

Әхтәм. Беләм. Ирегез ничек, әйбәтме? (*Сайрага.*) Ничек сезнең әтиегез, шәпме? Бөтен кешелек дөньясына үрнәк булырлыкмы?

Мәрвән. Утыр, Әхтәм, аша.

Әхтәм. Утырам һәм ашыйм. Чөнки мин кунакта. Әллә дөрес түгелме, Гашия ханым?

Гашия (*кычкырып*). Җитәр!! Хәзер үк чыгып кит. Чыгып кит. Эзең булмасын.

Сайра. Әни...

Гашия. Кит! Китегез! (*Булмәгә кереп китә.*)

Сайра. Сез нигә әнине үртисез?

Әхтәм. Мин аны үртәмәдем, чибәр кызый. Мин әтиегезне үртәргә теләгән идем, ләкин ул үртәлми. Ул салкын канлы, чыдам. Аны мыскыл итәләр, ул түзә. Чөнки ул түзәргә күнеккән. Аны күнектергәннәр. Күрәсең, шәп дрессировщиклар кулында тәрбияләнгән.

Мәрвән. Сөйләп бетердеңме? Утыр инде хәзер. Менә даруың. *(Шешәне Әхтәм алдына куя.)*

Әхтәм. Нигә тыймыйсың? Син бит сатучыга әйткәнсең, Әхтәмгә сатма, дигәнсең.

Мәрвән. Тапкансың ич, молодец.

Әхтәм *(ачык тәрәзәдән шешәне тышка ташлый).* Ятсын шунда, яшел суганнар янында.

Сайра *(көлеп).* Кыланчык.

Әхтәм. Кызың әйбәт, Мәрвән дус. Хатының да әйбәт. Бар, чакыр үзен. Тынычлап әбәтләсен. Бер сүз дә дәшмәскә, тәртипле генә утырырга сүз бирәм. *(Тыныч кына ашыйлар.)*

Сайра. Сез, Әхтәм абый, чын кеше кебек түгел.

Әхтәм. Кызык.

Сайра. Пьесаларда язылган герой кебек.

Әхтәм. Валлаһи, диген. Нинди герой соң? Яхшысымы, начарымы?

Сайра. Начары. Ләкин мин сездән курыкмыйм. Сез үзегез яхшы кеше булырга тиеш кебек.

Икмәк, сөт алып Гашия кереп киткән бүлмәгә юнәлә. Пауза.

Әхтәм *(Мәрвәнгә).* Я?

Мәрвән. Нәрсә, я?

Әхтәм. Ни әйтәсең дим?

Мәрвән. Бер сүз әйтмим.

Әхтәм. Әйтергә сүзең юкмыни?

Мәрвән. Әлегә юк.

Әхтәм. Кайчан булыр?

Мәрвән. Белмим.

Әхтәм. Алайса, мин бүген китәм.

Мәрвән. Ихтыярың.

Әхтәм. Ә мин сине кыйнап китәм.

Мәрвән. Рәхим ит.

Әхтәм. Ә бит синең әйтер сүзең бар, Мәрвән.

Мәрвән. Бар иде.

Әхтәм. Нигә хәзер юк?

Мәрвән. Чөнки аларны әйтүдән мәгънә юк... Я, ярый, мин басуга киттем. Күрешмәсәк, бигайбә, теге картка сәлам әйт.

Әхтәм. Хуш. Юлларың уңышлы булсын!

Мәрвән. Рәхмәт.

Әхтәм. Димәк, хатыныңа кушылып син дә мине куасың?

Мәрвән. Үзең китәм дидең.

Әхтәм. Кал дип әйтмисең ич.

Мәрвән. Әйтмим.

Әхтәм. Димәк, куасың. Ә ни өчен алып кайттың?

Мәрвән. Ялгыш булган.

Әхтәм. Менә аңлаштык.

Мәрвән. Син молодец. Бүген егетлек эшләгәнсең. Авыл уртасындагы пычрак күлдә казлар белән су коенгансың. Бер комбайнчыны сыйлагансың, эшкә бармаган.

Әхтәм. Ә ни өчен авыл уртасындагы күлне пычрак тотасыз? Нигә шундый алдынгы колхозның комбайнчысы урак өстендә эшенә җавапсыз карый? Нигә шундый бозык кешенең коткысына бирелә?

Мәрвән. Син бозык кешемени?

Әхтәм. Син шулай уйлыйсың минем турында. Кара, син сөйләмәскә теләгән идең ич.

Мәрвән. Гафу ит.

Әхтәм. Нигә китмисең инде? Эшең көтә.

Мәрвән. Сине озатыйм башта.

Зәйнуллин *(керә)*. Мөмкинме? Исәнмесез.

Мәрвән. Әйдүк, әйдүк, түрдән узыгыз, коллега. Кичә идарәгезгә кергән идем, очратмадым. Утырыгыз әйдә. Салкын катык...

Зәйнуллин. Рәхмәт. Мәрвән Идрисович, сез колхоз председателе, мин колхоз председателе. Сез үз колхозыгызда теләсә нишләгез, минем колхозга килеп минем җиргә хуҗа булып йөрмәгез.

Мәрвән. Беренчедән, иптәш Зәйнуллин, сезнең җирегез юк. Җир дәүләтнеке. Икенчедән, сабыррак, мин сездән өлкән кеше.

Зәйнуллин. Билгеле, сез өлкән, сез дәрәҗәле, без вак-төяк, бала-чага. Ләкин мин дә сезнең кебек үк югары белемле агроном.

Мәрвән. Югары белемле агроном, ә менә мелиораторлар чакырып, чишмәләрне корытып ятасыз. Сезне эзләп таба алмагач, мелиораторларга әйттем, ярамаган эш эшлисез, туктап торыгыз, дидем, председатель бераз ашыккан, дидем.

Зәйнуллин. Миңа икмәк үстерү өчен җир кирәк. Анда ничаклы сазлык.

Мәрвән. Кизләүне сазлыктан аера беләм мин, энекәш. Җир җитми дип, әнә, Иделне корытыгыз. Булган җирдән файдаланырга өйрәник.

Зәйнуллин. Әллә кем булдыгыз. Тегендә Идрисов, монда Идрисов. Идрисов депутат, Идрисов теге, Идрисов бу.

Мәрвән. Идрисов теге дә түгел, бу да түгел. Идрисов — коммунист. Җиребезнең киләчәге, кешеләрнең киләчәге турында уйланмаска Идрисовның хакы юк, иптәш председатель. Сез җир кирәк дип, бүген чишмәләрне киптерәсез, урманнарны кисәсез. Югары уныш та алырсыз. Ә киләсе заман кешеләре сезне мөртәт дип сүгәчәк. Идрисов депутат кына түгел, Идрисов райком бюросы члены да. Сез бюро алдында җавап бирәчәксез.

Зәйнуллин. Ул сазлыкны киптерүне мин үзем генә хәл итмәдем.

Мәрвән. Бергәләп җавап бирерсез. Тик карагыз, мелиораторларга әйтегез, эшкә тотынмасыннар. Мәсьәлә зурга китәчәк, энекәш. Кабатлап әйтәм. Җир-су сезнеке түгел, дәүләтнеке, халыкныкы. Анда теләсә кемнең теләсә ничек казынырга хакы юк. Сезгә кечкенә генә бер киңәш. Кайтыгыз да ак сакаллы картларыгызны җыеп сөйләшегез, киңәшегез. Алар ни әйтерләр икән. Я, утырыгыз.

Зәйнуллин. Рәхмәт, мин ашыгам. Сау булыгыз. *(Китә.)*

Әхтәм. Усаллангансың син.

Мәрвән. Сиңа рәхәт, сиңа җир дә, ил дә кирәкми.

Әхтәм. Кем белә... Әйдә, киттекме?

Мәрвән. Менә нәрсә, дус кеше, беркая да бармыйсың. Уйнама син минем белән. Уйнама, Әхтәм дус, үтенеп сорыйм. Сизәм бит мин, кыланганыңны сизәм. Тик нишләргә җыенганыңны, ни теләгәнеңне аңламыйм.

Әхтәм. Һәм өстәвенә минем кем икәнемне дә белмисең.

Мәрвән. Синең кемлегең миңа кирәкми дә. Мин синең җәмгыять тәненә ябышкан **паразит** икәнеңне күреп торам, шул җиткән.

Әхтәм *(сискәнеп китә)*. Паразит? Син миңа?.. Димәк, ачыктаначык сөйләшергә вакыт җитте. Димәк, уйнамыйбыз? Ә бит уенны син башладың, дускай. Шәһәр сыраханәсендә бер исерекне очраттың да, үзеңне кодрәт иясенә санап, шул мескенгә кулың суздың. Янәсе, беткән кешене хак юлга бастыру саваплы эш. Мәңге оҗмахлы буласың килде. Күрегез, иптәш колхозчылар һәм дә житәкче иптәшләр, мин нинди әйбәт кеше. Син дә күр, алла колы Әхтәм, рәхмәт әйтерсең миңа. Башта син кунак бул, караштыргала, минем бөеклегемә ышан. Аннан иманга килерсең. Мин синнән бер нәрсәне дә кызганмыйм, кирәк икән акча да бирәм, кыланганына да түзәм. Тик ышан гына. Дөресме? Ә нигә түзмәдең? Синең пәйгамбәр икәнлегеңә ышанырга, инанырга

теләмәгәч, паразитмы? Ә ни өчен ышанырга? Әйт, ни өчен мин сиңа ианырга тиеш?

Мәрвән. Әхтәм, шундый сүзләр әйтергә ничек телең әйләнә?

Әхтәм. Синең ничек әйләнә?

Мәрвән. Мәҗбүр иттең. Аңла, мин кодрәт иясе дә, шайтан да түгел. Кеше! Син дә кеше. Ләкин син хак юлдан чыккан кеше. Нигә алай, нигә тайпылдың — син аның сәбәпләрен ни өчендер яшерәсең, сер итеп саклыйсың. Бел, ишет, агай-эне, алып чыгам мин сине хак юлга, якаңнан сөйрәп алып чыгам. Тыпырчын, сүген, әллә ниләр әйт, барыбер алып чыгам. Кеше синең кебек яшәргә тиеш түгел, хакын юк. Аңлыйсыңмы? Дөнья гөр килә, җиде кат күккә менә кешеләр, җиде кат җир астына төшә, диңгез төбен айкый, син башыңны җүләргә салып йөрисең. Кемгәдер ачу саклыйсың. Кемгә? Кем сине рәнҗетте? Илеңме, кешеләреме? Беләсеңме, син үзеңнең паразитлыгыңны акларга азапланасың бит. Илгә кирәкми башладым, имеш, янәсе, ул ил өчен фашистка каршы сугышканда гына кирәк булган. Син акыл сатарга яратасың, башыңны эшләтергә иренәсең. Илгә кирәклегең бу хәлендә күпмедер, әмма ил синең үзең өчен кирәк. Әгәр син сугышып йөрмәсәң, ил харап булган булыр идеме? Син генә булмадың анда, ил белән булдык. Син фронттагы батырлыгыңны, кешелегеңне илгә әҗәткә биреп тордыңмыни, хәзер шуны түләүләрен таләп итәсеңме? Ә ил өчен башларын салган ир-егетләрнең гомерләре өчен кем түләр? Син исән калдың, шуңа шатлан, ул шатлыгыңны бүтәннәр күрсен, илең күрсен... Син үзеңне ниндидер оригиналь кеше дип уйлама. Бар синең кебекләр. Бер тиен яхшылык эшләп, ун тиен хөрмәт көтеп йөрүчеләр. Булмас, андый нәрсә өмет итмә. Без ил каршында, кешеләр каршында мәңгелек бурычлылар. Без ул бурычны йөрәк ялкыныбыз белән генә түли алабыз. Ә син ни белән түлисең?! Янмый синең йөрәгең. Кабынып китәргә теләгәндә дә, син аңа аракы сибеп сүндергәнсең. Паразит дигән сүз өчен хәтерең калган булып кыланма. Турысын әйтергә яратабыз без. Кеше үтерүчегә фашист дидек, илен сатучыга хыянәтче дидек, ахмакны ахмак дип атадык, хәтта аның чинына, дәрәҗәсенә дә карап тормадык. Илеңнән, кешеләрдән, дусларыңнан авыр сүз ишетәсең килмәсә, кеше бул, җанкисәгем.

Әхтәм. Ләкин мин паразит түгел! Түгел! Түгел!

Мәрвән. Кем? Бәлки, бик тәти егетсеңдер. Әмма мин аны күрмим. Мин синең исерек баштан теләсә ни сөйләнгәнеңне генә ишетәм.

Әхтәм. Паразит түгел мин! Әгәр минем өчен расходлангансың икән, түләрмен, бише белән кайтарырмын. Исерекбаш та түгел. Бик теләп исерек баш булыр идем, аракы алмый. Башым шайтан тәгәрмәче кебек бертуктаусыз әйләнеп тора. Дөрес, кыланам мин. Ә нигә кыланмаска? Дөньясы цирк икән, анда клоун да кирәк. Мин дә заманында нәкъ синең кебек идем. Институт бетердем, архитектор дипломы алдым. Барысы да бишлеләр иде дипломда, үзе кызыл тышлы иде. Кешелек турында синнән дә кызылрак итеп сөйли идем. Кешеләр өчен сарайлар төзергә хыялландым. Миңа әйттеләр — кешеләргә сарайлар кирәкми, аларга барак та ярап тора, диделәр. Исбатларга тырыштым. Көлделәр. Бер ахмагы кычкырып көлде. Ахмакны ахмак дип атаган өчен эшемнән куdылар. Хаклык эзләп йөрдем. Тагын ахмакка очрадым. Акыллылары да очрады. Тик алар ахмаклардан курыктылар. Менә шуннан синең кебек кызып китеп бер ахмакның танавына сыладым. Акыллы кешеләр хөкем иттеләр. Биш елга ябып куйдылар. Биш ел ташчы булып барак төзедем. Кызыл дипломлы архитектор булуым белән кызыксынучы булмады. Ә син ахмакны ахмак дип атарга курыкмыйм дисең. Ахмаклыкка каршы көрәшеп булмый. Уйнама, Мәрвән. Безнең юллар аерым.

Мәрвән. Синең юлың, бәлки, теге карт беләндер? Аның фәлсәфәсен кабатлыйсың. Ахмаклык, фәлән-төгән. Аның безгә ачуы булган, ә син бит безнең дошманнарыбыз сүзен сөйлисең. Кем уйлаган синнән шундый бәндә чыгар дип, кемнең башына килгән. Болай булырлыгыңны белгән булсам, синең белән разведкага йөрмәгән булыр идем. Безнең юллар аерым, имеш. Һәр юлның чиге була.

Әхтәм. Аның чигенә без синең белән бергәләп житәрбез. Тик каберләр генә икесе ике читтә булыр.

Мәрвән. Әхтәм, акылыңа кил. Ач күзеңне — дөнья бу.

Әхтәм. Дөрес түгел. Йом күзеңне — дөнья бу. Аш-суың өчен рәхмәт, хатыныңнан гафу үтенәм. Хуш! *(Чыгып китә.)*

*Пәрдә.*

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Район үзәгендәге милиция бүлеге. Өстәл артында лейтенант Йосыпов утыра. Аның каршында Сайра.

Йосыпов. Я, инде нишлибез, гражданка?

Сайра. Мин гражданка түгел, минем исем-фамилиям бар.

Йосыпов. Исемегез Сайра, фамилиягез Идрисова. Анысын беләек, ә менә правагыз юк. Правасыз килеш машинага утырып, район үзәгендә урам әйләнеп йөрисез.

Сайра. Һе. Мин урам әйләнмәдем, кирпечкә килгән идем. Кагыйдә бозмадым. Милиционерыгыз тик торганнан килеп бәйләнде.

Йосыпов. Милиция бәйләнми, тәртип саклый, Сайра Идрисова.

Сайра. Мин тәртип бозмадым.

Йосыпов. Правасыз рульгә утыру тәртип бозу инде ул, Сайра Идрисова. Сез үзегез белмәсәгез, сезгә машина ышанып бирүчеләр белергә тиеш.

Сайра. Мин машинаны кайбер правалы кешеләрдән әйбәт беләм.

Йосыпов. Шулаймыни?

Сайра. Шулай шул.

Йосыпов. Ярый соң, алай булгач, барлык правалы шоферларны куабыз да правасыз кызларны утыртабыз машиналарга.

Сайра. Җибәрегез, соңга калам.

Йосыпов. Ишем авылы биш кенә чакрым. Өлгерерсез. Мотоцикл белән үзем илтеп куярмын.

Сайра. Ә машина?

Йосыпов. Бездә калып торыр. Председателегез үзе килеп алыр.

Сайра. Юк, мин машинасыз кайтмыйм.

Йосыпов. Алайса, үзегез дә председатель килеп алганны көтәрсез. Бергәләп культура йортына танцага барырбыз. Тәк, сезнең исемегез Сайра? *(Көйләп.)* Сайра, сайра, сандугач, сандугач, син китәрсең, мин калам. Минем исемем Хәйдәр. Ишеткәнегез бардыр Хәйдәр Йосыповны?

Сайра. Юк.

Йосыпов. Кызганыч. Килештекме, Сайра?

Сайра. Нәрсә килештекме?

Йосыпов. Ярты сәгатьтән мин алышынам. Танцага барабыз.

Сайра. Аннан?

Йосыпов. Аннан мотоцикл белән авылыгызга.

Сайра. Һе. Ә машина?

Йосыпов. Машина бездә калып тора. Сезнең хакка мин биреп җибәрер идем дә, ярамый, Сайра. Сез тәртип бозгансыз икән, сез аклана аласыз, белмәдем дисез, ә милиция белмәдем дип әйтә алмый, ул барысын да белергә тиеш. Тәк, язып куйыйк. Машина номеры 56-95, «Тукай» колхозы, Сайра Идрисова, председателе Мәрвән абый. Тәк, фамилиясе ничек әле? Тәк, тәк, Идрисов бит? Әйе, Идрисов, Идрисов. Әллә сез аның...

Сайра. Кызы.

Йосыпов. О-о-о! Исәнмесез, исәнмесез, иптәш Идрисова. Хуш килгәнсез безгә. Монда түгел, башка җирдә күрешергә насыйп булсын... Сайра, сайра, сандугач, сандугач, китмә, китмә, сандугач... Тәк, Мәрвән абыйга шалтыратыйк, кызың ышанычлы кулларда дип әйтик.

Сайра. Шалтыратмагыз.

Йосыпов. Нигә?

Сайра. Ачулана ул.

Йосыпов. Ачулансын. Мәрвән абый районда данлыклы кеше, тик тәртип бозарга аңа да рөхсәт ителми. Кызына бигрәк тә.

Сайра. Зинһар шалтыратмагыз.

Йосыпов. Барыбер беләчәк бит.

Сайра. Вак-төякне тиз күрәсез, зур җинаятьләрне дә шулай күрсәгез иде.

Йосыпов. Барысын да күрәбез, Сайра. Күптән түгел бер рецидивистны эләктергән кеше утыра сезнең каршыда.

Сайра. Нәрсә соң ул рецидивист?

Йосыпов. Белмәсәгез, белмәгез инде сез аны, Сайра. Андый сүзне белмәвегез әйбәт. Нигә сез, Сайра, укып права алмыйсыз, бездә курслар бар.

Сайра. Кышка киләм.

Йосыпов. Бик әйбәт. Йөргән егетегез бармы?

Сайра. Анысы нигә?

Йосыпов. Анысы минем үземә кирәк. Белеп тору зыян итмәс, я күзем төшеп куяр, өйләнмәгән егет.

Сайра. Егетнең өйләнгәне дә буламыни?

Йосыпов *(көлеп)*. Әйбәт әйттегез, Сайра. Утырыгыз әле. Ашыкмагыз. Мине алыштырырга икенче дежурный киләчәк. Ул миңа караганда мәрхәмәтлерәк, бәлки, машинагызны биреп җибәрер. Мин булдыра алмыйм, гафу итегез. Утырыгыз әле.

Сайра. Нәрсә кирәксә сез миннән? Әллә мин сезгә уенчыкмы? Күңелең булсын, алыгыз машинаны. Бик курыктым. Китәргә рөхсәт итәсезме, әллә ябып ук куясызмы?

Йосыпов. Ашыкмагыз, Сайра, үзем озатып куярмын.

Сайра. Кирәгегез бер тиен.

Йосыпов. Ачуланмагыз инде.

Сайра. Милициягә алып кереп, кызларны куркытып танышмагыз, сезгә кем карасын.

Йосыпов. Монысы инде мыскыл итү, Сайра Идрисова. Мин сезне мыскыл итмәдем бит.

Сайра. Әллә тагын мыскыл да итәр идегезме? Хушыгыз.

Йосыпов. Хушыгыз.

Шалтыратырга дип телефон трубкасын ала. Кире куя да ишеккә бара. Ишекне ачып Сайраны чакыра.

Сайра! Сайра Идрисова! *(Сайра җавап бирмәгәч, телефон янына килә, шалтырата)*. «Тукай» колхозымы? Мәрвән абый кирәк. Мәрвән абый, бу — милиция бүлегеннән Йосыпов. Юк, куркыныч нәрсә юк. Правалы шофер җибәрегез. Машинагызны алып китсен. 56-95. Әйе, Сайра

Идрисова. Юк инде, юк... Мәрвән абый, Мәрвән абый.... *(Трубканы куя.)* Милиция сүзен ишеткәч, нигә курка бу кеше дигәнең. Сайра, сайра, сандугач, сандугач, сандугач...

Әхтәмне култыклап милиционер керә.

Милиционер. Менә, Хәйдәр Садыйкович, ашханәдә. Уртадагы өстәл артында яшерми-нитми эчеп утыра. Менә эчеп бетермәгән яртысы. Әйткән идем, талаша башлады, кешеләр алдында «молокосос» дип кычкырды, каршылык күрсәтте.

Әхтәм *(милиционерга)*. Молокосос! Мин аракы эчкәндә, син минем тынычлыгымны саклап торырга тиеш. Үррә катып, честь биреп.

Милиционер. Житте дим.

Әхтәм. Я, ишет мактау сүзен, мин килдем.

Милиционер. Килмәдең, алып килдем.

Әхтәм. Чеби! Инкубатор чебие!

Йосыпов. Утырыгыз, гражданин.

Әхтәм. Минем утырып торырга вакытым юк.

Йосыпов. Без вакытны табарбыз, борчылмагыз. Ашыксагыз, озак тотмабыз. Тик аңлашып аерылышыйк.

Әхтәм. Мин аңлашырга теләмим. Сезнең белән бүлешәсе нәрсәм юк.

Йосыпов. Сез исерекме?

Әхтәм. Исерек. Черек виноград суы эчеп кем исерә ала.

Йосыпов *(шешәне карап)*. Вермут. Тәк. Исерек тә булмагач, аңлашырга җиңелрәк. Утырыгыз.

Әхтәм *(утырып)*. Я, аңлаш.

Йосыпов. Аңлаш түгел, аңлашыгыз.

Әхтәм. Этикет. Каян килгән князь Юсупов.

Йосыпов. Князь Юсупов түгел, лейтенант Йосыпов. Тәк. Кем дип белик инде сезне?

Әхтәм. Кеше.

Йосыпов. Кеше. Әйбәт. Кеше булгач, нигә ашханәдә дуңгызлык эшләдегез?

Әхтәм. Дуңгыз абзарында кеше нишләргә тиеш?

Йосыпов. Нигә милиционерга каршылык күрсәттегез?

Әхтәм. Имеш, ашханәдә аракы эчәргә ярамый. Ә кайда эчим мин аны? Рестораныгыз юк, койма артына качсам, тагын сез.

Йосыпов. Документыгыз бармы?

Әхтәм. Разведчик разведкага барганда документларын калдырып китә. Әтиеңнән сора, үзең белмәсәң.

Йосыпов. Нишлибез соң инде, болай булгач? Сез безнең район кешесе түгел, анысын беләм. Ә кем икәнегезне белмим. Ачыкларга туры килер. Димәк, документыгыз юк?

Әхтәм. Юк.

Йосыпов. Ә тапсак? Мәрвән, кара кесәләрен.

Әхтәм. Мәрвән? *(Сикереп торып.)* Молокосос! Якын килмә. *(Кесәсеннән хәрби билет чыгарып өстәлгә куя.)* Кулыңны юып тотын.

Йосыпов. Утырыгыз. *(Хәрби билетын алып актара — укый.)* Мохтаров Әхтәм. 1925. Тәк, тәк... Югары белемле... Архитектор. Oho! Разведчик. Сержант. Тәк... Кызыл Йолдыз, «Слава» өченче дәрәҗә, тагын Кызыл Йолдыз, «Батырлык өчен» берәү, икәү, өчәү, дүртәү...

Әхтәм. Санама, бармагың җитмәс.

Йосыпов. Я, Әхтәм абзый Мохтаров. Таныштык та. Инде нишлибез? Командировкага килгән идегезме безнең районга? Килешми бит, Әхтәм абзый, югары белемле архитектор, командировкага килеп. Кайсы оешмага килдегез? Район башкарма комитетынамы? Хәбәр итми булмас.

Әхтәм *(кычкырып көлә)*. Тиле.

Иосыпов *(ачуы чыгып)*. Сез нәрсә? Кем дип беләсез үзегезне? Кайда утырганыгызны оныттыгызмы? Разведчик! Өч орден, ун медаль кавалеры! Үзегезне иң әшәке хулиган кебек тотасыз. Сезнең белән кешеләрчә сөйләшәләр. Югыйсә, милиция хезмәткәренә кул күтәргән өчен нәрсә буласын беләсезме? Нәрсә, закон белән таныш түгелме? Матур йортлар саласызмы? Менә хәзер акт төзибез дә, бик матурлап кына бездә төн кунып, иртәгә судья каршына басарсыз. Сезне кызганып актны йомшак язсак, унбиш тәүлек урам себерерсез. Кызганмасак, икенче урында йорт салырга туры килер. Архитектор! Без монда, сез тынычлап йортлар салсыннар, шәһәрләр төзесеннәр, төрле әшәке җаннар аларны борчымасын дип, төн йокламыйбыз. Ә сез?

Әхтәм. Куркыттың бит, әй. Калтырап утырам.

Иосыпов. Мәрвән, ач теге бүлмәне.

Әхтәм. Ашыкма, егет, мин синең белән сөйләшеп утырырга телим. Я, дәвам ит әле. Сез нишлисез дә без нишлибез?

Иосыпов. Анысын иртәгә күрербез. Мәрвән, урнаштыр.

Әхтәм. Сез... Әллә чынлапмы? Хакыгыз юк.

Милиционер. Кирәгез эйдә.

Әхтәм. Ахмаклар! *(Бүлмәгә кереп китә. Анда аның шаулаганы ишетелә.)*

Иосыпов *(өстәл артына язарга утыра. Милиционерга.)* Сөйлә, ниләр булды анда? Кара син аны. Әшәкелегенә каршы яхшылык эшләргә җыенасың, ул...

Милиционер. Командировкага килмәгәндер ул, Хәйдәр Садыйкович. Командировкага килгән кешенең өс-башы шулай булмый.

Иосыпов. Ачыкланыр.

Сайра керә.

Сайра. Мин китмәдем.

Иосыпов. Чуалмагыз әле, зинһар өчен, сезгә монда бала-чага юк. Кайтыгыз да китегез.

Сайра Мин машинаны алмыйча китмим.

Иосыпов. Әйттеләр бит сезгә.

Сайра. Шалтыратырга мөмкинме?

Иосыпов. Почтага барып шалтыратыгыз.

Сайра. Һе. Кансыз кеше икәнсез.

Әхтәм каты итеп ишек дөбердәтә.

Иосыпов Кара әле, Мәрвән, нишли ул анда? *(Милиционер бүлмә ишеген барып ача. Әхтәм чыга.)*

Әхтәм. Шаярма, лейтенант!

Сайра *(Әхтәмне танып алып)*. Әхтәм абый!

Әхтәм *(Сайраны килеп кочаклап)*. Мәрвән кызы! Сеңелем. Күр, нишләтәләр. Әхтәм Мохтаровны! Ни өчен?!

Сайра *(Йосыповка)*. Әхтәм абый — әтинең дусты.

Иосыпов. Ә-ә-ә. Шулмыни инде ул. Тәк, тәк...

Әхтәм. Молокосослар! Без сезне саклап... Фашист колы булмасыннар, дип... Шуның белән җавап бирәсезме? Куркытма, мин камераларны күргән кеше. Фашист мине ябарга азапланды, булдыра алмады. Сезнең көчегездән килә, әйеме? Сез теләсә нишли аласыз.

Сайра. Әхтәм абый, кирәкми. *(Йосыповка.)* Зинһар, этигә шалтыратып әйтегез. Үтенеп сорыйм.

Әхтәм. Үтенмә, сеңелем. Мин пычрак тазартырга күнеккән кеше. *(Йосыпов каршына килеп.)* Ә син!..

Иосыпов. Утырыгыз. Утырыгыз диләр. *(Милиционерга.)* Мәрвән, постыңа бар.

Сайра. Шалтыратыгыз этигә. Рөхсәт итегез үземә.
Йосыпов. Шалтыратыгыз.
Сайра *(шалтыратып)*. Кем эле бу? Хәлимә апа, әти анда юкмы? Районга? *(Трубканы куеп, Йосыповка.)* Сез әйттегезме?.. Нишләгән соң ул?
Йосыпов. Үзеннән сорагыз.
Сайра. Яхшы кеше ул.
Йосыпов. Аның ниндилеген без күрдек инде, Сайра Идрисова.

Сайра Йосыпов янына килә. Кесәсеннән Әхтәм ясаган рәсемне алып күрсәтә.

Менә, ул ясады. Бер минут эчендә. Охшаган бит.
Йосыпов. Коеп куйган. Шуңа күрә масая да ул. Имеш, разведчик булган, хәзер архитектор. Без беркем дә түгел. Без кансызлар.
Сайра. Гафу итегез. Телисезме мин сезгә бу рәсемне бүләк итәм.
Йосыпов. Ни өчен?
Сайра. Истәлек итеп.
Йосыпов. Мондый көнне мин истәлек итеп саклыйсым килми. Болай да ямьсез истәлекләрем күп. Мәрвән абыйның дусты булган. Нигә соң ул андый? Кайда эшли ул?
Сайра. Белмим.
Йосыпов. Әтиегезнең дусты, белмисез.
Сайра. Әти үзе дә белми.
Йосыпов. Кызык.
Сайра. Нишләтәсез инде аны?
Йосыпов *(Әхтәмнең урыныннан торганын күреп)*. Утырыгыз.
Әхтәм. Лейтенант, бир теге калганын.
Йосыпов. Йөгереп закуска да алып килмимме тагын? Утырыгыз.
Мәрвән *(керә)*. Мөмкинме? Исәнмесез.
Сайра. Әти, Әхтәм абый...
Йосыпов. Исәнмесез, Мәрвән абый. Менә нинди хәлләр. Сайра Идрисова правасыз район үзәгендә йөри, кызыгыз булып чыкты, бу сезнең дустыгыз ата хулиган булып чыкты. Нишлибез?
Мәрвән *(Сайрага)*. Нишләден?
Йосыпов. Әлегә берни дә юк. Ләкин... Шофер килдеме? Машина безнең ишек алдында. Алып китәргә мөмкин.
Мәрвән *(Сайрага)*. Бар. Нәҗип абыең урамда. Бар хәзер үк!

Сайра чыгып киткәч, Әхтәм янына килә.

Нихәл, Әхтәм. *(Әхтәм эндәшми.)* Нихәл дим?
Әхтәм. Сөен, каптырдылар.
Мәрвән. Сөенәм, билгеле. Шатлыгымнан елап җибәрәсем килә. Нәрсә, тагын дөньяны «төзәтергә» тотынган идеңме?
Йосыпов. Ашханәдә тавыш күтәргән. Безнең милиционерга сукканн. Һаман дулый. Теләсә ни сөйли.
Әхтәм. Нәрсә елыйсың?! Ябып куйдың бит. Тавыш куптарган. Ашханәгездә һәрбер өстәл астында шешә. Аны күрмисез, өстәл өстен дәгесен күрәсез.
Мәрвән. Инде шулай өстәл астындагы буш шешәләрне санар көнгә калдыңмыни? Я, тагын ниләр бар? Бәлки, ашханәдәге кашыкның сабы кәкрәйгәндер? Анысын күрмәдеңме?
Әхтәм. Мин синең янына бара идем. Мәрвән, көчең житсә, ал син мине моннан. Ал. Ишетәсеңме, лейтенант, мин бирелә**м**. Курыктым. Хәтта синнән гафу үтенергә әзер. Телисеңме?
Йосыпов. Кирәкми миңа сезнең гафуыгыз. Сез ялгыш миңем аякка басмадыгыз, закон боздыгыз.
Әхтәм. Закон бозу өчен языла.
Мәрвән. Әхтәм, житте. Йосыпов иптәш, уйлашыйк.

Й о с ы п о в *(Әхтәмгә)*. Чыгып торыгыз. Ләкин качарга уйламагыз.
Ә х т ә м. Качып кая барасың, лейтенант. Бик качар идем, кереп качарлык урын юк дөньяда.

### БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Авылдагы кунак йортының бер бүлмәсе. Яхшы җиһазландырылган. Вакыт кич. Тышта коеп яңгыр ява. Күзгә янгыр. Ә х т ә м кайтып керә. Арыган. Өске киемен, ботинкасын сала да караватларның берсенә ава. Ишек шакыйлар. Әхтәм теләмичә генә торып утыра. Тагын шакыйлар.

Ә х т ә м. Кем бар?
С а й р а т а в ы ш ы. Мин бу, Әхтәм абый.
Ә х т ә м. Кер.
С а й р а *(керә)*. Хәерле кич, Әхтәм абый.
Ә х т ә м. Хәерле кич. *(Ята.)*
С а й р а. Алай килешми, Әхтәм абый. Кызлар белән сөйләшкәндә, утырып сөйләшергә кирәк. Урынга, аннан соң, чишенеп яталар. Икенчедән, әйдәгез, киенегез.
Ә х т ә м *(торып)*. Нигә?
С а й р а. Киенгәч әйтермен.
Ә х т ә м. Арыдым. Шаярырлык түгел.
С а й р а. Әһә! Арыдыгызмы? Аяктан егылып, авырып ятачаксыз әле болай булса. Көне-төне, көне-төне ял итмичә, рәтләп ашамыйча кем эшли? Нигә алай итәсез? Бөтен авыл кешесе аптыраган, җен нәселеннәндер, ди безнең күршедәге бер әби. Адәм баласы бу хәтле хәлгә чыдамас, ди.
Ә х т ә м. Чыдар. Чыдарга тиеш. Мәрвән кайттымы?
С а й р а. Юк әле. Болай булса, бүген кайтып та җитмәс әле. Әйдәгез инде, Әхтәм абый, киенегез. Әни әйтте, көя, диде.
Ә х т ә м. Нәрсә көя?
С а й р а. Һе. Нәрсә булсын, бәлеш. Бәлеш пешердек. Тышын мин ясадым. Әйдәгез. Тиз кайтыгыз, диде әни. Әйдәгез инде, минем клубка да барасым бар.
Ә х т ә м. Рәхмәт әйт әниеңә.
С а й р а. Безнең өйгә кермәскә сүз бирдегезме? Нинди зур өебез бар, гостиницада ятасыз.
Ә х т ә м. Монда да яхшы.
С а й р а. Әллә нинди кеше сез, Әхтәм абый. Бүтән кешеләргә охшамагансыз. Дулаганда күзләрегез усал-усал, көлгәндә чәнчеп-чәнчеп алалар, уйлаганда моңсу-моңсу. Егетләр булсагыз, мин сезгә гашыйк булыр идем. Серле кешеләрне үлеп яратам мин, шул серне ачасым килә, беләсем килә.
Ә х т ә м. Бернинди дә сер юк, Сайра сеңелем, җүләрлек, тилелек.
С а й р а. Әһә. Үзегез дә әйттегез. Әти дә сезгә тиле дигән иде. Әхтәм абый, сез хәзер гараж салып ятасыз. Архитектор эше түгел ич ул, Әхтәм абый, институт бетереп нигә архитектор булып эшләмисез?
Ә х т ә м. Бар, сеңелем, клубыңа соңга каласың.
С а й р а. Ә мин сездән башка китмим. Мин бит, Әхтәм абый, әти кебек. Бер нәрсә эшлим дидемме, әллә ни булсын, барыбер эшлим. Әти дә шулай. Беләсезме, бер заман аны председательлектән алып ыргыттылар. Мин ул чакта бәләкәй идем әле. Районнан нәрсәдер эшләргә кушканнар, үлән чәчмәскәме шунда, ул тыңламаган. Ике ел бригадир булып эшләде, тагын куйдылар. Әхтәм абый, сезнең хатыныгыз бар, ди, әйеме? Кызыгыз да бар, ди.

Әхтәм. Бар.
Сайра. Ничә яшьтә?
Әхтәм. Синнән яшьрәк.
Сайра. Һе. Ә нигә алар белән тормыйсыз?
Әхтәм. Торасым килмәгәнгә. Бар әле, кайт. Йокым килә.

Сайра. Юк, йокламыйсыз, барыбер йоклатмыйм. Сезгә берәү дә кушмаган көне-төне эшләргә. Мин әле сезне клубка алып барам. Әние дә. Мине яратам дип йөргән бер егетне күрсәтәм. Читтән генә карап торырсыз да әйтерсез. Әй, сез аны беләсез бит. Теге Хәйдәр. Ике көнгә бер килә. Гашыйк булдым, ди. Ә минем өчен барыбер. Ярата белмим мин. Әйбәт егет. Ләкин бер сере юк. Мин бөтенесен белеп бетердем инде аның турында. Хәзер сөйләшергә сүзем юк. Ачуланмый да, үртәгәнгә дә түзә, юк, ни әйтсәң дә кеше серле булырга тиеш. Менә сез безгә килгәч аракы эчтегез. Туеп беттем сездән. Шуннан карандаш белән бер-ике сыздыгыз да минем рәсемне ясадыгыз. Үзегез әллә нинди батырлыклар эшләгәнсез, үзегез әнине үртәп тәм табасыз. Хәзер инде бөтенләй икенче кеше.

Әхтәм. Сайра, кил, утыр минем янымa.

Сайра *(Әхтәм янына утырып)*. Нәрсә, Әхтәм абый? *(Әхтәмнең үзенә төбәлеп каравыннан уңайсызланып.)* Нәрсә, Әхтәм абый?

Әхтәм. Мәрвән кызы. Укырга кирәк сиңа, Сайра сеңелем. Шофер булу синең эш түгел. Укырга кирәк сиңа. Син укымасаң, синең урыныңны бер туң йөрәк алуы бар. Кирәкми туң йөрәклеләр дөньяга, укыганнары мең кабат кирәкми. Аларның салкыны зәһәррәк. Зур кеше булырга кирәк сиңа. Ә минем сыман «серлеләргә» кызыкма. Бар кайт, Мәрвән кызы. Килүенә мең рәхмәт.

Сайра. Әни үпкәләячәк.

Гашия керә.

Гашия *(Сайрага)*. Киткәнеңә биш былтыр. Киткән жиреңнән кайта белмисең.

Сайра. Бармыйм ди Әхтәм абый.

Гашия. Аның кеше сынлы гына булмас инде. Кире беткән. Куганда китә белмәдең. Хәзер чакырып та килмисеңмени?

Әхтәм. Гашия ханым, нигә сез һәрвакыт ачулы?

Гашия. Ачулы булганга ачулы. Әйдә, киен.

Әхтәм. Я, бер көлегез.

Гашия. Менә хәзер биеп тә күрсәтәм. Киен диләр. Чыкмаган жаның гына калган. Мәрвәннең синнән башка да хәсрәтләре житәрлек. Нәрсә һаман жанын көйдерәсең. *(Тәрәзәгә күз салып.)* Коя гына. Юлда интегеп яталардыр. Көндез үк кайтып житәсе кеше. *(Әхтәмнең чөйгә элеп куйган киемен алып.)* Кара инде моны. Шуңа риза булып йөри бит. Чәченә чал кергән. Мәрвән кожанын киеп йөрсәң ни була. Көләсе кеше болай да көлә. Авылга бер дан булдың.

Сайра. Әни, үзең чакырырга килгән, үзең...

Гашия. Күп белмә. Нәрсә дип әйттем мин сиңа, артыннан кычкырып калдым. Килмәсә, сөйрәп алып кил дидем. Берүзем кайсына өлгерим. Дөньяны онытканcың. Капка төбендә милиционерың йөри. Рәхәт хәзер, бөтенесе үзебездә, тегесе дә, монысы да. *(Әхтәмгә.)* Кит, тор. Урын-жирең, и тамаша. Хатыны кочагында ятасы кеше. Эт куып йөри бит, ни үзенә, ни кешегә тынычлык юк. *(Урын-җирне җыештыра.)* Нәрсә каттың, киен!

Әхтәм. Рәхмәт, Гашия ханым.

Гашия. Синең рәхмәтең миңа кирәкми. Ашап, чәй эчеп кит. Я үлеп куярсың. Әйтер аннары Мәрвән, син үтергәнсең дияр.

Әхтәм. Гафу итегез, бара алмыйм.

Г а ш и я. Әллә үпкә саклыйсыңмы? Хатын-кыз кычкыра да тукталган ул. Кычкырып торучы булмаганга зимагур булып йөрисең. Мин кычкырганга пыртаясы юк. Мин гомеремдә өемдә исерек кеше күрмәдем. Әйдә, Мәрвәннең машинасы белән кырынып та китәрсең.

Мәрвән керә.

М ә р в ә н. Мин генә җитмим икән монда. Өйдә бәлеш исе, ә кеше юк.

Г а ш и я. Менә икәүләп ялынабыз. Нишләп соңга калдың? Гомер буе шулай сине көтеп ут йотып яшәрмен инде.

М ә р в ә н. Ярый, әнисе. Барыгыз кайта торыгыз, өйдә кунак бар.

Г а ш и я. Кем тагын?

М ә р в ә н. Кайткач күрерсең.

Г а ш и я. Әйдә. *(Сайраның кулыннан җитәкләп чыгып китә.)*

М ә р в ә н. Нәрсә, безгә аяк басмаска тәүбә иттеңме? *(Өстен салып элеп куя.)* Зарар юк. Гостиницамда яшәгәнне, өемә барырсың. Ничек, кикригең шиңдеме, әллә һаман көн-төн кирпеч өясеңме? Кайтканда карап үттек. Гараж өелеп бетә язган. Эх, тагын бер унлап кешенең синең кебек ачуы чыкса, шәһәр салыр идек.

Ә х т ә м. Миңа иртәгә расчет ясагыз. Сиңа бурычымны түләргә кирәк.

М ә р в ә н. Нинди бурыч?

Ә х т ә м. Паразит диден бит. Мин, агай-эне, исеңдә тот, беркайчан да паразит булганым юк. Кулларым әлегә исән. Эшем өчен расчет яса.

М ә р в ә н. Кара әчле дә кеше икән үзең. Торган саен серләрең ачыла бара.

Ә х т ә м. Сине шулай атасыннар әле.

М ә р в ә н. Бурыч түлим дисең инде. Унбиш көн эшләгәнең генә җитәр микән. Бурычың зур бит, Әхтәм дус. Бик зур. Ләкин миңа түгел ул, син үзеңә бурычлы... Син шуның өчен миннән качып йөрисең, алайса? Тилелегең җиткән, вак та булма. Болай да вакланып беткәнсең. Һәй, тагын ямьсез сүзләр. Ташлыйк әле. Шатлыкларым зур, Әхтәм.

Ә х т ә м. Мактау грамотасы бирделәрме?

М ә р в ә н. Көл әйдә, көл. Чәнче. Барыбер синеңчә бармый, минемчә бара тормыш. Зур эшләр майтарып кайттым бит әле. Синең өчен алар вак-төяк, билгеле, син дөнья күләмендә «эш йөртәсең». Ә миңа — колхозым. Беренчедән, ниһаять, авылны яңача сала башлыйбыз. Генеральный планның проектына тотыналар. Икенчедән, мин синең сугыштан соң нишләгәнеңне, кемлегеңне биш бармагым кебек беләм. Син хәзер минем каршымда уйный алмыйсың. Сине, Мәскәүдә институт бетергәч, Урта Азиягә эшкә җибәргәннәр. Анда килешә алмагансың, шуннан Исмаев дигән бер архитекторны кыйнап... Анысын үзең сөйләдең. Аннан Казанга кайткансың. Эшкә урнашып карагансың, тагын барып чыкмаган. Шуннан үчләшә башлагансың. Кулыңа карандаш белән кәгазь алмаска сүз биргәнсең. Дөресме? Хатыныңны яратасың икән. Син аңа, минем белән яшәп эрәм булма, икенче рәтлерәкне тап, дип чыгып киткәнсең. Үзеңнең төсең итеп хатыныңа кызыңны калдыргансың.

Ә х т ә м. Син Нажияне күрдеңме?

М ә р в ә н. Белдек. Инде боерыгым: менә сиңа дипломың. Гаражны эшләп бетерүчеләр табылыр. Син архитектор буларак бурычыңны түләрсең. Иртәгә ярты олау кәгазь, бер кубометр карандаш китерерләр. Сыза-боза башларсың. Булды. Инде әйдә безгә, бәлеш ашарга.

Ә х т ә м. Ничек син...

М ә р в ә н. Әйе, мин бу, мин. Син дә син. Елак малай. Проект оешмасында киңәштем, алар каршы түгел. Эскизлар эшлисең. Әлегә — не официально. Аңлыйсыңдыр. Официальносын икенче бер архитектор

эшләячәк. Ярышасың. Җиңеп чыксаң — син Әхтәм, җинә алмасаң, мине кыерсыталар дип, елавыңны дәвам итәрсең. Нәрсә карап торасың? Эт кеше икәнсең, дипме? Шулай, дус, син теләсә ни уйла, сүген, талаш, барыбер миннән ары китә алмыйсың хәзер. Чөнки син үзең генә йөри алырлык түгел.

Әхтәм. Син чынлап торып миңа хуҗа булырга җыенасыңмыни? Минем артта минем өчен...

Мәрвән. Синең өчен түгел, үзем өчен, дустым өчен. Хуҗамы, хуҗа түгелме, анысын син үзең аңларсың. Әмма бу авылдан сиңа киттем юк. Менә шушында ишек төбендә мылтык тоттырып ике абзыйны бастырачакмын. Ашарга конвой белән йөрерсең. Эшеңне үзем күзәтеп барырмын. *(Көлә.)* Әйдә инде, нигә киенмисең?

Әхтәм. Нажияне кайчан күрдең? Ничек таптың?

Мәрвән. Онытмаган булсаң, мин разведчик.

Әхтәм. Синең кәефең бик әйбәт. Ләкин...

Мәрвән. Әйдә дим. Вакытым юк. Өйдә синнән кадерлерәк кунагым көтә.

Әхтәм *(ачуы чыгып)*. Син нәрсә миннән уенчык ясыйсың?

Мәрвән. Тагын башлады. Нәрсә, алдыңа тезләнимме? *(Тезләнеп)*. Менә мә, күңелең булсын. Тагын ни эшлим? Әйдәле, Әхтәм, онытып тор бер минутка бөтенесен, урамнан җырлап кайтыйк. Эх!

Җиделе лампа якты яна
Фитилендә май булса,
Ир егетләр башын имәс,
Йөрәгендә җан булса.

*Пәрдә.*

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

### АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Мәрвәннәр өе. Өйдә Гашия, Нажия. Өстәлдә табын әзерләнгән.

Гашия *(тәрәзәдән карап торган килеш)*. Хәзер үз балаңа да сүз әйтергә ярамый. Чыкты китте. Яңгыр дип тормыйлар, буран дип тормыйлар. Чырк та чырк. *(Өстәл янына килеп.)* Әйдә эч син, юлдан килгән. Машинада булса да, юл талчыктыра ул. Яле, тагын бер чынаяк.

Нажия. Булды. Рәхмәт.

Гашия *(Нажиягә кызганып карап торып)*. И-и, малай җаным, ә? Шулай йөрим, диген. Әй, бу ир-атны. Белмиләр лә хатын-кыз кадерен. Менә үзебезнең Мәрвән. Интеккәннәремне белсәң. Гаменә дә кереп чыкмый. Көн чаба, төн чаба. Мине дә чаптыра. Бу синеке инде, я. Гаеп үзендә булдымы әллә? Тәрбия күрсәтә алмадыңмы? Шәһәр хатыннары бит алар бик крута булалар. Ирем-фәлән дип ялынып тормыйлар.

Нажия. Бардыр инде.

Гашия. Мәрвән әйткәч, киләсе булдың инде, ә? Нишләтәсең, алып китәсеңме? Теге исерекләрне төзәтә торган больница бар, диләр, әллә соң шунда саласыңмы үзен?

Нажия. Андый түгел ул.

Гашия. Мин дә шулай дим. Башын этлеккә генә салгандыр дим. Беренче килгәндә кыланмаганы калмады. Миңа да көн юк, Мәрвәнгә дә юк. Икенчесендә милициядән алып кайтты бит. Бирмибез дигәннәр, Мәрвән бик сорагач кына җибәргәннәр. Хәзер инде унбиш көн буе.. Дию пәрие диярсең. Ничек соң, болай законлап аерылыштыгызмы?

Нажия. Юк.

Гашия. Ташлады да чыгып китте диген, ә? Малай җаным, үзең юаштыр, минем кулымда булса... Әйдә, эч әле. Ничә яшьтә үзең?

Нажия. Кырык тулды инде.

Гашия. Миннән яшьрәк тә икәнсең. Чынлап әйтәм, малай җаным, илледән дә кимне биреп булмый сиңа. Беләм инде, беләм, картайта. Менә үзем дә. Вакытында кайт ашарга дим, кайтмый. Ашны пешерәм дә дуңгызлар карарга чабам. Дуңгызлар карата ул миннән. Председатель хатыны диген инде, ә, малай җаным. Юк инде, юк. Кайда эшлисең инде үзең?

Нажия. Укытам. Институтта.

Гашия. А-а... Вәт җүләрне... Менә, унны бетергәч, Сайрага күпме әйттем, бармады, укытучы буласым килми, ди. Хәзер районда шоферлыкка укып йөри. Үзем укый алмыйм, ди. Шул. Мәрвән укысын дип, җиде класс бетергән килеш калдым. Укулары авыр шул, эшләгәч тә. Интекте Мәрвән. Институтка укырга керү шулай бик кыенмыни? Сайра барыбер икеле алам дип бармады.

Нажия. Кемгә ничек инде.

Гашия. Сез әйтеп карагыз әле шуңа. Сезне тыңламасмы. Кияүгә генә чыгып куймаса ярар иде. Йөрәкләрем алынып тора. Бу Әхтәмне әйтәм, сезне дә санга сукмагач. Бик алай каты бәрелмәгез инде, тагын киреләнмәсен. *(Тәрәзәдән карап.)* Кайталар, ахры. Качып торасыңмы?

Нажия. Нигә?

Гашия. Белмим инде, болай гына әйтүем. Керәләр.

Нажия янына килеп утыра. Кызык көтә. Әхтәм белән Мәрвән керәләр. Әхтәм, Нажияне күргәч, аптырап кала.

Гашия. Әйдәгез инде. Көтә-көтә арып беттек. Мәрвән, өстен салдыр Әхтәмнең.

Әхтәм *(Мәрвәнгә)*. Бу нинди спектакль?

Мәрвән. Әйттем бит, синнән дә кадерлерәк кунагым көтә, дидем. Башта исәнләш.

Нажия Әхтәм янына килә.

Мәрвән. Утырыгыз, Нажия ханым. Үзе килеп исәнләшсен.

Нажия. Исәнме, Әхтәм.

Әхтәм. Исәнме.

Гашия. Мәрвән, мичтән бәлешне алырга булыш.

Мәрвән белән Гашия чыгып китәләр. Пауза.

Әхтәм. Бәлки, аңлатырсың.

Нажия. Әхтәм... *(Күз яшенә тыгылып сүзен әйтә алмый.)*

Әхтәм. Монысы яңалык түгел.

Нажия. Беләм.

Әхтәм. Кешегә күз яшьләре чама белән бирелгән. Киләчәккә дә калсын.

Нажия. Нигә шулчаклы каты бәгырьлегә әйләндең, Әхтәм? Андый түгел идең бит син, андый түгел идең.

Әхтәм. Күптән сөйләшенгән сүзләр. Нигә бертуктаусыз кабатларга. Тукта. Әллә ни уйларлар.

Нажия. Ничек яшисең?

Әхтәм. Ал да гөл.

Нажия. Ал да гөл түгел инде, сер бирәсең килми, беләм.

Әхтәм. Белгәч нигә сорыйсың? Мәрвән алып килдеме, үзеңме?

Нажия. Ул эзләп тапты, кайда яшәгәнеңне, нишләп йөргәнеңне сөйләде.

Әхтәм. Нишләп йөргән соң?

Н а ж и я. Акылына кил, Әхтәм. Болай йөрмә, бәгырем. Минем белән яшә димим, анысын үзең беләсеңдер, йөрәккә боерып булмый. Кеше бул, жаным. Дөньяга күтәрелеп кара. Күз алдында харап буласың. Көлмә, тагын кабатлыйм. Нишлим, беренче мәхәббәтем, кызымның атасы син. Белдем синең ни әйтәселәреңне. Син мине куып жибәрерсең. Үзеңә тиңнәрне тап дип кабатларсың. Минем яратуым, мәхәббәтем хакына, Әхтәм. Үзеңә дә авыр, сизәм бит, беләм бит, аңлыйм бит мин сине. Ачуланма, килми булдыра алмадым.

Ә х т ә м. Зөлфия кайда?

Н а ж и я. Әтиләрдә калды.

Ә х т ә м. Укуы ничек?

Н а ж и я. Яхшы. Укытучылары мактыйлар. Университетка керергә әзерләнә.

Ә х т ә м. Ничек әзерләнә? Әле ике ел укыйсы бар.

Н а ж и я. Үтә дә китә ул. Беркөнне ярамаган эш эшләдем. Үзе югында көндәлек дәфтәрен актардым. Шигырьләр күп, әллә үзе язган, әллә күчергән.

Ә х т ә м. Татарчамы?

Н а ж и я. Әйе.

Ә х т ә м. Кызык. Әйбәтләрме соң?

Н а ж и я. Үзең беләсең, мин шигырьне аңламыйм. Синең турыда да күп сүзләр бар көндәлектә.

Ә х т ә м. Әйтмә, кирәкми. Беләм, синең сүзләр.

Н а ж и я. Кызганычка каршы, синең сүзләр. Әти хаклы, дөньяның кызыгы юк, дигән бер урында.

Ә х т ә м. Аңа ни житмәгән?

Н а ж и я. Үзеннән сора.

Ә х т ә м. Син сорадыңмы соң?

Н а ж и я. Курыктым. Синең белән киңәшермен башта, дидем.

Ә х т ә м. Тапкансың киңәшерлек кеше... Килгәнсең, нишләтергә уйлыйсың инде мине, үгетләргәме?

Н а ж и я. Әхтәм, башлама ул хакта. Сине күрәсем килде.

Ә х т ә м. Күр инде, күр. Дипломны нигә Мәрвәнгә бирдең?

Н а ж и я. Сорап алды.

Ә х т ә м. Улниләр сорамас. Син барысын да сөйләп бирдең инде. Кызгандырырга тырыштың.

Н а ж и я. Әхтәм!.. Мин беркайчан да үземне кызгандырырга тырышканым юк. Яхшы беләсең, мин кызганыч кеше түгел. Кызганам икән, мин синең әрәмгә узып барган гомереңне, синең талантыңны кызганам. Соңгы мәртәбә үтенәм, зинһар, андый сүзләрең белән мине рәнҗетмә.

Ә х т ә м. Гафу ит. Сине рәнҗетергә минем хакым юк. Нишләтим, тупасландым. Телем дә, киемем дә, хәтта акылым да тупас. Бәхетсез кеше син. Олы жанлы, киң күңелле, әмма бәхетсез кеше. Язмышны әйтәм, нигә очраштырырга иде сине минем белән. Хәер, мин дә әйбәт кеше кебек идем, һәрхәлдә, хыяллана белә идем. Хәзер... Зөлфияне кара, шигырьләр яза, диген! Сәлам әйт үзенә, аңлатырга тырыш. Сукбай булсам да, бозык кеше түгел мин. Сиңа хыянәт иткәнем юк... Нигә елмаясың?

Н а ж и я. Болай гына.

Ә х т ә м. Ышанмыйсыңмы?

Н а ж и я. Ышанам. Синең белән яшәмим, дип ташлап чыгып киткәнеңә ике ел, хыянәт иткәнем юк дип сөйләвең кызык тоелды.

Ә х т ә м. Озак торырга уйлыйсыңмы биредә?

Н а ж и я. Ә син?

Ә х т ә м. Нәрсә мин? Сине эшең көтә.

Нажия. Сине котмиме? Сине эшең дүрт ел буе көтә. Хәзер күп нәрсәләрне онытып та бетергәнсеңдер инде. Артта калдың тормыштан. Мәрвән сиңа эш тәкъдим итмәкче була. Алынып кара, Әхтәм.

Мәрвән *(бәлеш күтәреп чыга)*. Кагылыгыз! Туй килә, ике җиңен селкә килә.

Гашия *(Мәрвән артыннан чыгып)*. Кыланма, Мәрвән, төшереп җибәрәсең. Куйма дим өстәлгә табаны. Әй, бу ирләрне. *(Нажиягә.)* Менә шулай интегәм инде, гомер буе шулай. *(Өстәлне рәтли.)* Әйдәгез, утырышыгыз, көеп тә беткәндер инде. *(Утырышалар.)*

Мәрвән. Көчкә алып килдем үзен, Нажия ханым. Ялындыра. Үгетләп кермәде, ачуланып та карадым. Ялагайланырга туры килде. Көйсез бала кебек. Тегене бирегез миңа, моны эшләгез, юкса, янәсе, елап җибәрәм.

Гашия. Булды. Әллә рәтле сүзең беткәнме. Һәрвакыт үзең башлап җибәрәсең. *(Нажиягә.)* Якынрак килеп утырыгыз. Гаеп итмәгез, бәлешемнең ничек булганын үзем дә белмим. Я, житешегез.

Мәрвән. Беләсеңме, Нажия ханым, минем үз гомеремдә берәүгә дә ярарга тырышканым, ялагайланганым булмады. Хәтта бик кирәк чакларда да үземне-үзем тыеп кала идем. Мәҗбүр итте бит. Эх, балачага булсаң, шушы кашык белән утыртыр идем маңгаеңа. Шартлап ярылсын иде кашык.

Әхтәм. Кашык миндә дә бар. Тик кызганыч, үз кашыгым түгел. Ярылса түлисе була.

Гашия. Ашаганда сөйләшмәгез.

Мәрвән. Тукта әле, әнисе. Эх, Нажия ханым, шәп итеп яшисе килә дөньяда. Хыяллана идек, беребез шәһәрләр салу турында, икенчебез икмәк турында. Тәки ирештек хыялларга.

Әхтәм. Көлмә.

Мәрвән. Ирештек, Әхтәм. Калганы үзебездән генә тора. Комачаулаучы юк.

Әхтәм. Идеалист син, Мәрвән. Бәхетең синең шунда.

Мәрвән. Гафу ит, дускай. Ярый, синеңчә булсын. Идеалист булыйм. Менә, күрәсең, безнең авыл... Шулай итеп төзербез авылны. Әкият булыр.

Әхтәм. Ә кем сиңа әкият төзергә рөхсәт итәр?

Мәрвән. Итәрләр. Безнең байлыгыбыз бар.

Әхтәм. Дөньяда типовой проект дигән нәрсәләр житәрлек. Дуңгыз абзарына да, культура сараена да. Кайвакытта аларны бер-берсеннән аеруы да читен.

Мәрвән. Син миңа аерып бир, калганын карарбыз. Әкият эшлә син безгә! Теләсәң ничек шашын, хан сарайларыннан шәп булсын! Без таш өемнәренә риза түгел. Киләчәккә истәлек булып калсыннар без төзегән авыллар.

Гашия. Китте, китте. *(Нажиягә.)* Әйдәгез, ашагыз. Аны тыңлап ач калырсың.

Нажия. Рәхмәт. Кызык бит.

Әхтәм. Дөньяда Исмаев дигән бер кеше бар иде, сөйләгәнем бар. Синең киләчәгең Исмаев кебек кешеләр кулына эләксәме?..

Мәрвән. Һаман кемнәндер өркәсең. Исмаев, Исмаев... Төкерәм мин синең Исмаевларыңа. Җәелеп яшим. Сине өркеткән пәриләр минем өчен чүп тә түгел. Алар булмаса, кызык та булмас иде дөньясы. Черки дә кирәк җиргә. Каныңны суырырга кунган черкине сытасың да үзеңнең кеше булып туганыңа шатланасың. Черки бозаулар өчен генә куркыныч. Әгәр инде син әйткән Исмаевлар син уйлаганча ук явыз икән, син төти егет икән, эшләп исбатла.

Әхтәм. Исбатладым, әйеме, Нажия?

Нажия. Ә син тагын исбатла.

Ә х т ә м. Әйдәгез, әйдә! Гашия ханым, сез дә кушылыгыз. Күрәсез, миннән кеше ясыйлар. Тарихи момент — дөньяга яңа кеше туа.

М ә р в ә н. Шулай булды, ди. Миңә бүген, хәзерге сәгатьтә, сиңа ошамаган, сиңа комачаулаучы кире типларны кырып ташладылар, ди...

Г а ш и я. Аңарга ошамаган кешеләрне кырып ташласалар, дөньяда адәм баласы калмаячак.

Ә х т ә м *(кычкырып көлә)*. Рәхмәт, Гашия ханым.

М ә р в ә н. Миңә шуннан әйттеләр, ди, я, иптәш Мохтаров, сиңа юл ачык, кайда эшләгән эшләреңне диделәр, ди. Кайда алар?

Ә х т ә м. Башымда.

М ә р в ә н. Минем башымда һәр гектардан илле центнер бодай ята. Тик аны амбарга салып куеп булмый, ул тамак туйдырмый. Ә менә без алган егерме ике центнер ул инде безнең эш. Синең башыңда әле чүп тулып ята.

Ә х т ә м. Мыскыл ит, әйдә. Мине мыскыл итәргә синең хакың бар, Мәрвән. Теләсә ни әйтсәң дә ачуланмыйм. Син бит Мәрвән! Мәрвән!.. Шәп кеше сезнең ирегез, Гашия ханым. Эшләр идем мин сиңа проект, агай-эне, шундыйны эшләр идем...

М ә р в ә н. Ябыш бәлешкә.

Г а ш и я *(Әхтәмгә)*. Син бүген гостиницаңа кайтасыңмы, бездә кунасыңмы?

М ә р в ә н. Таптың сөйләшерлек сүз, әнисе.

Г а ш и я. Ни булган? Сиңа гына сөйләргә дигәнмени? Урынны син җәясе түгел, мин җәясе.

М ә р в ә н. Бездә куна инде, алайса, бездә куна.

Г а ш и я. Үзенең дә теле бар, синекеннән ким түгел.

Ә х т ә м. Борчылмагыз, Гашия ханым.

Г а ш и я. Борчылырсың шул менә. Ярый ла, сез ирләр борчылмыйсыз. Киреләнеп чыгып китәсез дә — хатын-кыз теләсә нишләсен. Әйт менә, бергә җәйимме урыныгызны, аерым-аерым ятасызмы?

М ә р в ә н. Гашия!.. Нәҗия ханым, гафу итегез.

Г а ш и я. И-и, мине җүләргә санап утыра инде. Монда бала-чага юк. Төрле чак була, аерым-аерым да ятасың, бергә кочаклашып та ятасың. *(Нәҗиягә.)* Менә шулай туры әйтә торган гадәтем бар инде, ачуланмагыз.

Н ә җ и я. Зарар юк.

Г а ш и я. Зарар юк, дип. Бер дә аптырап тормагыз, кочаклагыз да алыгыз. Ирләрнең шуңа да көнелләре була, җибеп төшәләр. Яратасыздыр, яратмасагыз, килеп йөрмәгән булыр идегез.

М ә р в ә н. Әнисе, әйдә, самоварны алып чыгыйк.

Әхтәм кычкырып көлә.

Г а ш и я. Нәрсә авызыңны ерасың. Синең дә адәм шикелле көләр көнең булыр икән. Әй, минем кулымда булсаң...

М ә р в ә н. Болай, Әхтәм дус. Балта остасының балтасы, председательнең печате була. Архитекторларның да үз эш кораллары бардыр. Иртәгә эшкә тотынасың.

Г а ш и я. Тукта инде! Һаман шул, һаман шул колхоз. Ничек туймыйсың? Әйдә, алып чыгыйк самоварны.

Ишек шакыйлар.

Килделәр. Өйне кәнсәләр итеп бетердең. Көн димиләр, төн димиләр, шушында чабалар.

Мәрвән барып ишекне ача. И с м а е в керә.

Исмаев. Исәнмесез. Гафу үтенәм. Шулай килеп чыкты. Юллар начар. Председатель сез буласызмы?

Мәрвән. Мин.

Исмаев. Идрисов бит, ялгышмасам. Мин Исмаев. Сельхозпроекттан. Менә авылыгызны күреп китәргә килдем. Гостиницагызга тукталган идем дә, туктале, мин әйтәм, хуҗаны күрим. Кунакларыгыз бар икән, гафу итегез.

Мәрвән. Узыгыз әйдә, тик яманлап йөрисез икән, бәлешнең түбәнә җиткән идек.

Исмаев. Анысы булыр. *(Чишенә.)*

Мәрвән. Әйдәгез, өстәл янына. Бусы минем хәләл җефетем, бу — якын дустым, бусы аның хатыны.

Исмаев *(Нәҗия белән күрешкәндә)*. Таныш йөз. Кайдадыр күргәнем бар дип әйтимме. Коя яңгыр. Аяз көндә күрәсе иде авылыгызны. Менә шушы була инде, иптәш Идрисов, сезнең авылыгызны җимерәчәк кеше.

Мәрвән. Җимергәч, төзисе дә була.

Исмаев. Хуп мәйле. Төзербез, иптәш Идрисов, чакырып алдылар да, үзәгебезгә үтте бер председатель, диләр, бүген үк юлга чыгыгыз, таныша башлагыз, диләр. Карап карарбыз, мин әйтәм, хуҗа ничек каршылар. Ачык йөз күрсәтерме, дим. Гафу итегез, иптәш Идрисов, кунагыгызның исеме ничек?

Әхтәм. Әхтәм Мохтаров, хатынымның исеме Нәҗия Мохтарова.

Исмаев *(аптырап)*. Мохтаров, Мохтаров... Сез ничек бирсдә?

Әхтәм. Кайда булырга тиеш?

Мәрвән. Әллә танышлармы?

Әхтәм *(Мәрвәнгә.)* Ишетмәдеңмени, Исмаев, диде бит. Хәлил Саматович бит, ялгышмасам?

Исмаев. Гаҗәп. *(Мәрвәнгә.)* Без Урта Азиядә бергә эшләгән идек Мохтаров белән. Байтак еллар. Онытыла язган. Ун еллар узгандыр. Әйе, әйе, узгандыр. Хәзер кайда?

Әхтәм. Урта Азиядән кудылармыни, Хәлил Саматович? Хәзер авылларны бозарга керештегезме?

Исмаев. Гафу итегез...

Нәҗия. Әхтәм, кирәкми. Әллә кайчангыларны..

Әхтәм. Шикләнмә, мин бу юлы аңа сукмаячакмын.

Исмаев. Сез һәрвакыттагыча әче телле, Мохтаров. Кешенең әллә ни уйлавы мөмкин. Күрәм, иптәш Идрисов, минем кирәгем шуның гына хәтле, сезнең архитекторыгыз бар. Мохтаров — талант. Тик, кызганычка каршы... Хәер, сез ул хакта дустыгызга сөйләгәнсездер инде, Мохтаров.

Мәрвән. Кызыклы очрашу. Ләкин...

Исмаев. Ләкин бу хакта элегрәк әйтергә кирәк иде. Официально. Безнең архитектура оешмаларында Мохтаров дигән архитектор юк. Әйе, әйе, юк. Ничек бирегә килеп чыккан, анысы билгесез.

Әхтәм *(сикереп торып)*. Бар, Исмаев. Мохтаров исән.

Мәрвән. Туктагыз әле, ачыклыйк.

Исмаев. Гафу итегез. Кыскасы, иртәгә мине пристаньга илтеп куярсыз дип ышанам. Минем мөһимрәк эшләрем дә бар. *(Әхтәмгә.)* Ә сез юкка миңа ачу саклыйсыз, Мохтаров. Мин теге чакта сезнең житәкчегез буларак, сезнең нииндидер чынга ашмаслык фантастик проектларыгызны тәнкыйтьләгән өчен сез мине мәсхәрә иттегез, һәм сезне закон нигезендә хөкем иттеләр. Нигә аңа үпкәләргә.

Әхтәм. Үпкәләмим мин сезгә. Минем сезне сытасым килә, Исмаев. Мохтаров дигән архитектор юк, ә? Мохтаров юк? Менә ул сезнең кар-

шыгызда басып тора, Мохтаров бар! Бар ул Мохтаров! *(Мәрвәнгә.)* Китер кәгазең, китер карандашың, куй сакчыларыңны. Бар ул Мохтаров! Бар! Бар!..

### ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Икенче күренештәге шәһәр бакчасы. Сәхнәдә Әхтәм белән Нажия.

Нажия *(арлы-бирле йөргән Әхтәмгә)*. Тынычлан, Әхтәм. Утырып тор.

Әхтәм. Ничек тынычланыйм, Нажиям. Анда техсовет... Минем эскизларым... Язмышым хәл ителә. Куркам, Нажиям. *(Йөренә. Яңадан Нажия янына килеп.)* Нишләтерләр икән, аңларлар микән? Теге әрәмәлекне шәп итеп бәйләп куйдым мин авылга, әйеме, Нажия? Мәрвән, молодец, диде... Нигә чыкмый ул?

Нажия. Үзенә шунда булырга иде.

Әхтәм. Куркам.

Мәрвән керә

Нажия *(Мәрвән каршына барып)*. Ничек, Мәрвән?

Мәрвән. Кайта торыгыз, Нажия ханым. Табыныгыз әзер булсын.

Нажия. Әллә?

Мәрвән. Әллә.

Нажия чыгып китә.

Әхтәм. Я?

Мәрвән. Нәрсә я? Кереп бел. Куркак куян.

Әхтәм. Тәпәләделәрме?

Мәрвән. Тәпәләделәр.

Әхтәм. Алдыйсың.

Мәрвән. Мохтаров дигән кеше нинди икән ул, күрәсебез килә, диделәр. Иртәгә үзе килсен, диделәр. Эшкә тотынасың. Безнең авылның проекты синең эскизларың нигезендә эшләнәчәк.

Әхтәм. Алдыйсың, Мәрвән, кил, үбим әле бер үзеңне.

Мәрвән. Хатыныңны үбәрсең. Әйдә.

Әхтәм. Кая?

Мәрвән. Сезгә кайтабыз. Өендә кунак булырга да вакытым тигәне юк.

Сәхнә буйлап атлыйлар.

Әхтәм. Эх! Дөнья ни әйтсәң дә матур, әйеме, Мәрвән?.. Мәрвән, нигә дәшмисең? Матур бит дөнья.

Мәрвән. Матур булмый карасын.

Иңнәрен-иңгә куеп атлыйлар.

*Пәрдә.*



## Марсель Галиев

*Унберенче классны Азнакай мәктәбендә тәмамладым.*
*Бүген Казан дәүләт университетының журналистика бүлегендә укыйм.*
*Мин үткән гасыр кешесенә сокланам. Бүген яшәвемә шатланам. Киләчәк кешесеннән көнләшәм.*
*Без туганчы Җир өстендә күп ачышлар ясалган. Анда әле күпме ачылачак ачышлар, васыятьләр, ядкарьләр...*
*Кеше биеккәрәк күтәрелә барган саен, поэзия матурлыкны җирдән эзли...*

## Мин — дәвамы булып...

Еллар аша бала чакка кайттык,
Туган нигез инде үзгәргән.
Безгә акыл биргән ил картлары
Мәгънә көтә безнең сүзләрдән.

Сынап карап барысын сорашалар,
Килешәләр микән, икеле.
Ә күзләре моңсу елмаялар,
Баеп барган кояш шикелле.

Сагыш кебек ачы тәмәкене
Салмак кына тәмләп суырып,
Алар сиңа тагын киңәш бирә
Ата булып, якын, үз булып...

Дары исен ерак яшергәннәр...
Хәрби кием кайсы кимәгән!
Изүләрдә хәзер калган бары
Җиз йолдызлы ялтыр төймәләр.

Җир шары да инде алар өчен
Түбәтәй күк гади бер нәрсә.
Илләр иминлеген иңгә салып,
Алып килгәч шушы көнгәчә,

Тынычлыкны, изгелекне әле
Һаман әзер алар якларга,
Мин — дәвамы булып башым иям
Мондый гади-бөек картларга.

## Мәхәббәт

Төнне үртәп кычкырасы килә:
— Без кавышкан урын шушында-у!
Иң кадерле сүзләр сүнәмени,—
колакларда рәхәт пышылдау.

Ышанасы килә, инде безне
аерасы мизгел юктыр ул.
Ә мәхәббәт үзе ерак якты,
без алданган матурлыктыр ул.

●

Кошлар кебек язлар алып
Килде күпме хатларың.
Зәңгәр гөрләвектәй юллар,—
Ак кәгазьдә — антларың.

— Хатларым саклама,— дидең,—
Еллар кунса — саргайтыр.
Без очрашкач үткән көннәр
Хатирә булып кайтыр.—

Сары ялкыннарга салды
Миндәге бар хатларың.
Кара күбәләкләр булып
Җилгә очты антларың.

## Чегәннәр

Бар мөлкәтен, тарихларын салып
Кызу, дәртле җырга, атларга,
Китеп бара әнә шаулы табор
Бәхет эзләп чит-ят якларга.

Табигать күк хәрәкәттә алар,
Охшап моңга, җилгә, болытка.
Аларда да сагыш булыр икән,
Җыр шикелле бәйсез булып та...

Соңгы җайдак шәфәкъ ялкынында...
Бөдрә чәчле чегән егете,
Гитараның күкрәгенә ауган,
Өзелгәнме әллә өмете?

Шашып җырлый-җырлый илсез табор
Күчеп йөри — калмый ятларда.
Кешелекнең узган бала чагы
Кайтып килгән гүя атларда,
Юлы аның кайсы якларга?!.

# Госман Садә



*Татар шигърияте — куәтле Идел бит ул. Идел дигәннән, безнең авылның чишмә сулары да Караидел, Агыйделләр аркылы аңа барып кушыла.*

*Гүзәл Башкортстан киңлеге, урманга һәм елгаларга бай Аскын районы Әмир авылы — туган бишегем дә, бүгенге дөньям да. Туган ягымның үзе кебек үк киң күңелле кешеләр яши бездә. Күз алдында бала чак хатирәләре: сабан туйлы матур җәйләр, болынга печәнгә чыгулар...*

*Миңа егерме ике яшь. Әле Уфада университетта белем алам. Табынганым — шигърият. Үземнең шигырьләрем нindидер инде... Хәер, чишмә суының тәмен белү өчен бер йотымлап карау да җитә, диләр. Шулай булгач, укучым, мин синең хөкемең алдында.*

## Адымнар

Карт солдат тәмәке көйрәтә...
Оныгын атларга өйрәтә:
Өйрәтә аякка басарга,
Беренче адымын ясарга.

Йөрәктә үткәннәр кагышы...
Урамда адымнар тавышы:
Кул болгый яшь кызлар, ханымнар,
Урамда адымнар... адымнар...

Кешеләр бик ерак бардылар.
Бардылар... Күпме юл ярдылар.
Туплардан аттылар — аудылар,
Утларда янсалар яндылар,
Кешеләр барыбер бардылар!
Батырлар Берлинны алдылар!!

Карт солдат тәмәке көйрәтә.
Карт солдат оныгын өйрәтә:
Беренче адымны ясарга,
Атларга... Җиргә нык басарга!

## Язгы җыр

Дустым Рафаэль хулиганнар
кулыннан һәлак булды.

Язгы кич... Бөреләр тереләә,
Бөрегә бөреләр үреләә.
Күңелгә мәхәббәт юл яра.

Урамда күрше кыз Гөлнара,
Күзләре төнмени — чем-кара.
Гөлнара, яныңнан кем бара?

Кем бара, гитара уйнатып,
Гөлләрне җыр белән юатып?
Ул һаман җилләргә кагыла.
Нинди моң! Кыллардан агыла,
Сыймыйча Агыйдел ярына:
«Йөрәкләр сөюдән ярыла-а-а».

Язгы су ярлардан артыла.
Ай чума агачлар артына.
Ояла, тартына-тартына
Кочаклар кочакка тартыла.
Кайдадыр аккошлар коена.
Аккоштай ак нурлар коела.

О, керсез мәхәббәт! Каршыла:
Дүрт егет, дүрт пычак каршыңда.
Пычаклар... Салкын нур ялтырый.
Куркудан бөреләр калтырый.
— Яр юлы өеңә кайтара,
Курыкма, бар йөгер, Гөлнара!

Гөлнара, бар йөгер. Карама! —
Соңгы сүз яр буйлап тарала.—
— Күрегез, сөюем бер кочак!
...Кадала кочакка дүрт пычак.
Язгы кич... бөреләр йомылган,
Бөреләр кан белән юылган.

Кайгыдай кара күз Гөлнара.
Яр буйлап кайларга ул бара?
И елый, өзелә, сызлана,
Сызлана гөнаһсыз кыз бала.
Күңелгә таныш җыр кагыла:
«Йөрәкләр сөюдән ярыла-а-а,
Йөрәкләр...»

## Яңгыр

Яшьнәде дә күкрәп, җәйге яңгыр
Китеп барды таулар артына.
Яңгырдан соң гөлләр уяндылар,
Бер кыз чыкты капка алдына.

Яңгыр үтте кинәт кенә шаулап,
Тын бакчалар калды яшәреп.
Егет китте, китте ерак юлга,
Кыз күзләре калды яшьләнеп.

Күкрәүләрме аны тетрәттеләр,
Шук җилләрме кагылып үттеләр;
Тамчылармы әллә елатканчы
Керфек очларыннан үптеләр?!

## Югалту

Бик кыендыр чаганга
Соңгы яфрагын кою.
Унлата кыен миңа
Синең юклыкны тою.

Сыгыла, елый чаган,—
Еларга кем дә белә.
Сыгылмас, сынмас өчен
Күңел ныклыгы телә.

Яфраклар оча бары —
Югалту шушы бугай.
...Ә күктә ай дерелди
Шул чаган яфрагыдай.

## Шаян кыз авызыннан

Яратмыйсың булмэгезгә
Шаяртып кергәнемне.
«Бик чуалма монда, дисең,
Бирермен кирәгеңне!»

Җенең сөйми, тел чыгарып,
Үчекләп йөргәнемне.
«Яхшы чакта югал, дисең,
Бирермен кирәгеңне!»

Мин көтәм, көтәм зарыгып:
Бирсәнә кирәгемне,—
Күп кирәкми мин гашыйкка,—
Бир генә йөрәгеңне.

## Бөре шәһәре кызына

Бөре кызы булгангамы,
Минем өчен бөре идең.
Бөренең дә әллә нинди —
Мин белмәгән төре идең.

Бер елмайсаң, бар Уфаны
Якты нурга төрер идең,
Бөре генә иреннәрең! —
Иреннәрдә эрер идем.

Ачылмаган бөреләрнең
Серлеләрдән серлесе син.
Унсигез ел ачылмаган
Нинди гөлнең бөресе син.

# Зиннур Мансуров



*Мин 1949 елда ямьле болында туганмын.*

*Тукайның кайбер шигырьләрен яттан белгән мәрхүмә әнием җыр-такмаклар чыгарырга ярата иде. Кулыма каләм алуыма шагыйрәнә күңелле әнкәем сәбәпче булгандыр дип уйлыйм.*

*1966 елда урта мәктәпне тәмамлап, татар әдәбиятын, дөнья әдәбиятын өйрәнү өчен Казан дәүләт университетына килдем.*

*Туган җирем — Мамадыш районы Түбән Ушмы авылы.*

## Казлар китә

«Канат төртмәгән җирләрем
калды микән күгемдә?!
Җылы канатым астында
Туган ил бар бүгенгә...»

Күктә тавыш,
          авазлар...
Таныдым:
былтыр озаткан казлар!

«Болытларга кагылыймчы,
зәңгәрлеккә манылыймчы;
Сине күрми миңа читен —
нинди микән син, күк чите...»

Күктә тавыш, авазлар...
Таныдым...
быелгы бала казлар...

## Туй күлмәге

*Әнием истәлегенә*

Кыз чагында күлмәк теккәнсеңдер,
чыгар вакыт җиткәч кияүгә,
Теләк теләп,
          насыйп булсын диеп
тик бер генә тапкыр кияргә,
тик бер генә тапкыр кияргә...

Ник ашыктың, әни,
туй күлмәгең
син икенче тапкыр киярга,
«...Туй күлмәгем белән... кабер эчем
якты нурлы булсын...» диярга...

●

Миңа да бер йолдыз бардыр
өлешемә тигәне,
Күкнең кайсыдыр төшендә
«Оялчаным...» дигәне.
Миңа да бер кыймый гына
Ташлар әле карашын.
Мин бәхетле итмәммени
Җирнең бер кыз баласын!

## Сагыну

Кайнап-кайнап чирәм чыккан.
Күренеп үсә чаган!
Сагындырган үлән исе,
Ах, ничек сагындырган!..

Бәби табар киленнәр күк
иде бөреләр кичә.
Бүген инде яфрак туган
берсеннән әллә ничә...

Кайнап-кайнап чирәм чыккан.
Җилдән җир исе килә.
Тай күк керт-керт үлән өзеп
утлап йөрисе килә!

## Малай чакны искә төшергәндә

Бар иде кочып караган,
хәтта бар иде үпкән...
...Без озатып йөргән кызлар
инде тормышта күптән.

Өзелдең безне бәйләгән
Син, мәхәббәт зынҗырым,
Беренче садә шигырем,
Минем беренче җырым...

Күрсәм, ни дип дәшим сиңа?
«Саумы»,— диярмен бары...

Сөяргә өйрәтеп киткән,
Миңа язмаган ярым.

## Мәхәббәт илендә

Учак-учак йолдызлары,
кочак-кочак кызлары...
Минем кочакка кергәне
Син бердәнбер кыз бары.

Кычкырасым килә күккә:
«Гомерлегем, яктым...— дип,
Мәхәббәттә ятим чагым,
Сау бул, инде таптым!..» дип.

Сөю сукмаклары озын —
барасы да барасы...
Ничек кулга иялэштең,
ах син, болан баласы...

## Ак буран

Ак аттай уйный буран...
Кар белән тулган бура —
Яшьләр салып керәсе өй...
теләсә нигә юра.

Буранның ак байталы,
чуалган ап-ак ялы...
Кызларны урлап китәр күк
ак чанасына салып...

Ак бураннар, ап-ак атлар
бездәнме качып йөргән.
Ап-ак буран безгә үзе
Капканы ачып кергән...

Теләсә нигә юра —
авылда ап-ак буран...

Җәүдәт Кәлимуллин

# ҺӘРБЕР ТЕЛӘК— ЯКЫН КИЛӘЧӘК

КамАЗ КӨНДӘЛЕГЕ

Көмеш очкыч Казан өстеннән кыйгачлап бер әйләнде дә илебез башкаласына юл алды. Салондагы пассажирлар таныша-сөйләшә башладылар, Мәскәүдә күпмедән буласын сораштырып алучылар да булды. Аннары һәркем үз шөгыленә кереште. Кемнәрдер, юл кыскарак булыр дип, укып барырга аэропорттан алган газета-журнал битләренә текәлде, пассажирларның беришесе, дөнья хәлләрен уртага салып, әңгәмә куертты. КамАЗ төзелешендәге зур подразделениеләрнең берсендә — төзелешне механикалаштыруның икенче идарәсендә эшләүче Ольга Плотникова исә каерылып тәрәзәдән карап баруында булды. Самолетка беренче утыруы түгел аның, байтак очканы бар. Биеклек өркетми дә, гаҗәпләндерми дә. Хезмәте дә биектә бу кызның. Кранчы булып эшли: күтәрелеп килә торган автогигант корпусларын, Чаллы шәһәренең мәһабәт яңа торак массивларын җирдәгеләргә караганда ачыграк та, якынрак та итеп күрергә күнеккән. Күк гөмбәзе дә якынрак төсле аңарга. Төнге сменада эшләгәндә егет-җилән халкы кайчак шаярта:

— Оля, Олина, Олечка! Сүзебезгә колак салсана! Чаллының кайсы бәхет йолдызы астында корылганын тиз генә күрсәт әле. Син бит йолдызларга якынрак эшлисең...

— Йолдызларны берәм-берәм чүпләп кесәгезгә салмыйммы тагын?! Чуалмагыз кран угы астында. Грамоталы кешеләр бит сез, укыр идегез. Нәрсә дип кисәтелгән? «Кран астында торма!» дигәнме?..

— Оля, Олечка! Минем бәхет йолдызымны төртеп күрсәт әле! Шәп җемелдиме икән?

— Бәхет йолдызың тулай торактагы урынында татлы йокыга талган инде, изрәп йоклый. Әле син тел шомартып торгач та, аның иртүк сменага барасы бар ич. Бригада алдында күңел сандугачыңның адресын кабатлатасың килсә, шуны әйтүдән йөрәгеңә ял булса, әй-

тим. Йорты алты да алты, квартирасы туксан бер, койкасы ишектән керүгә уң кулда беренче... Күңелең булдымы?

Бүген исә Ольга йолдызларның бүтәне хакында уйлана. Хыялында Кремль йолдызларының, рубин йолдызларның балкышын күрә ул. Әченнән шуларга елмая, кул изәгәндәй, баш иеп сәламләгәндәй була. Мәскәүгә Ольганың беренче баруы әле. Кызыл мәйдан ташларына басканы булмаса да, сабый чактан ук укыган китаптагы рәсемнәрдән, күргән кинофильмнардан киртләч стеналы чал Кремльне, Спасс манарасындагы сәгатьне, җир йөзендәге изге теләкле һәммә кешеләрнең күңел күзе төбәлгән мәрмәр Мавзолейны, каршысына басып карагандай, күзаллый ул. Курант чыңы колагыннан китеп тормый. Ак болытлар аша, вак болытлар аша челтәрләнеп, шакмакланып күренгән кырлар, көмеш тасмалардай боргаланган елгалар, күгелҗемләнеп утырган урманнар өстеннән очканда ук уйлары, хыяллары белән Кызыл мәйданда иде инде ул. Ил йөрәге типкән изге урыннан хыял канатлары аны комсомол Үзәк Комитеты бинасы янына, Богдан Хмельницкий урамындагы зур йорт янына китереп куйды. Ватан яшьлегенең штабына да сокланып карады ул.

Кемнәр генә булмаган бу йортта! Революция һәм гражданнар сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышының легендар геройлары, халык хуҗалыгын дәһшәтле сугыштан соң сафка бастырган фидакарьләр... Чирәм җирләрне үзләштерергә китүчеләр. Әсгать Җиһаншин җитәкчелегендә рәхимсез океанда кырык тугыз көн буена табигать стихиясе белән көрәшкән экипаж, Гагарин һәм Титов, совет космонавтларының плеядасы, Даманский каһарманнары, дөньяга даннары таралган спортчылар, фән-техника, әдәбият-сәнгать өлкәсендә Ленин комсомолы лауреатлары... Менә бүген, Чаллыдан килүче бер төркем иптәшләре белән, Ольга да ВЛКСМ Үзәк Комитетына керәчәк, комсомолга илебез биргән алты орден саклана торган залга аяк басачак. Алар делегациясе составында да бу бинага еш кына килгәләп торучы кеше бар. Ул — «Жилстрой-1» нең 51 нче төзү-монтаж идарәсенең ташчылар бригадасы җитәкчесе Вазих Мәүлихов. Вазих — ВЛКСМ Үзәк ревизия комиссиясе члены, комсомолның XVI съезды делегаты. Аңардан тыш, Чаллы яшьләре делегациясендә «Жилстрой-2» нең 61 нче төзү-монтаж идарәсенең монтажчылар бригадасы башлыгы Рәис Сәлахов, шул ук идарәдән шундый ук коллектив җитәкчесе Рафис Сабирҗанов, «Промстрой»ның 15 нче төзү-монтаж идарәсенең штукатур-маляры Валентина Задаткова, «Минмонтажспецстрой»ның электромонтажчысы Леонид Чесноков, ВЛКСМның Яр Чаллы шәһәр комитетының беренче секретаре Валерий Кузьминнар да бар.

Безнең чорда Казан белән Мәскәү арасы чутмыни ул? Менә алар илебез башкаласында. Хыял-канатлар реаль канатларга әйләнде ләбаса! Әнә шанлы Кремль, Мавзолей... Әнә Космонавтлар аллеясы... Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсе... Күз алдында ялтйолт килеп балкып калган метро станцияләре... Ленин таулары, университет...

*1972 ел. 1 март.* КамАЗчылар ВЛКСМ Үзәк Комитетында Социалистик Хезмәт Герое Мария Ивановна Виноградова, Алексей Харитонович Бусыгин һәм Иван Иванович Гудов белән очраштылар. Бу исемнәр Ольгага да, аның хезмәттәшләренә дә тарих буенча билгеле, әти-әниләренең хәйран калып кат-кат сөйләүләре буенча да мәгълүм. Заманында хезмәтләре белән илне шаулаткан батырлар, стахановчылык хәрәкәтенең нигезен коешкан шөһрәтле каһарманнар. Алар, Алексей Стаханов һәм Петр Кривонос белән бергәләп, Кама автомобиль заводы төзелешендәге социалистик ярыш инициа-

торларына, андагы барлык эшчеләргә хат язганнар иде. Ул хат бишьеллыкның иң зур төзелешендә социалистик ярышның яңа дәрт белән көчәеп китүенә сәбәп булды. Инде менә үзләре яшьләрнең янәшәсендә... Исемнәре Чкалов һәм Байдуков, Полина Осипенко һәм Мария Гризодубова, Гыйльфан Батыршин һәм Иван Чернопятко, челюскинчылар, Мөхәммәт Зиннуров һәм Хәбибулла Галиуллинның ил шаулаткан исемнәреннән аерылгысыз булган хезмәт батырлары, инде олы яшьтә булуларына карамастан, яшьлеккә хас җанлылыкны, терелекне җуймаганнар. Кулларны каты кысып күрешүләрендә үк беренче бишьеллыкларның кайнарлыгы, шул еллардагы комсомолның дәрте сизелеп тора сыман.

Очрашу Ольга күңелендә әйтеп аңлаткысыз җылы тәэсир калдырды. Анда әйтелгәннәрнең барысын да истә калдырырга теләп тыңлады ул.

Шушы көрешүне башлап җибәргәндә ВЛКСМ Үзәк Комитетының эшче яшьләр бүлеге мөдире Олег Иванович Высокос болай диде:

— Кадерле дуслар! Безнең өчен бу — истәлекле очрашу. Безгә кунакка беренче бишьеллыклар геройлары килделәр. Алар бүген безнең алга партия куйган бурычларны хәл итүдә комсомолның барлык буыннары туплаган тәҗрибәне уртаклашачаклар. Комсомолның данлы тарихында удар төзелешләр сәхифәсе алтын хәрефләр белән язылган. Волхов ГЭСы, Магнитка, Турксиб, Амурдагы Комсомольск, Абакан-Тайшет тимер юлы, Братск, Красноярск ГЭСлары, Волжск автомобиль заводы һәм менә КамАЗ... КамАЗ тугызынчы бишьеллыкта иң зур төзелешләрнең берсе булып санала. Шушы заводлар комплексы төзелешенә билгеләнгән капиталь салымның, төзелешнең моңарчы күрелмәгән колачы һәм тизлеге хәтта белгечләрне дә хәйран калдыра. Бүген меңнәрчә егетләр һәм кызлар — илебезнең барлык союздаш республикалары, край, өлкәләр комсомол оешмаларының иң алдынгы вәкилләре — шушы удар төзелештә эшлиләр. КамАЗ төзелешендә илебезнең 70 милләт вәкиле катнаша. Шулай булгач, бу төзелешне ничек бөек дуслык төзелеше дип әйтмисең?! Чөнки КПСС Үзәк Комитетының «Совет Социалистик Республикалар Союзы төзелүнең 50 еллыгына хәзерләнү турында»гы карарында әйтелгәнчә, «Коммунизмның материаль-техник базасын, коммунистик җитештерүче көчләрне булдыру, иҗтимагый җитештерүне һәрьяклап интенсивлаштыру... яшь кеше формалашу кебек гаять зур проблемаларны хәл итү күп милләтле Совет державасының бөтен куәтен концентрацияләүне таләп итә».

Социалистик ярыш ветераннары чыннан да эшлекле, чыннан да югары җитештерүчәнлеккә китерүче ярыш җәелдерүдә үзләренең уйкиңәшләрен әйтеп, КамАЗ һәм шәһәр төзүчеләргә махсус хат белән мөрәҗәгать иттеләр. Бүген менә, яшь дуслар, алар ВЛКСМ Үзәк Комитеты бинасында.

Беренче булып сүзне Мария Ивановна Виноградова алды. Иң әүвәл аның биографиясеннән берничә деталь. Дуся, Маруся Виноградовалар Иваново өлкәсенең Вичуга шәһәрендә Ногин исемендәге туку фабрикасында эшлиләр. Дуся белән Маруся бертуган сеңелләр түгел, фамилияләре генә адашлар. Ләкин хезмәтләре буенча Евдокия Викторовна һәм Мария Ивановна чыннан да бертуган. 1936 елда Дуся һәм Маруся Виноградовалар Мәскәүгә промышленность академиясенә укырга керәләр. Каникулларга кайткач, алар искиткеч рекордлар куялар.

Укуны тәмамлагач, Мария Ивановна Мәскәүдә Фрунзе исемендәге фабриканың директор урынбасары итеп билгеләнә. Социалистик

Хезмәт Герое М. И. Виноградова — 1963 елдан бирле сүс-тукыма Үзәк фәнни-тикшеренү институтының директор урынбасары. Очрашу вакытында М. И. Виноградова болай диде:

— ВЛКСМ Үзәк Комитетында яшь дусларым белән очрашуга мин бик шатмын. Бала чактан бирле без бу стеналарны изге, иң кадерле дип исәпләп киләбез. Бу — безнең туган йортыбыз. Бирегә гүзәл эшләрне хуплап каршылыйлар, авыр минутларда ярдәмгә киләләр.

Без дә сезнең кебек яшь идек. Совет власте әле аякка гына басып килгән чак. Ашарга да җитми иде. Дуся белән без ул чагында икешәр туку станогында эшләдек. Менә Англиядән туку станоклары кайтарыла башлады. Без шул станокларда эшли башладык. Башта безнең карамакта 12 станок булса, тора-бара ул 26 га җитте. Шулай да әле безнең шактый буш вакытыбыз кала иде. Шимбә көннәрендә фабрика идәннәрен дә үзебез юа идек. Малайлар шау-гөр килеп су ташыйлар, ә без җырлый-җырлый идән юабыз. Тора-бара безнең кул астындагы станоклар саны да 40 ка җитте. Инглизләр фабрикага килделәр. Бу хәлне күреп шаккаттылар. Аларча, 26 станокта эшләү соңгы чик иде.

Илебез аякка ныграк баса барды. Безгә Ленинград шәһәреннән менә дигән туку станоклары китерелде. Шуннан соң без 70 станокта эшли башладык.

1935 елның 21 августы. Бу көн минем һәм дусларымның хәтерендә нык саклана. Шушы көнне без «Центральная Ирмино» шахтасының күмер чабучысы Алексей Стахановның норма буенча 7 тонна урынына 102 тонна күмер чапканын белдек. Бу батырлык безне искиткеч дулкынландырды. Без дә егетләрдән калмаска дип сүз бирдек. Һәм 1935 елның октябрь аенда 100 станок-автоматта эшли башладык. Моңа без хезмәтне нык уйлап оештыру хисабына ирештек. Шуннан соң бөтен илдә социалистик ярыш хәрәкәте көчәйде. Стаханов башлангычы бөтен илне дулкынландырды. Безнең рекордны уздырып җибәрәчәкләре дә көн кебек ачык иде. Чөнки Иваново кызларының да кул кушырып утырмаячакларын сизә идек.

Аннан соң безне Кремльгә чакырдылар. Бу вакытта инде без хезмәт күрсәтә торган станокларның саны 140 ка җиткән иде. Серго Орджоникидзеның елмаеп әйткән җылы сүзләре һаман да истә. «Сезгә карыйм да күзләремә ышанмыйм. Яшь-яшь малайлар, кызлар, ә шулай да нинди рекордлар куясыз!»

Без белә идек — ирешелгәннәр чик түгел. Тагын да тырышыбрак эшләргә кирәк. Шулай итеп, үзебезнең карамакка 180 станокны алдык. Ә Тася Одинцова исә 200 не! Без шуны да белә идек: мәсьәлә рекордларның югарылыгында гына түгел. Сүз хезмәтне югары җитештерүчән итү өчен көрәш турында бара. Мин КамАЗ һәм шәһәр төзүче меңнәрчә яшьләрдән, Рәис Сәлаховтан, аның чакыруына кушылучылардан, яхшы мәгънәсендә, көнләшәм. Зур, рухландыргыч эшкә алынгансыз. Сәлахов егетләре башлангычы эшне бөтен төзелеш масштабында уйлап планлаштыруны, төзү материаллары белән даими тәэмин ителешне, хезмәтне чын-чынлап фәнни оештыруны таләп итә.

О. И. Высокос:

— КамАЗ төзүчеләре, Мария Ивановна, сез куйган бурычларның катлаулылыгын яхшы аңлап эш итәләр. Озак бәхәсләшкәч, барысын да үлчәп карагач, Сәлахов бригадасы егетләре заданиене көн саен, атна саен, ай саен һәр объектта арттырып үтәргә, һәр эшнең югары сыйфатлы булуын тәэмин итәргә сүз бирделәр. Мәгълүм булганча, җиңел бурыч түгел бу. Хәтта рекорд куюга караганда да катлаулырактыр. Син ничек уйлыйсың, Рәис?

Рәис Сәлахов:

— Без үзебезнең нинди җаваплы эшкә алынганлыгыбызны аңлыйбыз. Максат җитди. КамАЗ төзелеше срогының кыска булуы планнарга төзәтмә кертә. Эшне фәнни оештыру бурычын алга куя. Безнең бригада бишьеллыкка алган йөкләмәләрне яңадан карап чыкты һәм аны дүрт елда үтәп чыгарга сүз бирде. Көнлек норманы даими рәвештә 140 процентка үтәп барачакбыз. Хөрмәтле хезмәт ветераннары! Безнең коллектив сезнең хатны җентекләп тикшерде. Сез башлаган эстафетаны дәвам итәргә сүз бирәбез. Тагын да яхшырак эшләрбез. Безгә биргән наказыгызны үтәрбез!

Яшь төзүчеләр белән әңгәмәгә Александр Харитонович Бусыгин кушылды. Менә аның биографиясеннән берничә белешмә. 1930 елның көзендә шаулап урман үскән Ветлуга якларыннан Нижний Новгородка Бусыгин исемле малай юл тота. Ул кемнәндер бу якларда автомобиль заводы төзелә башлавын ишеткән була. Фамилиясе урынына бары тик тамга гына куя белә торган егет башта балта остасы булып эшли, 1932 елда заводның тимерчелек цехына җибәрелә. 1935 елда ук инде Горький автомобиль заводы эшчеләре хезмәт җитештерүчәнлеге буенча Франциянең атаклы «Рено» фирмасының үкчәсенә басалар. Чиратта Америка белгечләре билгеләгән норма кала. 10—17 сентябрьдә тимерче Александр Бусыгин дөнья автомобиль промышленностенда моңарчы күрелмәгән рекордлар куя.

А. Х. Бусыгин:

— Мин, иң элек, безнең чакыруны кабул итүегез өчен сезгә рәхмәтебезне белдерәм, дуслар! Без — тордәш машина төзелеше кешеләре. Шулай булгач, бер-беребезне аңлау кыен булмас. Безнең завод төзелешендә авырлыклар күп булды. Палатка, бараклар... Ә сезнең кулда менә дигән төзү техникасы. Без заводны көрәк, тачка һәм «кәҗә» белән төзедек. «Кәҗә» озынлыгы бер метр булган әскәмияне хәтерләтә. Шуны аркага куеп кирпеч ташыйсың. Мин дүрт ай буена үз җилкәмдә шул «кәҗәне» йөрттем. Завод 18 ай эчендә төзелеп бетте.

Төзелешкә Горький өлкә комсомол оешмасы, ВЛКСМ Үзәк Комитеты бик зур ярдәм иттеләр. Комсомол рухы төзелешнең һәр участогында сизелеп торды. Шундый вакыйгалар истә әле: син аяктан егылырлык булып арып-талып эштән кайтасың, ә төнге сәгать икеләрдә комсомол оешмасы секретаре килеп ишек кага. Кирпеч килгән, бушатырга кирәк, ди. Коеп яуган яңгыр астында таң атканчы кирпеч бушатабыз. Яңгырны да, аруны да сизмибез.

Тимерчелек цехында эшли башлагач, беренче көнне үк мин норманы бер ярым тапкырга арттырып үтәдем. 625 урынына 800 терсәк валы эшләдем.

— Хуп. Иртәгә ничегрәк булыр инде? — диделәр иптәшләрем, бу хәлгә ышанырга теләмичә.

— Тагын да күбрәк ясыйбыз.

Төн буе уйланып яттым. Һәм иртәгесен 901 вал чүкедем. Бу көннәрдә Стаханов турында газеталарда шаулатып язалар иде. Бездә дә аңа иярү теләге көчле иде. Тора-бара мин 1200 вал чүки башладым. Шуннан соң тукталыш булды. Чөнки мичнең мөмкинлекләре чамалы иде. Безне Мәскәүгә чакырдылар. Серго Орджоникидзе кабул итте. Миңа ул чакта 23 яшь булса да, ябык һәм кечкенә идем. Серго Орджоникидзе: «Болар кешеләр түгел, автоматлардыр»,— ди. Үзе елмая.

Америка эшчеләре бер терсәк валын чүкүгә 36 секунд сарыф итсәләр, безнең заводта бу норма 50 секунд тәшкил итә иде. Мин бу

операцияне 30,8 секундка калдырдым. Аннан соң бер сменада 1670 терсәк валы җитештерә башладым. Бу — нормага әйләнде. Америка белгечләре моңа һич тә ышанырга теләмәделәр. Икенче сменадан кайтып йокыга гына киткән идем, бүлмәгә бер төркем кеше килеп керде. Мине чеметеп карыйлар. Күрәсең, болар да автомат дип уйлаган булганнардыр. Юрган астыннан кеше килеп чыккач, шаккаттылар.

Иван Иванович Гудов Рәис Сәлаховка сорау бирде:

— Сезнең йөкләмәләрегез бик югары, аларны нәрсәләр хисабына үтәргә уйлыйсыз?

Рәис Сәлахов:

— Техникадан нык файдалану, төзү материаллары белән тәэмин итешне вакытында булдыру исәбенә.

О. И. Высокос:

— Бүгенге төзелештә, әлбәттә, техника зур роль уйный. Ләкин эзләнүләр һәрвакыт кирәк. Шулай бит, Вазих?

Вазих Мәүлихов:

— Дөрес әйтәсез, Олег Иванович. Менә мин Чаллыда өченче ел эшлим инде. Безнең бригада беренчеләрдән буларак комсомол-яшьләр коллективы исемен алды. Ике дистәдән артык яңа объект төзеде. Даими рәвештә призлы урыннарны алдык. Безнең девиз: «Ике-өч кеше өчен эшләргә!» Яңалыкны эзләнү дигәннән, шуны әйтергә телим: бригадада хезмәттә катнашу коэффициенты уңышлы файдаланыла. Әйтик, бер үк разрядка ия булган эшчеләрнең төрле-се төрлечә эшләргә мөмкин. Хезмәт коэффициенты әнә шуны билгеләли. Һәр эшчегә, хезмәт активлыгына карап, балл куела. Шушы баллар нәтиҗәсендә хезмәт хакында да аерма була. Бу адым хәзер барлык бригадаларда да кулланыла. Балл чыгару нәтиҗәләре бригада советы утырышында раслана. Хуҗалык исәбе, нарядсыз эшләү кебек алымнар да үз-үзен аклыйлар.

М. И. Виноградова:

— Төзелешкә кайчан килдегез? Кайда яшисез? Палаткалар бармы?

Вазих Мәүлихов:

— Моңа кадәр Казанда органик синтез заводында аппаратчы булып эшләдем. Шәһәр комсомол оешмасы чакыруы буенча, КамАЗ төзелешенә килдем. Семьям белән квартирада яшим. Бездә палаткалар, гомумән, юк. Торак күп төзелә, мәктәпләр салына.

А. Х. Бусыгин:

— Төзүчеләр кайсы яклардан киләләр? Аларны нинди хыяллар тарта?

Валя Задаткова:

— Урта мәктәптә укып чыкканнан соң КамАЗга килдем. Мин үзем Ярославль ягыннан. Бригадабыз бик тату.

Шуннан соң хезмәт ветеранына җавапны Мәскәүнең яшь төзүчеләре Галя, Зоя һәм Володя бирделәр. Алар өчесе дә КамАЗ төзелешенә барырга җыеналар. Зоя инде зур төзелеш романтикасын белә. Тольяттида эшләп кайткан. Володя да Воскресенск шәһәрендә химия заводы төзелешендә катнашкан. Ә менә Галяның читкә беренче тапкыр чыгуы.

— Авырлыклардан курыкмыйсызмы? (Бу сорауны А. Х. Бусыгин бирде.)

— Ю-у-к...

О. И. Высокос:

— Валерий, төзелешкә килгән комсомолларны сез ничек каршылыйсыз?

Валерий Кузьмин:

— Яшь иптәш үзен туган коллективта итеп сизсен өчен без барысын да эшләргә тырышабыз. Яшь эшче бер-ике көн эчендә коллективка урнаша. Ветераннар белән очрашулар, завод шәһәренең киләчәге турында сөйләү, яшь кеше алдындагы перспективаларны күрсәтү — болар барысы да үз рольләрен уйныйлар.

Сүзгә Леонид Чесноков кушылды:

— Комсомол-яшьләр коллективын бердәмлек, дуслык ныгыта, үзенә булган хөрмәтне һәр коллектив члены тырыш хезмәте белән яулап ала. Безнең бригадада 11 кеше эшли. Без барлык мәсьәләләрне дә киңәшеп хәл итәбез. Егетләрнең яртысы диярлек эшче яшьләр мәктәпләрендә укый. Укучылар белән дә дус яшибез. Шефка алынган мәктәптә балаларга профессиональ ориентация бирү буенча эшлибез.

О. И. Высокос:

— Леонид дөрес әйтә. Яшь кеше коллективта тәрбияләнә. Моңа мисалны без комсомолның барлык буыннарыннан да таба алабыз. Иван Иванович Гудов та аны үз тормышы мисалында аңлата алыр иде.

И. И. Гудов сүзләрен тыңлар алдыннан аның биографиясенә күз салыйк. Ваня исемле егет 1934 елда Калуга өлкәсенең Дебри авылыннан Мәскәүгә килә. Бөтенләй укый-яза белмәгән егет авылда сабан сөрә, торф чыгаручы, көтүче, кочегар, каравылчы, хәтта тәрбияче булып та эшли. Мәскәүнең Орджоникидзе исемендәге станок төзү заводында ул кара эшче булып урнаша. Ә бер елдан соң менә дигән фрезерчы булып җитешә. Немецлар билгеләгән технологиягә каршы чыгып, И. И. Гудов кисү операциясенә киткән вакытны бермә-бер киметә. Бу «тәртипсезлеге» өчен аны заводтан чыгаралар. Ләкин стахановчыны яклаучылар да табыла һәм И. И. Гудов тәнге сменаларның берсендә заданиене 410 процентка үти. Металл эшкәртүдә югары тизлеккә нигез әнә шулай салына.

И. И. Гудов:

— Мин беренче бишьеллыкларның биш герое арасында булуыма шатланам. Эшче намусы дигән төшенчә һәрвакыт югары бәяләнде. Минем яшь дусларым да аны шулай дип аңларлар. Уңышлар телим сезгә, дуслар.

Валерий Кузьмин:

— Сезнең мөрәҗәгатегез, хөрмәтле ветераннар, КамАЗ һәм шәһәр төзүчеләрдә искиткеч омтылыш һәм көч тудырды. Мин барлык яшь төзүчеләр исеменнән сезгә зур рәхмәт әйтәм, исән-саулык телим.

М. И. Виноградова һәм башкалар:

— Рәхмәт сезгә.

О. И. Высокос:

— Без ышанабыз, КамАЗ төзү турында партия һәм хөкүмәт карары уңышлы үтәләр. Сез, кадерле ветераннар, Кама елгасы буенда җәелгән зур төзелешне үзегез дә барып карагыз. Мин сүземне сезнең хатта әйтелгән сүзләр белән тәгалләргә телим: «Сезнең инициативагыз, кадерле дусларыбыз, үз үрнәгегезгә КамАЗ төзүчеләрнең барысын да ияртә алган очракта гына яхшы нәтиҗәләр бирәчәк!»

...Очрашудагы һәр сүз, һәр аваз, магнитофон тасмасына язылган сыман, Ольга Плотникованың күңеленә теркәлә барды. Бүтән иптәшләре дә аңардан ким дулкынланмый иделәр.

Казанга очканда Ольга үзен кранында итеп күрде, бәхет йолдызларын төртеп күрсәтүне үтенеп сагызланган егетләрнең көр тавышларын ишеткән кебек булды. Татар халык шагыйре Һади Такташның «Киләчәккә хат»ларын русча укыганы бар аның. Андагы берничә юл хәтергә уелып калган:

...Хыял — безнең өчен чит бер нәрсә,
Һәрбер теләк — якын киләчәк!

Шагыйрь, канатлы хыялны түгел, мәгънәсез, тузга язмаган буш хыялны кире кагып әйткән бу сүзләрне, тормыш чынбарлыгына нигезләнгән якты омтылыш-хыялны яклап әйткән.

Бишьеллыкның бөек гигантлары
Һаман үсә,
Һаман күккә таба үреләә,
Башларыннан инде сез яшәгән
Коммунизм кыры күренә...

Әйе, ул гүзәл кырны күңел күзе белән ачык күргәнгә күрә дә, Ольга һәм аның кебек меңнәр, миллионнар һәр көнне, һәр сменада кулларыннан килгәннең һәммәсен эшләргә ашкыналар. Беренче бишьеллык баһадирларының тәҗрибә уртаклашып, яңа казанышларга рухландырып әйткән сүзләре, биргән киңәшләре киеренке хезмәткә уңышлар яуларга биргән хәер-фатиха булып яңгырый.

## Җәмит Рәхимов

# ӨЧЕНЧЕ ЭТАП

### БИШЬЕЛЛЫК АДЫМНАРЫ



Ул көнне урамнар тантанага күмелгән иде. Кая карама — кызыл комач паннолар, күңелне алга әйдәп торган лозунглар, транспарантлар. Машиналарга беркетелгән транспарантлардан анда утыручыларның адресларын да укырга була: Лениногорскидан, Азнакайдан, Баулыдан, Актүбәдән...

Әйе, 14 майда республикабызга зур бәйрәм килде. Татарстан нефть ятмаларын эшкәртә башлаганнан бирле алынган җир маеның беренче миллиардын тутырган соңгы тонналар 16 сәгать 30 минутта трубопроводлар буенча илебез заводларына озатылды.

Әнә шул тарихи вакыйганы хәбәр итеп, сигез нефтьче — Социалистик Хезмәт Геройлары — тыныч хезмәт ярышында яулап алган ал байракларны Әлмәттәге иң мәшһүр, зиннәтле бинаның түренә күтәрделәр, бу искиткеч җыену турында Ленин орденлы «Татнефть» берләшмәсе начальнигы Әгъзам Вәлиханов белдерде. СССР Министрлар Советы председателе урынбасары, СССР Госпланы председателе Н. К. Байбаков, КПСС өлкә комитетының беренче секретаре, КПСС Үзәк Комитеты члены Ф. Табеев, ТАССР Министрлар Советы председателе Г. Усманов, СССР Нефть промышленносте министры В. Д. Шашин һәм башкалар әнә шул рухландыргыч вакыйга белән нефтьчеләрне тәбрик иттеләр. Бу хәбәр, ашкындыргыч авазга әверелеп, ерак-еракларга таралды.

Әле ай ярым гына элек нәкъ шушындый хәбәр карт Бакуда канатланып, илебез киңлекләренә таралган иде. Ул чакны Әзербәйҗанның атаклы нефть осталары иң өлкән нефть районнарының берсеннән миллиардынчы тонна сыек ягулык алулары турында туган илебезгә рапорт бирделәр.

Аллы-артлы ике куанычлы хәбәр. Тик шунысын әйтергә кирәк: Әзербәйҗанга бер миллиард тонна нефть чыгару өчен йөз елдан артыграк вакыт кирәксә, Татарстан миллиарды чирек гасыр да үтмәстән алынды.

Гомумән, безнең илдә нефть чыгару соңгы егерме биш елда әйтеп ышанмаслык тизлек белән, 15 мәртәбәгә артты. Россиядә нефть промышленносте барлыкка килгәннән соңгы 105 ел эчендә Җир куеныннан алынган 3,4 миллиард тонна сыек ягулыкның 2 миллиард тоннасы, ягъни яртысыннан күбрәге, соңгы ун елга туры килә.

Нефть чыгару промышленностеның зур уңышларын соңгы елларда Көнбатыш Себердә, Мангышлак ярымутравында һәм башка өлкәләрдә яңа чыганакларны үзләштерүгә генә кайтарып калдырырга ярамый. Ул, барыннан да элек, техник прогресс, нефть чыгару технологиясен камилләштерү, нефть мәйданнарын үзләштерүнең фәнни нигезләнгән ысулларын булдыру, катлам басымын саклау — нефть мәйданнарын эчтән һәм тирәли сусландыру, катламнарга газ һәм һава кудыру кебек яңа ысуллар куллану белән бәйле.

Кыйммәтле чималны җир өстенә чыгаруның төрле ысулларын кешеләр элек-электән кулланганнар. Әмма ничек кенә тырышмасыннар, бу ысуллар бер нигезгә кайтып калган: җир мае катламнарда булган гайрәт белән табигый режимда чыгарылган. Берике чакрым җир астында яткан катламнарга берничек тә тәэсир итә алмаган әле кеше. Җирнең үз юмартлыгы белән бер җайга өскә калыккан сыеклыкка канәгать булып яши биргән ул.

Ләкин совет галимнәре, инженерлары бу хәлгә битараф булып кала алмадылар. Нефть мәйданнарын эшкәртүне тизләтү һәм шул максат белән катламнарга ясалма тәэсир итү мәсьәләсе торган саен җитдирәк булып алга басты. Ниһаять, күп еллар буе түгелгән көчнең нәтиҗәсе булып, сыек ягулыкны катламнардан су, һава яисә газ белән кысрыклап чыгару ысуллары барлыкка килде. Шулай итеп, нефть чыгаруда икенче этап — өстән торып катламнарга тәэсир итү этабы башланды. Моның нәрсә бирүен ачыклау өчен үзебезнең күз алдындагы бер мисалны китерү генә дә җитә булыр. Әйтик, дөньядагы иң зур нефть чыганакларыннан берсе — Ромашкино ятмаларын элеккечә эшкәрткәндә, андагы җир маен алып бетерү өчен берничә гасыр кирәк буласын галимнәр алдан ук әйтеп куйганнар иде. Ләкин совет кешеләре моны башкача хәл иттеләр. Катламнардан нефтьне су белән кысрыклап чыгару әлеге срокны күп мәртәбә кыскартты. Нефть промышленностеның соңгы елларда гөрләп үсү хикмәте менә шунда, икенче этапның башлануында инде. Әнә шуның нәтиҗәсе буларак, соңгы 20 елда катламнардан нефть алу коэффициенты 0,20—0,30 дан 0,40—0,45 кә җитте.

Бу саннар безне шатландыра да, сискәндерә дә. Чөнки алар әле катламнарда бик күп хәзинәнең алынмый калуы турында да сөйлиләр бит. Җир куеныңдагы искиткеч байлыкның 40—50 проценты шунда мәңгелеккә ятып кала икән ләбаса.

Менә шуңа да партия һәм хөкүмәтебез, нефть чыгаруда икенче этапка таянган хәлдә, өченче этапны башлап җибәрү, ягъни катламнарга химик юллар белән тәэсир итеп, алардан нефть алу коэффициентын арттыру бурычын куйды. **«Нефтьне катламга ясалма тәэсир итү методларын кулланып чыгаруны,**— диелә КПССның XXIV съезды Директиваларында,— **бишьеллык азагына бөтен чыгару күләменең кимендә 75 процентына җиткерергә».**

Нефтьче инженерлар һәм галимнәр бу күрсәтмәне үзләренә маяк итеп алдылар һәм җир маен чыгаруны химияләштерү турында ныграк уйлана башладылар. Бу өлкәдә беренче карлыгачлар күренә дә инде. Димәк, нефть чыгаруда өченче этап башланды.

* * *

Катламнарның нефть бирүчәнлеге коэффициентын күтәрү — чыганакларны эшкәртүдә иң мөһим проблемаларның берсе. Бу мәсьәләдә инде галимнәр һәм инженерлар узган гасыр азагында ук уйлана башлаганнар. Күп кенә хезмәтләр язылган, байтак кына акыллы фикерләр әйтелгән. Соңгы елларда исә нефть чыгаруны интенсивлаштыру өстендә дистәләгән институтлар эшли. Алар инде катламнарга физик һәм химик тәэсир итүнең кайбер ысулларын таптылар һәм аларны тормышка ашыру өстендә эшләүчеләр инде бар. Илебезнең нефть районнарында катламнарга сыегайтылган газ, күбек кудыру, яисә аларга җылылык белән тәэсир итү ысуллары сынала. Безнең күршеләр — Башкортстан нефтьчеләре исә катламнарга кудырыла торган суга ОП-10, полиакриламид кебек күбекләнүче, юдыру сәләте яхшы булган матдәләр кушалар. Бу ысулларның әйбәт эффект бирүе расланды да инде. Тик алар әле бөтен нефть районнарына да таралып китә алмады.

Нефть алуны арттыру мәсьәләсе Татарстан галимнәрен дә байтактан кызыксындыра. Фәннәр кандидаты Иван Факанович Глумов җитәкчелегендәге катлам физикасы лабораториясе коллективы шушы өлкәдә күп эш алып барды һәм катламнарга химик тәэсир итүнең гаҗәп эффектлы юлын тәкъдим итте.

Катламнарга кудырыла торган суга кайбер химик матдәләр кушканда, аның тәэсир итү көче артканы галимнәргә күптән билгеле иде, әлбәттә. Күршеләре — Уфа институтындагы коллегаларының тәҗрибәсе белән дә хәбәрдар иде алар. Ләкин Глумов һәм аның иптәшләре бу юл белән бармаска булдылар. Чөнки кыскача ПАВ дип аталган ул

матдәләр дефицит һәм кыйммәтле, аларны куллану алынган нефтьнең үзкыйммәтенә сугачак иде.

Галимнәр арзанрак реагентлар эзләп карарга булдылар. Моның өчен сульфат (күкерт) кислотасы кулайрак булыр сыман тоелды. Безнең илдә ул аш тозыннан кала иң күп җитештерелә торган әйбер. Әйтик, 1970 елда ул 12 миллион тоннадан артыграк эшләп чыгарылды.

Сульфат кислотасына тукталуның сәбәбе ул гына түгел иде, әлбәттә. Әле 1962 елда ук институт галимнәре, лаборатория шартларында тәҗрибә ясап, катламнарга су кудыру алдыннан аңа концентрацияләнгән сульфат кислотасы кертсәң, нефть алу коэффициентының сизелерлек күтәреләчәген белделәр. Ләкин беренче тәҗрибәдән чыгып кына чаң сугу галимнәргә хас сыйфат түгел. Тәҗрибәләр тагын һәм тагын ясалды. Ниһаять, уникенчесеннән соң дөрес юнәлеш алуларына, сульфат кислотасының гаять перспективалы реагент икәнлегенә ышандылар алар. Озак эзләнүләрдән соң шул мәгълүм булды: сульфат кислотасы катламнардагы сыеклык белән реакциягә кереп үзе ук юдыруга сәләтле матдәләр барлыкка китерә. Бу исә нечкә генә каналлардагы җир маен этеп чыгаруда мөһим роль уйный. Өстәвенә, реакция нәтиҗәсендә зур күләмле җылылык бүленеп чыга, скважина забоенда температура 100 градуска күтәрелә. Нәтиҗәдә нефть тагын да сыеклана, аның агу сәләте арта. Болар нефть алуны арттыра торган өстәмә шартлар тудыра.

Шулай да зур калалардагы өлкәнрәк галимнәр белән киңәшеп карарга булдылар. Әмма Татарстан энтузиастларының ачышы галимнәр дөньясында яклау тапмады. Аерым шартларда нефть белән сульфат кислотасы кушылудан сумала сыман матдәләр барлыкка килә икән. Әнә шул «сумала» сыек ягулык юлларын тагын да томалар, нефть алуны киметер дип шикләнделәр кайберәүләр, һәм ачыш кәгазьдә килеш караңгы сейфның ерак почмагына салып куелды.

Ләкин лаборатория коллективы моның белән килешмәде. Галимнәр тәҗрибәне производство шартларында ясап карарга һәм нәтиҗәләренең дөреслеген чынбарлыкта расларга диган карарга килделәр.

Тик бу эш ансаттан булып чыкмады. Сынап карагач, сульфат кислотасының да шактый кыйммәткә төшүе мәгълүм булды. Галимнәр башына тагын уй төште. Уйлана торгач, нефть эшкәртү заводларындагы кислота калдыкларын тикшереп карарга булдылар.

Заводларда нефтьне эшкәрткәннән соң, кислотаның 90 процентлы концентрациясе дә кабат куллану өчен яраксыз булып кала икән. Җитмәсә, күп кенә предприятиеләр бу куркыныч реагентны кая куярга белми интегәләр. Ә андый калдыклар илебез буенча елга 250—300 мең тоннага җыела. Калдыклар саф кислотага караганда 3,5 мәртәбә арзанга төшә. Кабат-кабат тикшереп караулар аның катламнарга кудыруга тулысынча яраклы булуын күрсәттеләр.

Ниһаять, 1967 елның ноябрендә Бондюг якларындагы 453 нче номерлы скважинага 335 тонна сульфат кислотасы кудырылды. Ике ел узгач, Яңа Елховой мәйданындагы 31 нче скважинага аны 560 тонна керттеләр. Шул ук елны тәҗрибә Көнбатыш-Лениногорск мәйданындагы 6312 нче скважинада кабатланды.

Скважиналарда куныл-төнеп ятулар, төннәр буе баш күтәрмичә исәпләүләрдән күренгәнчә, катламнарга зур күләмнәрдә кислота кудырып ясалган кайма катламнарның нефть бирүчәнлеген 12—15 процентка арттыра, ягъни җир астына кудырылган кислотаның һәр тоннасы 20—30 тонна өстәмә нефть бирә.

Монысы инде галимнәрнең ныклы һәм авторитетлы сүзе иде.

Ләкин меңәр тонна белән исәпләнәчәк сульфат кислотасын, эшчеләр телендә әйткәндә «коточкыч йөкне» галимнәр үзләре кудырмаячаклар ич. Бу мәшәкатьле эшкә кем алыныр? Кем?!

* * *

Татарстан нефтьчеләре яңа бишьеллыкны үзгә шартларда башлап җибәрделәр. Хикмәт шунда: хәзер республикабызда нефть чыганакларын эшкәртүнең соңгы стадиясе башланды. Бу стадия өчен нефть чыгаруның стабильләшеп җитүе, продукциядә су-

ның күбәя баруы, скважиналарның күпчелеген механикалаштырылган юл белән эшләтә башлау, төп фондның бораулапып бетүе характерлы. Бер карагандa көннән-көн саега барган «кара алтын» чишмәләрен муллапдыру юллары юк та кебек.

Ләкин тәҗрибәле нефтьчеләр мондый чорның җитәсен белеп, сизеп тордылар. Нефть чыгаруны киметмәүнең дистәләрчә юллары алдан ук билгеләнгән иде. Максатка ирешү өчен, иң элек, әлбәттә, продукция составында суның арта баруына юл куймаска, димәк, коеларга килә торган су юлларын изоляцияләү эшләрен киң җәелдерергә кирәк. Шул ук вакытта катламнарга су кудыруны арттыра барырга, моның өчен исә катламнарның сыеклыкны кабул итүчәнлеген күтәрергә, ягъни су кудыру скважиналарын үзләштерүнең яңадан-яңа юлларын эзләргә. Шулар белән бергә тик торучы скважиналарны сафка бастыруны да дәвам иттерергә.

Бу эшләрнең барысы да скважиналарны капиталь ремонтлау бригадалары җилкәсенә төшә иде. Вәгъдәне үтәү, ягъни Татарстан җирендә берничә ел дәвамында 100 әр миллион тонна сыек ягулык алуның язмышы капиталь ремонтчылар кулында дисәң дә арттыру булмас. Скважиналарны капиталь ремонтлау цехларының эше ничек оештырыла, изоляция эшләре һәм су кудыру нинди методлар белән башкарыла — нефть язмышын менә шулар хәл итә иде.

Әнә шул таләпләр көн тәртибенә скважиналарны капиталь ремонтлау буенча специаллашкан махсус контора булдыруны куйды. Һәм андый контора оештырылды да.

Яшь коллективның берничә айлык эш нәтиҗәсе бу чараның мөһимлеген раслады. Оешу чорындагы мәшәкатьләргә һәм кыенлыкларга карамастан, эшчеләр капиталь ремонт темпларын арттырдылар, изоляция эшләренең эффектлылыгын күтәрделәр, скважиналарны үзләштерү һәм су юлларын томалауда яңа ысуллар куллана башладылар.

Көннәрнең берендә контора директоры, Татарстан нефте ветераны Виталий Николаевич Каменевны һәм баш инженер Виталий Кондратьевич Петуховны берләшмәгә чакырып алдылар. Сүз катламнардан нефть алуны арттыру турында барды. Фәннитикшеренү институты галимнәренең яңалыгы да телгә алынды. Контора коллективына бүгенге көн белән генә яшәмичә, алгарак карау кирәклеге дә әйтелде.

Киңәшмәдән соң контора җитәкчеләре уйга калдылар. Оешу чорының мәшәкатьләре бетмәгән, ремонт һәм изоляция эшләренең яңадан-яңа методлары сыналып ята — эш муеннан. Җыелышларда үзара киңәшкәч, ремонтчылар тәвәккәлләргә — скважиналарга сульфат кислотасы кудыруны да үз өсләренә алырга булдылар. Бишьеллыкның беренче елында ук катламнарга 12 мең 400 тонна кислота кертелде. Шуның нәтиҗәсендә мең тонна өстәмә нефть алынды.

Кәгазьдә яки телдән сөйләгәндә бөтен эш тә ансат кебек. Үзең тотындың исә бөтенләй башка. Кырыкмаса кырык мәсьәләне хәл итәргә, кыенлыкларны ерып үтәргә кирәк. Барыннан да элек, сульфат кислотасының көчле реагент булуы аптырашта калдырды. Мәгълүм булганча, ул үзе генә түгел, аның пары да, тәнгә тигәндә, яндырып ала. Киемнәрне, җиһазларны теткәләп бетерә. Аңлашыла: аны кудыру герметизацияләнгән юл белән башкарылырга тиеш. Кислотаның граммы да җиргә таммасын, ачыктишекләрдән пары чыкмасын — кешеләргә хәвеф-хәтәр килмәсен. Хәвефсезлек дигәннән, кислота белән эшләгәндә махсус киемнәр, противогазлар, күзлекләр, битлекләр — тагын әллә нәрсәләр дә кирәк булачак бит әле. Җитмәсә, мондый көчле кислотаны кудыру өчен махсус агрегатлар да юк хәзергә.

Әнә шул бихисап шартлар, санап очына чыга алмаслык «кирәк»ләр очсыз-кырыйсыз мәшәкатьләр тудырдылар. Әмма чигенү турында сүз булуы да мөмкин түгел иде.

Ул көннәрне баш инженер бүлмәсе сугышчан штаб урнашкан блиндажны хәтерләтә иде. Бирегә берәмләп тә, төркем-төркем дә инженерлар керә, кызу бәхәсләр бара. Кемнәрдер ашыгып чыга һәм машиналарга утырып каядыр кабалана. Баш инженер өстәленә төрле сызымнар төшерелгән, тәкъдимнәр язылган кәгазьләр җыела. Аларның кайберләре кайтарып бирелә, кайсылары җентекләп тикшерү өчен бер читкә куела.

Техника бүлеге начальнигы Адольф Константинович Арсеньев бүлмәсендә генә чагыштырмача тыныч иде бу көннәрне. Анда — бер төркем рационализаторлар: башлары сызымнарга иелгән, кулларда исәпләү линейкалары. Бүлмә хуҗасы А. К. Арсеньев, директорның технология буенча ярдәмчесе М. Т. Быков, катламнарны гидравлик

ярдыру участогы начальнигы К. А. Климов сульфат кислотасын герметик кудыру технологиясенең сызымын барлыкка китерделәр.

Рационализаторлар тәкъдиме буенча, һәрберсе 100 әр кубометр сыйдырышлы зур чаннардан — булитлардан торган поездлар булдырырга, аларга тутырылган кислота һава басымы астында агрегатларга бирелергә тиеш. Ә насослардан соң юл — җир астына.

Болай карап торуга ансат кебек иде бу эш! Әнә ул инде кәгазьгә төшерелгән: булитлар урынында, алар трубалар белән тоташтырылган, контроль-үлчәү приборлары, саклагыч клапаннар да куелган — бар да уйланганча. Әмма болар бары да кәгазьдә генә шул әле. Аны тормышка ашыру өчен каяндыр булитлар табарга, иләмсез зур чаналар ясарга, дистәләрчә трубаларны бөгәргә, ялгарга, аларның барын да сынап карарга — тагын әллә ниләр эшләргә кирәк иде. Димәк, электросварщикларны, слесарьларны төп эшләреннән — бораулау җиһазлары ремонтлаудан аерырга, болай да начар тәэмин ителгән капиталь ремонт бригадаларын «ялангач» калдырырга туры килә. Ә дәүләт планы? Яңа бишьеллыкның беренче елында кимендә 1320 скважина ремонтлыйсы бар ич. Планнан тыш 300 скважинаны сафка бастырырга дигән вәгъдә дә үзен искә төшереп тора. Шундый вакытта коллектив каушап калмасмы, бөтен эш сүтелмәсме?

Әнә шундый икеләнүләр кемнең генә башыннан узмады икән ул көннәрдә. Шулай да ремонтчыларның җиңүгә ышанычлары зур, дәрт һәм гайрәтләре җитәрлек иде. Кешеләр үзләренең ихтыяр көченә һәм фидакарь хезмәтләренә исәп тоттылар һәм ялгышмадылар.

* * *

Әйтерсең дөньяның кендеге әлеге чаннарда — булитларда гына, конторада көннең көнендә сүз шулар турында барды. Ләкин якын-тирәдәге предприятиеләрнең берсендә дә моңа яраклы чаннар табылмады. Контора вәкилләре көн саен йөзләрчә чакрым җир урадылар, күрше шәһәрләрдәге предприятиеләргә барып гозерләрен сөйләделәр, ялындылар, үтенделәр. Тик барысы да нәтиҗәсез калды: чаннар я хуҗаларның үзләренә кирәк, яисә яраксыз иделәр.

Шундый көннәрнең берендә берләшмәдән яңа адрес хәбәр иттеләр. Миңлебай газ-бензин заводының иске участогында зур-зур чаннар буш ята икән. Ремонтчылар шул сәгатьтә үк заводка юл алдылар.

Байтак сөйләшүләр, кәгазьләр рәсмиләштерү һәм мәшәкатьләрдән соң, беренче булит ремонт-техника цехының ишек алдына кайтарып куелды. Әле скважинага илткәнче аның җиһазларын үзгәртеп ясыйсы, җиң сызганып эшлисе бар иде.

Булитны хәзерләү эшенең ремонт-механика цехына йөкләнүе аяз көнне яшен үйнагандай булды. Әле яңа оешып, аяклана башлаган 30—40 кешелек бу коллектив булган станокларын да урнаштырып бетермәгән, цехка дип билгеләнгән иске бина да ремонтланмаган иде. Бригадалардан килгән кочак-кочак заявкалар белән нишләргә аптыраган цех начальнигы Исхак Дәүләтбаев, эшкә әле генә урнашкан өлкән инженер Иван Карчин бер мәлгә өнсез калгандай булдылар.

Шулай да өскә ишелеп төшкән таудай эштән куркып торыр чак түгел иде. Бөтен контора коллективының күзе шушы нәни цехка төбәлгән, өметләр шуңа бағланган. Читтән ярдәм көтәргә урын юк.

Сәлам эскертен хәтерләткән булит янында тимер чыңы яңгырады, яшен яктысы чыгарып утлар җемелдәде. Электросварщик Александр Есипов, Михаил Иванов, слесарьлардан Равил Шәрифуллин, Евгений Аксенов һәм Степан Ильиннар бу тимер тавының җиһазларын ботарлый, алар урынына үзләре ясаганнарын — технологик схема буенча кирәкләрен монтажлый башладылар. Кешеләр әйтерсең хәлсезләнеп калган борынгы кәлтә-динозавр янындагы кырмыскалар иде. Ай-һай, эше күп, яңа нәрсә, дип тормадылар, янгын сүндерүчеләрдәй җитез хәрәкәт иттеләр. Хезмәт ыгы-зыгысы бер генә минутка да туктамады.

Әмма җиһазларның барын да бирәдә — скважинадан еракта урнаштырып бетерү

мөмкин түгел иде. Куәтле машиналар булитны Көнчыгыш Сөләй мәйданындагы 10186 нчы скважинага алып киттеләр.

Шуннан соң ремонт-механика цехы басуга күчкәндәй булды. Слесарьлар белән электросварщиклар гына түгел, цех начальнигы белән өлкән инженер да шунда кунып-төнеп яттылар. Барысы да беренче мәртәбә эшләнә, күчермәләр дә юк, күп кенә нәрсәләрне кабат һәм кабат ясарга туры килде.

Ничек кенә булмасын, атна-ун көн дигәндә булит урынына баскан, җиһазлары һәм контроль приборлары да үз урыннарын алган иде. Ерак юлдан кислота кайта башлады.

Конторада киеренкелек артты, зур сынау көне якынлаша иде. Башлап җибәрү өчен бер булиттагы 160 тонна кислотаны гына кудырып карарга булдылар.

...Нидер дәулап төн буе бәрелеп-сугылып йөргән февраль җиле таң белән тагын да көчәйде. Ул кабалана-кабалана карны бер урыннан икенчесенә куып йөртте, юлларны күмеп китте. Шулай да нефть мәйданнарындагы хәрәкәтне туктата алмады. Минзәләбаш авылы янындагы тау башында җанлылык аеруча көчле иде. Кызыл флаглар белән уратып алынган мәйдан эчендә зур-зур агрегатлар, кешеләр. Тиктормас бульдозерлар кар өемнәрен һаман читкәрәк этәрәләр.

Скважина ремонтлый торган мачта мәйдан уртасында мәһабәт басып тора. Аны ярым боҗрага урап, агрегатлар тынып калган, мондарак коточкыч йөге белән булит горурланып утыра. Читтәрәк культбудка, вагон-ашханә, автомобильләр. Скважина янында да, агрегатлар тирәсендә дә кешеләр кайнаша. Алар әйтерсең лә яңа гына башка планетадан очып килгәннәр. Һәркайсы тупас резина киемнән, башларында каска, маңгайларындагы зур күзлекләр аларны очучыларга охшата. Кислота тирәсендәгеләр исә противогазлар киеп алганнар. Контора директоры белән баш инженер да башкалардан аерылмыйлар. Күнекмәгән киемнән килешсез атлап, мәйданның әле бер, әле икенче башына чыгалар.

Ниһаять, катламнарны гидравлик ярдыру участогы начальнигы Николай Климов контора җитәкчеләре янына килде:

— Бар да әзер.

— Хәерле сәгатьтә,— диде Каменев, тыныч кына.— Башлагыз.

Дизельләр «йөрәк кагып» куйды, аларга насослар шавы кушылды. Ләкин системада әле кислота түгел, солярка иде. Бөтен трубаларны һәм җиһазларны югары басым белән сынап карамый торып, алардан кислота кудыру ярамый иде.

Аккан-тамган урыннар ямалды, мәйданда процесста катнашучылар гына калды. Кулына тавыш көчәйткеч тоткан Николай Климов «капитан күперчегенә» менеп басты. Биредә хәзер фәкать ул хуҗа.

Менә, Николай кушуы буенча, скважинаның үзәк япкычын ачтылар. Компрессорлар пошкырды, агрегатларның берсе әкрен генә эшли башлады. Приборлардан күренгәнчә, скважина авырсынып булса да реагентны кабул итә башлады. Бераздан агрегатларның икенчесе хәрәкәткә килде. Аннан өченчесе... дүртенчесе.

Минутлар үткән саен, кешеләрдә киеренкелек тә кими бара. Агрегатлар тигез эшли, кислота су сыман ансат кына җир астына ага да ага.

Төштән соң скважинага «Татнефть» берләшмәсе начальнигы Ә. Валиханов, баш инженер В. И. Грайфер һәм нефть чыгару промышленносте министры В. Д. Шашин килеп төштеләр. Контораның баш инженеры В. К. Петухов кунакларны кислота кудыруның принципиаль схемасы белән таныштырды. Яңалыкның авторы И. Ф. Глумов процессның асылы турында сөйләде. Министр технологиянең үзенчәлекләре, яңалыктан көтелгә торган эффект белән кызыксынды, эшчеләр һәм инженерлар белән сөйләште. Мондагыларга уңышлар теләп, алар үз юлларына китеп бардылар.

Кышкы кыска көн тәмамланганны белдереп, куәтле прожекторлар кабынды, янәшәдәге урманнар караңгылыкта югалды. Биредә исә бар да элеккечә торып калды: агрегатлар гүли, компрессорлар пошкыра. Ә кешеләр тынгысызланып нәтиҗә көтәләр.

Кинәт агрегатлар тынып калды. Көтеп торучылар ни булганын аңларга өлгермәде, скважина ягыннан тавышлар яңгырады:

— Беттеl

Бар да агрегатларга ташландылар, шау-гөр килеп берсен берсе җиңү белән тәбрикләделәр.

* * *

Иртәгесен баш инженер В. К. Петухов бүлмәсенә процесста катнашучыларның бөтенесе диярлек җыелды. Беренче тәэсирләр үткән, киерелгән нервлар бераз йомшый төшкән, беренче операция турында салкын баштан иплэп сөйләшергә, тиешле нәтиҗә ясарга мөмкин иде.

Авыз тутырып шуны әйтергә була: беренче процесс технологик схеманың максатка яраклы һәм ныклы булуын күрсәтте. Кайсы яклап карагаңда да аңа сүз килерлек түгел. Ләкин кимчелекләр дә җитәрлек иде әле. Әйтик, төнлә эшләү өчен яктылык җитми иде. Агрегатчылар белән җитәкче арасында элемтә шәптән түгел, кием-салым һәм саклану средстволарын ишәйтәсе, ышанычлыракларын табасы бар...

Шунысы яхшы: кем әйтмешли, төрле булса да, беренче коймак әйбәт пешкән иде. Димәк, коллектив бу зур эшне ерып чыга ала!

Янәшәдән 10187 нче номерлы скважинага беренче булитны күчергәнче, яңа урынга башкалары да килә башлады. Аларны монтажлауга, автоколоннаның иң булдыклы шоферлары В. Ильин, М. Шәйдуллин, Н. Зайцев һәм башкалар Кама буеннан кислота ташый башладылар. Бу юлы аны 680 тонна күләмендә кудыру планлаштырыла иде.

Менә көне дә җитте. Николай Марков, Сабир Минхәеров, Георгий Титов, Махиан Сәгыйров һәм башкалар агрегатларын тагын ерактагы тау түбәсенә кудылар. Скважина янында тагын кешеләр кайнады, Андрей Ильинның компрессорлары пошкырды, моторлар гүләде. Хезмәт шавы таңга кадәр дәвам итте. Таң яктылыгында елмаешкан йөзләр бу юлы да процессның әйбәт, хәвеф-хәтәрсез узуын раслыйлар иде.

Шуннан бирле иләмсез зур бу чаннар нефть мәйданнарының берсеннән икенчесенә күчеп йөри башладылар. Алар бер скважина янында атна-ун көн генә торалар да икенчесенә күчәләр.

Катламнарга яңача, химик юл белән тәэсир итү бөтен нефть краенда ыгы-зыгы тудырды. Процесс булачак скважинага берәмләп тә, төркем-төркем дә нефтьчеләр килә. Татарстандагы барлык нефть һәм газ чыгару идарәләреме҃н дә вәкилләре бар иде алар арасында. Ул да түгел, конторага бер-бер артлы заявкалар килә башлады, һәр идарә процессны күбрәк аның промыселларында үткәрүне сорый иде. Кислота кудыру үз территорияләрендә барган идарә вәкилләре исә шунда кунып яталар, ремонтчыларга теләсә нинди ярдәмгә әзерләр. «Азнакайнефть» идарәсенең 4711 нче скважинасында узган төн аеруча хәтердә калган.

...Эш көйле генә бара, агрегатлар тигез эшли. Төн уртасы авыр йөк булып керфекләрне баса. Әмма «Азнакайнефть» идарәсенең баш инженеры Евгений Игнатьевич Старов белән баш геолог Виктор Иванович Беженцевның кайтып ял итәргә исләрендә дә юк. Алар Николай Климовны уртага алганнар да һаман кислота турында сорашалар. Анда бернечә көн элек кенә 800 тонна кислота кудырылган иде.

— Беләсезме,— ди Е. И. Старов,— ике-өч көннән соң янәшәдәге скважиналардан нефть алу бернечә мәртәбә артты. Дөрес, мин моны нәкъ менә кислота ярдәме, дип әйтә алмыйм. Катламга кудырылган теләсә нинди сыеклык тәэсирсез калмый. Скважинаның суны ике-ике ярым мәртәбә күбрәк кабул итә башлавы — монысы инде кислота хикмәте. Ә артык кудырылган һәр кубометр су өстәмә нефть диган сүз ул. Шуңа да кислота кудыруга биш куллап ябыштык без.

Яңалык Татарстанда гына шау-шу тудырып калмады, аның турында хәбәр тиз арада бөтен Союзга таралып өлгерде. Кислота кудыру илебездә беренче тапкыр башкарыла иде шул әле.

«Лениногорскнефть» идарәсенең 4087 нче скважинасы. Бөтен нәрсә әзер, агрегатларны менә җибәрәбез дип торганда, мәйдан кырыена бөтенләй ят номерлы автомобиль килеп туктады. Аннан таныш булмаган кешеләр төшеп, скважинага таба атладылар. Тик эшчеләр аларны шунда ук туктаттылар.

— Без Куйбышевтан,— дип акландылар кунаклар,— яңалык күрергә килдек.

Ләкин бу юлы татарлар традициягә хыянәт итеп, кунакларга урынны түрдән бирмәделәр. Алар процессны читтән генә карап тордылар. Аның каравы, соңыннан культбудка түренә утырып сызымнар белән таныштылар, иркенләп сораштылар.

Су кудыру скважиналарын кислота белән эшкәртү Башкортстан, Ухта һәм башка районнарның да нефтьчеләрен кызыксындырды. Әйе, яңалык предприятиенең исемен,

данын ерак-еракларга алып китте. Ул гына да түгел, контора язмышына төзәтмә кертте. 1971 елның июненнән ул катламнардан нефть алуны арттыру һәм скважиналарны капиталь ремонтлау идарәсе итеп үзгәртелде.

* * *

Октябрьның 54 еллыгы якынлашкан көннәрдә идарә коммунистлары чираттагы җыелышларына килделәр. Трибунага баш геолог Әнәс Кәлимуллин күтәрелде:

— Быелның узган ун аенда,— диде ул,— катламнарга 10 мең тоннадан артыграк кислота кудырылды. Нәтиҗә әйбәт һәм шатлыклы. Скважиналар суны элеккегедән 1,5—1,7 тапкыр күбрәк «йота» башладылар. Димәк, бу өлкәдә алдыбызга куелган бурычның үтәләчәге шөбһәсез. Шунысы куанычлы, кислота белән мавыгу төп эшкә, ягъни скважиналар ремонтлауга, һич кенә дә зыян китермәде. Ун айда 1142 скважина сафка бастырылды, шуның 27 се планнан тыш.

Баш геологның докладында, асылда, коллективның бишьеллык заданиеләрен уңышлы үти баруы турында рапорт иде. Шулай да коммунистлар үзләреннән канәгатьләнеп утырмадылар. Башкарылган эшнең нефть чыгаруның өченче этабына әлегә беренче адымнар гына булуын яхшы аңлыйлар иде алар. Бишьеллык ахырына кадәр барысы 90 мең тонна кислота кудырырга, 100 скважинаны төрле матдәләр белән куертылган су белән эшкәртергә, битум ятмаларын эшкәртүнең яңа методларын табарга кирәк. Бу эшләр исә скважиналарны ремонтлауның үсә барган планына зыянсыз башкарылырга тиеш. Кислота кудыру эшләрен тагын да яхшырак оештыру мәсьәләсе бигрәк тә әһәмиятле. Чөнки әлеге технологик схема үзен аклаcа да, шактый кимчелекле. Ул катлаулы. Гадирәк схема эшлисе бар. Булитларны күчереп йөртү гаять күп вакытны ала. Аларны тәгәрмәчләр өстенә кую көн үзәгенә басты. Кислотаның үзен ташу да әлегә кадәр зур проблема булып тора. Коммунистлар нигездә менә шулар турында сөйләштеләр.

Әйе, Татарстан нефтьчеләре нефть чыгаруның өченче этабына беренче сукмакны салдылар. Әмма ул сукмак җиңел, такыр олы юлга әверелгәнче шактый эшләр башкарасы бар әле.

**Харис Якупов,**
РСФСРның халык художнигы,
Татарстан художниклар союзы
идарәсе председателе.

# ТАТАРСТАННЫҢ СЫНЛЫ СӘНГАТЕ

Бөтен дөньяны шаулаткан Октябрь идеяләре тормышыбызга өр-яңа сәнгать, җиңүче халык сәнгатен алып килде. Формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик татар совет сәнгате дә башка дус халыкларның сәнгатьләре белән идея бердәмлегендә үсте һәм үсеп килә. Менә ярты гасырдан артык инде Татарстан художниклары, бөтен көчләрен һәм талантларын бөек Ленин эшенә багышлап, илебезнең башка сынлы сәнгать осталары белән бер сафта атлыйлар, яңа җәмгыять төзү, аның якты идеалларын ныгыту, коммунизм төзүче халык батырлыгын сәнгатьчә типиклаштырып күрсәтү эшенә актив катнашалар.

Идел буендагы автономияле республикаларның, шул исәптән, Татарстанның да экономик, социаль һәм культура ягыннан үсүе ленинчыл милли политиканың зирәклеген һәм дөреслеген раслаган матур дәлил булып тора.

Ислам дине сурәт ясауны тыйганга күрә, революциягә кадәр татар халкының сынлы сәнгате булмаган диярлек. Бөек Октябрь революциясе халыкның иҗат көчләрен иреккә чыгарды, рәссамнар эшенә чиксез киң мәйдан ачты.

Совет Татарстанының сынлы сәнгате рус сәнгате белән иҗади аралашып, иҗади дуслыкта туды һәм ныгыды. Аның юл башында торган күренекле рус художникларыннан Н. Фешин һәм П. Веньковны күрсәтергә мөмкин. Бу изге гомумхалык эшенә П. Радимов, В. Тимофеев, М. Сутюшев, Н. Сокольский, П. Сперанский кебек художниклар зур өлеш кертте. Яшь республиканың сынлы сәнгате художникларыбыз Б. Урманче, Г. Арсланов, С. Ахун, М. Абдуллин, Б. Альменовлар иҗатында уңышлы рәвештә дәвам иттерелде.

Татарстанның сынлы сәнгате тарихында егерменче-утызынчы еллар реалистик традицияләргә ныклы нигез салыну, коллективның формалашуы, үзенчәлекле иҗади эзләнүләр чоры дип билгеләп үтелә. Ә инде кырыгынчы еллар — Ватаныбызның бәйсезлеген саклап калучы, җимерелгән авылларны һәм калаларны торгызучы халкыбызның фронтта һәм тылда зур батырлык күрсәткән еллары — иҗади хәрәкәтнең аеруча активлашуы белән характерлы. Чөнки бу елларда заман үзе сәнгать әһелләре каршына героик эпоханы бөтен бөеклеге, бөтен тулылыгы белән ачык итеп чагылдыру бурычын куйган иде.

Безнең сынлы сәнгатебез кырыгынчы елларда сан ягыннан да, сыйфат ягыннан да бик нык алга китә, хәтта, әйтергә кирәк, зур сикереш ясый. Бу чорда коллективка иҗат дәрте белән янган фронтовиклар кайта, яшьләр көч сыный. Әкренләп иҗади үзәк оеша. Омтылышлар киңәя, идеялелек үсә, эмоциональ яңгыраш көчәя, зур күргәзмәләрдә беренче уңышлар яулап алына.

Тарих һәм бүгенге көн — кырыгынчы-алтмышынчы еллар художникларының полотноларында чагылыш тапкан төп темалар менә шулар. Л. Фәттахов «Колхоз симфониясе» дигән зур әсәрен иҗат итә, В. Кудelькин һәм С. Ротницкий төрле жанрдагы кызыклы әсәрләр язалар, замандашларыбызның портретларын ясыйлар. А. Бурлай, М. Усманов, М. Хәйретдинов «Кара алтын» ягын, шул якның хезмәт батырларын сурәтлиләр. А. Родионов үзенең картиналарында Бөек Ватан сугышының кырыс чынбарлыгын тасвирлый. Ә Н. Кузнецов исә илебезнең яңа төзелешләрен гәүдәләндерә. Г. Рәхманкулова, К. Максимов, С. Лывин, А. Прокопьевларны Ватаныбызның иксезчиксез киңлекләре, аның искиткеч матур табигате илһамландыра, В. Зуевка натюрмортлар тынгылык бирми.

Әгәр дә республикабыз художникларының соңгы еллардагы эшләренә генә күз салсак та, аларның иҗат дәрте белән янып яшәгәннәрен күрербез. Безнең иң яхшы әсәрләребез В. И. Ленинның тууына 100 ел тулуга багышланган Бөтенроссия, ә соңрак Бөтенсоюз күргәзмәләренә куелды. Безнең художникларыбыз шулай ук «Тынычлык сагында» дигән Бөтенсоюз (1965 ел), Бөтенроссия яшьләр (1967 ел), Бөтенсоюз сатира (1970) күргәзмәләрендә, «Сатира тынычлык өчен көрәштә» исемле Халыкара күргәзмәдә катнаштылар.

Зона күргәзмәләре оештыра башлау Идел буе художниклары һәм, гомумән, Идел буе сынлы сәнгате тормышында әһәмиятле вакыйга булды. «Зур Идел» зонасына тугыз өлкә һәм биш автономияле республика художниклары керә.

1967 елда Волгоградта оештырылган зона күргәзмәсенә Татарстаннан 50 сәнгать остасы барды. Күргәзмәгә аларның 130 хезмәте куелды. Ә Ульяновск шәһәрендә уздырылган юбилей күргәзмәсендә (1970 ел) безнең 40 авторыбызның 82 әсәре игътибар үзәгендә булды. Бу — бөтен күргәзмәнең уннан бер өлеше дигән сүз. Күргәзмәгә катнашучылар һәм экспонатлар саны буенча Татарстан художниклары бары тик Горький өлкәсе художникларыннан гына калыштылар. Күрәнебезчә, татар сынлы сәнгате хәзер республика чикләреннән чыкты һәм күп милләтле Россия Федерациясендә күренекле урын тота.

Әле күптән түгел генә безнең сәнгать көчләребез Казанда гына тупланган булса, хәзер инде художество коллективлары Бөгелмәдә, Түбән Камада, Зеленодольскида, Чаллыда, Алабугада һәм нефть районнарында барлыкка килде. Бүгенге көндә Художниклар союзы һәм худфондның Татарстан бүлеге үз эшләрен бөтен республика буенча җәелдерделәр.

Татарстанда сынлы сәнгатьтән махсус белем бирү зарланырлык түгел. Махсус уку йортларының ишекләре сәләтле яшьләр өчен һәрвакыт ачык. Мондый уку йортлары арасында бигрәк тә Казан һәм Лениногорск художество училищелары игътибарга лаеклы. Моннан тыш, республикада дистәгә якын художество мәктәпләре эшләп килә. Ә үзешчән художниклар өчен клублар, культура йортлары каршында сынлы сәнгать түгәрәкләре оештырылды.

Союзда художниклар саны Казан художество училищесын һәм башка уку йортларын тәмамлаган сәләтле яшьләр хисабына елдан-ел арта бара. 1971 елда гына да союзга 14 кеше кабул ителде. Татар совет сынлы сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен безнең коллективның 19 художнигы хөкүмәтебезнең мактаулы исемнәренә лаек булды.

В. И. Ленинның тууына 100 ел, Татарстан төзелүгә 50 ел тулуга багышлап үткәрелгән күргәзмәләрдә Татарстан художниклары сәяси һәм иҗади өлгергәнлеккә зур сынау уздылар, ленинизм эшенә чын күңелдән бирелгәнлекләрен күрсәттеләр.

В. И. Ленин күргәзмәсенә хәзерләнгәндә Ленин темасы, әлбәттә, безнең төп темабыз иде. Сүз уңаенда әйтеп китәргә кирәк, Ленин темасы Татарстан художникларын элек-электән илһамландырып килә. 1918 елда ук инде Ленин образына беренчеләрдән булып Н. Фешин мөрәҗәгать итә. Ә 1934 елда Н. Сокольский үзенең картиналарында Ленинны хезмәт ияләренең юлбашчысы, революция трибуны буларак күрсәтүдә уңышлы адым ясый. Х. Якупов белән Л. Фәттаховның «В. И. Ленин Татарстан АССР төзү турындагы декретка кул куя» дигән әсәре (1950 ел) күтәрелгән темасы буенча да, образның гәүдәләнеше буенча да татар совет сынлы сәнгате дөньясында күренекле урын тота дип бәяләнде. Художник В. Тимофеев гомеренең соңгы көннәренә кадәр Ильич образын иҗат итте. И. Хәлилуллинның «В. И. Ульяновның беренче

тапкыр кулга алынуы», А. Прокопьев һәм М. Семеновның «Кокушкинога почта» дигән әсәрләрендә Ленин образы уңышлы иҗат ителә. Ильич образын С. Богатырев, С. Ахун, Б. Урманче, И. Новоселов, П. Макаров, Н. Тузов скульптурада гәүдәләндерәләр.

Ленин темасына мөрәҗәгать иткән художникларның соңгы еллардагы иҗатында психологик тирәнлеккә, гомумиләштерүгә омтылу сизелә. Ленин образын иҗат итү буенча инде күптәннән эшләп килгән художниклардан Л. Фәттахов, М. Семенов яшь Ильичны бөек үзгәрешләр алдыннан, Идел ярында, гади халык арасында күрсәтәләр. Аларның «Протест» һәм «Шушенскоеда» дигән уңышлы картиналары бар. Мәкалә авторының «Пролог» исемле әсәре дә Ильичның яшьлегенә багышланган. Бу әсәр Володя Ульяновның Казан университетында беренче сугышчан чыныгу алуы хакында сөйли. Г. Мелентьевның «Ана» картинасында Ильичның әнисе М. А. Ульянова образы игътибарны җәлеп итә. С. Лывин иҗатында исә Ленин темасы Россия табигате, Россия пейзажы белән бергә үрелеп бирелә. Бу художникның полотноларында Кокушкино һәм аның тирә-ягы киң чагылыш тапкан. Графикада Ленин темасына М. Мавровская, Т. Зуева, Л. Потягунин, Кочунов кебек художниклар мөрәҗәгать итә, скульптурада А. Бәширов көч сынап карый.

Ленин темасы — гаять катлаулы, җаваплы тема. Теманы дөрес һәм төгәл чишү художниктан иҗади киеренкелек кенә түгел, әхлакый сафлык, хезмәткә чын мәхәббәт, ялкынлы патриотизм хисе, кыюлык таләп итә, художникның талант дәрәҗәсе, дөньяга карашының дөрес һәм фәнни булуы, чынбарлыкның катлаулы процессларында югалып калмыйча, зирәк һәм тугры фикер йөртүе алгы планга куела.

Революция юлбашчысының образын тулырак итеп ачу, совет халкының фидакарь хезмәтен бөтен катлаулылыгы һәм бөеклеге белән күрсәтү өчен, художник тормыш дөреслегенә аеруча сизгер булырга тиеш. Көнчыгышның борынгы рәссамнары арасында кызык бер гадәт булган, диләр. Алар, яңа бер хезмәтләрен элекке даннарыннан чыгып бәяләмәсеннәр өчен, еш кына исемнәрен алыштыра торган булганнар. Кайчандыр билгеле булып та, исемнәрен алыштыргач билгесез калган художникларга, халык арасында яңадан танылганчы, дөреслекне яңадан тапканчы, батырларча алга барырга һәм бик күп газаплар кичерергә туры килгән. Легенданың асылында художник бөтен гомере буе дөреслеккә омтылырга, тормыш дөреслеген эзләргә тиеш дигән фәлсәфи фикер ята. Ә бу фикер коммунизм төзү өчен кискен көрәш барган бүгенге көндә аеруча актуаль яңгырый.

Күп кенә художникларның хезмәтләренә очраклы штрихлар килеп керүе, материалның чын сәнгать әсәре булып эшләнеп җитмәве, Ленин образының инде моннан күп еллар элек кулланылган буяулар, төсләр, алымнар белән иҗат ителүе әлеге легенданың хаклылыгын тагын бер кат раслый. Ә бит халык күңелендә Ленин турындагы уйлар көннән-көн тирәнәя, көннән-көн яктыра бара. Димәк, шулай булгач, художникларның бурычы — кадерле Ильич образын нәкъ әнә шул, халык күңелендәгечә ачык итеп, якты итеп гәүдәләндерү, аның тормышы, эшләре турында тарихта калырлык, совет ленинианасының алтын фондына керерлек әсәрләр тудыру.

Художникларыбызны Ленин образы белән беррәттән татар халкының үткәнен, аның омтылышларын, уй-теләкләрен чагылдыручы тарихи-революцион тема кызыксындырып килә. Бу тема художниктан шулай ук фәлсәфи фикер йөртүне, фәнни анализ ясарга өйрәнүне, иксез-чиксез тарихи фактлар арасыннан иң әһәмиятлесен, иң типик дигәнен сайлап алып, сәнгатьчә синтезлаштыруны таләп итә. Мәсәлән, художник В. Куделькин «М. И. Калинин Татарстан крестьяннары арасында» дигән эпик полотносына уңышлы композиция тапканчы, озак кына эзләнә, озын иҗат юлы уза. И. Хәлилуллов та, егерменче-утызынчы еллардагы татар авылы тормышы һәм коллективлашу темасына мөрәҗәгать итеп, бик күп иҗат газаплары кичергәннән соң гына колхозларда беренче буразналар сызучы татар коммунистларын һәм авыл ярлыларын чын сәнгать югарылыгында сурәтли алды.

Буыннар дәвамын сурәтләүче художнигыбыз И. Язынин халыкның үткәнен һәм бүгенгесен революцион үсештә сурәтләп килә. Аның «Әтиләр юлы белән», «Ант итәбез» дигән агитплакатларында бу бигрәк тә ачык күренә.

Урта буын художникларыбыз М. Хәйретдинов, Н. Бикташев, И. Рәфиков һәм башкалар герой шагыйрь Муса Җәлил образын калку итеп сурәтлиләр. Яшь художник

В. Федоров халыкның героик үткәнен, батырлыгын, патриотизмын, чит ил илбасарлары белән көрәштә үз көченә нык ышануын оста гәүдәләндерә. В. Зелинский «Тарих безнең белән» дигән график әсәрләр сериясендә сугышка һәм реакцион көчләргә каршы чыга. Мин соңгы хезмәтемдә — «Ирекккә очу» дип аталган дүрт кисәкле композициядә — Советлар Союзы Герое Михаил Девятаев батырлыгын сынлы сәнгатьтә гәүдәләндерергә тырыштым. Максатым — халыкның героик узганын, совет кешеләренең кыюлыгын, фидакарьлеген, гуманизмын күрсәтү иде.

Күп кенә художникларыбыз яшьләрне әтиләребезнең данлы традициясендә тәрбияләргә омтылалар. Гражданнар сугышы һәм Бөек Ватан сугышы елларында халкыбыз күрсәткән батырлык төрле жанрларда чагылыш таба.

Тарихи-революцион темага уңышлы яңа эзләнүләр алып барыла. Ләкин уйланган материалны югары сәнгать әсәре итеп башкарып чыгу өчен художникларыбыз күп көч куярга тиешләр әле. Күренекле совет художнигы П. Корин болай дигән иде: «Безнең хисләребез, фикерләребез, идеяләребез никадәр генә изге һәм бөек булмасын, әгәр дә дөрес әйтелмиләр икән, алар гамәлгә ашмаячак, алар яшәмәячәк».

Бүгенге көн проблемасы — Татарстан художниклары иҗатында иң актуаль тема. Бу өлкәдә иң актив эшләүче художникларыбыз, минемчә, В. Кудelькин белән Е. Симбирин. Алар үз геройларын халыктан, тормыштан эзлиләр һәм һәрвакыт диярлек уңышка ирешәләр. Мәсәлән, Е. Симбирин Социалистик Хезмәт Герое Сәрвәр Нәфикова портретын язганда кызыклы гына иҗади табышка юлыккан. Ул героиняның хатын-кызлар арасында сирәк очрый торган профессия вәкиле — тимерче булуына артык басым ясамый, ә бәлки аның эчке дөньясын, кешелек сыйфатларын мөмкин кадәр тулырак итеп ачып бирергә тырыша. График Э. Ситдыйков «Кызыл байрак» кешеләре сериясендә гади колхозчыларның физик ныклыгын, рухи матурлыгын ачып бирә алды; художник И. Зарипов «Өйдә» картинасында яшь ана образын поэзия югарылыгында гәүдәләндерде. В. Павловны нефтьчеләрнең данлы хезмәте, күзәтүчән художник В. Майоровны кеше күңеле, аның таб гате, психологиясе дулкынландыра.

Портрет жанрында эшләүче авторларның күбесе хезмәт кешесен гәүдәләндергәндә купшы бизәкләр кирәкмәгәнлеген, хезмәт кешесе физик һәм рухи яктан бертигез дәрәҗәдә үсүе белән матур икәнлеген яхшы аңлап иҗат итәләр.

Бер төркем художникларыбызны халык әкиятләре, героик дастаннар, легендалар рухландыра. Бу өлкәдә графиклар аеруча уңышлы эшләп киләләр. Мисалга Б. Альменов, Л. Коньюранд, В. Карамышев, Т. Хаҗиәхметов, И. Әхмәдиев, Р. Кильдебеков һәм химиклар культура сарае өчен бакырга чукып ясалган «Игелек батырлары» дигән хезмәт авторы Е. Киселеваны күрсәтергә була.

Без еш кына сәнгатьтә миллилек һәм интернациональлек турында бәхәсләшәбез. һәм һәрвакыт милли форма үзенең башлангычын халык иҗатыннан, фольклордан алган әсәрләрдә дә, бүгенге көн әсәрләрендә дә тулы чагылыш таба дигән нәтиҗәгә киләбез. Безнеңчә, әгәр дә художник иң алдынгы марксистик-ленинчыл теория белән коралланган булса һәм үзенең әсәрләрендә халык язмышын, аның омтылышларын, хыялларын, уй-теләкләрен тулы итеп яктыртса, ул чын мәгънәсендә милли була. Кызганычка каршы, милли форма, милли типлар, декоратив халык иҗаты безнең эшебездә әлегә тиешенчә файдаланылмый. Хәтта милли чыганакларга мөрәҗәгать итү мөмкинлекләре аеруча зур булган безәү сәнгатебезнең дә башка республикалар художникларының хезмәтләреннән әллә ни аермасы юк. Сынлы сәнгатьнең бу төрендәге хезмәтләр күбесенчә китаплардагы, журналлардагы рәсемнәрне хәтерләтә. Берәүгә дә кочләп такмыйча, үз фикеремне әйтәм, мисале, мәсәлән, сатирик журналыбыз «Чаян»ны соңгы елларда Балтик буе республикалары һәм чит ил художниклары иҗаты тәэсирендә ясалган рәсемнәр күмел китүе борчуга сала. Милли формага игътибарсыз караш сынлы сәнгатьнең башка төрләрендә, башка жанрларында да нык сизелә.

Республикабыз художникларының күңелен җилкендергән темаларның тагын берсе — Ватаныбыз пейзажы, Идел киңлекләре. Индустриаль пейзажны Н. Кузнецов аеруча мавыгып сурәтли. Аның нефть ягына, Казанның һәм Мәскәүнең яңа төзелешләренә багышланган полотнолары искиткеч кызыклы һәм үзенчәлекле. Художниклар М. Хәйретдинов, Х. Хәйдәров, М. Усмановлар да үзләренең иҗатларында нефть ягы пейзажына киң урын бирел киләләр. А. Прокопьев белән Г. Рәхманкулова лирик

картиналар, Е. Зуев белән С. Неустроев натюрмортлар жанрында эшләүләрен дәвам иттерәләр. Безнең китап һәм журнал графикасына заманча яңа сурәтләү чаралары, сәнгать ысуллары алып килүче Б. Альменов, Т. Хаҗиәхметов, В. Карамышев, И. Колмогорцева, И. Язынин, И. Әхмәдиев, Ю. Лысогорский кебек художникларыбыз бар. Сәхнә художникларының да эше уңышлы гына бара. Мәсәлән, П. Сперанский, В. Никитин, Э. Гельмс, Ө. Тумашев, М. Сутюшев, Л. Сперанская, А. Нагаева хезмәтләре Мәскәүдә, Ленинградта, Киевтә театр белгечләре тарафыннан югары бәя алды. Соңгы елларда скульпторлар коллективы да сизелерлек дәрәҗәдә үсте һәм ныгыды. Бу коллективта талантлы скульпторлардан Б. Урманче, В. Маликов, Р. Нигъмәтуллина, Н. Адылов һәм башкаларны күрсәтергә мөмкин.

В. Маликов, архитекторлар А. Спориус һәм Г. Пичуев проекты буенча, Казан шәһәрендә Совет власте өчен көрәштә һәлак булганнарга һәйкәл эшләде. Соңгы өч-дүрт ел эчендә районнар һәм колхозлар заказы буенча Ватан өчен корбан булганнар истәлегенә обелисклар әзерләнде.

Республикабызның көнкүреш сәнгате беренче адымнарын ясый. Әкренләп үз керамикабыз, келәмнәребез, чүкеп ясалган әйберләребез туа. Ләкин, шуны да әйтергә кирәк, республикабызның уңышлары турында сөйли торган истәлекле бүләкләр, сәнгать әсбаплары бездә әле җитәрлек эшләнми.

Безнең заманда бизәү сәнгате, техник эстетика проблемалары көннән-көн актуальрәк була бара. Бу әле яшь сәнгать, ләкин аның адымнары ышанычлы. Алдыбызда торган бурычлар мактаулы һәм искиткеч кызыклы. Без кешене көнкүрештә дә, производствода да матурлык дөньясы белән чолгап алырга тиешбез. Республика художниклары тарафыннан уңышлы бизәлгән объектларга: сынлы сәнгать музееи, «Яхонт» ювелир магазинын (авторы Н. Артамонов), университет интерьерын һәм Казан шәһәренең башка биналарын кертергә мөмкин.

В. И. Ленинның тууына 100 ел, Татарстан төзелүгә 50 ел тулуга багышлап, Н. Артамонов, В. Охотин, Р. Мостафин татар ашлары йортын, Е. Киселева, С. Бубенов, Е. Федоров химиклар культура сараен, «Татарстан» гостиницасы бинасын, В. Попов цирк интерьерын, И. Новоселов һәм В. Охотин цирк тирәсендәге монументаль панноны, В. Карамышев һәм Р. Кильдебеков сәүдә үзәген, А. Крылов университетның уку корпусын һәм башка бик күп биналарны, комплексларны бизәделәр. Ләкин әле болар диңгездән бер тамчы гына.

Безнең художникларны, шул исәптән, Бөгелмә һәм Түбән Кама производство участоклары художникларын да киләчәктә киң планда бизәү эшләре көтә. Әнә шул зур, кирәкле эшкә кадрлар хәзерләү максаты белән Художниклар союзының бизәү секциясе предприятие художниклары өчен ике еллык семинар үткәрә башлады. Әмма югары квалификацияле кадрлар, проектчы художниклар, техник эстетика буенча художниклар хәзерләү мәсьәләсе әле һаман мөһим бурычларның берсе булып кала. Әгәр художниклар белән архитекторлар берләшеп эшләсәләр, авылларны һәм шәһәрләрне бизәү мәсьәләсе, әлбәттә, ансатрак хәл ителәчәк. Ә бит тормыш үзе безнең алга китереп куйган проблема — сынлы сәнгать белән архитектураны синтезлаштыру проблемасы — дөрес хәл ителсә, архитектура да, монументаль-декоратив сәнгать тә тәрбияви рольләрен уңышлырак башкарырлар иде.

Без Совет Татарстанының сынлы сәнгате үсешенә анализ ясаганда Россия Федерациясенең 16 автономияле республикасы художникларының әсәрләре куелган күргәзмә нәтиҗәләренә игътибар итмичә булдыра алмыйбыз. Мәскәүдә КПССның XXIV съездыннан соң ук ачылган бу күргәзмә совет сәнгате үсешенең әһәмиятле бер этабы булып тарихка кереп калыр. 16 автономияле республиканың сәнгать әсәрләре әле беркайчан да болай бергә туплап һәм тулы итеп күрсәтелгәне юк иде. Күргәзмә безгә, художникларга, үзара тәҗрибә уртаклашырга, бер-беребезнең кимчелекләрен, уңышларын күрергә мөмкинлек бирде. Күргәзмә шулай ук һәрбер автономияле республикада, союздаш республикалардагы кебек үк, үзенчәлекле милли художество мәктәпләре үсеп китәргә мөмкин икәнлеген раслады. Без автономияле республика художниклары иҗатында, милли үзенчәлек белән бергә, үзара якынаю, прогрессив ысуллардан үрнәк алу, социалистик интернационализмга омтылу кебек күп милләтле совет сәнгатенең нигезен тәшкил иткән гүзәл сыйфатларны күрдек.

Совет Татарстаны художникларының күргәзмәгә куелган әсәрләре зур темаларга

багышланулары белән аерылып тора иде. Бу бигрәк тә тематик картиналарда, пейзажларда, политик графикада, политик сатирада һәм (күргәзмәдә бердәнбер булган) агитплакатларда ачык чагылды. Зур темаларга алыну, ул темаларны фәлсәфи планда чишәргә омтылу, гомумән, Татарстан художникларының күптәнге күркәм сыйфаты. Шуңа күрә дә без фикерсез, идеясез сәнгатьне кире кагып килдек. Без, әлбәттә, сәнгатьчә сурәтләү өчен тагын да тәэсирлерәк чаралар һәм формалар эзләүгә каршы түгел. Мәсәлән, Карелия художникларыннан, Башкортстан сәнгать осталарыннан, Кавказ скульпторларыннан, Якутия графикларыннан без күп нәрсә өйрәнә алабыз. Ләкин тышкы форма белән мавыгып, эчтәлеккә, әсәрнең идея юнәлешенә игътибар бирмәгән художникларның хезмәтләрен без кабул итә алмыйбыз.

Татарстан экспозициясен карагач, сынлы сәнгатебезнең аерым төрләре һәм жанрларының тигезсез үсүе, скульптураның рәсем белән графикадан нык кына калышуы, скульпторларыбызның композициягә җитди игътибар бирмәүләре күзгә ташланды. Бүгенге көнкүреш сәнгатенең дә шулай ук артта калуы сизелә. Моны җиң сызганып эшләү өчен ныклы база булмау белән аңлатырга кирәктер.

Театр художникларыбыз күргәзмәгә югары профессиональ дәрәҗәдәге әсәрләр белән катнаштылар. Оештыру эшләренә ныграк игътибар ителгән булса, алар бүгенге көнне яктырткан әсәрләрен тагын да күбрәк күрсәтә алырлар иде. Без хәзер портрет-картина, натюрморт кебек жанрларны акрын һәм сүлпән үстерәбез. Кызганычка каршы, сүлпәнлек, аерым жанрларның артта калуы гомуми төс ала бара. Моннан җитди бер нәтиҗә ясап була: художникларыбыз «кыен» бирелә торган жанрларда да уңышка ирешә алган республикаларның сәнгатенә аеруча игътибарлы булырга, алардан өйрәнергә тиешләр.

Заман темасына багышланган олы хезмәтләребез әлегә күп түгел. Күп кенә художникларыбыз әсәрләрендәге стиль, композиция бертөрлелеге, төсләр ярлылыгы, әлбәттә, иҗади эзләнүләргә әһәмият бирмәү нәтиҗәсе. Аерым художникларның уңышлары күпләрнең иҗат торгынлыгын яшереп кала алмый. Күргәзмәдә катнашкан байтак кына коллективларның иҗатлары өчен характерлы сыйфатлар — заманга тугрылык, төсләр гаммасының байлыгы, гомуми иҗади күтәренкелек җирлегендә безнең соңгы еллардагы хезмәтләребез ничектер 50—60 еллардагы иҗатыбызны хәтерләтә.

Коллективка яшьләрне тарту, яшь кадрлар хәзерләү — хәзер безнең өчен иң мөһим бурыч. Республиканы художниклар белән тәэмин итүче төп чыганак — Казан художество училищесы бүгенге сәнгать таләпләренә җавап бирерлек киң эрудицияле художникларны дүрт елда гына хәзерләп чыгара алмый. Художество училищеларында бишьеллык уку системасы кертүне тормышка ашырырга вакыт. Аннан соң югары квалификацияле художникларны үзебезнең республикада хәзерләгәндә яхшы булыр иде. Чөнки илебезнең художество вузларыннан Татарстанга җибәрелгән художникларның саны әлегә безне канәгатьләндерми. Художество культурасы бөтен республика буйлап җәелгән һәм художниклар өчен иҗат мәйданнары киңәйгән бүгенге заманда моңа, һичшиксез, зур игътибар бирелергә тиеш. Ачыграк итеп әйткәндә, сүз Казан педагогия институты каршында художество-педагогика факультеты, яисә Татарстан республика культура институтында изофакультет ачу турында бара. Әнә шундый факультет булганда гына республикабызның сынлы сәнгатен тизрәк үстерергә, коллективны квалификацияле кадрлар белән тәэмин итәргә мөмкин булачак.

Безнең хезмәтебездә тагын бер җитди кимчелек — иҗат ителәчәк әсәрнең фикере, мәгънә тирәнлеге турында уйлап җиткермичә ашыгып эшкә керешү һәм шулай ук ашыгып тәмамлап та кую. Безнең әсәрләребез арасында кайбер «урта кул» хезмәтләр очрый икән, ул әле, талант җитмәүдән бигрәк, ашыгу нәтиҗәсе. Димәк, безгә художество осталыгы турында ныклап уйланырга вакыт. Бүгенге заман художнигы, совет художнигы тирән фикерле әсәрләр иҗат итәргә, халык тормышы, халык язмышы белән бәйле икәнлеген даими рәвештә тоеп яшәргә һәм, ниһаять, даими рәвештә художество осталыгына омтылырга тиеш.

Татарстан художниклары союзы — үсә торган сәләтле коллектив, һәм без, КПССның XXIV съезды карарлары нигезендә, аңа зур бурычлар куярга, һәр художниктан чын иҗат дәрте белән янып, җәмгыятебез, халкыбыз һәм партиябез каршында тагын да зуррак җаваплылык хисе тоеп эшләвен таләп итәргә хаклыбыз.

Равил Фәйзуллин

# ХИКМӘТЛЕ ДӘ ЖЫРЫ, ДӘРТЛЕ ДӘ

*(Шагыйрь иҗаты турында уйланулар)*

Язмышлары, ялгышлары белән
Әрни-әрни сөйдем илемне.
Әгәр дә ваз кичсәм илдән-телдән,
Син мине үз итәр идеңме?

*Н. Арсланов*

50 еллар уртасында шагыйрь Нури Арсланов «Кордашлар җыры» исемле шигырь язган иде. Композитор тарафыннан көй язылып, ул шигырь чыннан да җыр булып китте. Анда мондый юллар бар:

**Солдат булып йөрдек сугышларда,**
**Үттек таулы-ташлы юллардан...**
**Ни кичмәде безнең бу башлардан,**
**Ни килмәде безнең куллардан.**
**Гаҗәп түгел чәчкә чал керсә,**
**Булса да тик кырык яшь безгә!**

10 еллап гомер үтте. Бу җыр үзгәрде. Исеме дә, сүзләре дә, көе дә.

**Ир уртасы — илле яшь, дигәннәр.**
**Кемнәр безне картка саныйлар!!**
**Егетләрчә әле безнең хәлләр.**
**Кемнәр шуны күрә алмыйлар!!**
**Картаербыз, бәлки, без йөздә...**
**Хәзергә тик илле яшь безгә.**

Тагын 10 ел үтте. Бу юлы шагыйрь әлеге җырны кабат үзгәртеп тормады, инде моны яңадан эшлисе юк дигәндәй, «Ир уртасы — илле яшь» исеме белән «Моңсар» исемле зур сайланма китабына кертте... Мәсьәлә ачык: картаербыз, бәлки, без йөздә... Хәзергә — шигырьләр, шигырьләр...

**Акыл белән эш ит диләр миңа...**
**Ә йөрәкне кая куясы!**
**Анда һаман әле давыл уйный,**
**Анда һаман «җеннәр оясы!»**
**Аның әле амур укларыннан**
**һаман килә яра аласы.**

Булса булыр икән бу кадәр дә
Тынгы белмәс адәм баласы!..

Типсәң тимер өзәр чак узса да,
Мин калышмыйм әле ярыштан.
Мәйдан тотсам — исемем генә түгел,
Бөтен рухым, җисмем арыслан.
(«Азат җанлы булып туганмын мин»)

Азмы җирдә тумый картайганнар!!
Син картайгач, бер ту яңадан!
Олыгайган саен хәят телим,
Мин яшәгән саен яңарам.
(«Пилигрим»)

Эшләр менә шулай тора шагыйрь Нури ага белән. Берәүләр аны «һаман яшь, һаман көләч» ди, икенчеләр аны «бөтен җаны белән елмаючы иптәш» ди. Шагыйрь үзе дә моны инкарь итми.

Баштук, ахры, күзгә чалындым мин:
«Яшь, диделәр, яңа!» — диделәр.
Ә картайгач: «Бу яшәгән саен
Гел яшәрә бара!» — диделәр.
(«Мин бик риза»)

Шулай да 60 ел гомер кителгән. 60 яз кичелгән. Хәер, Тукаебыз әйтмешли, «шагыйрь күңелендә кыш булмый да, кар ' яумый», анда гел яз. «Йөрәк әле һаман унсигездә». Тик акыл гына менә бераз өлкәнрәк бугай. Еллар шуңа ишарәли... Күпме җир гизеп, күпме юл үтеп, кемнәр белән генә очрашылмаган да кем язмышларына гына шаһит булынмаган! Никадәр шатлык татылмаган да, ничаклы сагыш кичерелмәгән!..

Н. Арсланов 30 еллык иҗат гомерендә 20 дән артык китап чыгарган шагыйрь. Алар — төрле пафоста, төрле темага язылган, күләмнәре дә төрле булган (кайсы 25 бит, кайсы 400 биткә якын), әлбәттә, әдәби кыйммәтләре ягыннан да төрле дәрәҗәдә торган китаплар. Арада 50 елларда чыккан, хәзерге поэзиябез югарылыгыннан караганда йомшаграк басмалар белән беррәттән, Н. Арслановны зур шагыйрь итеп таныткан «Моңсар» кебек китаплар да бар. Шуңа өстәп күпме тәрҗемә! Җыйсаң, алар, ихтимал, 20 табактан да артып китәр. Шагыйрьнең үз сүзләре белән әйтсәк, «зур тау булыр иде иткән хезмәт, өеп куйсаң аны әгәр дә».

Әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан ничек кабул ителгән бу хезмәт һәм тәнкыйть аның иҗатын ничек бәяләгән соң? Н. Арслановның, шагыйрь буларак, татар совет поэзиясе үсешенә керткән өлеше, үзенчәлеге, көчле һәм йомшак яклары нидән гыйбарәт? Шагыйрь китапларын тагын бер кат укып танышу процессында шундыйрак сораулар туды һәм аларга җавап эзләү нияте белән мин, хәл кадәри, Н. Арсланов иҗатына карата үз вакытында матбугатта күренгән мәкаләләрне карап чыктым. Бер дә юк түгел икән рецензияләр, беркадәр бар икән, заманында чыккалаганнар икән. Менә Фатих ага Хөснинең моннан нәкъ 20 ел элек «Совет Татарстаны»нда (4 сентябрь, 1952 ел) чыккан мәкаләсе. Ул Н. Арслановның «Мәхәббәт» исемле китабына кергән «Ай Хян белән Ли», «Корея гөле», «Мәхәббәт» поэмаларына (рецензент аларны поэма дип түгел, мәхәббәт хикәяләре дип атый) анализ ясаган. Шагыйрь С. Хәким, республикабызда нефть промышленностеның көннән-көн күзгә күренеп күтәрелүенә сөенеп, инде «кара алтын» яклары кешеләре турында җырлар, поэмалар тууына куанып, Н. Арслановның «Девон фонтаннары» китабы турында фикерен әйтеп чыккан. Шул ук «Совет Татарстаны»нда Л. Җәләй шагыйрьнең «Рус кызы» исемле поэмасы хакында чыгыш ясаган. Шактый еллар узгач, Н. Арслановның «Ак таңнар» исемле чагыштырмача күләмле җыентыгы турында И. Саттаров «Социалистик Татарстан»да «Шигърият тавы каршында» исемле рецензия бастырган. Үз вакытында Ә. Исхак, Ш. Максудова, Р. Фатиховлар шагыйрь иҗатына үзләренең мөнәсәбәтләрен белдереп

чыкканнар. Төрле елларда чыккан китапларга З. Мансур, С. Хәким, М. Садриләр кереш сүз язган. Ихтимал, миңа очрамаган, мин тапмаган мәкалә, язмалар тагын бардыр. Димәк, үз вакытында шагыйрь иҗаты турында беркадәр язылган икән. Ләкин шунысы бар, бу мәкалә-рецензияләрнең һәммәсе дә я китап чыгу, я юбилей уңае белән язылган. Ә менә шагыйрьнең бөтен иҗатын яктырткан, гомумиләштерүләр һәм нәтиҗәләр ясаган күләмле мәкаләләр юк диярлек. Ниһаять, бу язма да юбилей уңае белән языла.

Төрле «уңай»лар белән язу, гәрчә күп яклардан акланса да, гадәттә әдәбият тарихында зур эз калдыра алмый. Дөресрәге, андый мәкаләләр объектив үк булып бетә алмый. Мәсәлән, китапка кереш сүз язучы кеше, беренче чиратта, әсәрнең уңай яклары турында сөйли, һәм бу табигый. Юбилей уңае белән сүз әйтүче дә, кагыйдә буларак, әдип иҗатының күркәм якларына күбрәк туктала.

Н. Арсланов бүгенге татар шигъриятендә ниндирәк урын тота һәм ул кай ягы белән үзгә шагыйрь? Гомумән, безнең кемнәребез бар соң? Бүгенге шигъриятебез шактый көчле. Артык күп булмасалар да (бәлки, шагыйрьләр йөзәрләп була да алмыйлардыр. Хәтта хәзерге рус поэзиясендә дә бик талантлы шагыйрьләрне дистәләп санау кыен. «Хакыйкатьне әйтеп бирү өчен бер Толстой җиткән, бер Тукай»), шагыйрьләребез юк түгел, алар бар. Сабыйларча беркатлы, интеллектуаль Туфаннары, халыктагы хәкимлекне һәм сабырлыкны үзенә җыйган зирәк Хәкимнәре, чәнечкеле Кадрәхмәтләре, әрем телле Гамилләре, самими һәм шук Шәүкәтләре, моңлы романтик Илдарлары, дистәләрчә сәләтле яшь шагыйрьләре... һәм тагы шушы ансамбльдә үзенчә аерылып торган горур һәм затлы Нури ага Арсланов бар. Ул үзенең килешкилбәте белән (аны шәхсән белмәгән, күрмәгәннәр өчен рәсеме белән) классик мәгънәдәге борынгы интеллигентны хәтерләтә. Ни өчен шәхеснең, күңеленнән бигрәк, шәкли ягына кагылдым. Чөнки кеше күзендәге кешеләр — әдәбият-сәнгать кешеләре өчен бу да бик мөһим. Эстетик байлык халык массаларына тирән үтеп кергән чорда, рухи иҗатчылар белән материаль байлык тудыручыларның интенсив аралашуы, берлеге заманында, әдип кеше һәр яктан сынала: кыяфәте дә, үзен тотышы да, шәхси тормышы да, әйткән һәр сүзе дә. Тыңлаучыда, шәхес буларак, уңай тәэсир ясыйсың икән, ул синең иҗатыңа да бүтәнчәрәк — яхшырак караячак, игътибарлырак булачак. Бу — әлбәттә, беренче сыйныфларда ук өйрәтелә торган хакыйкать. Ләкин бу хакыйкатьне форсат чыгып искә төшерүдән зыян юк. Сукбай булып халыкның исен китәрә торган заманалар узды. Әдип һәрчак әдип булырга тиеш. Интеллигент әдип дигәч, Пушкиннар, Байроннар, Ролланнар, Фадеевлар, Ибраһимовлар, Дәрдмәндләр, Рәмиевләр, Кутуйлар бар кыяфәт-сыннары белән күз алдына киләләр. Бу яктан Н. Арсланов — татар язучылары арасында байтак яшьләргә үрнәк булып торырлык интеллигент әдипләрнең берсе.

Н. Арсланов — чыгышы белән Казагыстаннан. Ул 1912 елда Кызылъяр (Петропавловск) шәһәрендә туа. Кокчәтауда җидееллык мәктәпне тәмамлагач, Казанга килә. Сәнгать техникумында укый. Аннан соң Татарстанның Кукмара районында рәсем, әдәбият укыта. 1934—36 елларда Кызыл Армия сафларында була. Тыныч хезмәттә берничә ел эшләүгә Ватан сугышы башлана. Н. Арсланов беренче көннәрдән үк фронтка китә. Рота командиры дәрәҗәсенә күтәрелә. Сугышчан батырлыклары өчен орден, медальләр белән бүләкләнә. Яралана. Сугыштан соң Татарстан китап нәшриятында, газета редакцияләрендә художник булып эшли. Шул ук вакытта һәр мөмкинчелекне иҗат өчен, шигърият өчен файдаланып калырга тырыша. Ә соңгы сигез елда Н. Арсланов «Казан утлары» журналының поэзия бүлеген җитәкләде. Анкета мәгълүматларын санап чыгу, әлбәттә, җиңел. Тормыш итү, яшәвеңне мәгънәле итү, ай, катлаулы! Бер шигырендә шагыйрь болай дигән иде: «Ярты гасыр җирдә яшәдем мин, бер гасырлык хәлләр кичердем». Ә «Тәрҗемәи хәлем» дигәнендә мондый юллар бар:

Төрле хәлләр кичте баштан — сабыр кылдым,
Башкалардан калышмадым — сафта булдым;
Кагылсам да, сугылсам да авыр юлда,
Бирешмәдем, мин абынган саен тордым.
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Ил каршында абруй өчен көраштем мин,
Башкалардай борчылдым, көнләштем, ләкин
Кызыксам да күреп миннән өстеннәрне,
Түбәннәргә карап күтәрмәдем борыным.

Тырышмадым җитди булып кыланырга,
Язмаганны сыктанырга-сорарырга,
Яшәмәвем өчен каш-кабагым төеп —
Гомерлеккә мин сакаллы сабый булдым.

Н. Арслановның укучыларга ирешкән беренче сүзләре — «Мәхәббәт» һәм «Рус кызы». Беренчесе госпитальдә дәвалану вакытында 1942 елда язылган һәм бер елдан соң «Совет әдәбияты»нда басылып чыккан, икенчесе — бераз соңрак. Заманында алар авторны таныткан әсәрләр була. Сугыш вакытында һәм соңрак бу әсәрләр укучыларда патриотик хис тәрбияләүдә, һичшиксез, зур роль уйный. «Рус кызы» турында 50 елларда бик күп мактау сүзләре әйтелә. Ләкин бүгенге поэзия биеклегеннән, шигъри әсәрләргә бүгенге таләпләр югарылыгыннан караганда, бу поэманың байтак кына йомшак яклары да күренә. Акланмаган озынлык күзгә бәрелә, тасвирчылык, риторик купшылык үзен нык сиздерә.

Үз вакытында Зоя Космодемьянская батырлыгы турында бүтән шагыйрьләр дә язды. Төрле халык шагыйрьләренең байтак әсәрләре чыкты. Кабат укып карыйм, чагыштырам, уңай якларын табам. Әмма, барыбер, бу поэма Н. Арслановның өйрәнчегрәк әсәре. Чын әсәр, шигырьме ул, хикәяме, теләсә кайсы вакытта да, теләсә нинди биеклектән караганда да, дулкынландыра, әсир итә. «Рус кызы» поэмасы — ул еллардагы поэзиянең типик бер үрнәге. Гомумән, никадәр генә аяныч булмасын, 50 еллар татар поэзиясе укучыларны зур һәм тирән мәгънәле шигъри әсәрләр белән артык куандыра алмады шул.

Беркадәр формальрәк булса да, Н. Арсланов иҗатын берничә чорга бүлеп карарга мөмкин. 43—50 нче еллар — өйрәнү чоры, 50—60 нчы еллар — чыныгу чоры, 60 нчы еллардан бүгенгегә кадәресен өлгерү чоры дип атарга мөмкин.

Беренче чор — тулысы белән диярлек Бөек Ватан сугышы тәэсирләреннән туган иҗат. Шагыйрьнең төп нияте — «җиңелмәс» фашист илбасарларын җиңгән, «дошман башын хурлыкка сала алган» совет халкының көченә, рухи бөеклегенә дан җырлау. Иҗатының бу чорын күзаллау өчен, югарыда әйтелгән поэмалардан тыш, «Авылда», «Сугышчы төне», «Хат», «Дустымны сагынганда» шигырьләрен китерергә мөмкин. Сугыш турында шагыйрь бу елларда байтак язса да, аның сугыш мөнәсәбәте белән язылган «Билгесез солдат кабере янында», «Триумфатор булып», «Адым саен әкият», «Унике батыр турында баллада» кебек көчле әсәрләренә соңрак туарга насыйп булды. Шунысы характерлы, сугыш турында ул, кайберәүләр кебек, «мин Берлинны алдым!» дип деклоратив рәвештә сөйләми. Гомумән, сугыш хәлләрен Н. Арсланов бөтен авырлыгы һәм дәһшәтлелеге белән бирергә омтыла. Шушы омтылыш һәм билгеле бер дәрәҗәдә шуңа ирешү аның әсәрләрен ышандырырлык итә дә.

Шагыйрьнең икенче чор иҗаты тематик диапазонның киңрәк һәм әдәби osталыкның чагыштырмача камилрәк булуы белән характерлы. Җирдә тынычлык өчен көрәш — Н. Арслановның 50 еллар иҗатының төп бер мәгънәсе шул. 7—8 елын фронтларда уздырган, утны-суны кичкән солдат-шагыйрь өчен бу бик табигый. Ул елларда Кореяда барган сугышлар, халыкара хәлнең киеренкелеге тынычлыкның кадерен белергә, аның өчен көрәшергә кирәклекне һәр даим искәртеп торды. Н. Арсланов, Корея халык иҗатын өйрәнеп, күләмле байтак шигырь-поэмалар («Корея гөле», «Ай Хян белән Ли», «Давыл кызы» һ. б.) иҗат итте. Тынычлык өчен көрәш ул, иң беренче чиратта, Ватан хакына фидакарь хезмәт итү. Татарстанда нефть промышленностеның үсеп китүе, нефтьчеләрнең тырыш хезмәте шагыйрь күзеннән читтә кала алмый. Н. Арсланов, беренчеләрдән булып, алар турында шактый кызыклы шигъри әсәрләр тудырды. 1953 елда чыккан «Девон фонтаннары» асылда җир асты байлыгын кояшка чыгаручы хезмәтчәннәр турында иде. Ул елларда Н. Арсланов сүзләренә З. Хәбибуллин тарафыннан язылган «Баулылар» җыры гаҗәеп популярлык алды. Байтак еллар буе бу җырны бөтенләй нефть исе килмәгән чит якларда

хәттә малай-шалайга кадәр җырлап йөрде. Н. Арсланов бу елларда балалар өчен дә байтак язды. «Карамай малай әкияте», «Сыерчык», «Ауда» кебек китаплар әнә шундыйлардан.

Н. Арслановның сугыштан соңгы 15 еллык хезмәтен тәкъдир иткән хәлдә, икеләнмичә шуны әйтергә мөмкин: иҗатының иң игелекле һәм күпләрне куандырган өлеше соңгы ун елга туры килә. Аның бу вакыт аралыгында язылган шигырьләре турында һичбер ташламасыз сөйләп, фикер әйтеп була. Әгәр Н. Арсланов элегрәк бу тормышта катнашучы-шагыйрь булып чыгыш ясаса, хәзер ул бу тормышта хуҗа-шагыйрь, шәхес-шагыйрь булып сүз әйтә.

Мәкаләнең кереш өлешендә үк сүземне шагыйрь соңгы елларда иҗади яшәрде дип башлаган идем. Табигый сорау туа: бу яңарышның сәбәбе нидә соң? Ни өчен аның яшендәге яки аннан өлкәнрәк байтак сәләтле шагыйрьләр иҗатларында этаплы «сикереш» ясый алмаганда, Н. Арсланов шигърияттнең алгы рәтенә чыга алды? Барыбыз өчен дә бу метаморфозага сәбәп-факторлар байтак булырга тиеш. Минемчә, бу яңарышның төп нигезе түбәндәгеләрдән гыйбарәт. Беренчедән, Н. Арсланов — тумыштан шагыйрь булып туган җан («үзең хаким, үзең дивана»). Һәм бу табигый талант өстенә аңа кеше буларак күркәм сыйфатлар: әдәплелек, затлылык, чама хисен нечкә тою («тырышмадым җитди булып кыланырга, язмаганны сыктанырга-сораныргa»), зирәклек һәм горурлык хас. Шушы асыл сыйфатлар заманның төрле җил-давылларыннан аның шагыйрьлеген исән-аман саклап алып чыкты да шикелле («сугыш аты кебек мин, мөлдерәп, күзләренә[1] карап яшәдем»). Икенчедән, Н. Арслановның иҗади күтәрелүенә 60 еллар башында илнең рухи тормышы кичергән үзгәрешләр, иҗади атмосфераның кешелекле һәм дустанә булуы, әдәби мирасның классик әдипләр исәбенә баюы һәм, гомумән, әдәби хәрәкәтнең тулы канлы булуы уңай тәэсир итте. Шунысы да бар: әдәби-иҗтимагый тормыштагы бу уңай үзгәрешләр, беренче чиратта, иҗатта үзенең анык кредосы, ил, халык сулышына сизгер күңеле һәм инанган позициясе булган, әдипнең иҗтимагый тормыштагы миссиясен ачык белгән, илсөяр табигатьле көрәшче шагыйрьләргә шифалы булды. Кайберәүләр иҗатында, кызганычка каршы, бу яңарыш үзен сиздерә алмады. Өченчедән, Н. Арслановның яшәрүенә аның яшь иҗатчылар белән тыгыз иҗади бәйләнештә булуы да билгеле бер роль уйнады. Яшьләр белән тулы аңлаша алу — яшь була алу дигән сүз ул. Яшь шагыйрьләргә үзенең иҗаты белән йогынты ясаган хәлдә, ул үзе дә кирәк чакта яшьләрдән өйрәнә алды. Чөнки һәр яшь иҗатчы әдәбиятка үз дөньясы, үз кызыгы белән килә. Аңа сизгер күңел битараф кала алмый. Моннан берничә ел элек «Татарстан яшьләре» газетасында Нури ага үзе дә болай дип язып чыккан иде. «Соңгы биш-алты ел эчендә... бик күп талантлы, өметле һәм бик җитди яшьләребез әдәбиятның киң һәм изге мәйданына кыю адымнар белән килеп керделәр. Аларның һәркайсының бер дә кабатланмаган үз җыры, үз моңы, үз авазы бар. Мин бу яшь шагыйрьләребезгә карап шатланам да, сокланам да. Алар безнең хакта ни уйлыйлардыр, ә минә миңа аларга карап үз тулпарымны еш чыбыркыларга туры килә». («Татарстан яшьләре». 1969 ел. 51 сан.)

**Өметле дә мин,**
**Бәхетле дә мин!**
**Тик, яшьләр, сезнең**
**Язмышны көнлим:**
**Ник сезнең белән**
**Кордаш түгел мин!**
**. . . . . . . . . . .**
**Яңа үрләргә**
**Ак юл, туганнар!**
**Яшьләр, сез нинди**
**Бәхетле җаннар!**

*(«Ник кордаш түгел»)*

---

[1] Ил, халык күзенә.

Яшьлегенә күңеле белән булса да һәр даим якыная алган кеше, ул — яхшы кеше.

Н. Арслановның соңгы еллардагы иҗади йөзен аның Туган ил, туган җир турында уйлану рәвешендә язылган шигырьләре һәм мәхәббәт лирикасы билгели. Бу шигырьләр әдәби җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итте һәм шагыйрьнең үзенә хөрмәт, ихтирам китерде. Шагыйрь Туган ил, Ватан төшенчәсенә фәлсәфи мәгънә сала һәм аны югары поэтик осталык белән укучыга җиткерә ала. Шагыйрь өчен Ватан төшенчәсе конкрет, ул аңа үткәне, бүгенгесе, киләчәге белән газиз. Ватан киң — ул Татарстан да, казакъ далалары да, Кырым ярлары да, Идел буйлары да. Шулай да шагыйрь өчен туган казакъ далалары һәм үзен кеше иткән, шагыйрь иткән Казан аеруча кадерле.

**Тусам да мин казакъ даласында,**
**Үссәм дә мин атта, ярдә,**
**Гел ашкындым Казан каласына —**
**Истәлекле изге җирләргә.**

**Бу туфракта минем туган илем,**
**Йорт корганнар монда бабамнар,**
**Монда минем акчарлаклы Иделем,**
**Үз халкым, үз республикам бар!**

Шагыйрь, кем генә һәм кайда гына булса да, үзенең бала чагыннан, үсмер чагыннан китә алмый. Дөресрәге, ул аннан китмәскә тиеш. Бала чак, авыр үткәнме, җиңелме, барыбер, һәр иҗат кешесе өчен бетмәс-төкәнмәс саф чыганак. Бала чак — кешенең дөнья белән эчкерсез, дипломатиясез сөйләшкән чагы, аңлашкан чагы...

**... миңа илһам аты биргән**
**Далаларым искә төшкәндә**
**Мин әйләнәм кабат буз балага —**
**Җан яшәрә, күңел нечкәрә.**

*(«Далаларым»)*

Н. Арсланов үзенең бала чагы үткән Кызылъяр, Кәрәкәү, Күкчәтау яклары, Колынды, Күксеңгер далалары турында кешелекле һәм тирән мәгънәле байтак шигырьләр иҗат итте. «Далаларым», «Кәрәкәү икмәге», «Сабира җыры», «Акбүз ат хикәясе», «Әти белән сөйләшү», «Тугайлы Иртеш буйлары» исемле шигырьләре, «Романтика», «Майра» кебек кечкенә күләмле поэмалар — әнә шундыйлардан. Ул як халкының тормышын, гореф-гадәтен, халык авыз иҗатын яхшы белү шагыйрьне бай телле итте.

**Майра, Майра,**
**Кәрәкәүле Майра,**
**Яшьле күзем, җайна!**
**Кызыл телем, сайра!**
**Сөйгән ярың кайда!**
**Майра, Майра!**

*(«Майра»)*

Гомумән, казакъ халкы тормышы хакында без Г. Ибраһимов, И. Салаховларның чәчмә әсәрләреннән, Н. Арслановның шигырьләреннән байтак мәгълүмат ала алабыз. Бу әсәрләрнең ике кардәш халык арасындагы дуслыкны тагын да ныгытуда ярдәме зур булды. Н. Арсланов рус халкы турындамы, казакъ, кыргыз, молдаван, Кавказ һәм Кырым халыклары турындамы, ул аларның һәркайсына тигез күз белән карап, тарихларын белеп, милли үзенчәлекләрен танып һәм хөрмәт итеп язарга тырыша. Милликәпәрәю һәм чикләнгәнлек шагыйрьгә ят. Аның килер буынарны чын интернациональ рухта тәрбияләнгән, сугышларны белмәгән, бай рухлы, азат һәм шат итеп күрәсе килә.

Сугышлардан дөнья сыкрый-сызлый.
Авыр яралары...
Үстерергә иде бер дә бозмый
Газиз балаларны.
(*«Карпат итәгендә». «Казан утлары». 1971 ел. 9 сан.*)

Татарстан һәм Казан турындагы шигырьләр шагыйрь иҗатында аерым бер урын тота. Гомеренең өчтән береннән артыгын яшәгән Татарстанга, асылда, аның төп туган иле булып киткән җиргә — Казанга шагыйрьнең үзенең ихтирамлы мөнәсәбәте бар, җыры бар, «Казан» дигән шигырендә ул болай ди:

Шуннан киттем ике сугышка да,
Тормыш юлын шуннан башладым;
Шуңаргадыр, монда тумасам да,
Казан җире, Казан ташлары —
Туган йортым бусагасы миңа,
Идел ярын Туган яр итәм...

Шагыйрь Туган ил, Татарстан темасын төрле яктан ача. Н. Җиһанов көй язган «Республикам минем» җырын кем генә тыңламаган икән.

Азат та син,
Гүзәл дә син,
Әй туган җирем,
Күкрәп яшә,
Республикам минем,
Татарстан, Татарстан!

Туган ил өчен горурлык хисе шагыйрьгә һәрчак юлдаш булды. Чөнки хезмәт сөючән, батыр татар халкының Ватан данын арттыручы уллары һәм кызлары бар, илне яңа үрләргә күтәргән хезмәте бар. Шагыйрьнең Р. Яхин көй язган «Уникe батыр турында баллада»сын Э. Җәләлетдинов башкаруында күз алдына китерегез.

Таш утрау шикелле бу төрмә,
Таш коймa әйләнә-тирәсе.
Белделәр бу ташлар мәйданга
Бүген дә корбаннар киләсен...

Дарларга уникe батырның
Ашуын бу ташлар күрделәр.
Таң калып тетрәде диварлар:
Батырлар елмаеп үлделәр,
Татарлар елмаеп үлделәр...

Шагыйрь җаны халкының үткәненә, тарихына битараф була алмый. Киләчәкне үткәннән, бүгенгедән аерып карап булмый, дөресрәге, аерып карасаң, дөрес булмый, гадел булмый. Менә шагыйрь үзенең бабалары туып-үскән Мамадышта. Ул бер конкрет шәхес аша татар халкының тарихын күргәндәй була. «Давылларда күтәрелгән комдай чәчелгәннәр, язмыш куганнар». «Үз илем, үз республикам бар» шигырендә шагыйрь болай ди:

Күзен киткән казлар язын кайта,
Кыйгаклашып, Идел-суларга.
Киек казлар... Без дә төрле якка
Таралганбыз, охшап шуларга.
Бер кайтмаса, бер кайталар кагә,
Өмет өзми кайталмаганнар.
Идел-йортта Татарстан дигән
Үз илем, үз республикам бар!

Тарихи үткән юл никадәр гыйбрәтле һәм четерекле булмасын, бар халык таныргык кылган игелекле гамәле, бөтен дөнья күрерлек гигант төзелешләре булган халыкка шагыйрь киләчәк тарихта мактаулы урын хәстәрли.

Атлантида! Атлантида баткан!
Эз калмаган бөек халыктан...
Ә без — менә, без — бар, эз бар җирдә —
Без батырган сәен калыккан.
. . . . . . . . . . . . . . . .
Татарстан дигән Ватаным бар,
Татар дигән халкым бар минем.
Узганнардан түгел, мин халкыма
Киләчәктән урын барлыймын.

(«Атлантида»)

Гомумән, Н. Арсланов иҗатында Татарстан, Казан турындагы шигырьләр күләм ягыннан да шактый. Югарыда әйтеп үтелгән шигырьләрдән тыш, аның бу темага язылган «Сагындым», «Ак таңнар», «Казан», «Казан кызы» һәм тагын башка яхшы шигырьләре бар. Казан дигәч, XVIII гасырның билгесез бер татар шагыйрәсе иҗат иткән юллар хәтергә килә: «Казанда булган туфрак — күз генәмә лә сөрмәдер...»

Н. Арслановның иҗади яшәрүен дәлилләрлек нинди шигырьләрен саныйсың дип сорасалар, мин иң әүвәл аның соңгы елларда язган мәхәббәт шигырьләрен китерер идем. Шагыйрьнең мәхәббәт лирикасы аерым алып махсус өйрәнелергә лаек. Әгәр шагыйрьне һаман яшь, һаман көләч дип әйтәләр икән, моны, мөгаен, беренче чиратта, аның мәхәббәт шигырьләрен истә тотып әйтә торганнардыр.

Мәхәббәткә рөхсәт сорамыйлар,
Мәхәббәткә рәхмәт әйтмиләр.
Ул бүләк тә һәм бурыч та түгел.
Мәхәббәтне гаеп итмиләр.
Сөя белгән, сөелә белгән җаннар.
Шулар белән бергә атладым:
Сөймәгәннең сөюен теләдем мин,
Сөйгәннәрнең бәхетен якладым.

Мәхәббәт кебек бөек хисне ниндидер категорияләр кысасына кертеп өйрәнергә тырышу ничектер уңайсыз, сөю шигырьләренә комментарийлар бирү артык кебек. Аларны укырга кирәк. Ошыйлар, дулкынландыралар икән, тагын укы, күңел сизгечләрен шагыйрь кичергән хисләр дулкынына көйлә. Теләсәң — сагышлан, көл, дәртлән, җырла... Яңадан укы!

Башларымның, акылын җуеп, әйләнгән чагы,
Яшәреп, җаным егеткә әйләнгән чагы.
Тел сөяксез — сөйләсеннәр, ни сан аларга!
Бүген минем күңелемдә бәйрәмнәр чаңы!
. . . . . . . . . . . . . . . .
Кайда тыңгы, кайда ирек!! — Күр, мин богаулы...
Әгәр дә син әмер итсәң — аударам тауны!
Таңресеннән вәхи алган пәйгамбәр сыман
Кояш иңде күкрәгемә, йолдызлар яуды!..

(«Сөйдең-көйдердең»)

Эх, сөймим димәсәнә,
Җаныма тимәсәнә...
Йөрәгем, көймәсәнә!
Сөйсәң сөй, сөймәсәң сөймә,
Сөймәсәң, сөймәсәнә.

(«Нәсимә»)

**Көннең көлеп туар иртәләре,**
**Айның аерылалмас кичәләре,**
**Даланың давылы,**
**Атның асавы,**
**Бәйгенең бүләге,**
**Ярның ялкынлысы**
**Инде миңа түгел...**
**Ләкин**
**Өмет өзәме соң күңел!**
*(«Көчле дә син!»)*

Мәхәббәт — күңел илендәге бер гүзәл чәчәк шул. Анда, салават күперендәге кебек, хәяттәге бөтен төсләр, кеше хисенең бөтен тирбәнешләре бар. Әйе, көчле дә ул! Сине я күкләрнең өске катларына күтәрә, я бөтен барлыгың белән үксетә. Ләкин ни генә булса да, мәхәббәт — яшәүгә көч биргән иң кодрәтле чыганак. Шагыйрь иҗатында ул шулай яңгырый да. Шәхси мәхәббәт хисе халыкны, илне, Ватанны сөю хисе белән үрелеп бара һәм шушы берлек шагыйрьнең шигырьләрен иҗтимагый бәһале итә дә.

**Мәхәббәтем белән яшәдем мин,**
**Рухландым мин аның нурыннан.**
**Мәхәббәттән мәхрүм булсам әгәр,**
**Нәрсә килер иде кулымнан!**
*(«Бер тәнкыйтьчегә җавап»)*

Шигырьләрнең эмоциональ тәэсирлеге, форма ягыннан төзеклеге, камиллеге байтак композиторларыбызның игътибарын шагыйрь иҗатына юнәлтте дә булса кирәк. Күренекле композиторлардан Н. Җиһанов, Җ. Фәйзи, А. Ключарев, З. Хәбибуллин, Р. Яхин, А. Монасыйпов, С. Садыйкова, үзешчәннәрдән М. Имашев, Е. Хисамовлар Н. Арсланов сүзләренә көйләр яздылар. Ул җырларның саны 30 дан артык. Бүгенге көндә аеруча киң таралганнары: «Республикам минем», «Унике батыр турында баллада», «Сезне яратам», «Казан кызы», «Нәсимә» һәм башкалар. Бу җырларны шагыйрьнең шигырьләрендәге Зөбәрҗәтләр, Дилбәрләр, Миләүшәләр, Мәдинәләр, Раузалар, Нисалар, Нәфисәләр генә түгел, бөтен татар иле җырлый.

**Гамьсезлектән җырлый диләр мине,**
**Үзем генә беләм хәлемне.**
**Өзелеп-өзелеп сулкылдый да бәгырем,**
**Җырлыйм: «Бөркән зәңгәр шәлеңне...»**
. . . . . . . . . . . . . .
**Гамьсезлектән җырлый диләр мине.**
**Гамьсезгә соң җыр-моң ни аңа!!**
**Эчендәге сагышлары кушкач,**
**Җырлый башлый миндәй дивана.**
*(«Гамьсезлектән җырлый диләр мине»)*

Гамьсезлек димәктән, кемгәдер Н. Арсланов либераль карашлы гамьсез гулливер кебек күренергә дә мөмкин. 50 елларда бер өлкән шагыйребез — «сак булыгыз, гамьсез гулливерлар, лилипутлар килә шигырьгә!» дип язып та чыккан иде. Бәхеткә каршы, безнең Нури ага алай гамьсезләрдән булмады. Озак еллар журналыбызның поэзия бүлегендә эшләү дәверендә яшь шагыйрьләр моны яхшы тойды. «Ничек кенә булмасын, кайчакта үз зәвыгына, үз стиленә каршы килеп булса да иҗади эзләнүләр юлында яшьләргә киң мөмкинлек бирергә кирәк», («Татарстан яшьләре». 1969 ел. 51 сан.) Әгәр без бүген поэзия жанрының сөенечле дәрәҗәдә үсүе, төрләнүе, тирәнәюе турында еш сөйләшәбез икән, иң яхшы поэтик әсәрләрне пропагандалаучы булган «Казан утлары» журналының һәм аның хезмәткәрләренең эшен танырга тиешбез. Н. Арсланов әнә шул җаваплы, тынгысыз эштә — редакциядә байтак еллар эшләде һәм ул төрле буын, төрле стиль шагыйрьләре белән уртак тел таба алырлык, әйткән сүзенә колак салырлык, үз позициясендә нык торган принципиаль авторитетлы

редактор булып саналды. Юк, бу дөньяда гамьсез булып булмый. Бу — егерменче гасыр. «Жирнең тарту көчен җиңеп пьедестальга менгән данлы гасыр, бу — бер котыптан бер котыпка канлы эзе яткан рәхимсез гасыр».

Тын, караңгы булмә. Тып-тын акыл.
Йөрәк кенә уяу, талпына.
Өзелердәй булып үзәктә кыл
Чамасыннан чыгып тартыла.

*(«Төнге шигырь»)*

Н. Арслановның «Шигырь китапханәсе» сериясендә чыккан сайланма шигырьләр китабының яртысын диярлек аның поэмалары, шигырь белән язылган әкиятләре, легендалары алып тора. Һәм алар күләм ягыннан да, идея-эстетик кыйммәте ягыннан да төрле әсәрләр. Арада мең ярым юлга сузылган «Егет яуда сынала» дигән шигъри хикәя белән бергә, кыска, дулкынландыргыч, шул ук вакытта фикри тирән «Майра» кебек әсәрләр дә бар. Арада, минемчә, иң мәгънәлесе һәм сәнгатьчә эшләнеше ягыннан да бик камил, нәфис эшләнгәне «Моңсар». Авторның бу әсәре үзенә дә бик газиз булса кирәк, китабының исемен дә «Моңсар» дип атаган. Шагыйрь белән тиран, хаким көч белән изелгән халык арасындагы бәрелеш, конфликт. Ил, халык күңелендәге әйтүче җырчы шагыйрьләрнең тормыштагы роле, бәндә буларак хәяттәге хәлләре — менә шулар турында бу әсәр. Әлбәттә, яңа хакыйкать түгел бу, борынгы заманнардан килә торган көрәш инде бу. Әмма шагыйрь бу әсәрен виртуозоста булып язган, шуңа да һәр строфаның матурлыгы һәм динамикасы сине үз стихиясенә алып кереп китә, дулкынландыра. Уй сөреше белән «Моңсар» безнең борынгы дастаннарны искә төшерә.

Тәхет биек, таҗ биек.
Тик җыр килмәс баш иеп.
Тотам дисәң — ул киек:
Аны җитәр толпар юк.
Аңа җирдә тоткар юк.
Ул — йөрәктән аткан ук:
Ул тисә, кан чыгармый,
Ләкин аның ярасы
Мәңгелеккә каласы.

«Моңсар» — җыр турында уйлану, җыр турында җыр. Шунысы куанычлы, шагыйрь җырны бөек идеаллар көрәшендә байрак итеп, халык күңеленең иң бөек ноктасы итеп күрә.

Җырны чабар балта юк
Бөтен дөнья йөзендә.
Хакыйкать бар, хата юк
Минем шушы сүземдә.
Җырның кисәр тәне юк,
Үлемдә бер гаме юк.
Җыр яши җанга кереп,
Җыр — үлемсез, мәңгелек!

Шагыйрьнең сайланма китабына, «Моңсар»дан тыш «Кинешма бәете», «Диңгез ярында», «Романтика», «Горур Гайшә» кебек яхшы әсәрләре кергән. Кырым легендасына нигезләнеп язылган «Горур Гайшә» — трагик ситуациясе һәм геройларының характерлары, тетрәндергеч язмышлары белән хәтердә кала. Гыйбрәтле, көчле, ләкин бәхетсез мәхәббәт турында бу әсәр.

Н. Арслановның төрле халык әкиятләреннән алып язылган «Икмәк валчыгы», «Тылсымлы кое», «Тапкыр игенче», «Көзге» кебек әсәрләрен укыганда шундый уй туды: әкиятләрне, легендаларны шигырьгә салуның артык хаҗәте бармы икән? Әкият әкият килеш, легенда легенда килеш, халык авыз иҗатындагыча саклансә да начар түгел иде. Алар бит шул килеш тә үзләренчә матур, үзләренчә килешле. Әлбәттә, әкиятнеме, легенданымы, сюжетлы берәр вакыйганымы йөгерек шигъри телдә сөйләү

җинел түгел. Бу — осталык эше. Әкиятләргә карата үз фикеремдә калган хәлдә, шагыйрьнең бу әсәрләрдә дә осталыгын барыбер танырга кирәк.

Н. Арсланов иҗаты турында сөйләгәндә аның тәрҗемә өлкәсендәге хезмәтләрен әйтми китү мөмкин түгел. Кемнәрне һәм нинди әсәрләрне генә тәрҗемә итмәгән ул! Аның ихтыяры һәм хезмәте нәтиҗәсендә Пушкин белән Лермонтов та татарча телгә килгән. Тагын Байрон, Гете, Шелли, Беранже, Хәйям, Хафиз, Мәхтүм Колый, Токтогул, Райнис, Гамзатов... Төрле заманда иҗат иткән төрле халыкларның зур шагыйрьләрен белү, аларның поэтик фикерләре белән эш процессында ныклап танышу, өйрәнү, чагыштыру шагыйрьнең үз иҗади йөзе формалашуында, һичшиксез, зур бер уңай фактор булган. Шагыйрьнең иҗатын өстән генә карап чыкканда күп гасырлык поэтик арсеналның нинди формаларын гына очратмыйсың! Шунысы шәп: төрле үлчәмнәрдә дә тел табигый һәм шигъри матур яңгырый. Тел дигәннән, бер яшь иптәш егет белән сөйләшү хәтергә килде. Ул болай дигән иде: «Нури агайның шигъри теле беркадәр кадимирәк». Әлбәттә, төрки телнең нигезен юньләп белмәсәң, шәрык шигъриятен белүең дә чамалы булса, андый уй килергә мөмкин. Менә бер генә мисал:

> Булса синдә Әфләтунның акылы,
> Садәлеге керсез сабыйның,
> Дәрвишлеге Хуҗа Насретдинның,
> Исәрлеге Мәшрәп сафиның,
> Телгә оста булсаң Чичән кебек,
> Уйга — йөгерек, дала атыдай,
> Гаделлектә Нәүширваннан гадел,
> Юмартлыкта булсаң Хатом-Тай...
> Анда да син камил түгел, шагыйрь!
>
> *(«Шагыйрьгә»)*

Монда инде аңлау-аңламау синең белемеңә, эрудицияңә бәйле. Ә телгә килгәндә, Н. Арсланов, минемчә, төрки телнең бөтен нечкәлекләрен иң нык белгән һәм иҗатында бу белүне иң уңышлы файдалана торган шагыйрьләребезнең берсе. Гомумән, әдәби сурәтләү чараларының байлыгы ягыннан аның иҗаты аерым өйрәнергә, аерым хезмәткә лаек. Максатыбыз шагыйрь иҗатына гомумирәк күз ташлау, барлау булганга һәм мәкаләнең күләме сыйдырмаганга күрә, табигый, шагыйрьнең әдәби осталыгы мәсьәләләренә бик тәфсилләп тукталa алмадык. Гадәттә, чыгышның ахырында нәтиҗәләр белән очлыйлар. Мин алай эшләмәскә булдым, чөнки шагыйрь турында нәтиҗәләр ясарга иртәрәк әле. Ул көннән-көн иҗади яшәрә бара, ул үсештә. Шуңа да ашыгыбрак ясалган нәтиҗәләр тиз искерергә мөмкин. Н. Арсланов иҗаты турында шушы уй-фикерләремнән соң, әйдә, шагыйрьнең үз сүзләрә дәвам итсен!

> Тумаганнар тусын бәхете белән,
> Ирекләләр җирдә ишәйсеннәр;
> Туганнары имин яшәсен:
> Баш өстендә кылыч яшьнәмәсен,
> Татулыкта дөнья яшәрсен.
>
> Кайтмаганнар кайтсын илләренә,
> Бәгырьләргә бәллүр булып яткан
> Сагыш тәерә, яшьләр эресен.
> Ленин рухы иңсен күңелләргә —
> Йөрәкләрдә ташлар эресен.
>
> Үлгәннәрнең урыны тыныч булсын,—
> Табутында сыкрап кыйналмасын —
> Яшәүчеләр эшенә наразый.
> Безнең кебек түгел, камил булып
> Үссен иде барлык нарасый.

**Рафаэль Мостафин**

# ТЕМА, ИДЕЯ, ӘДӘБИ ОСТАЛЫК

*Совет власте елларында татар әдәбияты зур уңышларга иреште. Аның социалистик чынбарлык белән, халык тормышы белән бәйләнеше тирәнәйде, идея һәм сәнгать камиллеге үсте, авторитеты бик нык күтәрелде.*

*Татар совет әдәбияты ирешкән уңышларда прозаикларыбызның зур өлеше бар. Татар прозасы укучыларның ихтирамын казанды, күп кенә уңышлы әсәрләре белән бөтенсоюз аренасына чыкты. Әмма прозаикларыбыз язган барлык әсәрләр дә әдәбият алдына куелган зур таләпләргә җавап бирерлек дип әйтеп булмый.*

*Шуны истә тотып, «Казан утлары» редакциясе бүгенге татар прозасының үсеш юллары турында фикер алышу уздырырга булды. Татар язучыларының роман, повестьларында һәм хикәяләрендә бүгенге чынбарлык, замандашларыбызның героик тормышы һәм эшләре никадәр тирән һәм тулы чагыла? Соңгы елларда басылган әсәрләрнең көчле һәм көчсез яклары нәрсәдә? Проза өлкәсендә яшәп килгән кимчелекләрдән ничек котылырга?.. Фикер алышу барышында күп кенә мәсьәләләр ачыкланыр дип ышанабыз. Бәхәсне тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин мәкаләсе белән башлыйбыз. Тәнкыйтьчеләрне, язучыларны һәм укучыларны фикер алышуда катнашырга чакырабыз.*

***РЕДАКЦИЯ***

## ТАЛӘПЛӘР МӘСЬӘЛӘСЕ

Шушы елның февраль урталарында Язучылар союзы каршындагы проза секциясенең чираттагы утырышы булып узды. Анда өч яшь прозаикның 1971 елда китап булып чыккан яңа әсәрләре тикшерелде. Ипле генә башланган утырыш тора-бара шактый шау-шулы, гаугалы төс алды. Тикшерүгә куелган әсәрләрне берәүләр бөтенләй тетеп, туздырып ташладылар, икенче кешеләр исә, киресенчә, яклап һәм хуплап чыктылар.

Шул чак трибунага күренекле прозаик Әмирхан Еники күтәрелде. «Сезне тыңлап утыра торгач, үзем дә буталып беттем, ахрысы,— дип башлады ул сүзен.— Бер яктан карыйсың, тикшерүгә куелган әсәрләр ярыйсы кебек, икенче яктан килеп карыйсың — начарлар... Нинди таләпләрдән чыгып якын киләсең бит. Таләпнең зурысын куеп карасаң, алар начар. Күнегелгән гадәт буенча, «ярый инде»гә кайтарып калдырсаң, алар чыннан да түзәрлек шикелле».

«Ярый инде»... 1971 елда «Казан утлары» журналында басылган проза әсәрләре белән танышканда, мин еш кына әнә шул сүзләрне искә төшердем. Чыннан да, иҗат практикабызда без ниндирәк таләп-критерийларга таянып эш итәбез? Бакламыйбызмы без аларны, матбугатта чыга торган әсәрләрнең сыйфатына таләпчәнлекне киметмибезме?

Әдәби әсәрләргә бәя биргәндә, без төрле критерийлардан чыгып эш итәбез. Шуларның иң нык таралганы, мөгаен, тематик критерийдыр. Яңа китап турындагы сүзне, кагыйдә буларак, һәр рецензент әсәрнең темасын ачыклаудан башлап җибәрә. Эш планнары төзегәндә, редакция һәм нәшрият хезмәткәрләре үзләренә кергән кульъязмаларның нинди темага язылган булуына карыйлар. Бу бик табигый һәм аңлашыла торган нәрсә. Чөнки әсәрдә дистәләрчә, йөзләрчә еллар элек булып узган тарихи вакыйгалар турында сүз барамы, әллә бүгенге көннең иң мөһим күренешләре тасвирланамы, язучы тормыштагы

вак, интим нәрсәләр тирәсендә әйләнәме, әллә заманның зур проблемаларын күтәрәме — безнең өчен барыбер түгел.

Инде мәсьәләгә, әнә шулай, тематик яктан гына карап якын килсәк, 1971 елгы прозабызның хәле яхшы, хәтта бик яхшы, дияргә була. Чыннан да, узган ел «Казан утлары» журналы битләрендә ике зур роман басылып чыкты, аларның һәр икесендә республикабыз территориясендә барган гигант төзелешләр турында сөйләнә. Сәббух Рафиковның «Тын елга буенда» исемле романы Европада иң зурлардан саналган Зәй ГРЭСын төзүчеләргә багышланган. Әхсән Баяновның «Ут һәм су» романы Кама ГЭСын һәм Кама автомобиль заводын төзүчеләр турында. Мөсәгыйть Хәбибуллинның «Икмәк кадере» исемле повестенда табигатьне, табигый байлыкларны саклау мәсьәләләре күтәрелә, анда без бүгенге көн кешеләре: партия эшчеләре, нефть промыселларының җитәкчеләре, колхоз председательләре белән очрашабыз. Барлас Камаловның «Ялыкмаслар» исемле повестенда райком секретаре турында, аның тынгысыз хезмәте һәм тормышы турында сөйләнә. Фатих Хөсни үзенең «Мәйдан» исемле повестенда республикабызның авыл хуҗалыгында барган зур үзгәрешләр, барыннан да бигрәк, шул үзгәрешләрне тормышка ашырган кешеләр турында яза. Гариф Ахуновның «Чикләвек төше» һәм Габдрахман Әпсәләмовның «Идел хикәяте» исемле повестьларында теләсә нинди сынауларны һәм кыенлыкларны җиңеп чыгарга сәләтле, тормыштагы һәр нәрсә өчен җавап бирүдән курыкмый торган чын кешеләр, чын коммунист образлары тасвирлана. 1971 елда журнал битләрендә басылган хикәяләрнең дә күпчелегендә бүгенге көн кешеләре, бүгенге көн мәсьәләләре турында сөйләнә.

Шулай итеп, күрәсез, проза йөз белән заман темасына борылды. Әле кайчан гына язучылар арасында сугыш елларындагы һәм сугыштан соңгы кыенлыкларны күпертеп сурәтләргә яратучылар бар иде. Аерым әсәрләрдә рухи гарип, әхлак ягыннан тотнаксыз геройларга мәйдан бирелә иде. Бүген татар язучылары иҗатында андый кимчелекләр очрамый диярлек. Моны бары хупларга гына кирәк.

Әйе, бүгенге прозаны актуаль темалардан, чорның иң зур проблемаларыннан артта калуда гаепләргә нигез юк. Аның каравы, прозаның икенче бик җитди кимчелеге — күпчелек әсәрләребезнең профессиональ яктан түбән сыйфатлы булулары ныграк сизелә башлады.

Шулай бервакыт тегү фабрикасында инженер булып эшләүче танышымны очраттым. Ул татар әдәбиятын бик ярата, шуңа күрә яңа әсәрләрне карап-күзәтеп бара торган кеше. Әдәби әсәрләрне бәяләүдә аның үз критерийлары бар икән. «Арып эштән кайтасың да, бераз ял итү, какшаган нервларны тынычландыру өчен, кулга китап я журнал аласың, ди. Әгәр әсәр яхшы икән, аннан төн урталарына кадәр аерыла алмыйсың. Инде уртача гына булса, ике-өч бит укуга, хет үтер, йокы килә башлый. Узган ел журналда чыккан бер генә романны да ахырга кадәр укып чыга алмадым», дип сүзен тәмамлады ул.

Бераз соңрак Баулы районындагы бер китапханә эшчесе белән дә шул ук мәсьәлә хакында сөйләшергә туры килде. Озак еллар укучылар белән эшләү дәвамында аның шулай ук әдәби әсәрләргә карата үз критерийлары калыплашкан. Китапханәченең сөйләвенә караганда, кызыклы яңа әсәр турындагы хәбәр, нинди дер юллар аша, көне-сәгате белән укучылар арасына тарала икән. Матбугатта ул әсәр хакында әле берниндн рецензия чыкмаган, әсәрне хәтта китапханә эшчеләре үзләре дә укып чыгарга өлгермәгән, укучылар инде журналның шул саннарын укырга чиратка язылалар, бер генә төнгә булса да биреп торыгыз, дип ялваручылар күбәя, журнал кулдан-кулга йөри башлый. Тузып, эштән чыгып бетмәсен өчен, журналның андый саннарын махсус төпләтеп алырга туры килә. «Ләкин узган ел сенсация ясарлык әсәрләр булмады,— диде ул.— Әнә карагыз: журналның 1971 елгы саннары киштәләрдә кул тимәгән килеш диярлек тора».

Күрәсез, узган елгы прозабызның хәлләре алай ук шәптән түгел икән. Беренче карашка нихәтле генә мөһим күренмәсен, сәнгать әсәрен ныклап бәяләү өчен тематик критерий гына җитми, сәнгатьчә эшләнеше йомшак булган әсәрне тема актуальлеге генә коткара алмый икән.

Кызганычка каршы, көндәлек иҗат практикасында кайбер авторлар тема актуальлеген әсәрләренең сәнгатьчә зәгыйфьлеген яшереп калдыру өчен калкан итеп файдаланырга тырышалар. Тагын шулай да була, актуальлектән файдаланып, иң мөһим, иң зур темаларга кайвакыт бөтенләй талантсыз кешеләр алына. Ләкин, үзләре тотынган теманы сәнгатьчә чишәргә көчләре җитмәгәнгә күрә, алар актуаль теманы бозалар,

укучылар алдында аның дәрәҗәсен төшерәләр. Кайчак актуаль темаларга тотынган авторларга ташлама ясарга, аларны яклап калырга чакыручылар очрый. Партия шулай куша, дип җибәрәләр алар. Ләкин кайчан, партиянең нинди документларында мөһим, һәммәбез өчен изге темаларны түбән сыйфатлы итеп эшләсәң дә ярый, диелгәне бар? Мин андый документны белмим. Киресенчә, партия Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карарында матбугатта чыга торган әсәрләрнең сыйфатына карата таләпчәнлекне арттырырга, халтурага, модный тема белән спекуляция ясарга маташучыларга каршы көрәшне көчәйтергә кирәк, диелә. Л. И. Брежневның партиянең XXIV съездында ясаган докладында әдәбият-сәнгатьнең хезмәт ияләрен коммунизм рухында тәрбияләүдәге роленә югары бәя бирелә, шуның белән бергә, әдәбият-сәнгатьнең бүгенге хәленә карата җитди тәнкыйть сүзләре дә әйтелә:

«Ләкин художество иҗаты өлкәсендә, бигрәк тә иҗат ителгән әсәрләрнең сыйфатына килгәндә, бөтенесе дә әйбәт дип әйтеп булмый. Бездә әле һаман да эчтәлеге ягыннан сай, формасы белән кызыксыз әсәрләрнең дөньяга чыгуын әйтеп үтәргә рөхсәт итегез. Кайчагында хәтта шулай да була: әсәр яхшы, актуаль темага багышлана, ләкин художник үзенең бурычына артык җиңел караган, хезмәтенә үз талантының бөтен көчен салмаган дигән тәэсир туа. Без барыбыз да сәнгать работникларыннан үзләренә һәм үзләренең профессиядәш иптәшләренә карата таләпчән булуларын көтәргә хакыбыз бар дип уйлыйм».

Әгәр узган елгы әдәби әсәрләргә партия куйган таләпләр югарылыгыннан торып якын килсәк, әгәр ул әсәрләрне темаларының актуальлеге ягыннан гына түгел, бәлки күтәрелгән темаларның сәнгатьчә эшләнешләре, ничек хәл ителүләре ягыннан да бәяли башласак, 1971 ел проза өлкәсендәге иң төссез һәм чырайсыз елларның берсе булды, дияргә туры киләчәк.

## ТЕМА ҺӘМ АНЫҢ ЧИШЕЛЕШЕ

Безнең арадан вакытсыз киткән Сөббух Рафиковның «Тын елга буенда» романы турында сөйләве кыен. Татар әдәбиятын үстерү өчен байтак эш башкарган авторның фидакарь хезмәте һәм ул узган авыр тормыш юлы безнең күңелдә аңа карата тирән ихтирам һәм хөрмәт хисләре уята. Ләкин гаделлек хакына таныырга тиешбез: Фатих Хәсни «Социалистик Татарстан» газетасында бастырган мәкаләсендә бу романны авторның уңышсызлыгы дип бәяләде һәм ул хаклы иде. Хикмәт каләмдәш дустыбызның истәлеген хөрмәт итүдә генә түгел бит әле. Әсәр басылып чыккан икән, ул инде халык байлыгына, бөтен әдәбиятның уртак милкенә әйләнә. Һәм без аңа объектив бәя бирергә, әсәрнең уңышлы һәм кимчелекле якларын ачыклап үтәргә тиешбез.

Еш кына теге яки бу әсәрнең йомшак эшләнүен авторның үзе яза торган тормышны җитәрлек белмәве белән аңлаталар. Бу очракта алай дияргә урын юк. Автор күп еллар буе Зәйдә торды, көн саен геройларының тормышын һәм ихтыяҗларын белеп яшәде. Әйтергә кирәк, романда төгәл тотып алынган детальләр күп, тәзүче хезмәтенең технологиясен белү сизелә, икенче пландагы персонажлар арасында уңышлы гына эшләнгән образлар бар. Ләкин бит сәнгать тормышны көзгедәге кебек чагылдырып кына калмый, ул аны әдәби образлар аша гәүдәләндерә. Чын художник тормыш фактларын фотографияләү, аларны рәттән теркәп бару белән чикләнми, ул тышкы тәэсирләрне иҗат фантазиясендә эретеп чыгара. Тормышны тирәнрәк ачу, аңа карата үз мөнәсәбәтен белдерү өчен, язучы реаль прототиплардан ераклаша төшә, тормышта чыннан да булган фактларны үзгәртебрәк сурәтли. Борынгы акыл ияләренең берсе: хакыйкатьне әйтү өчен художник ялганнарга мәҗбүр, дигән. «Тын елга буенда» романының авторына нәкъ менә шул нәрсә: тормыш фактларын иҗат фантазиясе аша уздыру сәләте, сәнгатьчә ышандырырлык, тулы канлы образлар иҗат итү осталыгы җитмәгән. Аның иҗади фикере «производство романнары» дип яман аты чыккан әсәрләргә хас, тапталган, әзер юлдан киткән.

Тәзелешкә Васил Сафин дигән энергияле яшь инженер килеп төшә. Килеп төшүе була, аңа кадәр беркем дә күрмәгән яки күреп тә исе китмәгән кимчелекләргә күзе төшә, шунда ук аларга каршы көрәшә дә башлый. Конфликтның икенче очында — баш инженер Юлдашев, ул Сафинның һәр яңа тәкъдименә, хәтта файдалы икәне әллә кайн күренеп торганнарына да, каршы килә тора. Әсәрне укыганда, мин аның Сафинга ни өчен адым саен аяк чалуын аңлый алмый аптырап беттем. Әгәр Юлдашев, автор раслаганча, үтә чыккан карьерист икән, логика кануннары буенча фикер йөрткәндә,

ул Сафин керткән тәкъдимнәрнең берничәсен генә булса да якларга тиеш иде ләбаса. Чөнки төзелештә эшләрнең уңышлы баруы аңа файда гына бит. Юлдашев исә атлаган саен Сафинга каршы төшә, әйтерсең аның төзелешкә үзе чакырып китергән шушы талантлы яшь инженерны сагалап йөрүдән башка эше дә юк. Ахыр килеп, ниһаять, аңлашыла башлый: Юлдашевның амплуасы шундый икән ләбаса. Авторның алдан корып куйган планы буенча ул консерватор булырга тиеш, шуңа күрә һәр яңалыкка каршы төшеп бара да.

Роман дәвам итә, конфликт кискенләшә бара, Сафинны җитди күңелсезлекләр көтә, аңа каршы көрәштә Юлдашев кайбер райком кешеләрен үз ягына аударып өлгерә. Әмма мәсьәләгә партком секретаре Сабировның килеп катнашуы була, барлык кыенлыклар җиңел генә хәл ителә дә куела. Әшәкелек (Юлдашев) җәза ала, гаделлек (Сафин) тантана итә.

Дөрес, Сафинның шәхси тормышында күңелсезлекләр килеп чыга. Хатыны, шәһәрдәге уңай квартирасын калдырып, төзелешкә күчеп китәргә теләми. Эш аерылышуга кадәр барып җитә. Ләкин автор Сафинга алдан ук сөйкемле һәм чибәр яшь кыз хәстәрләп куйган икән. Шулай итеп, роман ахырында төп героебызның шәхси тормышы да рәткә салына.

Гадәтләнгән сюжет алымнары, үзәк геройларның шаблонлыгы, тормышчан, җитди конфликтларны җиңелчә хәл итү — менә нәрсәләр боза бу романны.

Шундый сорау туа: әсәр үзе әдәби яктан зәгыйфь булгач, аның идеяләре һәм проблемалары мөһим булырга мөмкинме икәнни? Бу сорауга ничек җавап бирү әсәрнең идея юнәлеше дигән төшенчәне ничек аңлауга бәйләнгән. Нәрсә ул идея юнәлеше? Авторның яхшы ниятләре генәме, әллә шул ниятләрнең тормышка ашырылуы — әдәби әсәр үземе?

Марксистик әдәбият белемендә бу сорауга күптән төгәл җавап бирелгән. Сәнгать әсәрендә идеологик категорияләр эстетик категорияләр аша тормышка ашырылалар. Шул рәвешчә, язучының идея позициясе аның теге яки бу әсәр аша нәрсә әйтергә теләве белән генә билгеләнми. Хикмәт, барыннан да элек, әсәрнең укучыларга ничек тәэсир итүендә, аларда нинди хис-тойгылар уятуында икән.

Автор идеясе ул — әсәрнең ахырында бирелгән мораль, алдан уйлап куелган әзер тезислар гына түгел. Сәнгать әсәренең идеясе ул — әлеге әсәрнең укучы аңына ясаган тәэсире, хикәяләүнең бөтен барышы, сурәтләү чараларының бөтен арсеналы белән укучыларның игътибарын җәлеп итәргә тиешле фикер һәм нәтиҗәләр дигән сүз. Димәк, сәнгатьчә эшләнеше ягыннан зәгыйфь әсәр югары идеяле була алмый.

Романдагы төп уңай образны тикшереп карыйк. Ул авторның иң яратып тасвирлаган образы. Әсәрнең буеннан-буена язучы аны гел яхшы яктан күрсәтергә тырыша, ул аның булдыклы булуына, кешеләр белән сөйләшә белүенә, кыюлыгына, принципиальлегенә, мәхәббәттәге тугрылыгына басым ясый, башка бик күп уңай сыйфатларын саный. Ләкин әлеге уңай сыйфатлар кәгазьдә генә калалар, образ белән бер бөтен булып кушылмыйлар. Хикмәт, күрәсең, шундадыр: С. Рафиков сәнгатьнең бер мөһим закончалыгын искә алмаган. Ул укучыларның аңына һәм йөрәгенә эмоциональ тәэсир ясарга тиешлеген хәтердән чыгарган. Сафин образына сәнгатьчә ачыклык, калкулык һәм тулы канлылык җитми. Ул ничектер сүлпән, төссез чыккан, шуңа күрә безнең күңелдә тирән мәхәббәт тә, артык зур симпатия дә уята алмый.

Менә әсәрдән кечкенә бер эпизод. Катгый сөйләшү, гаилә мәсьәләсен тәмам хәл итү өчен, Васил хатыны Нурзилә яшәгән шәһәргә килә. Аның үз сүзләре белән әйткәндә, хатыны белән соңгы тапкыр сөйләшү, «көймәне урталыктан алып, я уң якка, я сул якка» чыгару өчен килә. Әле подъездда ук аңа «төз гәүдәле, борын астыннан гына калдырып мыек җибәргән» бер шикле бәндә очрый. Квартирасына килеп керсә, анда балта асып куярлык төтен, көл савыты тулы тәмәке төпчекләре. Дөрес, Нурзилә үзем тартам дигән була һәм шунда ук папирос кабызып җибәрә. Ләкин моны ул шулкадәр рәтен белми эшли, кабуга йөткерә, тончыга башлый. Эшнең шикле икәнен хәтта бала да сизәрлек.

Нурзилә төнге дежурга китә. Ул киткәннән соң ире кием шкафын ачып караса, анда ят әйберләр: саргылт төстәге болоний плащ һәм соңгы модадагы сай гына ирләр эшләпәсе. Актарына торгач, ул гаилә альбомыннан нечкә мыеклы, төз гәүдәле бәндәнең курортта Нурзилә белән төшкән фотосын да таба.

Шуларның һәммәсе Василга нинди тәэсир ясый соң? Менә карагыз:

«Очына барып чыкмаслык әллә нинди

авыр исәпләр башын кайнатудан ул озак кына йокыга китә алмый ятты. Әмма күзен бер йомгач, йокысы татлы булды» («Казан утлары» журналы. 1971 ел. 5 сан. 65 бит.). Шушы бер җөмләдән үк, автор телиме-юкмы, Василның үз йортындагы хәлләргә артык борчылмавы сизелеп тора. Шулай булмаганда, ай-һай, аның йокысы болай татлы була алыр идеме икән?

Иртә җитә. Нурзилә тиешле вакытта дежурдан кайтмый. ...Васил нәкъ иртәнге алтыда сикереп тора. Мәскәү радиосы командасын тыңлый-тыңлый, физзарядка ясый. Бер дә ашыкмыйча, бер дә исе китмичә генә озаклап салкын су белән бил тиңентен тәнен юа. Чәй эчә. Вакыт-вакыт сәгатенә күз төшереп алырга да онытмый... Автор Васил хатыны белән булган хәлне бик авыр кичерә дип ышандырырга күпме генә тырышмасын, укучы моңа ышанмый.

Ярый, мәхәббәт хисе сүнсен, Васил күңелендә башка хисләр уянсын ди. Ә бит ул шушы хатын белән ничә ел бергә яшәгән, шул хатын аның яраткан улының әнисе дә бит әле. Һәм төп геройның бу салкынлыгы укучыларны да Василның язмышына карата битараф калдыра.

Партком секретаре Сабиров образы тагын да төссезрәк чыккан. Автор безгә аны һәркемне үтәли күрә торган, беркайчан да ялгышмый торган кеше дип тәкъдим итә. Сабировның бер күреп сөйләшүе була, Карчыга кебек иң ялкау, иң начар кеше дә шунда ук төзәлә, адәм рәтенә керә. Ләкин образга мөлаемлык, кешечә җылылык җитми. Ул күңелгә ятмый, шуңа күрә хәтердә дә калмый. Романдагы Сабиров автор хыялындагы образдан, ул күрсәтергә теләгән образдан нык аерыла. Соңгысы күпкә кайтышрак.

Художникның осталыгы һәм идеялелеге, барыннан да ачыграк булып, нәкъ менә әдәби образда чагыла. Әйтик, Г. Бәшировның «Намус» романындагы Нәфисә образы характер бөтенлеге, күңел сафлыгы, Ватанга чиксез бирелгәнлеге белән дә аерылып тора. Әгәр Г. Бәширов аны шундый осталык һәм сәнгатьчә нәфислек белән иҗат итә алмаган булса, образның тәэсир көче нык кимер һәм аның иҗтимагый яңгырашы да кечерәер иде. Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повестендагы Галия образы, М. Җәлилнең «Моабит дәфтәре»ндәге лирик герой образы турында да шул ук сүзләрне әйтергә мөмкин. Димәк, сәнгать әсәренең идеясе үзенә аерым хәлдә яшәми һәм аның укучыга тәэсир көче дә форма ягыннан никадәр камил булуына бәйле икән. Югарыдагы мисаллар тагын бер тапкыр әнә шул фикерне раслыйлар.

## ЯҢА ЗАМАН, ЯҢА ТАЛӘПЛӘР

Алда бер тапкыр әйтелде: хикмәт әдәби әсәрләрне бәяләгәндә тәнкыйтьченең нинди критерийларга таянып эш итүендә. Бездәге тәнкыйть мәкаләләрендә, бигрәк тә рецензияләрдә, әдәби әсәр еш кына гомуми әдәби хәрәкәттән аерым тикшерелә. Мондый алым иң яхшы дигәндә укучыга әсәрнең эчтәлеге турында хәбәр итәргә, аның нииндидер уңай һәм җитешсез якларын күрсәтергә мөмкинлек бирә. Әсәр әдәбиятка нинди яңалык алып килә? Ул сәнгатьчә сурәтләү чараларын һәм образлар галереясын нинди яңалык белән баета? Ниһаять, автор кайда башкаларны кабатлый, китаптагы кайсы яклар аның үзенеке? Әсәрне әдәби процесстан аерып тикшергәндә бу сораулар җавапсыз кала.

Еш кына яңа китап шул ук авторның элекке әсәрләре белән чагыштырып тикшерелә. Мондый алымны бер адым алга китү дип санарга була. Ул язучының үсеш перспективасын күрергә, язучы үсәме, әллә бер урында таптанамы — шуны билгеләргә мөмкинлек бирә. Әмма безне бу алым да канәгатьләндереп җиткерми, чөнки урта кул авторның үз иҗатында бер адым алга китүе бөтен әдәбият ирешкән югарылыктан чыгып караганда күпмедер артка китү булып чыгарга мөмкин.

Кайбер чакта язучылар үз әсәрләрен башкаларныкы белән чагыштырганга ризасызлык белдерәләр. Янәсе, бу чагында авторның индивидуаль йөзе югала. Ләкин бит әсәрне бәяләү — бу инде үзе үк чагыштырып карау дигән сүз. Шунсыз әдәби әсәргә төгәл, дөрес бәя биреп булмый.

1971 елда «Казан утлары» журналында басылып чыккан икенче романга — Әхсән Баяновның «Ут һәм су» романына мөрәҗәгать итик. Әгәр аны авторның үз иҗат рамкасы кысаларында гына алып карасак, шикләнми әйтергә була, заманның актуаль мәсьәләләренә мөрәҗәгать итү Ә. Баяновка үз палитрасын баетырга һәм төрләндерергә ярдәм иткән. Моңарчы язган әсәрләрендә кимчелекле геройларга, тормышның кара якларына күбрәк игътибар бирелә иде. Бу җәһәттән «Ут һәм су» романын Ә. Баянов иҗатында борылыш этабы дип санарга була. Анда без бүгенге көн кешеләре, зур төзелештә эшләүчеләр, кызыклы

һәм үзенчәлекле характерлар белән очрашабыз. Инде шул ук романны үзебезнең һәм бөтен совет әдәбиятының казанышлары белән чагыштыра башласак, «Ут һәм су» романының зур таләпләрдән шактый ерак торганын күрербез.

Кызганычка каршы, Ә. Баянов та әзер штамп һәм схемалардан котыла алмаган. Бер ел дәвамында бер үк журнал битләрендә басылган әлеге романнарның хәтта сюжет төзелешендә дә уртак әйберләр байтак. Тегесендә дә, бусында да төп герой — эшкә атлыгып торган, энергияле яшь инженер. Сөббух Рафиковта ул участок башлыгы, ә Әхсән Баяновта — СМУ башлыгы. Тегесендә дә, бусында да төп герой төзелешнең баш инженеры белән конфликтка керә. һәр ике романда сюжетның югары ноктасын бәхетсез очрак — бер эшченең биектән егылып төшүе билгели. Аерма шунда гына, С. Рафиков романында егылып төшкән кеше үлә, Ә. Баяновныкы могҗиза белән исән кала. Тегендә дә, монда да гаепне төп герой өстенә аударырга тырышалар. Әмма ахырдан төп геройларның гаепсез булуы ачыклана. Яңалыкка аяк чалучы баш инженерлар эштән алына, төп геройларны исә тагын да югарырак яңа постлар көтә.

Романнар редакциягә бер үк вакытта диярлек кергәннәр. Хикмәт шунда гына, ике авторның да фикере бер юнәлештәрәк эшләнгән, алар әзер схемалар кысасыннан котыла алмаганнар. Әмма моннан укучыга ни җиңеллек!

Билгеле, Ә. Баянов романын югарыда сөйләнгән сюжет калыбына гына кайтарып калдырырга ярамый. Әсәрдә катлаулы, тормышчан проблемалар да, кызыклы тотып алынган образлар да бар. (Безнең әдәбият өчен, мәсәлән, Борис Филинов шактый кызыклы образ, ул аерып алып, махсус тикшерүгә лаек.) Ләкин күтәрелгән проблемалар һәм конфликтлар ахыргача чишелмәгән, образларның эчке логикасы эзлекле сакланмаган. Ә бит Ә. Баянов — сәләтле һәм өметле язучы. Аңа карата таләп тә зуррак. Шуның өчен романда адым саен очрап торган төгәлсезлекләр белән һич кенә дә килешәсе килми.

Гаделлек йөзеннән әйтергә кирәк, минем бу романга биргән бәям барлык кешегә дә ошап җитмәде. Әдәби ел йомгакларына багышланган җыелыш узып, күп тә тормады, проза секциясенең чираттагы утырышы булды. Әлеге утырышта язучы Б. Камалов «Ут һәм су» романын авторның җитди уңышы дип бәяләде. Белмим, әсәргә бәя биргәндә ул нинди критерийларга таянып эш йөрткәндер? Әмма факт факт булып кала: бу мәсьәләдә ул минем белән килешмәвен әйтте. Мин үзем тәнкыйтьченең бурычы авторга дусларча мәдхия җырлаудан бигрәк, аннан тулы көчкә эшләвен таләп итүдә дип уйлыйм.

Татар әдәбиятының зур һәм бай традицияләре бар. Совет власте елларында ул культурабызның алтын фондына керерлек әсәрләр белән баеды, безнең үз классикабыз барлыкка килде. һ. Такташ шигырьләре һәм М. Җәлилнең «Моабит дәфтәре», Х. Туфан һәм Ф. Кәрим, Ә. Фәйзи һәм С. Хәким шигырьләре, Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ы һәм М. Әмирнең «Агыйдел»е, Г. Бәшировның «Намус»ы һәм Ф. Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы» шундый әсәрләр рәтенә керә. Кызганычка каршы, соңгы елларда шушы исемлекне тулыландырырлык, һич югы, шулар югарылыгында торырлык әсәрләр язылмады диярлек. Безнең язучылар начаррак яза башлады, дип әйтергә җыенмыйм. Хикмәт анда түгел. Тик заман, таләп һәм бурычлар үзгәрде. Шуңа күрә дә классиклар югарылыгына күтәрелү өчен аларны кабатлау гына җитми, башкача язарга, заманга хас сурәтләү чаралары эзләргә һәм табарга кирәк. Безгә хәзер заманны тулы һәм сәнгатьчә дөрес сурәтләгән әсәрләр, идея көче һәм фәлсәфи тирәнлеге ягыннан да, әдәби эшләнеше ягыннан да иң зур таләпләргә җавап бирерлек әсәрләр кирәк.

Аннан соң күркәм традицияләр зур бурычлар да йөкли, алар, барыннан да элек, бездән таләпчән булуны, халтурага, чиле-пешле әсәрләргә юл куймауны сорый. Татар совет классикасының иң яхшы үрнәкләре басылган журналда, Ө. Шаминның «Өметле шайтан», С. Сабировның «Фирдәвес» хикәясе кебек, җитди әдәбият белән бернинди уртаклыгы булмаган әйберләр дә урын алып килә икән, бу безне борчымый кала алмый.

Соңгы вакытларда бездә художникның пафосы, аның ялкын көче кебек эстетик категориягә игътибар кими төште. Художникның пафосы — ул аның нәрсәгә бирелгәнлеге, нәрсә өчен көрәшүе, үз әсәрләрендә нинди идеяләрне яклавы дигән сүз. Димәк ки, язучының пафосы аның идея юнәлешеннән, әдәбиятның партиялелеге һәм халыкчанлыгы кебек төшенчәләрдән аерым яши алмый булып чыга.

С. Сабировның шул ук «Фирдәвес»

исемле хикәясен укыйсың да, шушы хәтле озын хикәя ни өчен язылды икән, аның төп идеясе нинди икән, дип аптырап утырасың. Хикәянең төп герое, елгачы егет, пляжда ятканда бик чибәр һәм сөйкемле бер кызны очрата, шунда ук аңа гашыйк та була. Ахырдан бу кыз бик очраклы төстә егетебез практика уза торган пароходка эшкә урнашкан булып чыга.

Автор хикәясенең сюжетын примитив алымнар белән төзи, очраклык өстенә очраклык өя. Әйтик, әлеге кызның «кияү егете» һәм, өстәвенә, баласы бар икән. Автор ихтыяры белән, кияү кеше шулай ук әлеге пароходка эләгә. Шуннан пароходта очраклы төстә пожар чыга. «Кияү», әлбәттә, куркак булып, төп образ исә, киресенчә, герой булып чыга, суга бата язган баланы коткарып кала. Кыз аңа үзен һәм йөрәген ышанып тапшыра. Ниһаять, иң ахырдан гына ачыклана: бала аның үзенеке түгел, ә үлгән апасыныкы икән... Әгәр без таләпләрне болай кимәтә башласак, әдәбиятны примитивлык һәм халтура басып китәчәк.

Кызганычка каршы, бездә анык идеясе һәм тирән фикере булмаган, сүлпән, хиссез язылган әсәрләр күп басыла. Ә бит чын ялкын белән сугарылган әсәрләр генә сәнгать әсәре була ала.

## ЯҢА ГЕРОЙЛАР ЭЗЛӘГӘНДӘ

Билгеле, мин прозаның хәле бөтенләй үк начар дияргә җыенмыйм. Бу нигилизмнан һәм булган кадәр байлыкны әрәмшәрәм итүдән башка нәрсә булмас иде. Миңа бары сүзне безнең калын журналыбыз таләпләренә җавап бирә алмый торган, бу хәлендә укучыларга тоттырырга ярамый торган әсәрләрне тикшерүдән башлап китәргә генә туры килде.

Алар белән янәшә журнал битләрендә чын сәнгать әсәре дип курыкмый сөйләрлек әсәрләр дә урын алган. Әлбәттә, ул әсәрләрнең дә үзләренә хас кимчелекләре, бәхәсле урыннары бар, ләкин болары инде башка характердагы, һәр сәнгать әсәрендә табылуы мөмкин булган кимчелекләр.

Даими төстә уңай герой, бүгенге көн кешесен эзләү — совет әдәбиятындагы иң матур традицияләрнең берсе. Коммунизм җәмгыяте төзүче замандашыбыз ниндирәк кеше? Аның характерында нинди үзгәрешләр бар? Аның интеллектуаль дөньясы ничек байый? Талант һәм сәләт дәрәҗәсенә карап, һәр язучы өнә шул сорауларга җавап табарга тырыша.

Алдынгы замандашыбыз образын гәүдәләндерүнең уңышлы бер мисалы төсендә, Гариф Ахуновның «Чикләвек төше» исемле повестена тукталасы килә. Исеме очраклы сайланмаган, язучы совет кешесенең рухи ныклыгын, партиячел принципиальлеген, идея ягыннан ышанганлыгын күздә тота. «Чикләвек төше» повесте исеме белән үк инде рухи гарип, чери башлаган яки эчен корт кимергән геройларны тасвирларга ярата торган әсәрләр белән бәхәскә керә кебек.

Язучы оригиналь алым сайлаган: хикәяләү повестьтагы төп геройның хатыны — Рокыя исеменнән алып барыла. Баштарак ул үз мәнфәгатен генә кайгыртып яшәргә гадәтләнгән тар, тынчу даирәдә үскән гади бер хатын булып күз алдына баса. Рокыяның бәхетне мещаннарча аңлавы белән иренең җәмәгать интереслары өчен кайгыртып йөрүе арасында кискен конфликт туа. Ире кылган гамәлләрнең күбесен Рокыя аңламый, хәтта аны битәрли, гомер буе аерылырга җыенып йөри.

Рокыя сөйләгән сүзләр, аның ирен хөкем итүе аша, дөресрәге, аның хөкем итүенә капма-каршы буларак, безнең алга һәр минут үз өстенә иң авыр эшне алырга әзер, кыю һәм принципиаль кешенең образы килеп баса. Әнә шундый гадәттән тыш шәхес тәэсирендә, акрынлап, Рокыя үзе дә үзгәрә, аның иренә булган мөнәсәбәте яхшыра, гаепләү, хөкем итү, соклану һәм чын мәхәббәт хисләре белән алмашына. Соңга таба инде ул югары оешмаларга, баштагы кебек, ире өстеннән жалоба белән түгел, ә аңарга ярдәм итү, аны хаксыз ялалардан яклап калу нияте белән йөри башлый.

Повестьның ахыры да көтелмәгәнчә тәмамлана: райком секретаре белән конфликтка кергән өчен, алдынгы колхоз председателе Саматовны эшеннән алалар. Беренче карашка, гаделлек аста кала, эшәкелек җиңеп чыга, тантана итә кебек. Ләкин бу — сюжет канвасының тышкы ягы гына. Председательне эшеннән алу мәсьәләсе каралган колхоз җыелышы безне нәкъ менә Саматов алга сөргән принципларның дөрес булуына ышандыра. Игътибар итегез: колхозчылар аның турында ничек яратып һәм үз итеп сөйлиләр, залдан ташланган һәр репликада Саматовка карата күпме мәхәббәт сизелә! Аның файдасына сөйли торган төп дәлилләр — колхозның уңышлары, ул бирегә килгәч ирешелгән

казанышлар. Алга таба ул бу колхозда эшләмәсен дә ди, ләкин ул һәрчак халыкка, партиягә кирәк кеше. Нинди генә урынга куелмасын, без аның һаман да талантлы оештыручы, принципиаль һәм кыю коммунист булып калачагына шикләнмибез.

Гариф Ахунов әсәрендәге мәсьәләләр күпмедер дәрәҗәдә Ч. Айтматовның «Хуш, Гөлсара»сы белән аваздаш яңгырый. Ләкин бу — тышкы охшашлык кына түгел. Бу — ике авторның да, ул никадәр генә ачы булып тоелмасын, хакыйкатьнең күзенә карарга омтылулары турында сөйли.

Г. Ахуновның повесте материалының дәреслеге, тормышчан булуы белән игътибарны тарта. Авторның үз сүзләренә караганда, аның нигезенә реаль кешенең чыннан да булган тормыш юлы салынган икән. Ләкин автор чынбарлык фактларына артыграк иярεп киткән кебек, бу исә повестьның сәнгатьчә бөтенлегенә зыян иткән. Әсәрдә вакыйгалар чамадан тыш күп, повесть герой тормышының артык зур чорын иңли. Халикъны без әле милиционер, әле юрист, әле тәрбияче, әле кадрлар бүлеге хезмәткәре, әле председатель буларак күрәбез. Укучының игътибары таркала башлый, бер пландагы эпизодлар бер-берсен кабатлыйлар, әсәрне хәтергә сеңдерү кыенлаша бара. Әгәр автор уңышлы табылган һәм тормышчан героен таррак участокта, герой тормышындагы кирәксез ваклыкларны төшереп калдырып, аны борылыш моментларында ачса, әсәр әдәби яктан отар гына иде.

Фатих Хөснинең «Мәйдан» повестендагы «Алсу алан» колхозы председателе Сәлим Ахунҗанов та эчке җылылык белән һәм ягымлы итеп тасвирланган образ. Язучы аны пьедесталга бастырмаган. Шулай да талантлы, сөйкемле, беренче карашка гади күренсә дә, бик үк гади дә булмаган җир кешесенең хәтердә калырлык җанлы образын тудыра алган.

Сабан туе күренеше гаҗәеп шәп язылган. Менә татарча көрәшне бик ярата торган председатель үзе дә көч сынашып карарга була. Дөресен әйтим, мин ул күренешне шактый шикләнеп укый башлаган идем. Хикмәт шунда, безнең кайбер язучылар, уңай геройларының дәрәҗәсен күтәрү өчен, аларны физик яктан да ифрат көчле кешеләр итеп бирергә яраталар. Андый герой берниндн әзерлексез сабан туенда көрәшеп батыр кала, берүзе унлап хулиганны тукмап ташлый, мәйдан буйлап тегермән ташы күтәреп йөгерә ала. Ләкин нәтиҗә киресенчә килеп чыга. Чама хисе булмаганлыктан, укучының авторга һәм әлеге геройга булган ышанычы какшый.

Фатих Хөсни бу юлдан китмәгән. Аның герое болай көчсез кеше түгел, ләкин сабан туенда батыр калу, ул хәтта бер колхоз буенча гына уздырылса да, җиңел эш түгел икән. Инде батыр калам дип ышанып беткәч кенә Сәлимгә каршы Таш елга авылыннан беркем белмәгән тракторчы егет чыга.

«Белгән кеше дип тә тормады Таш елга, биш баласы бар дип тә исе китмәде, ниһаять, «Председателем бит ул минем, соңыннан йомышым төшүе бар!» — дип тә курыкмады, Ахунҗановның үзе кебек, култык астына чумып, югалып та маташмады, алды биленнән кысып, чөеп күкрәк өстенә менгезде, бер мәл мәйданга күрсәтеп селкеп йөртте һәм... сау бул, председатель Ахунҗанов! Сау бул, ике йөз сумлык келәм, мәйдан «ух!» итеп гөжләде, ә председатель, бөтен мәктәп штангасын күтәреп җыйган мускуллары һәм батыр калырга чамалаган исәпләре белән бер якка чәчрәп барып төште» («Казан утлары» журналы. 1971 ел. 7 сан. 66 бит).

Шунысы мөһим, хурлыклы хәлгә калган председатель үзенең көндәшенә ачу сакламый. Киресенчә, колхозда таза, көчле егетләр үскәнгә чын күңелдән шатлана гына. Менә шулай башкалар шатлыгы өчен шатлана белү, бүтәннәр кайгысы өчен кайгыра белү, ихтимал, Сәлим образындагы төп сыйфат, аның характерының умырткасы сөягедер.

Истә калырлык тулы канлы образ тудыру — сәнгать әсәре алдына куела торган беренче шарт. Ф. Хөсни повесте бу шартка, һичшиксез, туры килә. Әгәр без әсәргә тагын да зуррак таләпләр куйсак, бу характер никадәр типик икән, дип сорасак, повесть андый таләпләргә җавап бирә алырмы?

Әсәрне укыганда мин гел бер хистән аерыла алмадым, анда гүя сүз сугыштан соңгы еллардагы колхоз авылы турында бара кебек. Хәзер, хуҗалыклар эреләнделәргәч, колхоз председательләренең эшчәнлеге башкачарак төс алды. Бу эштәге кешегә бер тырышлык, энергия һәм намуслы булу гына җитми. Хәзерге колхоз председателе кул астында югары белемле дистәләрчә белгечләр эшли, аның карамагында көчле техника. Бүгенге күп тармаклы хуҗалык белән идарә итү өчен, председательдән күп белем, даими уку, политик

өзерлек сорала. Ф. Хөсни иҗат иткән образ исә күбрәк кичәге көнгә карый.

Моңа кадәр безнең күп кенә язучыларның әсәрләрендә партия җитәкчеләре образлары ничектер төссез һәм таркау чыга иде. Бу образларны иҗат иткәндә язучылар гадәттә ике генә төрле буяудан: я дегет кебек кара, я сөт кебек ак буяулардан гына файдаланалар иде. Мондый алым белән ясалган геройларда чын тормыш сулышы булмый, алар укучыларны да тирәнтен дулкынландыра алмыйлар иде. Узган елгы прозабызның коммунист образларын тасвирлаудагы уңышлар шуңа да безне икеләтә куандыра. Бу хактагы сүзне Б. Камаловның «Ялыкмаслар» повестендагы райком секретаре Хафиз Кадергулов образыннан башлап китәсе килә.

Хафиз Кадергулов — чәйнәлеп беткән схематик образ да, йөз проценты белән уңай, идеаль герой да түгел. Шул ук вакытта аның характерында кайбер авторлар уңай геройларын тормышчан иту өчен юри кертә торган ясалма кимчелекләр дә юк. Кадергулов барыннан да элек әйбәт кеше. Юк, ул бөтенесен гафу итә, кеше белән мөнәсәбәтләре бозылудан куркып яши торган юаш кеше түгел, ә эшлекле, принципиаль, кирәк чакта рәхимсез һәм каты куллы да була белүче чын коммунист.

Үз янына килүчеләрне кабул иткәндә, ул һәркемнең гозерен зур игътибар белән тыңлый. Әмма һәркемгә ярарга, яхшылык эшләргә генә тырышып утырмый. Кайбер очракларда, бик теләсә дә, ярдәм итәргә кулыннан килми. Әйтик, яслеләрдә һәм балалар бакчаларында урын җитми икән, моны бер көндә генә хәл итеп булмый. Мондый чакта Хафиз булмас вәгъдәләр белән алдамый, бу хакта турыдан-туры әйтә. Икенче бер очракта ул үзендә кешеләрнең гозерен принципиаль төстә кире кагарлык көч таба.

Шулай бервакыт аның янына бик кыен мәсьәлә белән авылдан каенатасы Исрафил килә. Хафизның үлгән хатынының энесе Иршат авылдагы хәбәрче малайны кыйнап ташлаган. Каенесен суд скамьясы көтә икән. Иршатны коткарып калыр өчен райком секретареның бер шалтыратуы җитәр иде. Хафиз моңа бармый. Бармый, чөнки аның исеме һәм авторитетына аркаланып, туганнарының начар эшләр эшләп ятуларын теләми. Менә шундый кискен ситуацияләрдә Хафиз характерындагы төп сыйфат — аның партиячел принципиальлеге ачыла да.

Б. Камалов герой күңеленең иң тирән почмакларына күз сала, аны эшендә, гаилә тормышында күрсәтә, мәхәббәт маҗараларына китереп кертә. Нәтиҗәдә күренештән-күренешкә безнең геройга булган ышанычыбыз арта бара. Дөрес, повестьның композицион төзелешендә эчне пошырырлык кимчелекләр калган әле, алар әсәрнең тәэсир көчен шактый киметәләр.

Габдрахман Әпсәләмов — безнең иң популяр язучыларыбызның берсе. Шуңа күрә аның «Идел хикәяте» исемле яңа повестен, автор укучыларның өметен аклый алдымы икән дип, шикләнебрәк укый башлаган идем. Дөресен әйтергә кирәк, тулаем алганда, автор безнең өметләрне аклаган. Повестьта зур заводның баш инженеры булып эшләгән коммунист образы алына, әсәрдә аның тормышындагы иң кыен, иң фаҗигале момент сурәтләнә, каты авыру аның сәламәтлеген какшата, нәтиҗәдә ул яраткан эшеннән, коллективтан аерылырга мәҗбүр була. Ләкин повестьның герое авыруны җиңәрлек көч таба һәм яңадан эшчеләр сафында үз урынын ала. Повестьта автобиографик моментлар сизелә. Рушат характерында без авторның үзенә хас тырышлык, үз профессиясенә чиксез мәхәббәт һәм сынмас ихтыяр көче күрәбез. Әсәрнең тарту көче, бәлки, нәкъ менә шуның белән аңлатыладыр да.

Шулай да бер ризасызлык белдерәсе килә: мин әсәрнең жанрын билгеләү белән килешеп җитә алмыйм. Дөресен әйткәндә, ул повесть булып түгел, ә озын хикәя булып чыккан. Әсәрдә күтәрелгән проблемалар тирәнлек һәм күләм ягыннан повестька тартмый. Әгәр хикәя жанрына туры китереп, автор артык озынга сузылган һәм коры санап чыгу рәвешендә генә язылган тасвирлауларны бераз кыскартса, моннан әсәр бөтенләй генә иде.

Г. Әпсәләмов повесте кебек үк, Ә. Баянов романы да икенче дәрәҗәдәге, артык мәҗбүри булмаган сюжет сызыклары, төп геройларга турыдан-туры мөнәсәбәте булмаган тасвирлаулар хисабына кирәгеннән артык калынайган. Мәсәлән, Фәезнең авылга барып, Гөлнисаттәй белән очрашып йөрүләре бик озынга сузыла. Кәрим һәм аның гаилә тормышына караган сызык та сюжет белән турыдан-туры бәйләнми. Укучыларның игътибарын читкә алып китә торган мондый эпизодларны кыскарта төшкәндә, әйбәт кенә повесть килеп чыгачак. Ләкин эш әдәби информациянең күләмендә генә түгел. Роман шәхесне җәмгыять тормышы һәм башка кешеләр белән күп-

төрле бәйләнешләрдә күрсәтергә тиеш. Шуның өчен романнан хәтердә ачык булып калырлык образларның бөтен бер галереясе таләп ителә. Ә. Баянов әсәре исә бу яктан романга куела торган таләпләрне күтәрә алмый. Биредә Фаез һәм Борис характерлары гына чагыштырмача калку ител эшләнгән, ә калган персонажлар шактый тоссез чыкканнар. Әдәби жанрларның табигате хакында сүз барганда, әсәрнең күләменнән һәм башка тышкы билгеләреннән чыгып түгел, әсәрнең социаль яңгырашына карап фикер йөртергә кирәк. Дөрес, әсәрнең социаль кыйммәтен, психологик тирәнлеген, яңалыгын һәм эчтәлегенең әһәмиятен төгәл билгеләү җиңел эш түгел. Әмма, ни генә булмасын, нәкъ менә шулардан чыгып эш йөртергә кирәк.

## СӘБӘП НӘРСӘДӘ СОҢ!

Прозаның артта калуын, аның йомшак һәм тоссез булуын әйтү генә җитми. Шушы хәлне китереп чыгарган сәбәпләрне ачыкларга кирәк. Бу — артталыктан чыгу өчен кирәк, чын мәгънәсендәге көчле сәнгать әсәрләре, заманыбызга, героик халкыбызга лаек әсәрләр иҗат итү өчен кирәк.

Башта ук әйтеп китим, безнең прозаның үсешен тоткарлый торган ниндидер объектив сәбәпләр юк. Балтик буе әдәбиятлары (бигрәк тә литва һәм эстон прозасы) тәҗрибәсе, шулай ук кыргыз һәм казакъ әдәбиятларының кызу темплар белән үсүе талантның чын-чыннан чәчәк атуы өчен объектив шартларның һәр җирдә булуы турында сөйли. Бары ул шартларны файдалана белергә, ирешелгәннәр белән тынычланып калмаска һәм үз кабыгыңа төренеп яшәмәскә генә кирәк.

Кайберәүләр бөтен эш талантка бәйләнгән дип котылмакчы булалар. Янәсе, Пушкин, Тукай яисә Лев Толстой кебек талант туса, әдәбият шунда ук алга сикерәчәк. Бу да дөрес караш түгел. Алар юк, нишләргә соң? Кул кушырып, талантлар килүен көтеп утырыргамы? Даһилар шуңа да даһи, алар күп булмый. Йөз елга бер, хәтта аннан да сирәгрәк туа. Әгәр без әдәбиятыбызның алга китүен телибез икән, без аны булган кадәр көчләр белән үстерергә тиешбез. Миңа калса, эш барыннан да элек бер-беребезгә булган таләпчәнлекне күтәрүгә кайтып кала, классиклардан, совет һәм дөнья әдәбиятының иң яхшы казанышларын иҗади өйрәнүгә, әдәби осталыкны күтәрүгә, язучыларыбызның дөньяга карашларын киңәйтүгә кайтып кала.

Әдәби осталык һәм тормышны тирәнтен танып-белү кебек мәсьәләләр бер-берсеннән аерылгысыз. Берничә еллар элек укучылар арасында Ф. Хөснинең «Ләззәт тә бирәме?» дигән мәкаләсе зур кызыксыну уяткан иде.

Ф. Хөсни бик дөрес язганча, безнең тәнкыйть мәкаләләрендә, мәктәп дәреслекләрендә, әдәбият дәресләрендә китапның эчтәлегенә, образларына, анда күтәрелгән мәсьәләләргә шактый киң урын бирелә. Әмма игътибардан бер мәсьәлә читтә кала килә: әсәр эстетик ләззәт тә бирәме соң? Укучыларның әсәргә мөнәсәбәтен, аны ничек кабул итүләрен искә алырга кирәк, дип чыгуы белән Ф. Хөсни һичшиксез хаклы иде. Әйдәгез, алга таба китик һәм уйлап карыйк: нәрсә соң ул эстетик ләззәт? Ул форма камиллеге, тел матурлыгы һәм стиль нечкәлекләре генәме? Юк, эстетик ләззәт танып-белү шатлыгын да, эчтәлектә, образларда, әсәрдә күтәрелгән мәсьәләләрдәге яңалыкны ачу шатлыгын да үз эченә ала. Иң зур ләззәтне үзебезне эчтән баета торган әсәрләрне укыганда алабыз бит. Һәм, киресенчә, стиль ягыннан әсәр никадәр генә шәп күренмәсен, әгәр ул эчтәлеге ягыннан сай, буш икән, тормышның яңа катламнарын ачмый икән, андый әсәр туйдыра гына.

Ф. Хөснинең үз әсәрен — «Мәйдан»ын алыйк. Әсәр өлгергән, тәҗрибәле художник, менә дигән стилист кулы белән язылган, моны беркем дә инкарь итә алмас. Әмма, алда бер тапкыр күреп узганча, повестьта чын мәгънәсендәге ачышлар аз, ул безнең әдәбиятта күп тапталган коллизияләрне кабатлый. Бу исә әсәрне эстетик кабул итүгә дә тискәре йогынты ясамый калмый.

Әлбәттә, сәнгатьчә эчтәлек белән гыйльми трактат эчтәлеге икесе бер нәрсә түгел. Сәнгать әсәре иң элек безнең эмоциональ дөньябызга тәэсир ясый, шуңа күрә аның теле дә бай, образлы, ачык һәм лаконик булырга тиеш.

Укучыларны борчылырга мәҗбүр итә торган мәсьәләләрнең тагын берсе шул: соңгы елларда стильләрнең бер төслегә әйләнү тенденциясе көчәеп бара. Бу бигрәк тә урта һәм яшь буын прозаиклар өчен хас күренеш. Менә М. Хәбибуллинның «Икмәк кадере» исемле повестеннан бер характерлы мисал:

«Ул белә иде, идарә файдаланган нефть ятмасы вакытсызрак сүнә: геологлар планлаштырган запасны тулысынча бирми. Лә-

кин моңа Вәкилнең исе китмәде. Скважиналарны электрлаштыру, автоматлаштыру, батырма насослар төшерү хисабына айданайга планны арттырып үтәп килде. Бу эшкә ул чатыр ябышты. Югары басымга көйләнгән яңа куст насос станцияләре салдырды. Бу хәл катламга су тутыруны бермә-бер арттырды. Шуның хисабына меңләгән тонна өстәмә нефть алынды». («Казан утлары» журналы. 1971 ел. 1 сан. 29 бит.)

Менә шундый коры, газета стилә битләр буена сузыла. Башка авторларның әсәрләреннән дә мисаллар китерергә булыр иде. Теленә карап кына күбесенең кем әсәре икәнен дә белеп булмый. Ә бит сәнгатьчә индивидуальлек нәкъ менә стильдә аеруча ачык чагыла. Мәсьәләгә бу яктан якын килгәндә, безнең яшь прозаикларга өлкәннәрдән өйрәнер әйбер бик күп әле.

Соңгы елларда безнең әдәбиятта тышкы охшашлыкка нигезләнгән традицион хикәяләү стилендәге проза өстенлек итә. Дөнья әдәбиятында проза жанры туплаган бай тәҗрибәдән без аз файдаланабыз. Безнең әдәбиятта төп геройның язмышын сурәтләүгә корылган романнар өстенлек ала. Безнең иң яхшы әсәрләребез нигездә шушы жанрда эшләнгән (Ф. Хәснинең «Җәяүле кеше сукмагы», М. Әмирнең «Саф күңел»е. Г. Бәшировның «Намус»ы һ. б.). Вакыйгаларга корылган роман бик сирәк очрый. Заманында аның менә дигән үрнәген Г. Ибраһимов («Тирән тамырлар») биргән иде. Күптән түгел «Иностранная литература» журналында Артур Хэйлиның «Аэропорт» дигән романы басылды. Бу әсәр роман-вакыйга жанрының ахырга кадәр файдаланып бетермәгән зур мөмкинлекләре булуы турында сөйли. Тагын әле роман-хроника, роман-репортаж, документаль-биографик роман (Ш. Маннурның «Муса» романы), новеллалар чылбырыннан торган роман (Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр»), эпистоляр роман, шигъри роман (С. Батталның «Чирмешән ярларында» романы), детектив роман, фәнни-фантастик һәм башка төрле романнар бар. Повесть, хикәя, новелла кебек жанрларга мөрәҗәгать итсәк тә шундый ук төрлелек күрербез. Кызганычка каршы, безнең язучылар шушы зур байлыкның бик аз, кабатлый-кабатлый туйдырып бетергән өлешен генә файдаланалар. Язучыларны совет һәм дөнья романы туплаган бай тәҗрибәдән куюрак өйрәнергә чакырасы килә. Соңгы чорда күп кенә әдәбиятларда фәлсәфи роман активлашып килә (япон язучысы Кабо Абэның «Женщина в песках», «Сожженная карта», «Чужое лицо» романнары, рус язучысы Михаил Булгаковның «Мастер и Маргарита» романы һ. б.). Бу әсәрләрдә, реаль алымнар белән бергә, реаль булмаган, фантастик алымнар да киң кулланыла. Ләкин алар үзмаксат өчен кертелмәгән, үзләре теләгән идеяне укучыга җиткерерлек башка чаралар тапмаганда, авторлар фантастик алымнарга мөрәҗәгать итәләр. Моңа кадәр без фантастиканы үзенә аерым, саф бер жанр дип йөртә идек, аның җитди, реаль әдәбият белән бәйләнеше юк дип уйлый идек. Баксаң, бу ике алым үзара якыная бара икән. Нигә аптырарга, әле Бальзак кебек баштанаяк реалист язучы да, кешенең теләкләре һәм мөмкинлекләре арасындагы каршылык турындагы фикерне укучыларга җиткерү өчен, «Шагреновая кожа» романында саф фантастик образларга мөрәҗәгать иткән иде ич. Хәер, мисал эзләп ерак барасы да юк: Ф. Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт» повестен алыйк. Минем уемча, ул үз заманы кешеләре турында язылган тирән реалистик әсәр. Инде автор героен киләчәк тормышка күчереп сурәтли икән, бу — Фәтхулла хәзрәт кебекләрнең чикләнгәнлеген, артталыгын, үлемгә дучар ителгәнлеген күрсәтү өчен кулланылган шартлы алым гына. Үткәндәге мираска игътибар һәм саклык белән мөрәҗәгать итсәк, без анда Г. Колахметовның «Ике фикер»е кебек тагын бер үзенчәлекле әсәр очратырбыз. Монда язучы чынбарлыктан бөтенләй ераклаша, ул идея һәм фикерләрне кеше кыяфәтенә кертә.

Юк, мин язучыларны шартлы һәм фантастик алымнар белән генә язарга чакырмыйм. Мин стиль һәм алымнарның күп төрле булуы ягында. Бу җәһәттән яшь прозаик М. Мәһдиевнең уңышлары кызыклы. «Без — кырык беренче ел балалары» исемле бәләкәй генә повестенда ул безнең прозаны юмористик, чая хикәяләү алымы белән баетты. «Фронтовиклар» романында М. Мәһдиевнең стиле яңа сыйфатлар белән баеган, юмор тирән лиризм белән кушылган. Мондый юнәлештәге эзләнүләрне бары хупларга гына кирәк.

Нинди дә булса бер генә алымга өстенлек бирүе кыен, билгеле. Тик бер нәрсә бәхәссез: иҗади төстә даими эзләнү процессында гына безнең проза торгынлыктан чыга һәм ышандырырлык уңышларга ирешә алыр.

# МЕЩАНЛЫК БӘХЕТЕНӘ КАРШЫ

Юныс Әминовның моннан ике ел элек дөнья күргән җыентыгына[1] дүрт пьеса кергән: «Умырзая чәчәкләре», «Гөлчәчәк», «Тамырлар» һәм «Язылмаган законнар». Укучылар хәтерлидер, заманында аларның һәркайсы зур сәхнәләрдә куелды. Нәкъ шушы әсәрләре Ю. Әминовны сәләтле драматург итеп таныттьі, аңа дан-шөһрәт китерде. Тыштан караганда, бер-берсеннән никадәр генә аерылмасыннар, бу пьесаларның һәммәсенә хас уртак сыйфатлар да байтак.

«Гөлчәчәк» белән «Язылмаган законнар»ны алыйк. Аларның икесендә дә мәхәббәт һәм гаилә, шәхес һәм коллектив, шәхеснең җәмгыятьтәге урыны турында сүз бара. Бу әсәрләр сюжетлары, образлары белән дә үзара шактый якыннар. «Тамырлар»да да нигездә шул ук мәсьәләләр күтәрелә, тик монда алар күбрәк комик планда хәл ителәләр. «Умырзая чәчәкләре» темасы, язылышы, жанры ягыннан алдагы өч әсәрдән шактый аерылып тора. Биредә без сыйнфый көрәш вакыйгалары, көчле характерлар белән очрашабыз. Безнең күз алдыннан гражданнар сугышы елларындагы яшь көрәшчеләрнең умырзая чәчәкләредәй кыска гомерләре үзә.

«Умырзая чәчәкләре» — кискен конфликтларга корылган әсәр. Идә гражданнар сугышы бара. Сыйнфый көрәш авыл җирендә дә үзенең иң көчле, иң кискен ноктасына күтәрелә. Авыл халкы капмакаршы ике лагерьга бүленә. Баррикаданың бер ягында — ярлылар комитеты председателе Максут һәм аның иптәшләре. Икенче ягында — алпавыт улы поручик Давыт Гаянов, авыл мулласы Әхмәдиша, кулак Нуретдин, урман промышленнигы Сәмигулла, сәүдәгәр Малтабар, фельдфебель Кадыйрлар. Шул ике лагерь вәкилләре арасында кискен көрәш бара.

Максутлар, бер сынык икмәккә тилмерүче эшчеләргә җибәрү өчен, авыл байларыннан икмәк даулыйлар. Кулаклар исә бар ашлыкларын яшерәләр. Тоз, сабын, шикәр кебек әйберләрне сатмыйча яшереп ятып, халык арасында коткы таратырга, бунт чыгарырга өметләнәләр, террорга әзерләнәләр. Фронт һаман якынлаша бара. Озакламый, аклар авыл янына ук килеп җитәләр. Нишләргә? Җыелган кадәр икмәкне баржага озатырга да, кызыл частьларга кушылып, чигенергә була. Исән-имин калу өчен бердәнбер юл шул. Ләкин бу җиңел юл. Максутлар бу юлдан китмиләр, китә алмыйлар. Чөнки илдә ачлык, илдә тиф котырына. Гомерләрен куркыныч астына куеп булса да, икмәк җыюны дәвам иттерәләр. Җыеп бетерәләр, әрәм-шәрәм итми, Таштамак пристанендагы баржага озаталар. Әмма үзләре, ак фетнәчеләр кулына эләгеп, һәлак булалар.

Драма җыйнаклыгы, эмоциональ тәэсир көченең зурлыгы белән аерылып тора. Зур иҗтимагый вакыйгаларга геройларның шәхси язмышлары килеп кушыла. Максут белән Фирүзә арасындагы мәхәббәт хисләре, урта хәлле крестьян Мирсәетнең каршылыклы язмышы, фельдшер Фәһимә белән аның кызы Фәния әсәрне тагын да тормышчанрак, тагын да җанлырак итәләр. Вакыйгаларның гел үсештә бирелүе, персонажларның киеренке шартларга куелуы, сәнгатьчә табигыйлек һәм кыскалык авторның осталыгы турында сөйли. Героик көрәш вакыйгаларын тулырак күрсәтү өчен, драматург шартлы, романтик алымнарга мөрәҗәгать итә: романтик пролог, Җир-ана образы, җыр һәм шигъри сөйләм, чын-

[1] Ю. Әминов. Дүрт пьеса. Казан. 1970 ел.

барлык һәм хыял һ. б. Болар пьесага шигъри яңгыраш, романтик пафос бирә.

Вакыйгаларның зур, масштаблы булуы геройлар санына да тәэсир итми калмаган, билгеле. Әсәрдәге персонажларның саны берничә дистәгә җитә. Автор аларның һәркайсын остә калырлык, җанлы, тормышчан характерлар итеп бирергә тырышкан. Ярлылар комитеты председателе, коммунист Максут һәм авыл мулласы Әхмәдиша образлары аеруча җанлы чыккан.

Автор Максутны җаны-тәне белән революция эшенә бирелгән чын коммунист итеп сурәтли. Ул көчле ихтыярлы, принципиаль табигатьле кеше. Иптәшләреннән дә шуны ук таләп итә. Менә аның тоткынлыкка эләккәч ак офицерларга биргән җавабы: «Икмәк өчен нигә шул кадәр тартышасыз дисең, Давыт әфәнде. Салам түбәләрен күтәрә алмыйча кыйшайган бу йортлар урынына колач җитмәс тәрәзәләре белән балкып таш йортлар күтәрелсен өчен!.. Гәрәбә бодай кыры өчен... Кешеләр тигез булсын өчен тартышабыз без...» Ләкин Максут барысын да җиңә алучы гадәттән тыш шәхес түгел. Шатланудан бигрәк, аның ачынырлык көннәре күбрәк. Авыл кулаклары, Әхмәдиша муллалар аның һәр эшенә аяк чалып торалар. Урта хәлле Мирсәет исә «Микулай вакытында рәхәтрәк иде, тозы бар иде, ичмасам» дип, ярасына тоз сала. Ни дисен ул аларга, ничек җавап бирсен? «Их, Ленин, күрше авылда гына яшәсәң соң... Ат менеп, хәзер үк киңәш сорап кайтыр идем» дип өзгәләнә Максут андый чакларда.

Әхмәдиша образын эшләгәндә, автор персонажның үз-үзен фаш итү алымыннан оста файдалана. Әхмәдиша мулла сердәше ак офицерга менә нинди киңәш бирә:

«һе, мелла Давыт, миндә коралның кылыч, камчыдан да куәтлесе. Менә ул: «Корьән!» Кылычыңны кылыч белән, камчыңны камчы белән бәреп төшерерләр. Ә моны туп белән дә ала алмыйсың. Кылыч белән атна буе йөреп тә бер пот икмәк таба алмассың, ә Корьән ятимә хатынның чирле баласына дип сакланган соңгы тавыгын да суйдырыр. Менә нәрсә ул Корьән! Сугыш беткәч, кылычыңны куй да Корьән ал. Көчле дә, бай да булырсың».

Корьәнне корал дәрәҗәсенә күтәргән мәкерле Әхмәдиша хатынын, авылдашларын атарга фатиха бирүче мәрхәмәтсез бер зат булып истә кала. Шундый капма-каршы шәхесләр, характерлар бәрелешен автор шактый оста бирә алган.

«Умырзая чәчәкләре»нең зур уңыш казануы очраклы һәм көтелмәгән бер хәл түгел иде. Аңа кадәр автор, күп кенә иҗат тәҗрибәләре ясап, осталыкка өйрәнә килде. «Гөлчәчәк» — шундый пьесаларның берсе.

Әсәрнең сюжеты артык катлаулы түгел. Үзәктә Гөлчәчәк образы тора. Вакыйгалар барышында без аның тормышы, эше, язмышы белән танышабыз. Автор үзенең герое Гөлчәчәкне кыен хәлләргә куя, утлар-сулар аша чыгара. Менә ул, язгы пычракларга, салкын сулы елгаларга да карап тормыйча, авырып яткан лесничий Илшат янына (ул аның сөйгәне дә) ярдәмгә ашыга: операция ясап, аны үлемнән коткара. Әмма бу батырлыгы аңа бик кыйммәткә төшә. Гөлчәчәк үзе авырып егыла. Ул дәваланып ятканда, Илшат Сөмбел дигән тол хатын белән танышып ала, Гөлчәчәкне бөтенләй оныта. Ул да түгел, Илшат яңадан авырып китә. Менә ул тагын операция өстәлендә. Тиешле группа кан бирү белән генә аны үлемнән коткарырга мөмкин. Андый кан Гөлчәчәк белән Сөмбелдә генә бар. Сөмбел кан бирергә риза булмый. Гөлчәчәк, авыру булуына да карамастан, үз канын бирә, үзе үк аңа операция дә ясый. Әмма соңыннан Илшатның мәхәббәтен кабул итми.

Әсәрдә психологик тирәнлеге белән аерылып торган урыннар байтак. Мәсәлән, Илшатның Сөмбелгә өйләнергә рөхсәт сорап килгәч сөйләгән сүзләрен Гөлчәчәк ялгыш аңлый, аның ул сүзләрен үз адресына кабул итә. Монда классик «ялгышу» алымы бик отышлы кулланылган.

«Гөлчәчәк» — авторның элеккерәк әсәре. Шуңа булса кирәк, анда ясалма урыннар да очрый. Ремаркаларның артык күп булуы күзгә ташлана. Илшатка кан кирәк булгач, Гөлчәчәк белән Сөмбелнең генә каны очраклы рәвештә I А группалы булып чыга. Без Сөмбелнең кан бирмәячәген дә, Гөлчәчәкнең җиңеп чыгачагын да алдан ук белеп торабыз. Нәтиҗәдә, әсәрнең кызыксындыру көче, тамашачыны, «ни булыр» дип, кыл өстендә тотып тору көче нык кими. Әсәр кызыксызлана, барысы да әзер схема буенча бара башлый.

«Гөлчәчәк» әсәре белән башлаган сүзен автор «Язылмаган законнар» драмасында дәвам итә. Шәхес һәм коллектив, мәхәббәт һәм бәхет мәсьәләләренә багышланган бу әсәрнең конфликты гаилә эчендәге каршылыкларга корылган.

Колхозның алдынгы тракторчысы Шәйхенур бер заман масаеп китә. Эчкечелеккә бирелә. «Үзем мал табам, эшләмә, җыелышларга барма, хатын-кызга ни кирәк тагын, ир ир урынында булырга тиеш» дип, хатынын коллективтан, эштән аерырга тели. Җиңел карашлы фельдшер Назлыбикә белән өйләнешеп, семьясын ташлый. Назлыбикә исә аның бар мал-мөлкәтен туздырып бетерә, авыру әнисен кыерсыта башлый, Шәйхенурны бөтен авылдашлары алдында көлкегә, аяныч хәлгә калдыра. Әхлак нормаларын — язылмаган законнарны бозган бу кешеләргә авыл халкы да кырын карый башлый. Тора-бара Шәйхенур язылмаган законнар белән санашырга мәҗбүр була. Ахырдан үз гаиләсе белән берләшә. Әсәрнең төп сюжет сызыгы шуннан гыйбарәт.

Язучы тормыш күренешләрен, тормыштагы вакыйгаларны гади теркәп баручы гына түгел. Ул аларны гомумиләштерергә, кирәк икән күпертебрәк, калкурак итеп сурәтләргә тиеш. Тик бер шарт белән, чама тойгысын югалтмыйча, тормыш чынлыгына зыян китермичә. «Язылмаган законнар»да урыны-урыны белән автор шул нәрсәне — чама тойгысын онытып җибәрә. Шуңа берничә мисал.

Психологик драмада (әсәр сатирик комедия түгел) Назлыбикә белән Майлыбикә образларының, өлешчә Шәйхенур образының да карикатура формасындарак куерТылуы жанр ягыннан акланмый. Назлыбикәнең эче алынмаган тавык пешерүе, «бер айда егерме тавык йотуы» һәм башка дуамаллыклары, безнеңчә, сәнгатьчә куертылудан узып киткән. Шул рухтагы арттырулар башка урыннарда да очрый. Алар тамашачыны көлдерү өчен генә кертелгән. Автор көлдерүгә ирешсә дә, психологик драма күтәргән мөһим проблемалар шактый гадиләштерелә. «Бер тиенлек куян — биш тиенлек зыян» булып чыга.

Әсәрдә шактый сентименталь язылган урыннар бар. Мәсәлән, Шәйхенур болай сөйли: «Шуның өчен дә мине язылмаган законнар коточкыч газапка хөкем иттеләр. Ярый, Фәридә, моннан соң гафу үтенеп сине борчымам... Бер генә тапкыр, бәлки соңгы тапкыр, улымны кулыма алып сөяргә рөхсәт ит (Фәридә баланы бирә). Балам. Йөрәк бәгырем, мин синең алдыңда бик зур гаепле. Гафу ит мине (үкси)». Билгеле, гаилә җимерелү, баланың атадан аерылуы, сөйгән кешеңне югалту җиңел эш түгел. Ул тамашачы күңеленең иң нечкә кылларын тибрәтә. Әмма автор тамашачының бу «йомшаклыгыннан» артык күп файдалана. Төче сүзләр күбәеп, елаулар кабатлана башлагач, аларның артыкка китүе сизелә башлый. Сүз нечкә кылларга тимәү турында түгел, ә алар белән саксыз шаярырга ярамау турында бара.

«Язылмаган законнар»ның уңай ягын күрми үтү гаделсезлек булыр иде. Әсәрдә бүгенге авыл, хезмәт кешеләре күрсәтелә. Алдынгы сыер савучы Фәридә, аның әтисе Фазыл, әнисе Җәмилә, комсорг Хатыйп, фельдшер Әминә, үткен телле, гадел сүзле Саматлар, Былбыллар бер-берсен тулыландырып, ачыклап киләләр. Дөрес, аларның күбесе эпизодик күренешләрдә генә катнашалар, шулай да үзләренең көчле бер коллектив вәкилләре булуларын сиздереп торалар. Сәхнәдән тыш зур дөнья барлыгын, коллектив, авыл халкы барлыгын һәрвакыт тоеп була. Авторның максаты да коллектив көчен күрсәтү, һәм ул аңа нигездә ирешә.

Ю. Әминовның иҗат үзенчәлекләрен тулырак күзаллау өчен, бу китаптагы бердәнбер комедиягә — «Тамырлар»га да тукталу кирәк. «Тамырлар»ның темасы, идеясе — яңача, заманча яшәү. Бүгенге яшьләрнең яңача, заманча тормыш итәргә омтылулары турында ул. Әсәрнең комик конфликты аерым хуҗалык психологиясеннән аерылып җитмәгән колхозчылар Гапсаттар карт, Хәерниса абыстай белән аларның балалары Сәҗидә, Илдарлар, авыл яшьләре, алдынгы колхозчылар арасындагы комик каршылыкка корылган. Бүгенге көндә, колхоз авылындагы яңалыкларга каршы барып, искелекне яклап калырга тартышу көлке күренеш. Әмма авторның көлүе мәрхәмәтле, юмористик. Чөнки көлү объекты итеп алынган Гапсаттарлар, Хәернисалар үзләренең «гөнаһлары» белән сатирик көлүгә лаек түгелләр. Әсәрнең соңында алар хәтта яңа тормыш белән килешеп яшәргә мәҗбүр булалар. Масайган карт егет Зиннәт образы да күбрәк юмористик чаралар белән бирелгән.

Әсәрдә мәхәббәт һәм гаилә кору мәсьәләсе шәхес һәм коллектив проблемасына турыдан-туры бәйләнештә ачыла. Бөтен халык алма бакчасы утырту белән мәшгуль. Монысы зур коллектив тормышы. Аннан читтәрәк тагын бер кечкенә дөнья — Гапсаттар белән Хәерниса тормышы бар. Гапсаттарның «мунча түбәсенә булыр» дип ферма салучы осталарның кадакларын кыстырып кайтулары, көтүен ташлап, үзенә

утын әзерләп йөрүләре, Хәернисаның мунчама дип мүк җыйганда сазлыкка кереп батулары, булачак кияве Гомәрне кортлы алма белән «сыйлавы», мал алу теләге белән туң күңелле Зиннәткә кызларын бирергә ризалыкларын белдереп договор язышулары кебек вакыйгалар, көлке детальләр, ситуацияләр аша автор шәхси милекчелек ваклыгыннан, саранлыктан бик оста көлә. Комедия искелек яклыларның көлкеле җиңелүләре белән тәмамлана. Әсәр Гапсаттар сүзләре белән тәмамлана: «Яңа заман — яңа үлчәү. Анасы, бар, алып кайт балаларны, икесен дә чакыр... Гаеп бездә диген...»

Автор бу комедиясендә дә авыл кешеләренең образларын тормышчан итеп күз алдына китереп бастыра һәм халык күңелен, гореф-гадәтен, фольклорны яхшы ук белеп эш итүен күрсәтә. Ниһаять, истә калырлык (Зиннәт, Гомәр, Саҗидә, Гапсаттар, Хәернисa) образлар иҗат итә. Мәсәлән, бу әсәрдәге Гомәрне инде сез башка бер генә образ белән дә бутый алмыйсыз:

«Гомәр. Шадра Сәкинә малае бит мин, Гомәр... Сама знаешь, Хәерниса тетя, әтиәни оҗмахта, йорт йозакта, паспорт алмаштыру өчен каеткан идем... Постой, син кортлыны бирәсең. (Алма өзә.)»

Саранлыгы, хис-күңел ярлылыгы белән танылган Зиннәт үзен башкачарак тота:

«Зиннәт. Минем, иптәшләр, тәкъдим, иптәшләр, ягъни, иптәшләр, Гапсаттар абызыйга, иптәшләр, аңлату эшләре, иптәшләр, җитми, иптәшләр. Катырак итеп, иптәшләр, аңлатырга, иптәшләр, кирәк, иптәшләр».

Әсәрдә шундый матур урыннарны күп табарга мөмкин. Әмма шул ук Гомәр образында логик эзлексезлек тә сизелә. Үзсүзле, тәкәббер Гомәр Гапсаттар абыйдан менә ничек итеп кыз сорый: «...Зинһар, бик, бик үтенеп сорыйм, ризалыгыңны бир, Гапсаттар абзый... Озын берлекләр эзләп биш ел гомеремне җилгә очырдым. Хәзер бик үкенәм дә, тик үткәннәр кире кайтмый шул. Менә нәтиҗәсе: өем тарәүле, капкам кыйшайган, мунчам түбәсез, миче җебеп таралган. Тавыгым да юк. Кеше рәтенә басасым килә, кеше буласым килә, Гапсаттар абзый...» Бу күренештә Гомәр мескенләнеп, җебеп төшкәндәй була. Образның бөтенлегенә шактый зыян килә.

Гапсаттарларга килен булып төшкәндә яшь фельдшер Нәзирә дә кеше ышанмаслык сүзләр сөйли: «...Әйе, мин ярлы... Бары тик улыгызга карата олылау, ихтирам, аңа карата күкрәгемдә мәңге кимемәс йөрәк ялкыным гына бар. Әйе, мин ятим...» — ди ул ярсый-ярсый. Шул ук фикерне башкача да әйтә алыр иде бит ул.

Ниһаять, Ю. Әминов әсәрләренең жанрлары хакында берничә сүз. Билгеле булганча, бер үк тормыш материалы драматургиянең теләсә кайсы жанрында бер дәрәҗәдә уңышлы, отышлы чишелә алмый, ә үзе өчен уңайлы жанр сайлауны таләп итә. Алар белән санашмый чын сәнгать әсәре иҗат итеп булмый. Әйтик, «Умырзая чәчәкләре»нең нигездә героик драма жанрында эшләнүе ул әсәрнең көчен нык арттыра. Әмма калган өч әсәр жанрлары ягыннан бик үк ачык түгел. Безнеңчә, «Гөлчәчәк» белән «Язылмаган законнар» психологик драма буларак камилләшергә тиешләр. Моның өчен әсәрдә психологизм тагын да тирәнрәк булырга һәм геройларның эшхәрәкәтләре тагын да ышандырырлык мотивлаштырылган булырга тиеш иде.

«Тамырлар» исә лирик комедиягә дә, сатирик комедиягә дә тартым. Язучының бу әсәрдә кулланган көлү төсмеренә һәм конфликтның чишелешенә карап, ул лирик комедиягә якынрак тора.

Тагын шунысы бар, автор үзе бу җыентыкка кергән бер генә әсәренең дә жанрын анык билгеләмәгән. Барысы да пьесалар. Хәлбуки, М. Фәйзи, К. Тинчурин, Н. Исәнбәт кебек өлкән драматургларыбыз, хәзерге жанрлар әле формалаша башлаган елларда ук, әсәрләренең жанрларын билгеләп, я көлке, я фаҗига, я драма дип язып куйганнар. Ю. Әминов пьесаларының жанрын укучы, режиссер үзе генә билгеләргә тиеш булып чыга. Без моңа игътибар юнәлткәндә, драматург бөтенләй жанр йөзе булмаган әсәрләр биргән димибез, ә аның бу мөһим мәсьәләгә принципиаль карашта булуын гына телибез. Чөнки бу мәсьәлә бүгенге драматургиябезнең көн тәртибендә тора.

Без драматург иҗатының иң характерлы якларын гына күрергә омтылдык һәм шуңа кайбер мисаллар китердек. Йомгаклап шуны әйтик: әйе, безнең Юныс Әминов дигән үзенчәлекле драматургыбыз бар. Егерме еллык иҗат юлы — аның үсү юлы. Бүген аның иҗатына күз ташлаганда, без Ю. Әминовны «Язылмаган законнар», «Тамырлар» авторы буларак кына түгел, ә иң башлап «Умырзая чәчәкләре» авторы буларак белəбез һәм яңа иҗади уңышлар телибез.

**Назыйм ХАНЗАФАРОВ.**

# КҮП ЕЛЛАР АША

Е. Евтушенконың «Казан университеты» дигән поэмасы нигездә Россиядә демократик көчләрнең тупланучы, революцион идеяләрнең тәмам өлгереп җитүе хакында. Шагыйрь Казан университетына тегеләйме-болаймы бәйләнеше булган тарихи шәхесләрнең һәркайсына диярлек аерым бүлек багышлый. Әсәрнең төп темасы әнә шул тарихи шәхесләрнең катлаулы язмышларын, тарихи вакыйгаларны, аерым эпизодларны, характерларны бер-берсенә капма-каршы куеп сурәтләү ярдәмендә ачыла. Поэманың эпиграфыннан ук башланган фәлсәфи антитеза, беренчедән, революциягә кадәрге Россияне безнең күз алдыбызга бөтен тулылыгы белән китереп бастырса, икенчедән, ул авторның үз геройларына, үзе тасвирлаган күренешләргә мөнәсәбәтен билгеләү, бәя бирү чарасы булып тора. Моны бигрәк тә «Магницкий», «Лобачевский» дигән бүлекләрдә ачык күрергә мөмкин. Бер-берсенә капма-каршы куелган һәм шул ук вакытта бер-берсен тулыландырып, ачыклап килгән бу бүлекләрдә укучыны һәр шигырь юлын йотлыгып укырга мәҗбүр итә торган ниндидер яшерен көч, бердәмлек бар.

«Казан университеты» поэмасындагы иң уңышлы бүлекләрнең берсе — Лобачевский турындагы бүлек. Һәр строфасында, һәр юлында телнең афористик көче сизелеп торган, үзенчәлекле лирик буяулар белән чын сәнгать югарылыгында эшләнгән шигъри күренешләргә бай булган бу бүлектә авторның потенциаль мөмкинлекләре тулысынча файдаланылган. Хәр фикерле, кыю, чын мәгънәсендә гуманист Лобачевскийның антиподы — патша режимына колларча баш иеп, ирек сүзеннән коты алынып яшәүче, хамелеон характерлы Магницкийны автор менә ничек сурәтли:

Чинга табыну гына аны
Илгә тугры итеп йөртә.
Вольтерга да баш ияр ул,
Вольтер утырса тәхеткә.

Толстой хакындагы бүлектә авторның революцион идеяләрнең өлгереп җитүен бөтен тулылыгы белән күрсәтү максаты ничектер тараебрак китә, шигъри картиналар гомуми иллюстрацияләрне хәтерләтә башлый. Әлбәттә, рус дворяннарының алдынгы вәкилләре элек-электән халык язмышы өчен борчылып яшәгән. Аларның язмышы ил, халык язмышыннан аерылгысыз булган. Ләкин бу фикердә шигъри ачыш, шигъри яңалык юк диярлек. Шуңа күрә шигырьнең формасы оригиналь, кызыклы булса да, шагыйрь әйтергә теләгән фикер тулысы белән ачылып җитми. Вера Фигнер истәлегенә багышланган юллар да ничектер салкынрак. Аларга шигъри хис, шигъри кайнарлык җитенкерәми шикелле. Ә менә «Щапов», «Илья Ульянов» дигән бүлекләр образларның көчлелеге, тирәнлеге ягыннан да, кеше психологиясенең бөтен нечкәлекләре истә калырлык итеп сурәтләнүе ягыннан да һәм, ниһаять, узган гасыр тормышын кызыклы, мавыктыргыч шигъри детальләр ярдәмендә образлы итеп чагылдырылуы ягыннан да әле генә искә алынган бүлекләрдән күп өстен тора.

Талантлы, ләкин йомшак характерлы галим Щаповның язмышы, чыннан да, өметсез. Өметсез генә түгел, коточкыч. Аның рухи дөньясының вакытсыз җимерелүендә, яшьлек бунтарьлыгының вакытсыз сүнүендә, әлбәттә, патша җәмгыяте гаепле. Шагыйрь бу фаҗигане ышандыргыч итеп, күңел тетрәткеч итеп сурәтли. Профессор Лесгафтның һәм Илья Ульяновның кешелек сыйфатларын тасвирлаганда, Е. Евтушенконың шигъри сәләте тагын да ачыла төшә. Артта калган ярым феодаль җәмгыятьне революцион үсеш юлына чыгарырга тырышучы халыкка аң-белем бирүне үзенең иң изге бурычы итеп санаучы рус

интеллигенциясенең катлаулы язмышын гына түгел, шул заманга хас әһәмиятле нюансларны да шагыйрь сәнгатьчә дөрес чагылдыра.

Поэмада образлы фикерләү ягыннан да, хисләрнең чисталыгы, сафлыгы, кайнарлыгы ягыннан да иң камил шигъри юллар Володя Ульяновка багышланган бүлектә. Яшь Ульянов образы тыйнак та, мөлаем да, искиткеч көчле дә итеп бирелгән. Кайбер эпизодларда ул хәтта легенда, эпос героен хәтерләтә. Кыскасы, бу бүлектә шагыйрьнең иҗат фантазиясе һәм реаль чынбарлыкны дөрес аңлавы гармоник рәвештә үрелеп бара һәм мондый бәйләнеш, һичшиксез, тормыш картиналарын, аерым эпизодларны ничектер тулырак, баерак итеп күз алдына китереп бастыра.

Поэмадагы вакыйгалар үскән саен, аның тыгызлыгы да арта, динамикасы көчәя, масштабы киңәя. Оригиналь шигъри мотивлар белән баетылган эпик башлангыч алгы планга чыга. Поэма, ничектер, киңәеп, җәелеп ага башлый. Әсәрнең беренче бүлекләрендә чагылып-чагылып киткән фрагментларга тартым эпизодлар инде бөтенләй диярлек очрамый.

Эмоциональ киеренкелек, субъектив фикерләү аша тарихи һәм психологик дөреслеккә объектив бәя бирү, аерым шәхесләрнең сүзләре аша массалар теләген чагылдыру — болар «Шимбә» дип исемләнгән һәм Александр Ульянов турындагы бүлекләр өчен уртак сыйфатлар.

Ә инде «Татар җыры» бүлегендә Е. Евтушенко патша хөкүмәтенең төрле милләт халыклары арасында дошманлык мөнәсәбәтләре урнаштырырга тырышуын бөтенләй үзгә шигъри төсмерләр табып үзенчә трансформацияли. Килер бер көн:

... Барысы өчен уртак иман булыр,
Уртак дога җырда яңгырар:
Кешедән гайре юктыр һичбер алла,
Үз-үзенә кеше пәйгамбәр...

Киләчәккә зур өметләр баглаган олы җанлы кешеләр әнә шундый көннәр өчен көрәшкәннәр. Аларның берсе — Россиянең беренче марксисты, 17 яшьлек Коля Федосеев — караңгы илнең коточкыч авыр шартларына түзә алмыйча, сөргендә үз-үзен үтерергә мәҗбүр була. Шагыйрь аның изге максатка багышланган кыска гомер юлын тасвирлаганда яктырак, ачыграк лирик буяуларга мөрәҗәгать итә. Аннары ритмик агымның кискен генә үзгәреп китүе дә бу бүлеккә ниндидер үзенчәлекле яңа аһәң, яңа моң өсти. Гомумән, ритмның, шигъри үлчәүнең әледән-әле үзгәреп торуы әсәрнең художество функциясен көчәйтә, эмоциональ киеренкелекне тиешле югарылыкта тотарга ярдәм итә.

Яшь Ленин, студентлар сходкасына катнашып, беренче мәртәбә кулга алына. Поэмадагы соңгы бүлекләрнең нигезенә әнә шул вакыйга салынган. Бу бүлекләр монументальлеге, тарихи гомумиләштерелгән масштаблылыгы, аналитик фикерләүгә бай булулары белән үзенчәлекле. Шагыйрь житди иҗтимагый теманы яшьлек, киләчәк турында уйланулар, иҗади эзләнүләр җырлегендә чишә.

Әй син, яшьлек, оч биектә,
Хөкемдар бул, гел яшь бул син,
Һәм берсә-бер көрәшләрдә,
Ут белән боз көрәшкәндә
Көрәш бул син...

Ленин яшьлеге — революция яшьлеге, Октябрь ватаны яшьлеге. Шушы мәңгелек темага Е. Евтушенко өлгергән акыл, чарланган каләм белән керешкән һәм, иксез-чиксез әдәбият диңгезендә үз юлын табып, бу изге миссияне уңай хәл иткән.

**В. БРЮГГЕН.**
Харьков шәһәре

# БЕЗ КАПЧЫКТА ЯТМЫЙ

Менә: әдәби очерк дигәнебез тематик яктан тагы да киңәя төште — аңа Мәгъсүм Насыйбуллинның тикшерү һәм суд органнарында эшләүче кешеләребезне тасвир иткән китабы килеп кушылды.

Мәгъсүм Насыйбуллин — Татарстанның Кукмара егете. Ватан сугышында була. 1947 елдан бирле тикшерү органнарында хезмәт итеп килә: озак еллар Свердловск өлкәсендә, аннан Целиноградта, Уфада, хәзер исә Татарстан республика прокуратурасында эшли. Ике институт тәмамлый: юридик институт төп эшенә кирәк булса, филологик белемә язучылык эшенә куәт бирә. 1950 елдан яза башлый. Мәкалә һәм

очерклары үзәк матбугатта да, бик күп шәһәр һәм өлкә матбугатында да даими төстә басылып килә. Бик әйбәтләп кулга тотарлык беренче китабы 1968 елда русча, икенче китабы 1970 елда башкортча басыла.

1969 елдан башлап М. Насыйбуллинның имзасы «Казан утлары», «Социалистик Татарстан», «Татарстан яшьләре»ндә күренә башлый. Ниһаять, быел Татарстан китап нәшрияты аның «Без капчыкта ятмый» дигән китабын бастырып чыгарды.

Кыңгыр эш я җинаять турында язганда гади беллетристика белән дә факт дөреслегенә ышандырып була. Тик бу вакыт дөреслекне аң гына кабул итә. Мәгъсүм Насыйбуллин очеркларының үзенчәлеге шунда ки, ул тормыш фактын, хакыйкатьне аңга тертеп тукымый, ә бәлки һәммәсен йөрәк аша үткәреп, күңелләрне тибрәтеп уздырырга тырыша. Мавыктыргыч сюжет, композиция, персонажларның тос-кыяфәте, холык-фигыле, диалоглары һ. б. белән М. Насыйбуллинның очерклары чын хикәя кебек кабул ителә. Шуның аркасында вакыйга һәм кешеләре тере булып күз алдына килеп баса.

Китап «Хакыйкать юлы» һәм «Закон сагында» дигән ике бүлектән гыйбарәт. Беренчесендә явыз җинаятьчеләр, аферистлар һәм аларны тотып гадел хөкем алдына китереп бастыручылар тасвир ителсә, икенче бүлеге исә тикшерү органнарында эшләүче иптәшләрнең көндәлек, болай караганда гадәти эшләренә багышлана. Чынында исә китап бер бөтен: кешеләр иминлеге сагында торучы милиция, тикшерү, суд органнары эшчеләренең чыннан да күзгә күренми торган зур, бердәм хезмәтләре сурәтләнә.

«Бала чакта кем судья булырга хыяллана икән?» — ди автор. Хак сүздер. Ләкин җәмгыятькә судьясы да кирәк, прокуроры да. Һәм судья да, прокурор да булырга хыялланмаган балалардан бу эшкә җаны-тәне белән бирелеп, янып эшләгән бик талантлы судьяларыбыз, прокурорларыбыз үсеп җитешә. Кемнәр соң алар? Китаптан без шундыйларның берничәсен укып беләбез. Алар — иң зур җинаятьнең дә җеп очын тапкан Ильясовлар, Генкиналар, Гөлванарлар; бәләкәй генә кебек булып күренгән мәсьәләгә дә дәүләт масштабыннан караган Хәсәновлар, Мурзиннар, Ишмаковлар, Фидаилар... Һәркайсының җилкәсендә, күп еллар дәвамындагы юристлык эше тәҗрибәсеннән тыш, үткән сугыш, тормыш тәҗрибәсе дә тупланган.

Менә «Көмеш кылыч»тагы Даян Мурзин. Ул — гаҗәп язмышлы кешеләрнең берсе. «Җырларда җырланган ямьле Ык елгасы буена Балыклы дигән татар авылы урнашкан. Шул авылда 1921 елны ярлы крестьян гаиләсендә туган. Казанда юридик мәктәп һәм институт бетергән зур тәҗрибәле юрист», дип яза аны автор.

Даян Мурзинның Бөек Ватан сугышы вакытындагы батырлыгын риваять итеп сөйләрлек. 1943 елның февраль аенда ул җитәкчелек иткән десантчылар төркеме дошман тылына үтеп керә. Шул көннән алып сугыш беткәнчегә кадәр Мурзин дошман тылында эшли. Ул Моравиядәге партизаннар бригадасына җитәкчелек итә, әйтеп бетергесез авыр, куркыныч операцияләр оештыра. Немец командованиесе аны тотып биргән кешегә бер миллион марка акча бирергә вәгъдә итә. Тик тота гына алмыйлар! Фашистик Германияне җиңгәннең икенче көнендә үк, Чехословакиянең Злин (хәзер Готвальдов) шәһәрендәге зур урамнарның берсен «Майор Мурзин урамы» дип атыйлар. Чехословакиянең сигез шәһәре аны үзенең почетлы гражданины дип игълан итә, аның турында риваятьләр сөйлиләр, китаплар язалар; ЧССР хөкүмәте аны югары орденнар, медальләр белән бүләкли.

Яки менә Казан университеты профессоры Фидаи Фәтхуллинны алыйк («Фидакарь Фидаи»). Бер крестьян баласы. Аның да Шәйморза мәктәбендә укып йөргән чагында юрист — җитмәсә, профессор! — булу хыялы башына да килмәгәндер. Каян килсен! «Ир-ат сугышта. Авыл бушап калган шикелле. Өйдә бер ана да биш бала. Унике яшеннән колхоз эшенә йөрергә туры килә Фидаигә». Ләкин ул укуын ташламый. Кырык җиденче елны унынчыны бетерә. Башта район халык судында секретарь, соңра суд башкаручысы булып эшли. Ә кырык яшендә — профессор! Аның хезмәтләренә йөз яшәр кеше дә көнләшер иде, ә көндәлек вазифалары исә ун кешегә җитәрлек. Менә шундый искиткеч талантлы ир-егетләребез эшли безнең юридик гыйлем дөньясында!

Мин М. Насыйбуллин китабыннан ике генә мисал алып сөйләдем. Ә китапта үрнәкле дә, гыйбрәтле дә хәлләр, язмышлар бик күп.

Алда әйткәнемчә, очеркларның күбесе чын хикәягә тартым. «Без капчыкта ятмый», «Икенче группалы кан», «Гөлванар», «Иптәш прокурор», «Фидакарь Фидаи»

һ. б. хикәягә хас тел, сюжет, композиция белән язылган. Шул сәбәпле алар җиңел укыла, күңелдә кала. Әйтик, Сафин белән Гафиятуллин поши аталар да («Эзләр кая илтә?»), тотылып, җәзасын алалар. Моны информация итеп язсаң, төссез дә, кызыксыз да булыр иде. Ә Насыйбуллин аны әдәби очерк итеп язган. Башта ул урманга барган мәктәп балаларының поши һәм аның ике баласын күреп хәйран соклануларын матур итеп тасвирлый; аннары кышын ике браконьерның шул пошиларны эзәрләкләп атуларын сурәтли; азактан инде, кабат җәй җиткәч, янә дә поши күрү өмете белән урманга барган балаларның күңел халәтен яза. «Әмма балалар көткән, өметләнгән чибәр пошилар күренмәде. Гүзәл табигатьнең яме киткән кебек булды. Барысының да күңелләрен ниндидер моңсулык билəп алды...»

Яки әнә бер дә үтерү, талау булмаган «Иптәш прокурор» дигән очерк та әйбәт укыла. Бөгелмә прокурорының үзе дә, көндәлек эше дә, үзең күргәндәй, күз алдына килә дә баса.

Болар, әлбәттә, китапка да, авторына да әйтелгән мактау сүзләре. Ләкин моңа карап кына әле: «Китап тел-теш тидермəслек», дип әйтеп булмый. Телгә-тешкә тия торган нәрсәләр дә бар анда. Мәсәлән, «Закон сагында» дигән икенче бүлегендә әдәби алымнарның бер төрлелеге күзгә керен тора. «Фидакарь Фидаи» дигәннән башкаларның һәркайсында бүгенгедән чигенеп, үткәнне сөйләү алымы төп персонажның Ватан сугышында булуын сөйләүгә генә кайтып кала. Әлбәттә, үткәннәре бик кызыклы, төрлесенеке төрлечә, тәрбияви әһәмияте дә бик зур, әмма әдәби алымының бер төрлелеге ялкыта башлый.

Бу елларны кайсыбер яшь авторларыбызга тел җәһәтеннән бер чир кагылды. Алар, әйтик, хикәя кылына торган бер үк кеше исемен җөмлә саен кабатламаска кирәк дигән шыр ялангач бер кагыйдәне үзләштереп алалар да, керешәләр жонглерлык итәргә: кеше исемен, егет булса «егет» дип, кыз булса «кыз» дип, «тегесе» дип, «монысы» дип, тагын әллә нилəр дип алмаштырып бетерәләр. Шуның аркасында бер кеше урынына икеөч кеше килеп чыга. Бу чир М. Насыйбуллинга да йоккан.

«Ул ирә сөйләгәннәрнең барын да кире какты. Ильясов аны больницага ирә янына алып барырга булды.

— Әйт тә бир дөресен, нәрсә инде яшереп торырга,— диде тегесе хатынына» («Без капчыкта ятмый»). Кем ул «тегесе»? Автор моны, әлбәттә, «ире» дигән сүзне янәшә өч тапкыр кабатламас өчен язган, әмма «ире»нең, бөтенләй аерылып, икенче бер кешегә әйләнүен сизмәгән.

«Килүчеләр аңлатма язган арада прокурор озын сары чәчле яшь хатынны чакырып сөйләшеп алды. Тикшерүче Ибраһимованың эшләре күп булса да, аңа... әлеге сигнал белән кызыксынырга кушылды» («Тамчыдан — күл»). «Яшь хатын» белән «тикшерүче Ибраһимованың» бер үк кеше икәнлегенә бер ишарә дә юк монда: болар да — икесе ике кеше. «Үзенә чират җиткәч, Тимербаева сискәнеп китте. Ул кул куюдан катгый баш тартты. «Бәлки, үлчәүләр дөрес түгелдер», диде сатучы» (шул ук очеркта). Монысында да «Тимербаева» белән «сатучы» бер үк кеше булырга тиеш икән!

Ә «Югалган кеше» дигән очеркта хәтта Ярослав дигән бер егет, исемен кабатламаска тырышу аркасында гына, берүзе дүрт кешегә әйләнгән: яшь кеше, администратор, җинаятьче, өлкән официант!

Аннары М. Насыйбуллин очеркларында бик үк татарча булып бетмәгән сүз һәм җөмләләр дә җыйсаң байтак кына. «Директор ихтирам белән файдаланучы кеше». Моның сүзләре генә татарча, ә җөмләсе тоташтан русча уйлап корылган. Моны тел гыйлемендә калька диләр. Калькага тагын берничә мисал әйтик: «Һич көтмәгәндә аны ачулы кешеләр куып җиттеләр», «Дүрт сәгать буена Хатип, аннары Гали өендә нәтиҗәсез эзләнү» (үзе бер җөмлә), «Монда Габитовлар кебек аңлы кешеләр ярдәме хәлиткеч роль уйнады», «Сез качкан шәһәрдән Ибраев биреда», «Әллә аның исеме артында бутән берәү яшеренәме», «Кемнәрдер машиналарны куып алып китәләр дә...» (машина бит куып йөрергә хайван түгел!), «Гәрчә ул җинаятьтән ерак торган булса да...» («җинаять булмаса да» дип кенә әйтәсе иде, югыйсә) һ. б.

Мәгъсүм Насыйбуллинга киңәш шул: әдәби мәйданга аяк басарга җыенасың икән — инде көн саен, сәгать саен канынны, миеңне кызганмыйча әдәби осталыкка ирешергә кирәк. Язган бер әйбереңдә дә кеше сүз әйтерлек, бәйләнерлек нәрсәләр калмаска да, булмаска да тиеш. Иң әүвәл, әлбәттә, язу эшенең төп коралы булган телгә бәйләнерлек булмасын.

**ХӘСӘН САРЬЯН**

**Равил Фәхретдинов,**
археолог, тарих фәннәре кандидаты.

# БОЛГАР ШӘҺӘРЛӘРЕ

## Шәһре Болгар

„Гражданнар, иске хуҗалар китте, алардан соң зур мирас калды. Хәзер ул мирас халыкныкы... Бу мирасны саклагыз, һәрбер рәсем, һәрбер сын, һәрбер бина — болар сезнең һәм сезнең бабаларыгызның рухи көченең гәүдәләнеше. Сәнгать ул гүзәллек, ә бу гүзәллекне талантлы кешеләр хәтта залимнәр изүе астында да тудыра белгәннәр. Бу гүзәллек кеше рухының көче, бөеклеге турында сөйли.

Гражданнар! Бер ташка да кагылмагыз, истәлекләрне, биналарны, иске әйберләрне саклагыз — болар барысы да сезнең үткәнегез, сезнең горурлыгыгыз!»

Әлеге сүзләр 1918 елда Россия Үзәк Башкарма Комитетының бөтен халыкка язган мөрәҗәгатеннән алынды. Советлар иле гаять зур кыенлык кичерә. Илдә гражданнар сугышы бара, В. И. Ленин һәм Совет хөкүмәте тарихи истәлекләрне саклап калу турында кайгырталар.

Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң илебезнең тарихи, археологик һәм архитектура истәлекләрен саклауны дәүләт үз кулына ала, аларны җимерү закон буенча тыела.

Борынгы һәм урта гасыр шәһәрләрен, шул исәптән, шәһре Болгарны да өйрәнү планлы рәвештә алып барыла башлый. 1919 елда профессор А. С. Башкиров шәһәрнең культура катламын өйрәнә, ә 1938 елдан бүгенге көнгә кадәр профессор А. П. Смирнов җитәкчелегендә Мәскәү һәм Казан археологлары борынгы Болгар территориясендә тикшеренү эшләре алып баралар.

РСФСР Министрлар Советының 1968 елгы 9 февральдәге карары нигезендә Болгар дәүләт тарихи-архитектура заповеднигы дип игълан ителде. Болгар шәһәренең тарихы, таш хәрабәләре белән кызыксынып, фән оешмаларына, матбугат органнарына Татарстан районнарыннан һәм илебезнең төрле өлкәләреннән хатлар килә. Шушы ихтыяҗны беркадәр канәгатьләндерү йөзеннән шәһре Болгар һәм андагы архитектура истәлекләренең тарихына кыскача сәяхәт кылырга булдык.

Шәм Суар тарихына бәйләнешле язма чыганаклар белән танышканда[1] без Болгар дигән шәһәр исемен дә очратып үткән идек. Әмма ул чыганакларның берсе дә әлеге шәһәрнең кайчан салынуын төгәл генә әйтми. Күп кенә тарихчылар Болгарның төзелә башлавын бирегә ибне Фазлан килеп киткән чор, ягъни 922 ел белән бәйлиләр. Алмуш ханның Багдад хәлифәсенә язган үтенечен канәгатьләндерү йөзеннән шәһәр салынгандыр, диләр. Ибне Фазлан үзе бу хакта бер сүз дә әйтми. Хәер, Гаркави һәм Шпилевский фикерләренчә, ибне Фазлан язмаларында да Болгар шә-

[1] «Казан утлары»ның 1970 елгы 2 санында басылган мәкалә.

һәре турында аерым ишарәләр табарга мөмкин. Мәсәлән, алар «болгар патшасы яши торган җирдән Иделгә кадәр бер фәрсах ара» яки «русларның товарлар төялгән кораблары килеп, болгар пристанена туктыйлар» кебек сүзләрне нәкъ менә Болгарга туры килә дип саныйлар. Бу фикерләр X йөзнең икенче бер географы әл Бәлхи язмалары белән дә ныгытыла. «Болгар — ил исеме, аның халкы ислам дине тота. Болгар шулай ук шәһәр исеме дә, анда Җамигъ мәчет бар»,— ди әл Бәлхи [1]. Менә шушы сүзләрне һәм үткән мәкаләдә Суар турында сөйләгәндә телгә алынган хәбәрләрне әл Бәлхи «Әшкял әл билад» исемле китабында язып калдырган. Академик И. Ю. Крачковский фикеренә караганда, әл Бәлхи әлеге әсәрен 920—921 елларда тәмамлаган [2]. Димәк, әл Бәлхи Болгар иле турында ибне Фазланга кадәр үк белгән булган. Аңа таянып, без дә Болгар шәһәренең 920 елга кадәр үк салына башлавын дәгъвали алабыз. Ә аннан алда ничә ел элек салынган? Унмы, егермеме, әллә тагын да күбрәкме? Кистереп кенә әйтүе кыен. Шулай да 910—920 еллар арасында төзелгәндер, дип уйларга нигез бар. Чөнки Болгар иле турында шактый кызыклы мәгълүматлар калдырып, фарсы сәяхәтчесе ибне Рустә язмаларында шәһәрләр турында, шул исәптән, Болгар шәһәре турында да берниндн хәбәр юк. Мәгълүм булганча, ибне Рустә үзенең географиясен 903—913 еллар арасында төзи. Шулай итеп, Болгар шәһәре 913 белән 920 еллар арасында салынган дип уйлый алабыз. Бу дата нумизматика мәгълүматларына да каршы килми.

Әл Бәлхи язмалары, бигрәк тә аның Болгар һәм Суар, алардагы Җамигъ мәчет, агач һәм киез йортлар, гаскәр саны турындагы хәбәрләре гарәп-фарсы классик географиясенең башка вәкилләре, мәсәлән, әл Истахри, ибне Хәукаль, әл Мәкатдәси, әл Идриси, Йакут китапларында да очрый [3]. Алар әл Бәлхине кабатлап кына калмыйлар, Болгар тарихына кайбер яңалыклар да өстиләр. Ибне Хәукаль, мәсәлән, Болгарда рус товарлары сатылуын искә ала [4].

«Болгар елганың ике як ярына урнашкан,— ди әл Мәкатдәси,— анда йортлар агачтан һәм камыштан. Төннәр анда кыска. Җамигъ мәчет базар уртасында. Анда күптәннән мөселманнар хуҗа. Болгар Идел буена урнашкан, ул башкалага түгел, ә диңгезгә якынрак тора» [5]. Тексттан күренгәнчә, Болгар сүзе биредә ике мәгънәдә йөри. Башта ул ил мәгънәсен аңлатса, соңгы җөмләдә шәһәр турында сүз бара. Лакин әл Мәкатдәси нинди диңгез һәм башкала турында сөйли. Монысы аңлашылып бетми. Әгәр гарәп географларының язмаларында шуңа охшашлы аңлашылмый торган нәрсәләр очрый икән, моны, беренче чиратта, әлеге хәбәрләрне калдыручыларның Болгарда булмавы белән аңлатырга кирәк. Дөрес, бераз соңрак, XII йөздә ике сәяхәтче Болгар җиренә кадәр дә барып җиткәннәр. Аларның берсе — әл Җәвалики, икенчесе — безгә инде таныш булган әл Гарнати. Җәвалики биредә 1145 елда килгән. Кызганычка каршы, аның язмалары сакланмаган. Әл Гарнатига килсәк, аның кайсы шәһәр — Болгар турындамы, Булар турындамы — сөйләве бик үк ачык түгел. Безгә калса, ул Буләрдә булган булса кирәк. Монголларга кадәрге чорда, ягъни X—XII йөзләрдә Болгар шәһәренә кагылышлы гарәп-фарсы истәлекләре кыскача менә шулардан гыйбарәт [6].

Русның бу чорга караган елъязмаларында Болгар шәһәр исеме буларак кулланылмый диярлек. Болгарны 1164 елда Андрей Боголюбский һөҗүменә дучар булган Ибраһим шәһәре («Славный город Бряхимов») итеп карау гадәткә кереп киткән.

[1] Д. А. Хвольсон. Известия о хазарах, буртасах, болгарах... Рус телендә. СПб. 1869, 82 бит.

[2] И. Ю. Крачковский. Избранные сочинения. Рус телендә. IV том. Мәскәү. 1957 ел, 195 бит.

[3] Д. А. Хвольсон. Известия о хазарах, буртасах, болгарах...; А. Я. Гаркави. Сказания мусульманских писателей о славянах и русских. СПб. Рус телендә. 1870 ел; «Худуд ал алем». Рус телендә. Ленинград. 1930 ел, 32 бит; Б. Н. Заходер. Каспийский свод сведений о Восточной Европе. II том. 1967 ел. 36—39 битләр.

[4] Д. А. Хвольсон. Күрсәтелгән хезмәт. 108 бит.

[5] Шунда ук. 84 бит.

[6] Соңрак яшәгән кайбер язучыларның әсәрләрендә дә Болгарның борынгы тарихына караган язмалар очрый. Мәсәлән, ибне әл Варди (1349 елда үлгән), ибне Хәукальгә таянып булса кирәк, Болгар шәһәрендә мәдрәсәләр булганлыгын әйтеп уза. 1732 елда Стамбулда басылган «Җиһан намә» исемле җыентыкка кертелгән XV йөз фарсы язучысы Хомайринең бер әсәрендә Болгар хакында берничә сүз бар (мәсәлән, бу шәһәрдә 500 йорт һәм бер-ике мәчет булганлыгы әйтелә). Х. Френ шуңа охшашлы хәбәрне бер татарча кулъязмада да таба. Анда Хәйдәр хан заманында Болгар шәһәрендә 520 йорт бар иде диелә. Шундый хәбәр «Тәварих әд-дәваир» дигән кулъязмада да бар. Мәгълүм булганча, Хәйдәр X йөздә Болгар ханы булган, бу турыда Френ, Фукс һәм Мәрҗанилар төзегән шаҗәрәләр сөйли.

һәм бу — чыннан да шулай. Соңрак чорда, мәсәлән, XVI йөздә язылган «Казан тарихы» исемле елъязмада Болгар шәһәре Бряхимов (Бряхов) дип атала. XVIII йөздә Георги тапкан бер татарча кульъязмада да Ибраһим шәһәре телгә алына. Аксак Тимер турындагы кульъязмаларның кайберләрендә Болгар шәһәре Ибраһим исеме белән йөртелә»[1].

Болгарның борынгы тарихы турында безнең халкыбызның үз елъязмалары да булгандыр. Чөнки дәүләт кадәр дәүләтнең армиясе, суды һәм административ аппараты да яшәгән, анда шулай ук дипломатия һәм сәүдә мөнәсәбәтләре дә алып барылган. Бу эшләр телдән генә башкарылмагандыр. Болгарларның, медицина, астрономия кебек фәннәр белән берләттән, тарих фәне белән шөгыльләнүләре турында да мәгълүматлар бар. Мәсәлән, Якуб ибне Ногман исемле галимнең «Болгар тарихы» дигән китабы булган. Ул китапны әл Гарнати үзе укыган[2]. «Кыйссаи Йосыф» кебек әсәрләр иҗат иткән болгарлар илдә барган гадәти вакыйгаларны һәм көтелмәгән хәлләрне дә баян кыла белгәннәрдер. Димәк, ул елъязмалар сакланмаган дияргә генә кала...

Бүгенге көндә Болгар шәһәренә бәйле татар чыганакларыннан бары тик берничә легенда белән генә канәгатьләнергә туры килә. Болгар турындагы бер легенданы 1926 елда Сәид Вахиди Казан карты Габделлатыйф бабайдан язып алган. Ул легенданың эчтәлеге кыскача менә моннан гыйбарәт: Нух пәйгамбәрнең улы Яфәснең Гази, Төрек һәм Алып атлы өч улы булган. Алар арасында сугыш чыгып, Гази җиңелгән. Төрек белән Алып ерак, салкын җирләргә күчеп киткәннәр. Алып җирле халык белән аралашкан, аның ике улы туган. Аларга Болгар белән Бортас дип исем кушканнар. Болгар белән Бортас икесе ике җирдә шәһәр корганнар, бу шәһәрләрнең даны еракларга таралган... (С. Г. Вахидов. Татарские легенды о прошлом Волжско-Камского края, «Вестник научного общества Татароведения». 1924 ел, 4 сан. 82—84 битләр; Борынгы татар әдәбияты. Казан. 1963 ел. 23—25 битләр.)

Әлеге легендага охшаш хәбәр, беразүзгәртелеп, XV йөз фарсы язучысы Мирхонд язмаларында да китерелә. Әл Гарнати да кечерәк бер легенда язып алган булган. Анда да Яфәснең оныклары Болгар белән Бортас турында сүз бара һәм аларның шәһәрләр салуы турында сөйләнә[3].

Болгар тарихына караган истәлекләрне актарганда «бөек» эпитеты күзгә еш чалына. Бер яктан, гарәп географлары әл Бәлхи, әл Истархи, ибне Хәукаль (X йөз), әл Идриси (XII йөз), икенче яктан, Көнбатыш Европа сәяхәтчеләре (Юлиан, Плано, Карпини, Рубрук (XIII йөз) безнең борынгы бабаларыбыз яшәгән илне Бөек Болгар иле дип атаганнар. Шул ук шәрык әдәбияты (Рәшидетдин) һәм рус елъязмалары буенча бу дәүләтнең XII йөз — XIII йөзнең яртысындагы башкаласы Бүләр Бөек шәһәр исеме белән мәгълүм. Алтын Урда чорында Болгар җиренең яңа үзәгенә әверелгән Болгар шәһәрен дә Бөек Болгар дип зурлаганнар. Ә безнең халык аны, үзенә хас тыйнаклык, ләкин нииндидер эчке бер җылылык белән, гади генә итеп шәһре Болгар дип йөрткән.

...XIII йөзнең 20—30 еллары Европа һәм Азия халыкларына күп бәла-каза, авыр фаҗигаләр алып килә. Ил артыннан ил яулап, шәһәр артыннан шәһәр җимереп, Чыңгыз хан гаскәре безнең якларга килеп җитә. Ләкин никадәр генә көчле һәм мәрхәмәтсез булмасын, Чыңгыз хан армиясе үзе буйсындырган халыкларның гасырлар буе тир һәм кан түгеп төзегән матди һәм рухи культурасын җимереп бетерә алмый. Үзе буйсындырган халыклар белән чагыштырганда һәр яктан күп түбән торган монголлардан күзгә күренерлек әллә ни мирас та калмаган. Хәер, аларның төп өлеше ахырдан кире үз өйләренә, Үзәк Азия далаларына кайтып киткән.

Чыңгыз хан үлгәч, ул төзегән монгол империясе, билгеле булганча, дүрт кисәккә бүленә. Аның көнбатыш өлешендә, ягъни Иртыш буйларыннан алып Константинопольгә һәм Болгардан Дәрдбәндкә кадәр булган җирдә Алтын Урда дәүләте төзелә[4]. Бу дәүләт турында сөйләгәндә бер нәрсәне ассызыклап үтәргә кирәк. Үзәк Монгол

---

[1] «Татарстан АССР тарихы»ның яңа басмасында (Казан, 1968 ел. 47 бит. Рус телендә.) Ибраһим шәһәре Бүләр шәһәре белән бер итеп күрсәтелгән. Тарихи фактлар моңа каршы килә.

[2] А. А. Монгайт. Абу Хамид ал-Гарнати и его путешествие в русские земли 1150—1153 гг. «История СССР» журналы, 1959 ел, 1 сан, 171 бит.

[3] Борынгы татар әдәбияты, 26 бит.

[4] Чын исеме Күк Урда. Алтын Урда дип руслар атаганнар. Бераз соңрак, Урта Азиядәге җирләр бүленеп, Ак Урда исеме белән йөртелә башлый.

дәүләтеннән аермалы буларак, Алтын Урда моңарчы утрак һәм ярым утрак халыклар яшәгән территориядә оешкан. Шуңа күрә аның составына кергән болгар, кыпчак, черкас, алан, мукшы һәм башка халыклар үзләренең элекке экономик һәм культура дәрәҗәләрен саклап кала алганнар. Дөресен әйткәндә, монголларның власте асылда әлеге халыклардан ясак җыюга гына кайтып калган. Тора-бара бу монголлар да җирле халык тарафыннан йотылып беткән. Заманында Карпинилар, Альбериклар күргән антропологик типның (тәбәнәк буйлы, сирәк сакаллы, артык кысык күзле, җәлпәк борынлы чын монголның) Алтын Урданың көчәйгән чорында, ягъни XIV гасырның беренче яртысында эзе дә калмый[1]. Алтын Урда Каракорымдагы Бөек ханга буйсынмаучы мөстәкыйль дәүләткә әверелә. Батый ханнар, Субудайлар вакытында какшаган экономика яңадан торгызыла, ә Рус һәм Болгар кебек шактый иртә феодаль җәмгыятьтөзи алган һәм шәһәр культурасы тудырган илләр үсешнең яңа баскычына күтәреләләр. Монгол яулап алулары нәтиҗәсендә аерым Болгар шәһәрләре кырылсалар да, кайберләре яңадан торгызыла һәм көчәеп китә. Шундыйлар рәтенә, беренче чиратта, шәһре Болгар керә.

Болгар шәһәренең тарихта якты эз калдырган чоры шушы Алтын Урда дәверенә туры килә. Кайбер тарихчыларыбыз шул чорлардагы Болгар шәһәрен һәм болгарлар яшәгән җирләрне Алтын Урдадан бәйсез, ниндидер бер мөстәкыйль дәүләт итебрәк карарга яраталар. Мондый караш татар этногенезына Алтын Урда чорының катнашы булмады, дип исбатларга тырышудан килеп чыга кебек. Ләкин Болгар тарихыннан 200 елны сызып ташлау, аны шул замандагы бөтен бер төрки дөньядан аерып карау дөрес булмас иде. Алтын Урда тарихы буенча кыйммәтле истәлекләр калдырган XIII—XV йөз географлары һәм тарихчыларыннан Җүзҗани, ибне Фазлулла, әл Мөфаддаль, Әзхаби, Казвини, ибне Хальдун, әл Гасади, «Искәндәр анонимы»ның авторы, Шәрәфетдин Йәзди, Габдерраззак, «Төрек шәҗәрәсе»нең авторы, Гаффәри Болгар җирен һәм аның үзәге Болгар шәһәрен Алтын Урда составындагы җирләр һәм шәһәрләр рәтеннән санап үтәләр[2]. XIV гасырның күренекле географы, Мисырның дәүләт эшлеклесе Шиһабетдин әл Гомәри Болгарны Алтын Урданың иң күренекле шәһәрләреннән берсе, ди[3].

Дөрес, бу чор гарәп-фарсы чыганаклары арасында шәһре Болгар турында махсус язылган истәлекләр бернича генә. Шуларның берсе — исеме югарыда телгә алынган ибне әл Варди язмалары. Ул, Болгарны шарык дөньясында дан тоткан шәһәр иде, аның турында язып та, сөйләп тә бетерергә мөмкин түгел, ди[4]. Гарәпнең атаклы сәяхәтчесе ибне Батута 1333 елда Алтын Урдага сәяхәт кыла, Үзбәк хан аны шәһре Болгарга кадәр озаттырыпук куя. Әмма Болгарда өч көн яшәвенә карамастан, ибне Батута бу шәһәр турында әллә ни кызыклы әйберләр калдырмаган. Башка гарәп сәяхәтчеләре кебек, аны да бу якларда җәйге төннәрнең бик кыска булуы, төньяк халыкларның кыйммәтле мехлары күбрәк кызыксындырган булса кирәк[5].

Язма әдәбият мәгълүматлары нумизматик материаллар белән тулыландырыла. Алтын Урданың Сарай әл Мәхрус (Сарай Батый), Сарай әл Җәдид (Сарай Бәркә), Гөлстан, Азак, Кырым, Каффа, Үргәнеч, Сарайчык, Урда, Мукшы, Үкәк, Маҗар, Сыгнак, Тәбриз, Баку, Мәхмүдабад кебек шәһәрләре белән беррәттән, болгарларның Болгар әл Мәхрус (Болгар), Болгар әл Җәдид (Иске Казан), Булар, Кирмән кебек шәһәрләрендә дә акча сугыла[6]. Биредә бер нәрсәне искәртеп үтәргә кирәк. Кайбер тарихчылар Болгар шәһәрләрендә акча сугылуын аларның Урдадан бәйсез булулары белән аңлатырга телиләр. Мондый фикер белән килешүе кыен, чөнки болгарлар әлеге акчаларны Урда ханнары исеменнән сукканнар.

Алтын Урда дәверенең беренче яртысы, ягъни 1250 еллардан алып 1350 еллар азагына кадәрге чор — бу дәүләткә буйсынган халыклар, шул исәптән, болгарлар

---

[1] XIV гасыр тарихчысы һәм географы әл Гомәринең монголларның кыпчаклар тарафыннан ассимиляцияләнүен тасвирлап язган хәбәрләре антропологик тикшеренүләр белән дә раслана.

[2] В. Г. Тизенгаузен. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. I том. СПб. 1884 ел. 197, 206, 378, 447 битләр; II том. М.-Л. 1941 ел. 19, 86, 91, 127, 145, 164, 205, 211 битләр.

[3] В. Г. Тизенгаузен. I том. 237 бит.

[4] Д. А. Хвольсон. Күрсәтелгән хезмәт. 89 бит.

[5] В. Г. Тизенгаузен. I том. 296—297 битләр.

[6] Г. А. Федоров-Давыдов. Клады джучидских монет. «Нумизматика и эпиграфика» журналы. 1960 ел. I сан. 188—189 битләр.

тормышында да иминлек чоры. Шушы беренче йөз еллыкта болгарларның житештерү көчләре яңа үсеш ала. Моңа Болгар, Суар, Җүкәтау, Иске Казан кебек шәһәрләрне казыганда табылган матди культура калдыклары ачык дәлил. Ювелир сәнгате, архитектура, бигрәк тә таш һәм кирпеч йорт-сарайлар төзү, керәмика эшләү элеккегә караганда нык алга китә. Европада беренчеләрдән буларак, чуен кою үзләштерелә, ташны чокып язу, нәкыш үю шушы чорда киң колач җәя. Сәүдә көчәя. Көнбатыш һәм Көнчыгыш илләре арасында барган халыкара сәүдәне Түбән Иделдә Сарай үз кулында тотса, безнең бу якларда, ягъни Урта Иделдә, шундый ук вазифаны шәһре Болгар үти. Болгар базарларында, бер яктан, Рус дәүләте, Балтик буе, «вису» һәм «юра» халыклары, Чулман иле, икенче яктан, башкорт һәм кыпчак далалары, Урта Азия, Кавказ, Иран, Кытай, Һиндстаннан килгән товарлар сатыла.

Алтын Урда культурасы дип аталган бай һәм үзенчәлекле культура туа. Бу культураның нигез ташларын салуга болгар культурасы да зур өлеш кертә. Түбән Иделдәге Урда шәһәрләрен казыганда археологлар күп кенә болгар истәлекләре табалар: алтын һәм көмеш чыбыклардан үреп эшләгән ювелир әйберләр, каралтылган көмеш йөгертелгән кыйммәтле савыт-саба, бизәк төшерелгән бронза көзгеләр, ат яки эт рәвешендә эшләнгән көчкенә йозаклар h. б. Өченче ел, Сарай Бәркә һәм Сарай Батый шәһәрләрен казыганда, әлеге шәһәрләрнең борынгы керамика сәнгате белән танышырга туры килде. Үзенең тышкы күренеше, бизәкләре һәм балчык составы буенча ул болгар керамикасына якын.

Үзбәк ханның улы Җанибәк идарә иткән чорда да Алтын Урда сәяси һәм экономик яктан көчәя бара. Әмма шул ук вакытта Сарайда чуалышларның беренче билгеләре дә күренә башлый. Властька Җанибәк үзе ике туганын, шул исәптән, тәхет варисы Тәнибәкне үтереп килә. Табигый бәла-казаның чыгуы сәяси хәлнең тагын да кискенләшүенә ярдәм итә. 1346 елда Кытайдан чума авыруы тарала. Озакламый ул күп җирләрне басып ала, хәтта Италия, Франция, Англия кебек илләргә барып җитә. Бу коточкыч афәттән Дәшти Кыпчак зур зыян күрә. Бер Кырымда гына 85 мең кеше үлә, ә Сарай, Хаҗи Тархан (Әстерхан) һәм Үргәнечтә шул кадәр кеше кырыла ки, хәтта үлгәннәрне күмәргә кеше табып булмый...

Чуалышлар көчәйгәннән-көчәя бара. Сарай әһелләре арасындагы хыянәткә чит ил коткысы, шымчылык килеп өстәлә. Тәхет өчен бала атаны, туган туганны суя. 1357 елда Җанибәкне үтереп, тәхеткә аның улы Бирдебәкне утырталар, ике елдан соң Бирдебәк үзе шундый язмышка дучар була. Шуннан соңгы 20 ел эчендә, ягъни 1378 елда Туктамыш властька килгәнгә кадәр, Сарайда 25 хан идарә итә, кайберләре тәхеттә нибары берәр ай гына утырып кала.

Шушы чуалышлардан файдаланып, кайбер әмирләр һәм бәкләр Сарайга буйсынмаучы аерым олыслар төзергә тотыналар. 1361 елда әмир Булат Тимер Болгарны ала. Шул ук елда Токай атлы икенче бер әмир Мукшы (Наручад) шәһәрен үз кулына төшерә, янәдән бер әмирлек төзелә. Хаҗи Тархан, Сарайчык, Харәзем, Алтын Урдадан аерылып чыгып, мөстәкыйльлеккә юл алалар.

1367 елда Суздаль кнәзе тарафыннан җиңелгәч, Булат Тимер Сарайга кайтып китә һәм шунда Урда ханы Газиз тарафыннан үтерелә. Газиз хан Болгарны яңадан Алтын Урдага буйсындырганмы-юкмы, анысы мәгълүм түгел. Ләкин ике елдан соң, Сарай тәхетеннән бәреп төшерелгәч, Хәсән атлы икенче бер хан Болгарга кача һәм үзен Болгар әмире дип игълан итә. 1370 еллар азагында Мамай һәм Урус хан Алтын Урданың бердәмлеген беркадәр торгызалар. Болгар яңадан буйсындырыла. Тәхеткә Туктамыш утыргач, Алтын Урданың бердәмлеге тагын да ныгый төшә. Хәтта Куликово сугышында Мамайны җиңгән Дмитрий Донской да Туктамышның властен танырга мәҗбүр була. Туктамыш Сарайда да, Болгарда да ханлык итә [1]. Аңа «Бөек хан» исеме бирелә, бу исемне Алтын Урданың башка бер генә ханы да, хәтта Батый белән Үзбәк тә йөртмәгән була. Әмма шул ук Туктамыш заманында Алтын Урда нигезеннән җимерелергә тотына. Моңа, бер яктан, Куликово сугышы сәбәп булса, икенче яктан, Чыгытай олысының әмире, атаклы җиһангир Аксак Тимер (Тамерлан) җимергеч удар ясый. 1388 һәм 1391 елларда Туктамыш ягыннан Аксак Тимергә каршы сугышта болгар гаскәре дә катнаша. Бу сугышлар, бигрәк тә 1391 елның 18 июнендә

[1] Бу хәбәр В. Н. Татищевта бар (История Российская. V том, Мәскәү, 1965 ел. 152 бит).

борынгы Болгар җирендә — Кондызча елгасы янында булган дәһшәтле сугыш, болгарларга зур зыян китерә. Сугышта җиңгәннән соң Аксак Тимер кинәт Сәмәркандка кайтып китә һәм дүрт елдән соң, ягъни 1395 елда, Төньяк Кавказда Туктамыш белән соңгы кабат сугыша. Туктамыш бу юлы да җиңелә һәм Болгар ягына кача. Кайбер тарихчылар Аксак Тимер шул елны Болгар шәһәрен дә җимергән дип уйлыйлар. Шушы чорларны тасвирлаган барлык татар легендаларында һәм кульязмаларда, Шәрәфетдиннең «Тәварихы Болгария»сендә җиһангирның шәһре Болгарны тар-мар китерүе турында сөйләнә. Алтын Урда тарихының зур белгече профессор М. Г. Сафәргалиев та шундый фикердә тора[1]. Тамерланның шәһре Болгарны алуы никадәр дөрестер, әмма XIV йөзнең икенче яртысында Алтын Урдада барган сәяси кризис һәм канлы сугышлар Болгар җире һәм аның үзәге Болгар шәһәренең иминлеген нык какшаталар.

Болгар шәһәрләренә тагын да зуррак зыянны Новгород ушкуйниклары китерә. Бу юлбасарлар, безнең якларга да килеп җитеп, кала һәм авылларны талап йөри башлыйлар. Алардан башка Суздаль һәм Новгород князьләре дә Идел буена берничә һөҗүм оештыралар. Юлбасарларның һәм әлеге князьләрнең 1360, 1366, 1370, 1374, 1376, 1391, 1396, 1401 еллардагы һөҗүмнәре нәтиҗәсендә Болгар, Җүкәтау, Кирмәнчек, Казан (Кашан?) һәм башка шәһәрләр нык зыян күрә[2]. 1360 елда юлбасарлар Җүкәтауны талап киткәч, Хызыр хан рус князьләренә шул пиратларны тотып җәзаларга куша, һәм князьләр Кострома шәһәрендә җыелып киңәшәләр дә юлбасарларны тотып Сарайга җибәрәләр. Әмма тәртип урнаштыру өчен бу чара гына җитми, юлбасарлар башбаштаклыкларын дәвам иттерәләр. Алтын Урданың үз мәшәкатьләре күп булу сәбәпле, ул Болгар шәһәрләрен элләни яклый алмый. Хәер, 80—90 елларга таба Болгар җирләре, бигрәк тә Иске Казан тирәсенә тупланган төньяк өлкәләр, әкренләп Урда йогынтысыннан чыга баралар. Ул җирләрнең акча системасы да Урда акча системасыннан аерыла. Ә инде Кама аръягының, ягъни Болгарның экономик һәм хәрби көчләре нык аксый, 1374 елда хәтта болгарлар юлбасарларның 90 көймәлек отрядын да куып җибәрә алмыйлар, 300 сум йолым түләргә мәҗбүр булалар[3]. Менә шундый кискен халыкара хәл шәһре Болгарга элекке куәтен торгызырга мөмкинлек бирми. 1431 елда Бөек князь Василий II нең гаскәр башлыгы Федор Пестрый шәһре Болгарга җимергеч һөҗүм ясый[4]. Данлы шәһәр тарих битләреннән төшеп кала, аны XIV гасыр башларында ук күтәрелеп чыккан Иске Казан алыштыра.

Дөрес, әле шуннан соң да Болгар исеме кайбер чыганакларда очрый. XVI йөз шагыйре Мөхәммәдьяр үзенең «Нуры Содур» исемле поэмасын 1542 елда шәһре Болгарда Казан ханы Мөхәммәт Әмин каберен саклаганда язган диган фикер йөри. Шагыйрь үзе хан каберенең «Болгар шәһре Казан дәрвазәсендә», ягъни Болгар шәһәрендәге Казан капкасында, дөресрәге, капкасы янында булганлыгын әйтә[5].

Икенче бер татар шагыйре Мәүлә Колый да үзенең кайбер хикмәтләрен «шәһре Болгар кәндләрендә» яза[6]. Әмма ни генә булмасын, ул заманда Болгарны кеше яши торган шәһәр дип күз алдына китерүе шактый кыен. Дөресрәге, ул инде ярым хәрабәләр белән тулы шәһәр калдыгына әверелгән булгандыр, язарына азык эзләп, борынгылар каберенә гыйбадәт кылырга дип йөрүче шагыйрь һәм һәртөрле мөсафирлар җыйнала торган булгандыр анда. Шул ук Мәүлә Колыйның әйтүе буенча, аның остазы Болгарда үзенең шәехләренә ике эстанә (мавзолей) төзегән...

---

[1] М. Г. Сафәргалиев. Распад Золотой Орды. Рус телендә. Саранск. 1960 ел. 164—166 битләр.

[2] Полное собрание русских летописей (ПСРЛ). X том. Мәскәү. 1965 ел. 232 бит; XI том. Мәскәү. 1965 ел. 6, 12, 20, 25, 126, 164 һәм 211 битләр.

[3] Никон елъязмасындагы мондый хәбәрләргә, ихтимал, саграк карарга кирәктер. Елъязмаларга, гомумән, беркадәр шапырыну, тегә яки бу вакыйганы берьяклырак яктырту хас. Мәсәлән, рус князьләренең болгарларга походын алар бик җентекләп язалар, ә инде болгарлар ягыннан булган һөҗүмне, ягъни үзләренә ошамаган күренешне алар бик сирәк яктырталар. Әйтик: «Шул ук елны болгарлар Муромны алдылар», «Болгарлар Устюгны алдылар» кебек хәбәрләр әйтү белән чикләнәләр.

[4] ПСРЛ. XII том. Мәскәү. 1965 ел. 9 бит.

[5] Мөхәммәдьяр. Төхфәи Мәрдан. Нуры содур. Казан. 1966. 83 бит. Казан ханын Болгарга илтеп күмүләре бераз сәер тоела тоелуын. Шулай да борынгылар кабере белән тулы «изге җирдә» күмеп, бәлкем, ханга хөрмәт күрсәткәннәрдер. Бирәдәге Казан капкасы дигән сүзне Болгардан Казан ягына чыга торган юл капкасы дип аңларга кирәк. Борынгы шәһәрләрдә икенче бер шәһәргә яки илгә таба чыгучы юл белән бәйле капканы шул шәһәрнең яки илнең исеме белән атаганнар. Мәсәлән, XVI йөздә Казанда Алат, Арча, Нугай, Галич һ. б. капкалар булган.

[6] Борынгы татар әдәбияты. 481 бит.

1712 елда Казан һәм Зөя метрополиты Тихон Казан губернаторы Апраксинга «борынгы мөселманнар шәһәре Болгар»ның юкка бушап ятуы, анда таш хәрабәләрдән бүтән берни дә җан иясе юклыгы, менә шул урынның монастырь төзү өчен бик тә уңай булуы турында аңлатып хат яза. Бу фикер губернатор күңеленә хуш килә: ирләр монастыре төзү турында карар кылына. Андрей Михайлов атлы бер дьяк, шул ук елның сентябрендә Болгарга барып, монастырь астында калачак урыннарны, шулай ук аның карамагына керергә тиешле чәчүлек җирләрне, болыннарны һәм урманнарны үлчәп кайта. Берләттән ул шунда, тарихта беренче буларак, Болгар хәрабәләрен язып ала. Алар белән танышканда, Михайловка Кадыйрмөхәммәт исемле укымышлы карт аңлатмалар биреп йөри[1].

Монастырь төзелә. Аны борынгы шәһәрнең үзәгенә — хан сарае һәм Җамигъ мәчет булган урынга салалар. Башта ул агачтан гына эшләнә, монастырь өчен хәтта бер-ике Болгар төрбәсе дә файдаланыла. Озакламый аның тирәсендә рус бистәсе барлыкка килә.

1722 елның 8 июнендә, Иран сугышына китешли, Петр I кызыксынып Болгарга туктый. Бирәдә ул 3 сәгать була, атка утырып, шәһәрне әйләндереп алган, 7 чакрым озынлыктагы урларны йөреп чыга, таш биналарны тамаша кыла. Ике манараның өсләренә менеп тирә-якны күзәтә, аларны төзегән болгарларның осталыгына хәйран кала, берсенең ярыла башлаганын күреп, тимер кыршау салырга боера, хәтта манара ташына үзенең исемен язып калдырырга да онытмый. Бер айдан соң Петр Әстерханнан Казан губернаторы Салтыковка хат яза, хатында Болгар хәрабәләрен саклау кирәклеген әйтә, аларны төзәтү өчен ташчылар һәм известь җибәрергә куша, җирдә аунап яткан кабер ташларының язуларын күчереп алырга да әмер бирә.

Шул ук заманда 50 кабер ташының язулары күчереп алынып, тәрҗемә ителә, әмма императорның башка боерыклары онытыла. 1732 елда Казанның бай сәүдәгәре Михляев тарафыннан Болгардагы монастырь өчен таштан гына чиркәү салына. Аны төзү өчен болгар хәрабәләренең ташлары файдаланыла, кабер ташларының да күбесе чиркәү нигезен һәм идәнен түшәргә китә. Монастырь 1770 еллар тирәсендә ябыла, монахлар Чабаксарга күчереләләр, әмма чиркәү үз урынында кала. Бистә әкренләп зур авылга әверелә. Чиркәү нигезеннән артып калган кабер ташлары авыл өйләрен салырга тотыла.

1768 елда Болгарга Екатерина II килеп чыга. Әгәр Петр I заманында анда 70 тән артык бина калдыгы сакланган булса, Әби патша килгән елда аларның саны 44 кә калган була. Соңыннан атаклы француз философы Вольтерга җибәргән хатында императрица болай ди: «Идел буйлап сәяхәт итеп йөргәндә мин, баркамнан чыгып, борынгы Болгар шәһәрен карарга киттем. Бу шәһәрне үзенең кияве өчен Тамерлан яулап алган дип сөйлиләр. Мин бирәдә күп кенә таш биналар һәм бик нык эшләнгән тугыз манара күрдем. Шул хәрабәләрнең берсе янына килдем, ә анда кырыклап татар басып тора иде. Губернатор миңа бу җирне татарларның изге итеп санавы, аларның күпләп бирегә гыйбадәт кылырга йөрүләре хакында сөйләде»[2].

Екатерина II дән соң Болгарда академик Паллас була. Паллас Болгар пулатлары һәм төрбәләре турында кызыклы язмалар калдыра, кайберләрен рәсемгә төшерә. Шул ук елны академик Лепехин да шул хәрабәләрне өйрәнә. XIX йөздә Эрдман, Свиньин, Шмит, Френ, Кафтанников, Турнерелли, Вторые, Березин, Риттих Болгарда булып, аны әйләндереп алган урларны һәм җимерекләрне янәдән тасвир кылалар, яңа мәгълүматлар өстиләр, планга төшерәләр.

Үткән гасырда, җир өстендә сакланып калган архитектура истәлекләреннән башка, сукаланып яки язгы сулар белән актарылып җир астыннан чыккан бик күп табылдыклар да җыела. Бу табылдыклар зур-зур коллекцияләр тәшкил итәләр. Кызганычка каршы, Нелов, Фукс, Дарьян, Толмачев, Березин, Ешевский, Заусайлов, Лихачевлар җыйган коллекцияләрнең күбесен табып булмый. Дәрес, Хельсинкиның милли музеенда, Мәскәүдәге Тарих музеенда, Ленинград Эрмитажында, Татарстан дәүләт музеен-

---

[1] Михайлов язмаларын Мәскәү архивларының берсеннән К. И. Невоструев табып ала һәм үзенең хезмәтендә китерә: О городищах древнего Волжско-Болгарского и Казанского царств. «Труды I Археологического съезда». II том. Рус телендә. Мәскәү. 1871. 526—540 битләр.

[2] Цитата И. А. Ардашевның «Развалины Болгар и древние болгары по описанию англичанина Э. П. Турнерелли» (Казан. 1901 ел. 32 бит) исемле әсәре буенча китерелде.

да күбесе Болгарда җыйналган археологик табылдыклар әле дә тупланган, әмма алар, халык әйтмешли, диңгездән бер тамчы гына.


1877 елда Казанда IV археологик съезд үткәрелү Болгар шәһәренең тарихын өйрәнүдә зур адым була. Съезд делегатлары Болгарга сәяхәт ясыйлар. А. Ивановский, В. Поповский, В. Радлов тарафыннан бер көнлек казу эшләре алып барыла. Икенче елны Казан университеты каршында төзелгән Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте Болгарны үз карамагына ала, анда планлы казулар башлап җибәрә, архитектура истәлекләренә ремонт ясау эшләрен сештыра. 1887 елдан 1916 елга кадәр төрле вакытларда В. Глинский, В. Казаринов, А. Штукенберг, П. Пономарев, М. Хомяков, П. Кротов, Б. Крелленберг, С. Покровский, М. Худяков, В. Смолин шәһәр мәйданын һәм андагы кайбер җимерекләрне, Кече шәһәрчек дигән урынны, Ага Базарны өлешчә казыйлар. 1884, 1885, 1889, 1896, 1905 елларда Кара пулат, Кече манара, өч төрбә ремонтлана, аларга күз-колак булу өчен сакчы билгеләнә.

1919 елда А. С. Башкиров шәһәрлекнең культура катламын өйрәнә, ә 1938 елдан бүгенге көнгә кадәр А. П. Смирнов җитәкчелегендә Мәскәү һәм Казан археологлары бирегә зур тикшеренү эшләре алып баралар. Менә шушы санап үтелгән экспедицияләр нәтиҗәсендә шәһре Болгар тарихы буенча бай материал туплана.

Петр I Болгар белән танышканда анда 77 дән артык, ә Екатерина II килгәндә 44 таш бина булганлыгын әйткән идек. XIX йөз урталарына аларның күбесе җимерелеп таш нигезләре генә калган була. 1869 елда Рус археология җәмгыяте рәисе А. С. Уваров үтенече буенча Болгар шәһәрлегенең планы төзелгән була, анда шул чорда билгеле булган 37 җимерек һәм ярым җимерек бина яки аларның эзләре исәпкә алына. Шуннан соң үткәрелгән археологик тикшеренүләр нәтиҗәсендә бүгенге көндә 82 таш хәрабә, дөресрәге, аларның урыннары билгеле. Шуларның 70 ләбе шәһәр мәйданында, калганнары аның читендә. Чагыштырмача яхшырак сакланганнары, ягъни әле җимерелеп бетмәгәннәре бары тик бишәү генә.

Түбәндә без шул хәрабәләрнең кайберләрен кыскача карап үтик.

**Җамигъ мәчет** дип аталган таш мәчетнең аскы өлеше. Дүрт почмагында 4 манара калдыгы басып тора. Төньяк стенада ишек урыны бар, икешәр тәрәзә һәм берәр ишек урыннары ян стеналарда да сакланган. Таш идәндә дүрт рәт итеп, һәрбер рәттә бишәрләп утыртылган теракләрнең (колонналарның) нигезләрен күрергә мөмкин. Бинаның нигезе җиргә сугылган субайлар өстенә салынган.



*Җамигъ мәчет хәрабәләре (реставрациядән соң). Тәрәзә урыны аша арткы планда «Изге Николай чиркәве» исемле төрбә күренә. Реставрация эшләре җитәкчесе — архитектор С. С. Айдаров.*

*Автор фотосы*

1712 елда Кадыйрмөхәммәт Сенчәлиев Михайловка әлеге хәрабәнең элек зур мәчет булганлыгын әйтә. Кафтанников язмалары буенча, Болгарда гыйбадәт кылырга йөрүче татарлар, башкортлар, үзбәкләр һәм кыргызлар нәкъ шушы хәрабә янында җыйнала торган булганнар.


**Олы манара.** Аның ярыла башлаган өстенә Петр I кыршау кидертә. Соңгарак Казанның вице-губернаторы аның башын такта белән каптыра, ә 1837 елда Казанның ике бае аны калай түбә белән алыштыралар, бөтен манарага штукатур салдыралар. Шул ук 30 нчы еллар азагында Болгарга сәяхәт ясаган инглиз Э. Турнерелли манараның бик мәһабәт булып басып торуын, ләкин Пизан башнясыдай бер якка таба авыша баруын, әгәр дә вакытында чарасын күрмәсәләр, берничә елдан авып, янәшәсендәге чиркәүне дә җимерәчәген әйтә. Берничә елдан (1841 елда) манара чыннан да ава.

**«Изге Николай чиркәве»** дип аталган хәрабә. Алай аталуының сәбәбе шул — аны 1732 елга кадәр монастырь чиркәве итеп файдаланганнар. Бина төрбәләргә хас стильдә эшләнгән; татарлар арасында сакланган истәлекләр буенча, биредә ир затыннан булган кешеләр күмелгән.

**«Монастырь базы»** дип аталган хәрабә. Исеменнән үк аңлашылганча, бу да монастырь өчен файдаланылган. Тышкы күренеше белән ул Николай чиркәвенә тартым, тик тәбәнәгрәк һәм яннарында өстәмә терәткечләр юк. Риваятьләр буенча, бусында хатын-кызлар күмелгән. Баз казыган чагында монахлар биредә хатын-кыз чәчләре һәм алтын парча кисәкләре тапканнар дигән хәбәрләр дә бар. XVIII йөз башында төрбә эчендә кабер ташлары булган.

Санап үтелгән хәрабәләрнең барысы да борынгы Болгарның үзәк өлешендә урнашканнар. Заманында алар урлар (валлар) белән урап алынган булган. Шунда ук хан сарае да булган, аның калдыкларын Михайлов «патша йорты» дип атый һәм Җамигъ мәчеттән 10 сажин итеп күрсәтә. Кызганычка каршы, аның урыны чиркәү астында калган.

**Ак пулат.** XVIII—XIX йөзләрдә күп сәяхәтчеләрнең игътибарын җәлеп иткән таш бина. 1860 еллар азагында җимерелгән, хәзер нигезе генә беленеп тора. Пулатны



*«Монастырь базы» исемле төрбә (реставрациядән соң). Реставрация эшләре җитәкчесе — архитектор С. С. Айдаров.*

*Автор фотосы*

мәчет яки ханнарның мәҗлес сарае булган дигән карашлар да йөрде, ләкин тикшеренүчеләрнең күпчелеге аны мунча дип саныйлар һәм бу фикер хәзер бәхәс куптармый инде.


Озынлыгы 30 м һәм биеклеге 6 м дан артык булган бу мунча өч кисәктән торган. Уртада мунчаның үзәк өлеше, аның дүрт почмагында ян бүлмәләр эшләнгән. Мунчаның көньяк өлеше үзе ике кисәккә бүленеп, ял итү һәм киенү-чишенү урыннары булып хезмәт иткән. Төньяктагы аерым зур бер бүлмәдә мич һәм казаннар урнашкан булган. Аннан үзәк залга идән астында эшләнгән юллар буйлап җылы һава, ә стеналар эченә ясалган балчык һәм тимер торбалар буенча су килгән. Мондый торба калдыклары Эрдман һәм Кафтанников тарафыннан әле мунча җимерелеп бетмәгән вакытта табылалар. Мунчаның түбәсе биш гөмбәзле булган.

Ак пулат Болгардагы зур мунчаларның берсе — җәмәгать мунчасы булгандыр. Шундый ук мунча 1938—1940 елларда А. П. Смирнов тарафыннан казыла һәм аңа, эчке ягының штукатур төсенә карап, Кызыл пулат дип исем бирәләр.

Мунча салуга таләпчәнлек, андагы архитектур төгәллек болгарлардагы чисталыкның бер чагылышыдыр. Безнең халык өчен хас бу күркәм сыйфатның, күрәсең, тирән тамырлары бар. Гарәпләрнең укымышлы һәм күпне күргән кешеләреннән Исмәгыйль Әбү әл Фида Болгар иленең башкаласында өч зур мунча булуын әйтә. Фарсы язмасы «Фәрһәң намәдә Болгар ханының кызы авыргач, аны Чулман (Кама) буйларында үскән каен себеркесе белән дәвалаганнар дип язылган. Чисталыкның бөтен кагыйдәләрен төгәл үтәп баручы гарәп һәм фарсы зыялыларының әллә кайдагы болгар мунчаларына игътибар итүе ул мунчаларның шактый мәгълүм булулары хакында сөйли булса кирәк.

**Кече манара.** Биеклеге 15 метрлы бу манара бүгенге көндә чагыштырмача иң яхшы сакланган истәлек. Олы манарага охшатып, ак ташлардан өелгән бу манараның да нигезе дүрт почмаклы, төньягында ишеге бар. Өскә 48 басмалы әйләнмә баскыч алып менә, баскычны яктырту өчен стеналарда берничә ян тәрәзә калдырылган.

Үз гомерендә шактый җирләр һәм шәһәрләр күрергә өлгергән инглиз Турнерелли, әлеге манараны искә алып, менә нәрсә ди: «Шушы җимерелгән шәһәр уртасында басып торганда һәм үткән белән хәзерге заман турында уйланганда, күңелне газаплы уйлар басып алды. Хәрабәләргә бер күз сирпеп алу тарихның дәһшәтле чорларын мең төрле фәлсәфи фараз кылуларга караганда да тизрәк күз алдына китереп бастыра. Бу тойгы йөрәкләрнең түренә үтә һәм безне үзебез турында уйла-



*Кече манара (реставрациядән соң). Реставрация эшләре җитәкчесе — архитектор С. С. Айдаров. Автор фотосы*

нырга мәҗбүр итә. Заманында бу диварларда да менә хәзер безнеке кебек тормыш кайнап торган...»

**Кабер ташлары.** Петр I нең болгар истәлекләрен саклау кирәклеге турындагы боерыгын үтәү йөзеннән 50 кабер ташының күчерелеп алынып, тәрҗемә ителүләре, әмма соңгарак чиркәү нигезенә салынулары турында югарыда әйтеп узган идек. Шуларның 47 се болгар ташлары була, аларны Кадыйрмөхәммәт Сөнчәлиев, ә 3 әрмән ташын Иван Васильев тәрҗемә итәләр. 1771 елда академик Лепехин тәрҗемәләрне бастырып чыгара. Ул вакытта әле алар шактый начар тәрҗемә ителгән булалар. 1831 елда Ю. Клапрот шул ук 1722 елда эшләнгән эстампажлар нигезендә болгар ташларының французча тәрҗемәсен бирә, ләкин аларның датасын билгеләүдә хата җибәрә, таш куелган елны белдерүче «җиаты җәр» сүзенә ялгыш аңлатма бирә. Клапрот бу сүзләрне гарәпчә дип уйлап, аларны саннар ярдәмендә «тәрҗемә итә» һәм 623 (1226) ел китереп чыгара. Шушы елны монгол яулап алулары башланган «бәла килгән ел» дип атый. Шушы ук фикерне 1832 елда Эрдман, 1852 елда П. Березин куәтләп чыгалар. Бу ялгышны 1863 елда татар галиме Хөсәен Фәезханов төзәтә: Тәтеш өязендә табылган өч ташны укып, ул «җиаты җәр»нең берничә гарәп сүзе булмавын, ә җиде йөз дигән сан икәнлеген әйтә. Бу гади генә, әмма ифрат та кыйммәтле ачыш соңыннан фәндә кабул ителә. Шуннан соң әлеге 47 болгар ташының яңа тәрҗемәләрен эшләү кирәклеге алга килеп баса. Әмма Петр I заманында күчерелгән язмаларның кайдалыгы гына билгеле булмый тора. Тик 1967 елда гына атаклы эпиграфист һ. В. Юсупов аларны Мәскәүнең Үзәк дәүләт архивыннан табып кайта.

Болгар хәрабәләренә карата язылган махсус хезмәтләрдә һәм гомуми әдәбиятта әйтелгән фикерләр буенча, бу хәрабәләр — XIII йөзнең икенче, бигрәк тә XIV йөзнең беренче яртысы истәлекләре. Бу чор, әйткәнебезчә, Алтын Урда һәм Болгар культурасының чәчәк ату дәвере. Ул чорда монументаль архитектураның үсеше эпиграфиканың үсеше белән үрелеп бара, һәм бу күренеш гомуми тарихи үсеш белән нык бәйләнгән. Болгар архитектурасының Урта Азия, Кавказ, Мисыр архитектурасына беркадәр якынлыгы бар, ә менә язулы кабер ташлары Идел буенда бары тик болгарларның үзләренә генә (соңрак Казан татарларына) хас.

...Соңгы сүз шәһре Болгарның хәрби корылмалары турында.

Болгар шәһәренең хәрби ныгытмалары археологик әдәбиятта шактый кызыксыну уяткан истәлекләрдән саналалар[1]. Заманында полковниклар Н. Савенков, А. Штраус, А. Риттих, инженер П. Ефимов бу ныгытмаларның үлчәүләрен алып һәм планга төшереп, алар турында кызыклы гына фикерләр дә әйтеп чыгалар. Соңга таба бу урларны А. П. Смирнов, О. С. Хованская, В. А. Красновлар археологик яктан тикшерәләр, аларны казып, ныгытмаларның элекке кыяфәтен күз алдына китерерлек материал туплыйлар.

Бу тикшеренүләр соңында шәһре Болгар ныгытмаларының тарихын кыскача болайрак күз алдына китереп булыр иде: монголларга кадәрге чорда урлар белән шәһәрнең үзәге генә әйләндереп алынган булган. Алтын Урда дәверендә бөтен бистәләрне дә чолгап алырлык озын һәм биек урлар өелгән, аларның өстендә бүрәнәләрдән бурап һәм ур борылышларында манаралар калдырып, биек стена тезелгән. Ике рәт итеп эшләнгән стеналарның киңлеге ике метрга якын булган, уртасына яндырылган балчык һәм вакланган кирпеч тутырылган. Алгы стена арттагысына карaганда биегрәк, аңа яшеренеп ату өчен тишекләр калдырылган. Стеналар һәм манаралар өстән кыек түбә белән ябылган. Канаулар су белән тутырылган, аларның төбеннән очлы казыклар тырпаеп торган. 7 чакрым озынлыктагы мондый урлар берничә урында киселеп, капкалар ясалган булган. Көнчыгыш яктагы ныгытмаларда

---

[1] XVIII йөздә Россиядә селитра эшләү заводлары төзелә башлый. Моның өчен борынгы шәһәр урыннары файдаланыла: чөнки алардан калган урларда селитра кайнатырга чималл булырлык кеше һәм хайван сөякләре күп табыла. Федоров дигән бер капитан Идел буен йөреп чыга һәм соңыннан Казан губернаторы Мещерскийга җибәргән хатында, берничә шәһәрлек белән беррәттән, Болгарга да селитра заводы төзергә кирәклеген яза. Шул фикерне яклап губернатор Сенатка тәкъдим кертә. Әмма Сенат завод төзү тарихи истәлекләргә зур зыян китерер дип, аңа каршы килә. Екатерина II Сенатның карарын кире кага, «мөмкин кадәр борынгы хәрабәләрне сакларга тырышып, ул җирне губернатор тәкъдим иткәнчә файдаланырга» дип кул куя. 1770 еллар азагында Болгарда берничә селитра заводы салына һәм алар XIX йөзнең урталарына кадәр эшлиләр. Шул вакыт эчендә борынгы шәһәрне әйләндереп алган урларга зур зыян килә.

шактый оста һәм, әйтер идек, хәйләкәр итеп эшләнгән капка бар. Капка һәм аның ике ягындагы урлар шундый итеп тоташтырылганнар, капкага һөҗүм итүче дошманнар стеналар һәм манаралар өстендәге сакчылар ягыннан калканнар белән сакланмаган уң якларын куеп керергә тиеш булганнар. Ә тәз атучы укчыларга шул гына кирәк тә.

Шәһәр ныгытмалары, көньякта тагын да ныграк эшләнеп, анда өстәмә бер кальга төзелгән булган. Гомумән, Болгарның көньякка, ягъни дошман һөҗүме мөмкин булган дала якка таба тараеп, почмакланып эшләнгән урлары болгарларда саклану тактикасының шактый югары булуы турында сөйли. Әлеге урлардан тыш, читтәрәк корылган, ләкин шул ук шәһәрне саклау өчен эшләнгән башка ныгытмалар да булган. Мәсәлән, төньякта, Идел ягыннан мөмкин булган һөҗүмне тоткарлый алырлык ясалма сазлык эшләнгән булган. Аның өчен болгарлар Иделгә коючы кечкенә генә елганы буып, суны күтәрткәннәр.

Болгарның бу эчке ныгытмаларыннан тыш, бөтен бер зур ансамбль тәшкил итәрлек тышкы ныгытмалары да булган. Шуларны мин 1962, 1964 елларда өйрәндем. Аларның берсе Утка елгасы буенда, бернича шәһәрлектән һәм аларны тоташтырган урлардан гыйбарәт. Икенчесе Молостовка диган авыл янында зур бер үзәнлек буеннан башланып, Болгарга 4 километр чамасы килеп җитмичә, янә бер үзәнлеккә килеп тоташа. Ике рәт урдан һәм алар арасындагы тирән чокырдан торган бу ныгытманың буе 7 км ярым, иң киң урыны 60 метрга якын. Аның урлары шул кадәр текә һәм биек (кайбер җирдә 10 м га җитә), аның аркылы атлы гаскәр түгел, җәяүле сугышчының үтүен дә күз алдына китерүе бик кыен. Күп гасырлар үтү белән урлар инде тәбәнәкләнгән һәм канавы саеккан. Өстәмә агач ныгытмалар булганмы-юкмы— казымыйча анысын әйтүе кыен. Алар булмаган тәкъдирдә дә, бу корылма дошман явы өчен зур тоткарлык булып торган. Күз алдына китерик: дала яктан ургылып атлы гаскәр килә һәм кинәт көтелмәгән тигез җирдә пәйда булган биек ур алдында туктап кала. Тәвәккәлләп һәм зур кыенлык белән алдынгы отряд беренче урны үтә һәм шунда ук упкындай тирән чокырга тәгәри. Ат басудан, аягы-кулы сынудан, сөңге кадалудан исән калган сугышчылар икенче урга омтыла, тик ур өстендәге сакчыларның аткан уклары аларның аркаларына килеп кадала. Күп көчен югалткан дошман, урны ала алмыйча, аны читләтеп үтәргә мәҗбүр була, анда үтеп, иңкүлектәге сазны кичкәнче, болгар гарнизоны шәһәргә кереп бикләнә... А. П. Смирнов һәм О. С. Хованскаялар Болгар оборона системасының Идел буенда гына түгел, ә бөтен Көнчыгыш Европада шактый югары дәрәҗәдә торганлыгын әйткәннәр иде. Әлеге тикшеренүләр вакытында мин ул иптәшләрнең фикерләре дөрес булуына тагын да ныграк ышандым.

□□□□□□□□□□□

# ҖИЛКӘННЕ ҖИЛЛӘР ЕКМАГАН!

**Исәнмесез, Фәнис абый!**

**Бу хатны мин Сезнең «Җилкәнне җилләр еккач» дигән повестегызны укыгач язарга булдым.**

**Фәнис абый, минем сезнең турыда ишеткәнем бар иде. Кайбер шигырьләрегезне дә укыдым. Ләкин мин аларга игътибар бирмәгәнмен. Ә бүген мин аларны кабат укып чыктым.**

**«Җилкәнне җилләр еккач» миңа ошады. Аеруча Фәнияр образы ошады. Минем Фәнияр кебек нык рухлы буласым килә. Миңа уналты яшь хәзер. Тугызынчы класста укыйм. Бик күпләр кебек мин дә батырлык турында хыялланам. Сезнең әсәрне укыгач, мин уйлана башладым. Әгәр дә мин Фәнияр хәлендә калсам, нишләр идем! Юк, мин түзә алмам кебек. Мин Сезнең дә Фәнияр кебек булуыгызны, шундый хәлдә урта мәктәп, университет тәмамлавыгызны беләм. Сезнең дә авыруны җиңүегезне беләм. Сезгә мин чын-чынлап сокланам.**

**Фәнис абый, шундый батыр да, горур да, көчле дә кеше образы тудырган өчен рәхмәт сезгә!**

**Мин тагын шуны әйтергә телим: Фәнис абый, җилкәнне җилләр екмаган, ексалар да, ул икенче егылмаслык булып торгызылган. Икенче егылмас бит ул, мин ышанам.**

Кайнар комсомол сәламе белән
СОЛТАНОВА ЛӘЛӘ.

# КӨЧЛЕ РУХЛЫ ШАГЫЙРЬ

*(Рәхим Саттарның тууына 60 ел)*

„Татарча укырга, язарга яхшылап өйрән. Туган телне белмәсәң, бер телне дә яхшы белмәссең». Бу юллар шагыйрь Рәхим Саттарның 1942 елда фронттан улына язган хатыннан алынды.

Әйе, Рәхим Саттар туган телен, туган халкын, туган илен чын күңелдән яратучы кешеләрнең берсе булган. Аның сугышка кадәр язылган шигырьләре дә, сугыш вакытында язылганнары да Ватанга чиксез мәхәббәт тойгылары, патриотизм рухы белән сугарылган. Фашист әсирлегендә коточкыч газаплар кичергән шагыйрьнең йөрәк тавышын без күп еллардан соң гына ишеттек. Тоткынлыкта язган шигырьләре белән Р. Саттар бик хаклы рәвештә Муса Җәлил кебек патриот шагыйрьләр сафына басты.

Тәрбияләдең мине горур итеп,
Баш имәдем әле буй җитеп
Бер дошманга, иркен тын алам,
Кулда богау, капка йозакта,
Ләкин рухым иркен, хөр кала,—

ди шагыйрь «Рухым гали» дигән шигырендә Совет Ватанына мөрәҗәгать итеп.

Рәхим Саттар 1912 елда Башкортстанда туа. Бөек Ватан сугышына киткәнче яшьләр газетасында эшли. 1942 елның 27 маенда Көнбатыш фронттагы каты сугышларның берсендә яраланып дошман кулына эләгә. Язучы Абдулла Алиш үзенең бер хатында:

«1942 елның азагында Берлин янындагы лагерьда шагыйрьләрдән: Муса Җәлилне һәм Рәхим Саттарны («Кызыл яшьләр» газетасыннан) очраттым»,— дип язган иде. Рәхим Саттарның концлагерьдан качуы турындагы хәбәр дә безгә Абдулла Алиш хатлары аша билгеле. Ләкин, кызганычка каршы, батыр йөрәкле шагыйрь үзебезнең якка исән-сау чыгып җитә алмаган...

Рәхим Саттарның «Җыр дәвам итә» дигән китабы 1966 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан иде. Журналның бу санында без шагыйрьнең моңарчы матбугатка чыкмаган ике шигырен урнаштырабыз.

## Р. Саттар

### Сөям мин

Кар бураны булсын, төне булсын...
Яратам мин шушы җир өстен.
Туган илем, синең күкрәгеңнән
Яшәү көче алып мин үстем.

Тирән хисле туган телгә рәхмәт,
Көчле итеп мине яраткан.
Җылы, нәфис җанда зур мәхәббәт,
Әрәм итеп юкка таратмам.

Гыйшык тулып күңелемдә минем,
Җылы яңгыр булып агылсын,
Ташкын көче кебек дәрте белән
Синең кылларыңа кагылсын!

Сөям сине гаҗәп сөю белән,
Сөйгән кебек туган илемне,
Таң томаны кебек хыялыңда
Тибрәт мине, бәгырем, сөй мине.

1940

●

Күптән түгел, үткән көннәремдә
Кем кешегә мине санады!
Тормыш корган һәрбер скопидом
Миңа бер чүп итеп карады.

Гомер кышы килеп, күңелемә
Җылы эзләп йөргән көннәрдә,
Әйтегезче, җылы бер сүз ишетеп,
Җылы караш күрдем кемнәрдән!

Мин бүгенге көнне көрәшләрдә
Сугышып алдым, көчем кызганмый.
Ватып барам тормыш дәрьясында
Юлларыма яткан бозларны!..

## Заһирә Гомәрова

### Яфрак-парашют

Көз. Яфраклар коелалар
Көнгә ялтырап,
Талгын гына төшеп килә
Әнә бер яфрак.

Башкаларга бәрелми дә,
Ялгыз — бер читтә:
Үрмәкүч төшә тирбәлеп
Яфрак бишектә.

Барча яфраклар торалар
Моңа карашып:
Үрмәкүчне алып төшә
Яфрак-парашют.

### Синнән дә матур итеп

Әй оста соң бу Рәсим,
Ясады ул бер рәсем
Чын әтәч төсле итеп,
Белсә әтәч карар иде
Үзе дә исе китеп.

Тик югалды бу рәсем,
Тәрәзне җил ачтымы?
Әтәче чын әтәч булып
Шуннан чыгып качтымы?

— Кикрикүк,— дип кычкыра,
Кунган да ул киртәгә.
Тик Рәсим дә сер бирми:
— Синнән дә матур итеп
Ясармын,— ди иртәгә.

### Чакырсыннар

Еракларда туңганнардыр,
Кунганнардыр кыяларга...
Кайтсыннар инде кошчыклар
Без ясаган ояларга.

Җылы, иркен өйләрендә
Бик рәхәтләнеп торсыннар.
Ләкин оя туйларына
Башта безне чакырсыннар.

## Гамил Афзал

# ХАЛЫК БЕЛӘН ОЧРАШУ

ХИКӘЯ



Алга» колхозының парторгы, шул ук вакытта авыл мәктәбендә директор булып эшләүче иптәш Гыйләҗев безгә таныш кеше иде. Бервакыт шәһәр мәгариф бүлегенә килгән мәлне, Гыйләҗев өзгәләнеп үтенде:

— Безнең якларга килеп чыксагыз, туп-туры үземә сугылыгыз, егетләр, үзем — баш, үзем — түш үк булмасам да, аллага шөкер, сүзем үтә, авторитет та бар,— дигән иде.

— Насыйп булса...— дигән булдык без, кыстатып чәй эчкән кодагый кебек.

— Насыйбын-ниен көтеп торырга ничу, безнең халык белән дә очрашырга кирәк бит, бүтән колхозларда йөрисез, безнең халыкның да тере язучыларны күрәсе килә, так что, бер килеп чыгыгыз әле, егетләр...

— Дөнья хәлен белмәссең,— дигән булдык без, җилкәне кашып.

— Кәтәрбез, егетләр, туп-туры үземә,— диде Гыйләҗев, киндер машинасының ишеген ябып.

Берничә ай үткәч, без — бер төркем Әлмәт язучылары — «Алга» колхозына шап итеп килеп төштек. Кечкенә генә агач мәктәптә Гыйләҗевне эзләп таптык, Гыйләҗев безне күргә артык сөенмәсә дә, аның бәләкәй генә кабинетында күңелле шау-шу ясап күрештек, хәл-әхвәл сораштык. Коридорга балаларны җыеп, өстәл, урындыклар куеп, җәйләр, кышлар, этләр, песиләр, каз бәбкәләре турында шигырьләр, хикәяләр укыдык. Балалар елмаеп кул чаптылар.

— Әйдәгез әле, егетләр, иптәш Шәйхетдинов белән дә танышып чыгыйк,— диде Гыйләҗев.

— Кем ул иптәш Шәйхетдинов?

— Безнең пред, бик башлы егет.

Алты почмаклы, иркен генә иске йортка идарә урнашкан. Хисапчылар бүлмәсеннән аерым итеп, такта белән генә бүленгән пред-

седатель кабинеты, кабинет димәсәң хәтере калыр, Гыйләҗев шунда кереп китте. Без, озын агач эскәмиягә утырып, «язмышыбызның хәл кылынуын» көтәбез. Гыйләҗевнең пред белән сөйләшкәне безгә аерым ачык ишетелеп тора.

— Язучылар килде бит әле, иптәш Шәйхетдинов.

— Нинди язучылар?

— Ну, брошюра, рассказ язучылар.

— Нишләп йөриләр алар монда?

— Халык белән очрашырга килгәннәр.

— Һе, очрашырга... Кем чакырган аларны!

— Һм...

— Иптәш Гыйләҗев, аларга әйтегез, ит планы үтәлмәгән. Кассада бер тиен акча юк чагында мәтәшеп йөрмәсеннәр әле, бетмәс монда колхоз җилкәсен кимерергә килгән-киткән ыбыр-чыбыр.

— Алар килделәр инде, иптәш Шәйхетдинов, уңайсыз бит, көтеп утыралар.

Шуннан Гыйләҗев такта аралыкка, без утырган якка ымлап күрсәткәндер, ахрысы, аңлаштылар болар.

— Ым, ым, хы...

— Ым, ым, һе...

— Әһе, әһе...

— Әһем, шулай диләр аны, ну бик әйбәт булыр, культураны үстерергә кирәк, конечно, без культурага каршы түгел.

Ишек киң ачылып, Гыйләҗев белән Шәйхетдинов елмаешып килеп чыктылар. Кирза итек кигән, кыл кебек каты чәчен «ежик» алдырган, киң, кара-кучкыл битле Шәйхетдинов, йөз ел күрмәгән туганнарын очраткан кебек, йөзеннән нур балкытып, безнең белән күреште.

— О, исәнмесез, иптәшләр, исәнмесез! Ну, молодецлар да икән үзегез, бик көтәдер идек үзегезне, бик көтәдер идек,— диде ул, безнең кулларны каты кысып.

Без берни ишетмәгәндәй елмаеп күрештек, хәл-әхвәл сораштык. Аннары Шәйхетдинов, иптәш Гыйләҗевкә борылып, елмаймый гына боерык бирде.

— Сез, иптәш Гыйләҗев, кадерле кунакларны Мөшәрәфә апаларга урнаштырыгыз, алҗыганнардыр, ял итсеннәр, чәй эчә торсыннар, кич халыкны җыярбыз,— диде.

Һәр колхозда «килгән-киткән ыбыр-чыбырны» ашатып чыгара торган иркен генә, чиста гына бер йорт була. Без Мөшәрәфә апаның өендә ял иттек, чәй эчтек, чәчләрне тарап, кәгазьләр караштырып алдык. Кичкә таба Шәйхетдинов үзе килеп чыкты, ул танымаслык иде: әйбәтләп кырынган, өстендә энәдән-җептән генә чыккан кара костюм, кар кебек нейлон күлмәк белән кара галстук, аягында көзге кебек ялт итеп торган кара туфли.

— Әйбәт кенә ял иттегезме, иптәшләр? — диде ул, күңелле гөрелдәп,— Мөшәрәфә апа, сыйладыңмы кунакларны? Болар бит кунакларның иң кәттәләре!

Клубка барганда Шәйхетдинов колхозның хәле турында сөйләп барды, гектар, центнерлар, план, йөкләмә... Клубыбыз иске, яңаны салырга вакыт җитенкерәми тора әле, диде.

Клублары манарасыз иске мәчет инде, сәхнәдә озын өстәл, комач, графин белән су, фанердан гына эшләнгән, селкенеп тора торган трибуна.

Шәйхетдинов безне халык белән таныштырды, зурлап, мактап, безгә сүз бирде. Без сөйләгәндә үзе ихлас күңелдән көлеп, кул чабып утырды.

Очрашу бик күңелле үтте. Селкенеп торган фанер трибунадан без рәхәтләнеп сайрадык, мөгаен, бер сүзебез дә әрәм китмәгәндер. Дөньяны күргән, куллары яргаланган, бер карауда тупасрак күренгән агайлар, апалар, яшь җилкенчәк безгә пәйгамбәр авызына карагандай карап, сүзләребезне йотып утырдылар. Кызык урыннарда, бот чабып, күзләреннән яшь чыкканчы көлделәр.

Яратам мин шундый риясыз көлә торган эчкерсез халык белән тулы авыл клубларын, такта чәйле, якты чырайлы крестьян халкын.

Әдәби кичә тәмам булып, күп рәхмәтләр ишетеп, без халык төркеме белән бергә урамга чыкканда ярты төн иде.

Лапас түбәләреннән тулган ай калыккан, авыл серле дә, моңлы да кебек. Әллә кайда этләр өрә, капкалар шыгырдый, көмештәй нурга коенып карт өянкеләр йоклый.

Шәйхетдинов безне, күңелле кичә уздыручыларны, янә дә Мөшәрәфә апа өенә «бераз гына сөйләшеп утырырга» чакырды. Без әдәп белән генә баш тартып, вакытның инде соң булуын, иртәгә язу өстәле янына утырырга кирәклеген әйттек.

Председатель хәтта рәнҗегән сыман итте. Аннары үзен-үзе кулга алып, саубуллаша башлады.

Гыйләҗев белән Шәйхетдинов кат-кат безнең кулларны кысып, эшләпәләр болгап, авыл читендә озатып калдылар. Тагын килегез, иптәшләр, тагын килегез, бик күңелле булды, диештеләр.

Бу вакыйгадан соң байтак еллар үтте, дөньяда кем бар да, кем юк. Гыйләҗев белән Шәйхетдинов юл чатындагы карт өянке төбендә әле һаман да кулларын, эшләпәләрен болгап басып торалар кебек, иске клубның тәрәзәләре төбендә яшь каеннар җилләнә кебек тоела миңа.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ӘДӘБИЯТ ТУРЫНДА ЗУР СӨЙЛӘШҮ

Башкорт шагыйре Нажар Нәҗми: Казанга самолет белән, тимер юлдан һәм су юлыннан барып була, ләкин юлларның иң турысы, иң якыны — дуслык юлы, дигән иде. Менә шундый юл буйлап июнь аенда Мәскәүдән, Уфадан, Ижевскидан, Чебоксардан, Саранскидан, Йошкар-Оладан, Саратовтан, Новосибирскидан Казанга бик күп язучылар килде. Алар Идел буе әдәбиятларында хәзерге заманның чагылышы турында сөйләшү өчен РСФСР язучылар союзы идарәсенең күчмә Секретариаты утырышына җыелдылар.

20 июньдә Казанның Актерлар йортында Секретариат утырышын РСФСР язучылар союзы председателе, Ленин премиясе лауреаты Сергей Михалков ачты. Ул үзенең чыгышында, Идел буенда яшәүче язучылар алдында торган бурычларга тукталып, без бик әһәмиятле теманы тикшерәбез, чөнки хәзерге заман темасы ул иң элек совет кешесенең хезмәте дигән сүз, ә совет кешесе үзенең эшләрен дөрес яктыртуыбызны таләп итә, аның таләбен тормышка ашыру — безнең язучылык һәм гражданлык бурычыбыз, диде.

Секретариат эшендә катнашучы язучыларны КПССның Татарстан өлкә комитеты, ТАССР Верховный Советы Президиумы һәм ТАССР Министрлар Советы исеменнән партиянең Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Вәлиев котлады. Ул республикабызның бүгенге көне, аның промышленносте, авыл хуҗалыгы, фән һәм мәдәният өлкәләрендәге уңышлары турында сөйләде.

Татарстан язучылар союзы идарәсе председателе Зәки Нури, халыклар арасында дуслык хисләре тәрбияли торган китаплар язарга кирәк, диде. Хезмәтнең матурлык, шатлык чыганагы булуын раслаган әсәрләрнең күбрәк язылырга тиешлеген әйтте. Ф. Хөсни, Г. Бәширов, Б. Камалов, Г. Паушкин, М. Хәбибуллиннарның соңгы елларда иҗат ителгән повестьларына тукталып, аларның нәкъ менә шул планда язылуларын сөйләде. РСФСР язучылар союзының тәнкыйть секциясе председателе В. Дементьев Идел буе халыкларының әдәбиятына гомуми обзор ясады. Тәнкыйтьче И. Ростовцева, Идел буе поэзиясендә булган уртак тенденцияләргә тукталып, С. Хәким, Х. Туфан, М. Кәрим, Н. Нәҗми шигырьләрен анализлады. Р. Мостафин Идел буе өлкәләрендәге тәнкыйтьнең уңай якларына тукталды һәм алдагы бурычлар турында сөйләде. РСФСР язучылар союзы секретаре А. Ананьев авыл темасын яктыртудагы проблемаларга, М. Прилежаева, А. Алексин балалар әдәбиятына, «Сибирские огни» журналының баш редакторы А. Смердов Идел буе һәм себер халыклары әдәбиятының үзара бәйләнешенә, Б. Камалов татар прозасына кагылышлы проблемаларга тукталдылар.

РСФСР язучылар союзы секретарьларыннан П. Нилин башкорт язучысы Ф. Исәнголовның «Арыш башагы» һәм Ә. Еникинең «Рәшә» әсәрләренә, Ю. Бондарев башкорт прозаигы Х. Гыйләҗевнең «Погонсыз солдатлар» романына, тәнкыйтьче В. Разумневич Р. Мостафинның «По следам поэта-героя» китабына, А. Коптяева, И. Гази, Г. Ахунов, Ә. Бикчәнтәев романнарына тулы анализ ясады.

Мостай Кәрим әдәбиятта форма һәм эчтәлек мәсьәләләренә, язучы Ф. Хөсни, Мәскәү тәнкыйтьчесе С. Шуртаков, РСФСР язучылар союзы секретаре Д. Кугультиновлар милли үзенчәлек проблемаларына кагылышлы мәсьәләләргә тукталдылар.

Секретариат утырышларында Чувашстан язучылар союзы председателе Н. Дедушкин, башкорт шагыйре М. Гали, Йошкар-Оладан тәнкыйтьче Ким Васин, Мордва язучысы В. Горбунов, шагыйрь С. Орлов, Мордва язучылар союзы идарәсе председателе И. Девин, «Волга» журналының баш редакторы Н. Шундик, Мәскәү шагыйре М. Львовлар чыгыш ясады.

РСФСР язучылар союзы секретариаты утырышларында Татарстан Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Хәсәнов, партиянең Үзәк Комитет инструкторы Н. Жильцова, партиянең Татарстан өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. Мусин, Казан шәһәре башкарма комитеты председателе урынбасары И. Хәбибуллиналар катнашты.

Секретариат үз эшен зур әдәби кичә белән тәмамлады. Ул кичне консерваториянең актлар залы шигырь яратучылар белән шыгрым тулы иде. Бу кичәдә рус, татар, башкорт, чуваш, калмык, мари, мордва, удмурт шагыйрьләренең шигырьләре көчле алкышлар белән каршы алынды. Кичәне Ленин премиясе лауреаты, шагыйрь С. В. Михалков алып барды.

Казанга килгән кунаклар шәһәребезнең промышленность предприятиеләрендә, пионер лагерьларында, КамАЗда, Түбән Кама һәм Әлмәт шәһәрләрендә булып, күп санлы укучылар белән очраштылар.

## ЯШЬ ШАГЫЙРЬЛӘР ФЕСТИВАЛЕ

СССР төзелүгә 50 ел тулу уңае белән Казанга Советлар иленең төрле почмакларыннан поэзиянең яшь вәкилләре җыелды.

Бу форум 10 июньдә Төзүчеләрнең культура сараенда зур шигырь бәйрәме белән ачылып китте. Анда Мәскәү шагыйре Николай Зиновьев, Белоруссиядән Н. Федюкович, Молдавиядән Анатолий Чокану, Латвиядән Янис Рокпелнис, Литвадан комсомол җырларының республика фестивале лауреаты Витаустас Бараускас, Әрмәнстаннан Армен Мартиросян, Грузиядән Тагу Мебуришвили, Бакудан Әзербайҗан Ленин комсомолы премиясе лауреаты Ильяс Таптыг, Алма-Атадан Казагыстан Ленин комсомолы премиясе лауреаты Надежда Лушникова, Казагыстаннан Мөхтәр Шаханов, Үзбәкстаннан Абдулла Арипов, Фрунзедан Кыргызстан Ленин комсомолы премиясе лауреаты Турар Кожомбердиев, Төркмәнстаннан Алты Акмамедов, Уфадан Сәлам исемендәге премия лауреатлары Шәриф Биккол һәм Абделхак Игебаевлар, Чебоксардан Раиса Яковлева, Саранскидан Мордовия Ленин комсомолы премиясе лауреаты Сергей Кинякин, Ижевскидан Удмуртстан Ленин комсомолы премиясе лауреатлары Флор Васильев һәм Олег Поскребышевлар, Татарстаннан Муса Җәлил исемендәге премия лауреаты Равил Фәйзуллин, Татарстан шагыйрьләре Рәдиф Гатауллин, Тәүфикъ Камалиев, Мөдәррис Әгъләмов, Лидия Григорьева, Әхмәт Рәшитов, Гәрәй Рәхим, Николай Беляев, Зөлфәт Маликов, Шамил Маннаповлар чыгыш ясадылар.

Шундый ук кичәләр М. Горький исемендәге Үзәк культура һәм ял паркында, Казан шәһәренең культура сарайларында үткәрелде.

Шагыйрьләр КамАЗ төзүчеләре, Түбән Кама, Әлмәт, Бөгелмә, Лениногорск яшьләре алдында чыгыш ясадылар. Партиянең Татарстан өлкә комитетында республикабыз җитәкчеләре белән очраштылар.

Казан шәһәренең Актерлар йортында татар язучылары катнашы белән яшь поэзиянең үсеше турында семинар үткәрелде.

ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты һәм Язучылар союзы катнашы белән уздырылган бу фестивальдә Татарстан язучылар союзы идарәсе председателе Зәки Нури, Язучылар союзының иҗат эшләре буенча секретаре Ренат Харисов, ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты һәм ВЛКСМның Казан шәһәр комитеты секретарьлары катнашты.

## АЛТАЙДА ӘДӘБИЯТ КӨННӘРЕ

СССР төзелүгә 50 ел тулуга багышлап, Алтай өлкәсендә совет әдәбияты декадасы үткәрелде. Илебезнең төрле республикаларыннан килгән җитмешләп күренекле язучы Алтай өлкәсе хезмәт ияләре алдында күп санлы чыгышлар ясадылар. РСФСР язучылар союзы делегациясе составында барган Гариф Ахунов Барнаулда декада ачылу уңае белән оештырылган дуслык кичәсендә, яңа ТЭЦ төзелешендә, Поселиха районының машина сынау станциясендә, Колывань таш кисү заводы культура сараенда, Змеиногорск шәһәре культура сараенда, «Россия» колхозында, Рубцовск шәһәре эшчеләренең культура сараенда һәм Барнаул телевидениесеннән чыгышлар ясады.

## ПУШКИН БӘЙРӘМЕ

Июнь башында илебез бөек рус шагыйре А. С. Пушкинның туган көнен зур бәйрәм белән билгеләп үтте. СССР язучылар союзы оештырган бу бәйрәмгә чит илләрдән дә кунаклар килде. Алтынчы Бөтенсоюз Пушкин бәйрәменең үзәге елдагыча Псков өлкәсенең Михайловское авылы янындагы зур яшел аланда булды. Бу аланга Советлар Союзының төрле почмакларыннан меңәрләгән шигырь сөючеләр җыелган иде. Чит илләрдән килгән кунаклар һәм Советлар Союзында яшәүче төрле милләт шагыйрьләре тамашачылар алдында чыгыш ясадылар. Кунаклар шулай ук Ленинградта, Псков өлкәсендәге тарихи урыннарда һәм Пушкин заповеднигында, Новгород шәһәрендә булдылар. Бәйрәмнең соңгы аккорды Мәскәүнең Чайковский исемендәге залында яңгырады.

Бу зур бәйрәмдә татар шагыйрьләреннән Гәрәй Рәхим һәм Рәдиф Гатауллин катнашты. Шагыйрь Гәрәй Рәхим Михайловское авылы янындагы яшел аланда Татарстан язучылары исеменнән чыгыш ясады һәм шигырь укыды.

## ҮЗБӘК ДУСЛАР ЯНЫНДА

Быел Үзбәкстанда әдәбият үсешенә һәм аны пропагандалауга кагылышлы берничә иҗат бәйрәме уздырылды. Тугандаш әдәбиятлар атналыгында катнашырга Татарстаннан шагыйрь Зәки Нури барды һәм, Ленинград, Кыргызстан, Латвия, үзбәк язучылары белән бергә, Каракалпак автономияле республикасы, Хорезм өлкәсе авыллары һәм шәһәрләрендә күп санлы укучылар белән очрашты. Танылган үзбәк язучысы Камиль Яшенга 60 яшь тулуга багышланган иҗат кичәсендә катнашып, юбилярны Татарстан язучылары исеменнән котлады.

## ТӘҖРИБӘ УРТАКЛАШУ

Безнең илебездә социализм төзү тәҗрибәсен өйрәнү өчен, Татарстанга Англия коммунистлар партиясе вәкиле Идрис Кокс, Филиппин компартиясе вәкиле Филипе Малайя, Суданнан коммунист Госман Мәхҗүб иптәшләр килде. Алар республикабызда милли культураның үсеше белән аеруча кызыксындылар. КПСС өлкә коми-

тетының культура бүлегендә иҗат оешмалары җитәкчеләре Нәҗип Җиһанов, Харис Якупов, Зәки Нури, культура министры Булат Гыйззәтуллин, кинофикация һәм киностудия башлыклары аларга, мисаллар һәм саннар белән нигезләп, әдәбият һәм сәнгать турында сөйләделәр. Кунаклар исә Татарстанда күргәннәре һәм ишеткәннәре турында Прагада чыга торган «Социализм һәм тынычлык проблемалары» дигән журналда мәкалә бастырырга булдылар.

* * *

Әзербәйҗан ашугы Әләскәрнең туууына 150 ел тулу юбилее бөтен ил күләмендә билгеләп үтелде. Бакуда 9 июнь көнне М. Ф. Ахундов исемендәге Әзербәйҗан дәүләт опера һәм балет театры бинасында олы юбилейга багышланган тантаналы утырыш булды. Анда шагыйрь Сөләйман Рөстәм, Мәскәү шагыйре С. Васильев, украин шагыйре С. Телинюк, Кабардино-балкар шагыйре З. Тхагазитов, Ленинград шагыйрәсе Н. Полякова һ. б. иптәшләр чыгыш ясадылар.

Юбилейда Татарстаннан Ә. Баянов катнашып, тантаналы утырышта, Баку нефть эшкәртү заводында һәм телевидение аша чыгышлар ясады.

Юбилей халыклар дуслыгы бәйрәме булып әверелде. Кунаклар кабул итү кичәсендә Әзербәйҗан язучылары союзының беренче секретаре Мирзә Ибраһимов Муса Җәлил кебек бөек шагыйрь һәм геройны биргән татар халкына сокլануын әйтте һәм сәламнәр тапшыруны үтенде...

* * *

«Литературная газета» редакциясе Грузия язучылары союзы идарәсе белән берлектә май ахырларында Тбилисида «Күп милләтле совет әдәбиятында заман темасын яктыртуда новаторлык сыйфатлары» дигән темага багышланган киңәшмә үткәрде. Киңәшмәдә барлык союздаш республикалардан һәм Мәскәүдән килгән язучылар һәм тәнкыйтьчеләр катнашты. Бу киңәшмәдә Татарстан тәнкыйтьчесе Ф. Мусин чыгыш ясады.

## ӘДӘБИ ОЧРАШУЛАР

Җәй айларында язучыларның Г. Тукай исемендәге клубы үзенең эшен тагын да җанландырып җибәрде. Июнь-июль айларында гына да республикабыз мәктәпләрендә татар теле һәм татар әдәбияты укытучылары, балалар китапханәләренең мөдирләре һәм башка республикаларда татар теле һәм әдәбияты укытучылары белән очрашулар булып үтте. Бу кичәләргә Х. Туфан, С. Хәким, М. Әмир, Г. Бәширов, Г. Минский, Г. Кашшаф, Л. Ихсанова, Ш. Рәкыйпов, Ш. Галиев, Б. Камалов, Р. Ишморат, А. Расих һ. б. язучылар үзләренең әсәрләреннән өзекләр укыдылар, иҗат планнары белән таныштырдылар.

* * *

Республикабызның Балык бистәсе районында язучылар катнашы белән үткәрелгән әдәби кичәләр еш була. Бу районда туып үскән драматург Сәет Шәкүров һәм прозаик Вакыйф Нуруллин июнь аенда якташлары янына кайтып, күп кенә колхозларда булдылар һәм аларга татар әдәбиятындагы яңалыклар турында сөйләделәр.

* * *

Әлмәттә 12 нче номерлы мәктәп каршында Эрнст Тельман исемендәге дуслык клубы эшләп килә. Пионерлар чираттагы очрашуга Социалистик Хезмәт Герое — нефтьче Шакир Галиев һәм шагыйрь Әдип Маликовны чакырдылар. Шакир Галиев балаларга үзенең хезмәт юлы турында сөйләде, Әдип Маликов халыклар дуслыгына һәм нефтьчеләргә багышланган шигырьләрен укыды. Кичә ахырында укучылар нефть якларында яшәүче рус һәм татар шагыйрьләренең шигырьләрен, алар сүзләренә язылган җырларны башкардылар.

* * *

27 майда шагыйрь Әдип Маликов һәм драматург Юныс Әминов Әлмәт шәһәрендәге 16 нчы мәктәп укучылары белән очраштылар. Балаларга яңа әсәрләрен укыдылар, иҗат планнары белән таныштырдылар.

## ЯҢА КИТАПЛАР

Татар әдәбияты классигы Галимҗан Ибраһимовның исеме казакъ укучыларына бик күптәннән таныш һәм якын. Аның «Казакъ кызы», «Тирән тамырлар», «Алмачуар» дигән роман һәм повестьлары казакъ теленә тәрҗемә итеп басылган иде.

Быел Алма-Атаның «Җазушы» нәшриятында Галимҗан Ибраһимовның «Безнең көннәр» романын 29 мең тираж белән басып чыгарды. Китапны казакъчага Абитай Атыгаев тәрҗемә иткән.

* * *

Ташкентта Гафур Голәм исемендәге әдәбият һәм сәнгать нәшриятында Кави Нәҗминең «Язгы җилләр» романы басылып чыкты. Романны татарчадан үзбәкчәгә Азат Шәрәфетдинов тәрҗемә иткән. Китапның тышлыгын художник Б. Җәлалов ясаган. Татар халкының революцион үткәнен сөйләүче бу әсәр 75 мең тираж белән басылган.

* * *

Алма-Атаның «Җазушы» нәшриятында Роза Хафизованың «Курай-малай маҗаралары» да аерым китап булып басылды. Китапны казакъ язучылары Сәйдәхмәт Бердикулов һәм Машкар Гомәровлар тәрҗемә иткән.

## ДУСЛЫК КИЧӘСЕ

СССР төзелүгә 50 ел тулу уңае белән, Уфаның Актерлар йортында Татарстан сәнгать осталары катнашы белән зур кичә үткәрелде. Кичәне Бөтенроссия театр җәмгыятенең Башкортстан бүлеге председателе РСФСРның һәм БАССРның халык артисткасы Зәйтүнә Бикбулатова алып барды.

Уфа тамашачылары РСФСРның һәм ТАССРның халык артистлары Г. Шамуков, А. Аббасов, Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрының яшь артистлары Р. Хисамова һәм И. Хәйруллин, Качалов исемендәге Зур драма театры артистлары Л. Волкова һәм Б. Любимов, Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры солистлары Р. Нуриева, И. Хәкимова, Н. Сәрвәров, Г. Әхмәтовларның чыгышларын яратып тыңладылар.

## АВТОРЫБЫЗНЫҢ УҢЫШЫ

«Казан утлары» журналын укучылар аның тышлыгына басылган фоторәсемнәрне кызыксынып караулары турында әйтәләр. Республикабызның кешеләре, аның истәлекле урыннары, бөек төзелешләре турындагы бу фотоларның авторы — геология-минералогия фәннәре кандидаты, яшь язучы Эдуард Хәкимов. Аның фотолары күп кенә халыкара күргәзмәләргә куелды. Авторның Ленинград күргәзмәсенә куелган фотоларыннан берничәсе «Нева» һәм «Аврора» журналларында басылып чыкты.

## ХАЛЫКАРА КИТАП ЕЛЛЫГЫ

Май аенда КПСС өлкә комитетының Политик мәгариф йорты бинасында китап күргәзмәсе ачылды. ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсе, Татарстан китап нәшрияты һәм Таткниготорг оештырган бу күргәзмә СССР төзелүгә 50 ел тулуга һәм халыкара китап елына багышланды.

## ХЕЗМӘТКӘ — ХӨРМӘТ

Балаларга бик күп талантлы әсәрләр язуы өчен һәм 80 яшь тулу уңае белән язучы С. Радзиевская партиянең Татарстан өлкә комитеты һәм Татарстан Министрлар Советы Почет грамотасы белән бүләкләнде.

## ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫНДА

Татарстан Верховный Советы Президиумы Председателе С. Батыев бер төркем фән эшлеклеләренә, колхозчыларга, юл төзүчеләргә, журналистларга, медицина хезмәткәрләренә бүләкләр тапшырды.

Алар арасында «Казан утлары» журналының 50 еллык юбилее уңае белән бүләкләнгән иптәшләр дә бар иде.

«ТАССРның атказанган культура работнигы» дигән исем журналның җаваплы секретаре, язучы Ләбибә Ихсановага һәм журналның хатлар бүлеге мөдире, язучы Вакыйф Нуруллинга бирелде.

Журналның редколлегия члены, филология фәннәре кандидаты Нил Юзиев, тәнкыйть бүлеге мөдире Фәрваз Миңнуллин, журналның машинисткасы Мәгъмүрә Шәрәфетдинова һәм техник редакторы Роза Нәбиуллиналарга ТАССР Верховный Советының Почет грамотасы тапшырылды.


*КАДЕРЛЕ ДУСЛАР!*

**Сентябрь аеннан 1973 ел өчен «Ялкын» журналына язылу башлана.**

**«Ялкын» — татар телендә чыга торган бердәнбер балалар журналы.**

**Анда, татар совет язучыларының балалар өчен язылган иң яхшы әсәрләре белән беррәттән, балаларның үз иҗат үрнәкләре, мәктәп тормышын яктырткан мәкаләләр, фоторепортажлар, кызыклы хәлләр, баш ваткычлар басыла. Балаларның үзләрен нечкә тотарга өйрәтүче «Әдәплеләр» клубы эшләп килә.**

**«Ялкын», яңа совет кешесе тәрбияләү белән бер чиратта, безнең әдәбиятыбызның киләчәге өчен яңа авторлар һәм укучылар хәзерләү өлкәсендә дә бик күп эшләр башкара.**

**Аңа илебезнең теләсә кайсы элемтә бүлегендә язылырга мөмкин.**

**Язылу бәясе: бер елга 1 сум 80 тиен. Индексы: 73582.**

## «КАЗАН УТЛАРЫ» 1973 ЕЛДА:

Г. Әпсәләмов. **Күк күкрәр.** Роман.
Э. Касыймов. **Һаваларда тургай.** Роман. («Томан аша»ның икенче китабы»)
Ш. Маннур. **Агымсуларга карап.** Повесть.
Х. Хәйруллин. **Канатлар талмасын.** Повесть.
И. Низамов. **Дәрья күзе.** Повесть.
Х. Камалов. **Һәркемнең гомере бер генә.** Повесть.
Г. Иделле. **Беренче зур сәяхәт.** Истәлекләр.

Сибгат Хәким, Хәсән Туфан, Нури Арсланов, Зәки Нури, Гамил Афзал, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Әхсән Баян һ. б. шигырь һәм поэмалары укылып, басарга әзерләнә башлады.

Журналда шулай ук совет кешеләренең эшен, тормышын, уй-хисләрен чагылдырган әдәби очерклар, әдәби хәрәкәтнең актуаль мәсьәләләренә багышланган тәнкыйть мәкаләләре, халкыбызның тарихына, театр, музыка, рәсем сәнгате үсешенә караган фәнни материаллар, яңа чыккан китапларга рецензияләр, әдәбият һәм сәнгать яңалыклары турында хәбәрләр басылып бара.

Әгәр «Казан утлары» журналына ел башыннан ук язылып куйсагыз, сез боларның барысын да үз вакытында укып барырсыз.

Журналга Советлар Союзының барлык почта бүлекләрендә язылырга мөмкин. Аның өчен Союзпечать хезмәткәрләренә 73210 номерлы индексны әйтергә онытмагыз. Журналның бер саны 50 тиен, бер еллык бәясе 6 сум тора.

*Хөрмәтле укучылар!*

Журналыбызның 11 санында сез Мәдинә Маликованың **«Адашканга юл кайда!** исемле маҗаралы повестен, Марсель Зариповның **«Су буенда»** хикәясен һәм Хәсән Сарьянның **«Туган як моңнары»** исемле нәсерен укырсыз.

Театр сәнгатен сөючеләргә Сәет Шәкуровның **«Туган туфрак»** пьесасын тәкъдим итәбез.

Нәби Дәүлинең **«Тынгысыз йорт»** дигән поэмасыннан өзекнө, Рәдиф Гатауллинның **«Март-апрель»** исемле шигырьләр циклын, Егор Уткин һәм Булат Сөләйманов шигырьләрен урнаштырабыз.

Фәләх Насыйровның **«Үлемне җиңеп»** дигән очеркындагы вакыйгалар сезне гражданнар сугышы елларына алып кайтырлар.

Журналыбызның бу санында проза турында сөйләшүне дәвам итеп, Рифат Сверигинның **«Заман һәм тормыш таләбе»** дигән мәкаләсен бирәбез.

Болардан кала журналда әдәбият фәне мәсьәләләре һәм эстетика мәсьәләләренә караган мәкаләләр, китап күзәтү, безнең календарь, әдәбият һәм сәнгать яңалыклары белән танышырсыз.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210